ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ
Г. ИБРАҺИМОВ исемендәге
ТЕЛ, ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ИНСТИТУТЫ

# ХАТЛАРЫМНЫ ХАЛКЫМ САКЛАР, ЮГАЛТМАС...

*Ибраһим Салаховның шәхси архивыннан*

Казан
2017

**УДК 821.512.145-6**
**ББК 83.3(Рос=Тат)**
**Х 25**

*Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең*
*Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты*
*Гыйльми советы карары нигезендә нәшер ителә*

**Фәнни редактор**
филология фәннәре кандидаты **И.Г. Гомәров**

**Төзүче**
филология фәннәре кандидаты **Л.Ш. Гарипова**

**Х 25** **Хатларымны халкым саклар, югалтмас** (Ибраһим Салаховның шәхси архивыннан) / төз. Л.Ш. Гарипова. – Казан: ТӘһСИ, 2017. – 304 б.
ISBN 978-5-93091-231-9

ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә күренекле татар язучысы, шагыйрь Ибраһим Низаметдин улы Салаховның (1911–1998) шәхси фонды саклана. Анда язучының автобиографик язмалары, тормышына һәм иҗатына караган документлар, әсәрләренең кульъязмалары тупланган. Фондның зур өлешен хатлар алып тора (3000 гә якын). Алар арасында күренекле язучылар, И. Салаховның иҗаты һәм сикәлтәле язмышы белән кызыксынучыларның төрле елларда язылган хатлары саклана. Китапта аларның бер өлеше укучылар игътибарына тәкъдим ителә.

**УДК 821.512.145-6**
**ББК 83.3(2Рос=Тат)**

**ISBN 978-5-93091-231-9**

© Гарипова Л.Ш., 2017
© Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, 2017

## КЕРЕШ

*Хат язылa икән, күңел тормыш*
*белән арасын өзмәгән дигән сүз.*
*Хат – күңел сере!..*

А. Гыйләҗев

Татар әдәбияты мәйданында «Күкчәтау далаларында», «Имәннәр тамыр җәйгәндә», «Дала дулкыннары», «Колыма хикәяләре» кебек күләмле романнары белән киң танылган татар язучысы, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, ТР Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Ибраһим Низам улы Салахов (1911–1998) Казакстанның Күкчәтау шәһәрендә һөнәрчеләр гаиләсендә туа. Башта мәдрәсәдә, аннан татар мәктәбендә белем алганнан соң, 1928 елда Казан педагогия техникумына укырга керә, укуын тәмамлагач, «Яшь ленинчы», «Кызыл яшьләр» газеталарында, «Ялкын» журналында әдәби хезмәткәр булып эшли. Хәрби хезмәттә булып кайтканнан соң, Казан дәүләт педагогия институтының тел һәм әдәбият факультетына укырга керә, шушы чорда аның «Ярату» пьесасы, «Дуэль» повесте, шигырьләре тупланган «Постта» исемендә китаплары басылып чыга. Сәламәтлеге какшау сәбәпле, Ялтага дәваланырга барган яшь язучыны, Казанда нәшрият бастырасы җыентыкка Галимҗан Ибраһимовтан кульязма алып кайтырга җыенуы өчен, 1937 елның 25 октябрендә кулга алалар. Аны «халык дошманнары» белән яшерен контрреволюцион элемтә тотуда, аларга арадашчы булып хезмәт итүдә гаепliләр һәм ун елга ирегеннән һәм аннан соң биш елга гражданлык хокукларыннан мәхрүм итәргә дигән гаделсез хөкем карары чыгарыла.

И. Салахов сигез айлап Казанның Пләтән һәм ел ярым Тобол шәһәре төрмәсендә утыра, аннары Колыманың алтын приискаларына «хезмәт белән төзәтү» лагерьларына озатыла. Шунда И. Салаховка хөкем карарының мөддәте беткәнче өзлексез авыр

хезмәт, рәнҗетелүләр белән тулы тоткынлык мәхшәрен кичерергә туры килә. Язучы сәламәтлеген какшата, авариягә эләгеп аягын имгәтә, күзләренә зарар килә. 1947 елның 25 октябрендә азат ителгәч тә, аңа Казанда яки туган шәһәре Күкчәтауда яшәргә, матбугатта иҗади хезмәтләре белән катнашырга рөхсәт ителми, ул, Күкчәтаудан җиде чакрым ераклыктагы Кызыл Яр дигән авылга гаиләсе белән күченеп, райпотребсоюз ашханәсенә буфетчы булып эшкә урнашырга мәҗбүр була. 1956 елның 25 апрелендә И. Салаховны гаепләү эше СССР Югары судының Хәрби коллегиясе тарафыннан яңадан каралып, 1938 елның 12 маендагы хөкем карары нигезсез дип табыла һәм әдипкә бөтен гражданлык хокуклары, шул җөмләдән матбугатта әсәрләрен бастыру хокукы да кире кайтарыла.

Шул чорда ук И. Салахов үзенең атаклы документаль роман-хроникасын — «Колыма хикәяләре»н дә язарга керешә. Әсәр укучылар һәм әдәби тәнкыйть тарафыннан тоталитар режимның кешелексез сәясәтен, үз халкына каршы юнәлтелгән явыз гамәлләрен, җинаятьләрен фаш иткән, Сталин зинданнарында, концлагерьларында хаксызга һәлак ителгән миллионлаган репрессия корбаннарына мәрсия булып яңгыраган тарихи документ буларак кабул ителә. Озакламый романның русчага тәрҗемәсе дә чыга, аерым өзекләре радиотапшыруларда яңгырый, әсәр буенча эшләнгән сәхнә варианты узган гасырның туксанынчы елларында Казан Яшьләр театры тарафыннан да куела. «Колыма хикәяләре» китабы өчен И. Салахов 1990 елда Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек була, 1992 елда аңа «Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирелә[1].

Әлеге әсәр матбугатта басыла башлагач, китап булып дөнья күргәч тә, язучыга бик күп хатлар агыла: берәүләр хәбәрсез югалган туганнарының язмышын ачыкларга тырыша, икенчеләр чын мәгънәсендә тарихи документ булган әлеге әсәре өчен язучыга рәхмәтен җиткерергә ашыга... Күпме хат, күпме йөрәк авазы... Язучы һәрбер хәбәргә, хатка җавап бирергә тырыша, һәрберсен кадерләп саклап бара. Шул рәвешле, зур архив туплана бара, ул елдан-ел тулылана, байый...

[1] Әдипләребез: Библиографик белешмәлек: 2 томда: 2 том / төз. Р.Н. Даутов, Р.Н. Рахмани. Казан: Татар. кит. нәшр., 2009. 735 б.

Татар әдәбиятына зур мирас калдырган Ибраһим Салахов архивы ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәгенә 1995 елда кайтарыла. Аны Казакстанның Күкчәтау өлкәсендәге Кызыл Яр авылыннан институт хезмәткәре, филология фәннәре кандидаты Зөфәр Гомәр улы Мөхәммәтшин алып кайта. Әдип вафатыннан соң, аның башка шәхси архив материалларын Күкчәтау шәһәре татар мәдәни үзәге хезмәткәре, язучыга һәрчак ярдәм итеп торучы Әския ханым Әхмәтшина 1999 елда, И. Салаховның васыяте буенча, Мирасханәгә тапшыра[1] һәм алар нигезендә 156 нчы сан астында зур фонд оештырыла.

Фонд материаллары арасында язучы әсәрләренең төрле вариантлары, кулъязмалары, көндәлек дәфтәрләре, язышкан хатлары һәм башка бик күп төрле документлар бар. И. Салахов үзе исән чагында ук архивы өчен борчылган, аны урнаштыру юлларын эзләп, сөйләшүләр алып барган һәм нәкъ менә Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтына тапшыру теләген җиткергән.

Фондтагы материалларның иң зур өлешен хатлар алып тора. «Әле сиңа килгән хатлардан зур гына бер өлеш төзеп, аны «Казан утлары»нда бастырып чыгарасы иде. Мөгаен, хатлар арасында моңарчы без белмәгән, белә алмаган, тарихчыларның күзеннән читтә калган газиз милләттәшләребезнең, Сталин тәбеләрендә һәлак булганнарның исемнәре, якты гамәлләре бардыр. Сиңа килгән хатлар, романда телгә алынган исемнәр кебек үк, кадерле исемнәрне дөньяга чыгаралардыр, дип ышанам. Алар синең архивта сүзсез калмасыннар иде инде. Гомумән, егәрең барында син бу җәһәттә үтәргә мөмкин булганнарның барын да башкарып чыга алсаң иде!..» – дип яза татар әдәбияты классигы А.Гыйләҗев (1928–2002) үзенең бер хатында. Гомумән, Аяз Гыйләҗев Ибраһим Салаховның китапларын дөньяга чыгаруда иң зур ярдәм иткән шәхесләребезнең берсе.

И. Салахов А.Гыйләҗевка юллаган бер хатында һәрбер язучының, шул исәптән үзенең дә архивы, мирасы, архивындагы һәрбер хаты өйрәнелеп, укучыга барып җитәр дигән фикерен әйтә: «Әдипләрнең архивы, алар вафатыннан соң калган мирас

---

[1] Бу турыда: Бәдретдинов Х. Ибраһим Сәлахов аркадашы // Мәдәни җомга, август, 2016.

материаллары мине байтактан борчый. – дип яза А. Гыйләҗев ачынып. – Язучы вафат була, дөньялыктан күчә, мирас комиссияләре төзеп, аларны матбугатта белдерәбез. Шуның белән барлык эш сүнеп кала шикелле... Без хәзер бик арзанлы эйфорияләр болытына уралып: „уяндык, яшибез!“ дип сөрән салып шапырынсак та... чынлыкта татар бүген битарафлык йокысында. Нәкъ элеккечә гамьсезлек дулкыннарында, ваемсызлык сазлыгында. Шушы очсызлык, кадерсезлек тоташтан дәвам итә икән, бездән килгән хатлар, куен дәфтәрләре кемгә кирәк? Тарих мәйданына безне аңлый, кадерли торган буыннар килер дип кем күрәзәлек итә ала?..»

Фикер-бәяләрне истә тотып һәм язучының теләген тормышка ашыру максатыннан И. Салаховның үзе язган һәм аңа килгән хатларны туплап, укучылар игътибарына тәкъдим итәбез.

И. Салахов хатлары – әдәби процесс эчендә яшәгән шәхес хатлары. Аларда шул чорның иҗтимагый, мәдәни һәм әдәби тормышындагы кызыклы фактлар, күренекле язучы-шагыйрьләрнең, җәмәгать эшлеклеләренең, әдәби барышка өлеш керткән кешеләрнең теге яки бу мәсьәләгә ачык фикерләре, ялганга, икейөзлелеккә корылмаган ачыктан-ачык бәяләре чагылыш таба: «Озак дәвам иткән авыр тынлыгым өчен кичер, – ди А. Гыйләҗев бер хатында. – Татар китабының язмышы кыл өстендә. Китабың укучыга барып җитми икән, бу инде инкыйразның иң ачысы. Татар – китапка мәхәббәте белән танылган милләт иде. Инде бөтен милли сыйфатларыбызны тарихның кайсы тирән катламнарыннан эзләп табарбыз да, ничек итеп халыкның суык җанын җылытырбыз». Үзенең китабы чыгу уңаеннан язучы Ә. Еники И. Салаховка хат юллый: «...тынычланырга иртәрәк әле – тәнкыйтьчеләр сүзен ишетәсе бар. Ә тәнкыйть ул бик хикмәтле нәрсә, фокусник шикелле төрлечә китереп чыгарырга мөмкин. Тик бер хакыйкать бар: яңа әсәрне халык яратып кабул итсә, аны инде бернинди тәнкыйть тә юкка чыгара алмый. Шуңа ышаныйк!». «Безнең татар язучыларының күбесенең тарихи йөзе әсәрләрендә генә кала. Юбилейларны баштанаяк язып, кинога төшереп калдыру турында яшьләр уйламый. Язучылар союзында да бу мәсьәләдә бик мәшәкатьләнмиләр. Ә бит иң беренче, бу аларның бурычы бит!» ди Зәкия Садыйкова классикларыбыз Х. Туфан, М. Җәлил хакында язган бер хатында.

И. Салаховның хатлары белән таныша барган саен, аның никадәр кешелекле, игътибарлы, чын мәгънәсендә зыялы гади һәм

гали зат булганын күрәсең; ул кулдан килгәнчә үзенә мөрәҗәгать иткәннәргә – әдәбият мәйданына аяк баскан яшь язучыларга да, каләм тибрәтергә яратучыларга да ярдәм кулын сузган, гомумән халкыбыз тарихына, киләчәгенә битараф булмаган, җәмгыятебездәге теге яки бу хәлләргә, күренешләргә мөнәсәбәтен белдергән яки аңлатма эзләгән һәркемгә – һәрдаим җавап биреп барырга тырышкан. Бу аның көндәлекләреннән, куен дәфтәрләреннән күренә: нинди хәбәр алынган, кайсына җавап бирәсе, кемне котлыйсы бар.

1965 елдан Казакстанда «Семей таңы» дигән, аңа кадәр «Казакъ теле», «Кызыл дала», «Семей правдасы» исемнәрендә йөргән газета чыга. Әлбәттә, газетаның хәле төрле елларда төрлечә була. 1992 елда аның кушымтасы буларак татар телендә «Галиябану» газетасы чыга башлый. Газетаны дөньяга чыгару бик авырлык белән бара. Редакторы булган Наилә Абдулкәримова язучы И. Салаховка бу эштә ярдәм итүен сорый. Әлбәттә, язучы ярдәм кулын суза. Газетаның беренче елларындагы авырлыклар, бина бирелмәү, бирелгәннән соң да җимерек хәлдәге йортны аякка бастыру эшләре хатларда ачык чагылыш таба.

Шунысы аяныч, төрле фаҗигаләргә тарыган язучыга тыныч тормышта да тиешле, кешеләрчә игътибар җитмәгәнлеген күрәсең. Төрмә-лагерьларда сәламәтлеген югалткан И. Салахов дәвалануга мөмкинлеге, акча булмавыннан зарланып, кат-кат төрле оешмаларга гариза-үтенечләр язып карый. Ләкин күп җирдән бернинди дә җавап ала алмый, кайсыберләре исә кире кагыла. Гариза-хатлар язучының иҗат эшен тоткарлаган, рухи көчен алган; аның киеренке халәттә яшәргә мәҗбүр ителүен дә чагылдыралар. Бу күренеш язучының китапларын басмага тәкъдим итү, инде әсәрләре дөнья күргәч, аларны тәрҗемә итү эшендә дә нык сизелә. И. Салахов, әлбәттә, бик әрни, язучыларга, Язучылар союзына хатлар юллый башлый, ләкин, аяныч, җаваплылыкны үз өстенә алырга теләмәгән, бер-берсенә сылтаган хатлар чылбыры барлыкка килә. Салкын төрмә газапларыннан исән калган кешенең тыныч тормыштагы күңел газаплары, әрнүләре еракларга илтеп ташлана да, хәл ителә алмыйча, яңадан кире әйләнеп кайта...

И. Салахов күп әсәрләрен гарәп шрифтында яза: «Мин хәзерге рус алфавитына нигезләнгән яңа татар әлифбасын белмим дә, белергә дә теләмим. Ул бит, без төрмәдә утырганда – 1938 елда Бөек юлбашчыбызның бөек «тәгълимәте» нигезендә төрки халыкларга

көчләп тагылды ич. Бу алфавитны кабул итмим, бары тик үзебезнең тулы яңгырашлы гарәп әлифбасында гына язам. Ярый, бик ярсып, үзенчә яздың, ди. Ә соң ул язганны кем укый алыр. Яшьтәшләрең китә бара. Язу машинкасында бастыру мөмкинлеге юк. Менә бит аяк астында тагын бер тоткарлык», ди ул һәм кирилл хәрефләрендә яза башлый. Ләкин кульязмалары авыр укыла, күп әсәрләре нәшриятлардан кире кайтарыла. Аның язмаларын Газизә Гыйззәтуллина, Гайшә Сираҗетдиновалар – язучының якын дуслары – гарәп графикасыннан гамәлдәге язуга күчерәләр, машинкада бастыралар, үзләренә ярдәмгә башка кызларны да табалар һәм шул рәвешле, бик күп урау юллар аша, кулдан-кулга күчә-күчә, озак көннәргә, айларга, елларга сузылса да, әсәрләре халык кулына килеп ирешә.

Язмышында күп фаҗигалар күргән һәм шуларны яңадан йөрәгендә, күңелендә яңартып язарлык көч тапкан бу олуг шәхеснең архивы, андагы һәрбер хат, һәрбер документ аның тормышын, иҗатын тагы да тулырак күзалларга, язучының үзен дә аңларга ярдәм итәләр.

*Л.Ш. Гарипова*

## ХАТЛАРЫМ БАРЫП ҖИТӘРМЕ?

*Сәрвәр Әдһәмовага*
*1959*

Сәрвәр апа[1]!

Сезгә сагынып сәлам.

Бүген иптәш Шамовтан[2] хат алдым. Бу хат мине гаҗәпкә калдырды. (Кем белә, бәлки мондый хәлгә гаҗәпләнү урынсыздыр да...)

Мин үземнең иптәш Шамовка язган хатымда, романымны нинди авыр шартлар эчендә (төп эштән соң – төннәрдә, ял көннәрендә) язуымны, экономик яктан начар торсам да, бастырырга бирергә ашыкмыйча, кабат-кабат төзәтүемне, инде 40 табактан артык кулъязманы өр-яңадан төзәтеп-яңарта баруымны, үземнең барлык таралган-ватылган тазалыгымны шунда бирүемне дусларча белдереп, романны тизрәк төгәлләргә һич вакыт таба алмаганга, бер айга отпуск алырга уйлавымны әйтеп, шул бер айны башкарып чыгу өчен ярдәм бирә алмассызмы дигән идем.

Иптәш Шамов болай дип яза: «Мондагы иптәшләр, бигрәк тә идарә членнары кулъязмагыз белән бик кызыксыналар. Чөнки сезгә идарә тарафыннан берничә ел рәттән акчалата ярдәм күрсәтелгән...» (мин Кави аганың булышлыгы белән Мәскәүдән алган акчадан башка, союздан 1500 сум алдым) (*хат җибәрелми, ахырдан әлеге хатны И. Салахов түбәндәге сүзләр белән дәвам иткән*): «Эх! Ни файда бу хатны язудан. Кемгә мин кирәк. Алар минем әсәрләрем белән «кызыксыналар...», янәсе, акчаны алып-алдашып ята. Сез шулай минем кебек ятсагыз иде...».

*1959*

---

[1] Сәрвәр Әдһәмова (1901–1978) – язучы, тәрҗемәче.

[2] Афзал Шамов (1901–1990) – язучы, җәмәгать эшлеклесе.

*Рафаэль Мостафинга*
*1968, 22 гыйнвар*

Хөрмәтле Рафаэль иптәш[1]!

Хәерле көн.

Сезне соңлап булса да Яңа ел белән котлап, исәнлек һәм яңадан-яңа иҗат сөенечләре телим.

Мин, гадәтенчә, сезне борчырга теләмәгән идем.

Бүген Литфонд директоры иптәш Хәмидуллиннан СССР Литфонд идарәсе карарының күчермәсен алдым (нәрсә язып торам әле, решениянең үзен җибәрим әле).

Мин үз гомеремдә ял йортында, иҗат йортында була алмадым. Хәзер бер яктан арыдым, икенче яктан 60 яшь якынлаша – итәк-чабуны җыярга вакыт...

Яза башлаган ике повестем бар иде, һич очлап чыга алмыйм. Бар вакыт кооперация эшендә кала. Ә «китеп барганчы» язып бетерергә иде...

Сезнең редакция портфелендә инде икенче ел 1. «Күкчәтау» – С. Сәйфуллиннан тәрҗемә. Поэма; 2. «Фәхретдин бине Мифтахетдин...» – тарихи-документлар һәм эзләнүләр; 3. «Революция чишмәләре» (Г. Абдрашитов турында истәлек) яталар. Редакция иптәшләренең әйтүләренә караганда, алар чиратта...

Иҗат йортына бик барасым килсә дә (бару, иҗат өчен мәтлуб булса да) мөмкинлегем юк. Ялгыз үзем эшлим, гаилә зур.

Бәлкем, югарыдагы әсәрләрне карап чыгып, журналыгызда урын бирсәгез, мин шуларның гонорары исәбенә, гомеремдә бер тапкыр иҗат йортында булып, ичмасам, бер әсәрне алга алып барып ташлый алыр идем?

Сез ничек карыйсыз?

Өйдә гаилә кала, юлга акча кирәк, анда акчасыз барып булмый. Рад бы в рай, грехи не пускают.

Ярый инде, гаепләмәгез, аптырагач, якын күреп, киңәш рәвешендә яздым.

Ихтирам белән Салахов
*22.01.1968*

---

[1] Рафаэль Мостафин (1931–2011) – әдәбият галиме, тәнкыйтьче, Татарстан Республикасының Г.Тукай исемдәге Дәүләт бүләге лауреаты, 1965–1968 елларда «Казан утлары» журналының баш мөхәррире.

*Альберт Галиевка*
*1968, 23 сентябрь*

Здравствуйте, Альберт Абубакирович[1]!

Примите мой искренний салям.

Недавно, к сожалению, с большим опозданием, я услышал о Вас и очень обрадовался.

Дай бог Вам здоровья, сил и новых успехов – открытий в мире наук.

Я почти Ваш сосед – Кокчетавец. Поэтому, мне особенно радостно было узнать, что рядом растет такой талантливй молодой ученый.

Вчера я получил письмо от ответственного редактора «Казан утлары» (орган союза писателей Татарии. Казань), поэта Заки Нури. Он очень заинтересовался Вами и просил меня выехать в Новосибирск, встретиться с Вами и написать для журнала очерк о вашей научной деятельности. Это необходимо. Широкая татарская общественность, особенно молодежь, должна знать о Вас.

Поэтому я решил обратиться к вам с этим письмом, когда и как могли бы мы организовать нашу встречу?

Я сам полагаю, лучше было бы в ноябре-декабре текущего года. Как, Вас устраивает это время?

Дорогой Альберт!

Я не ученый, а писатель. До нашей встречи мне бы хотелось познакомиться с некоторыми Вашими научными трудами. Не сумеете ли Вы их выслать хотя бы с условием возврата?

Для знакомства, я посылаю Вам на память свой последний роман «Күкчәтау далаларында».

Привет Вашей семье. Жду Вашего ответа.

С уважением к Вам: Ибрагим Салахов, член Союза писателей СССР.

*23 сентября 1968 г.*

---

[1] Альбе́рт Әбүбәкер улы Галиев (1940) – физик, 1992 елдан Россия Фәннәр Академиясе академигы.

*Фәридә Равскаяга*
*1968, 2 октябрь*

Здравствуйте Фарида ханум[1]. Салям.

Весьма благодарен Вам за «Воспоминание». Как раз по времени, я заканчивал свой очерк о дорогом мне человеке – Сабире Шарипове. Рахмат.

Да, друг Вашего отца, который был на том же заводе – Миннебай Хисаметдинов. Он и жена умерли. Жив дочь – Гайша, живет в Лангетаве. Видимо, вы встречали и Мифтахутдиновых (Хади и Нафиса), тоже друзья Сабир ага. Они погибли в 1937 году.

Я очень внимательно прочел Ваши воспоминания.

Сабир ага большой человек. Он революционер, писатель, человек. Наша задача воскресить именно такого Сабира. Самая бурная жизнедеятельность его проявилось с 1916 г. по 1924 г., к сожалению, Вы об этом не знаете.

Вы пишите, продолжайте свои воспоминания. При этом я бы советовал: соблюдать хронологическую последовательность. Как бы Вы не писали, в центре должен быть он, все остальное только для того, чтобы раскрыть его деятельность, характер, положение. В Ваших письмах он уходит на второй план, нельзя допустить этого.

Например, можно было начинать с того, как Вы первый раз приехали в родную деревню. Описать эту деревню. Потом отступлением дать его биографию до того времени, как Вы уже сами начали узнавать.

Он в своем автобиографии (я получил копию, пишет, что отец умер в 1895 г., когда ему было 15 лет. А вы пишете, что он остался от родителей в 7 лет. Кому верить.

Вы пишите воспоминания. Здесь даты должны быть исключительно точны, достоверны.

Вы уже подходите ко времени, когда он находился в Иране, очень прошу, не спишите, покажите Сабир ага таким, каким он был тогда деятельным. Вы нигде не указываете даты. Может забыли? Постарайтесь восстановить в памяти.

С уважением к Вам Салахов.

*2.10.1968*

---

[1] Фәридә Равская – язучы Сабир Шәрипов (1882–1942) кызы.

*Әнвәр Әлимжановка*
*1972, 1 июль*
с. Красный Яр

Хәерле көн, хөрмәтле Әнвәр-бәк[1]!

Сәлам.

Зимой, в дни моего шестидесятилетия, у меня был сердечный приступ, потом инфаркт.

Через полгода меня выписали из больницы и сказали:

– Не расстраиваться.

И вот я сегодня получил сюрприз – рухнула моя последняя надежда.

Дело вот в чем: приближаясь к своему 60-летию я обращался и в казахский и татарский союзы писателей с просьбой помощь мне в издании сборников моих произведений. Татиздат в 1971 г. выпустил небольшой сборник «Төн кызы». От казахского союза ответа не получал. И вышло у меня так, что средний гонорар за 1969 г. – 180 р., а за 1970 г. (с которого исчисляется пенсия) 110 р. Значит пенсия – 50 р. А у меня – семья. Кокчетавский обком партии и облисполком ходатайствовали об установлении мне пенсии Республиканского значения.

Я – коренной Кокчетавец. Принимал активное участие в организации первых комсомольских организаций, был уполномоченным по организации колхозов, в 1930–32 годах. Работал в республиканских газетах-журналах. С 1937 г. по 1947 г. находился в заключении. Реабилитирован, инвалид. Решением секретариата СП СССР мой лит. стаж утвержден 33 года. Коммунист. И вот решение комиссии – отказать. Инфаркт – хорошая гарантия на скорый уход. Не это устрашает меня.

Главное – я хотел завершить свой начатый роман «Степные орлы».

После больницы я написал несколько глав и послал в «Казан утлары». Как мне его завершить при таком материальном положении? Я обращаюсь к Вам, дорогой Анварбек, не столько как нашему первому руководителю Союза, но и как депутату – члену Правительства:

– Как быть?

---

[1] Әнвәр Әлимжанов (1930–1993) – казак язучысы, публицист, җәмәгать эшлеклесе

– Неужели я уйду не завершив свой роман, не раскрыв страницы больших революционных событий Сары-Арке?

Простите, что отнял у вас времени.

Хуш булыгыз. Ихтирам белән Ибрагим Салахов.

*1.07.1972*

*«Казан утлары»журналына*
*1972, 7 июнь*
Күкчәтау

Хөрмәтле «Казан утлары» егетләре, кызлары.

Барыгызга да, барыгызга да сагынып, бер күрергә зар-интизар булып, кайнар сәлам.

Бу ел кышын инфаркт белән егылгач, иң курыкканым үлү түгел, менә бу романны, бигрәк тә менә бу Кәрим Сутюшевның үтерелү фаҗигасен язалмыйча китү иде. Кәрим Сутюшев, Сабир Шәрипов, Усман Абдрашитов һәм бик күп башка татарлар Күкчәтау җирендә революцияне әзерләгән һәм шул юлда корбан булган фидакарьләр бит. Алар бик олы, баһадир кешеләр булганнар, үтә авыр, фаҗигале юл үткәннәр.

Менә шул гали җаннарны терелтү, аларны аякка бастыру һәм үзебезнең сафка кую минем бурыч бит. Мин дә язмасам, алар турында кем язсын соң?!

Менә шуның өчен бу главаны язарга утырдым.

Хәзер калган главаларын язам. Бу – документаль роман. Вакыйгалар, геройлар (хәтта провокатор Али Алиев та) чынбарлыкта булганнар.

Материал бихисап күп, бары тик кыскартып, һәрберсен үз урынына гына куярга кирәк.

Сәламәтлек – уртача.

Сагынып, ихтирам белән Ибраһим Салахов.

*7.06.1972*

*Еркен Аульбековка*
*1973, 16 декабрь*

Герою социалистического труда, первому Секретарю Кокчетавского областного комитета КП Казахстана тов. Аульбекову Еркен Нуржановичу.

От члена Союза писателей СССР Салахова Ибрагима Низамовича.

В партию я вступил в 1933 году в Казани, в Бауманском райкоме партии. Трудовой стаж у меня с 1930 г, до этого я жил на своей родине в Кокчетаве. Работал я литсотрудником республиканских газет и журналов, и редактором молодежного журнала в Казани. С 1937 по 1947 год я работал шахтером на золотых приисках Колымы. С 1947 по 1953 год работал плотником на строительстве Кокчетава. Печатаюсь с 1930 года. Первая книга вышла в 1935 году «На посту», стихи, в 1936 г. вышла пьеса «Любовь», в 1937 г. повесть «Дуэль», в 1957 г. «Степные волны», стихи, в 1960 г. «Кокчетавские мотивы», а в 1965 г. роман «В степях Кокчетава», в 1971 г. сборник рассказов «Дождь в ночи». Сейчас пишу роман о революционных событиях в Кокчетавском уезде.

С момента моего вступления в партию прошло сорок лет. Всю свою энергию, все свои знания я отдал родному народу и нашей ленинской партии. Даже в труднейших условиях Колымы, я помнил о задачах, которые должен выполнить во имя победы коммунизма и светлых ленинских идей.

В настоящее время у меня пенсия 80 рублей. Прошу пересмотреть этот вопрос и дать мне персональную пенсию республиканского значения.

С уважением писатель Салахов И.Н.

*16.12.1973*

*Саимә Ибраһимовага*
*1973, 22 октябрь*

Исәнмесез, хөрмәтле Саимә сеңлем[1]!

Ничек диләр әле, кан тартмаса, җан тарта, диләрме.

Бик кызык булды әле.

Нәкъ менә сезнең пакетны алыр алдыннан «Серле мәгарә һәм аның хуҗасы» дигән истәлек хикәя язып бетереп, уйланып утыра идем.

[1] Саимә Ибраһимова (1928) – журналист, тәрҗемәче, ТАССРның атказанган мәдәният хезмәткәре, 1960–1983 елларда «Яшь ленинчы» газетасында эшли.

– Кемгә җибәрергә икән, – «Яшь Ленинчы»гамы, «Ялкын»гамы?

Бу хикәя Валерьян Владимирович Куйбышевның Күкчәтаудагы балачагы – беренче революцион адымнары турында, аның сеңлесе (хәзер Күкчәтауда В.В.Куйбышев мемориаль музее директоры) Елена Владимировна белән алып барган әңгәмәләр нигезендә туган документаль әсәр. 20дән артык фото бар.

Менә хәзер күргәнегезгә (укый алмыйча аптырыйсыз бит), минем почерк ташка үлчим...

Менә шуның өчен мин үземнең кулъязманы радиокомитет машинисткасы Суфияга җибәрәм. Ул машинкада басып миңа җибәрә.

Менә шуннан соң гына ул әсәрне сезгә җибәрәм – «Вәгъдәмне бәлки аклый алырмын…». Һәрхәлдә, сезнең хат мине дулкынландырды. Искә алуыгыз өчен бик зур рәхмәт.

Сезгә, редакторга, редакциянең башка хезмәткәрләренә күп сәлам. Ихтирам белән иске «ленинчы».

*22.10.1973*

*Еркен Аульбековка*
*1973, 17 декабрь*

Герою социалистического труда, первому Секретарю Кокчетавского областного комитета КП Казахстана тов. Аульбекову Е.Н.

После своих первых, неудачных попыток на прием с Вами, я решил было не беспокоить Вас, но сейчас обстоятельства сложились так, что без Вашей помощи я дальше не могу.

Уже больше пяти лет я работаю над романом о судьбах первых большевиков Кокчетавского уезда. К сожалению не могу завершить.

Работать и писать роман трудно. Думал выйду на пенсию, буду трудиться только над романом. Не вышло. Сперва – инфаркт. Потом пенсия всего – 80 рублей. Пришлось опять идти на работу.

За год до ухода на пенсию я обращался в союз писателей Казахстана с просьбой – помочь мне в издании моих произведений. Ответа непоследовало. А Татарский союз писателей сам готовит писателей к пенсии – издает произведения перед пенсией и у них нет ни одного писателя, который бы получал пенсию менее 120 р. Казахский союз пистателей также не помогал в ходатайствии мне

персональной пенсии республиканского значения. Неоднократно я обращался в союз с просьбой организовать переводы моих произведений на казахский, русский языки – молчание.

Литфонд тоже отказывает в помощи.

А когда я находился на учете в Татарии Молдагалиев Ж. и Алимжанов А. говорили «ты же наш Казахстанский писатель, переходи к нам. Мы поможем во всем». И забыли.

У меня сейчас тяжелое материальное положение. А роман остается не дописанным. Как быть? Прошу Вашей помощи, дорогой Еркен Нуржанович. С уважением к вам Салахов.

*17.12.1973*

*Хәсән Туфанга*
*1974, 21 сентябрь*
Күкчәтау.

Исәнмесез, хөрмәтле Туфан ага[1]!

Хәерле көн.

Бүген «Казан утлары»ның 7 саны килде. Ачтым, сезнең шигырьләр. Укып чыктым. Тагын укыйсы килде. Кабатлап укыдым. Күңел дулкынлана башлады. Нәрсәнеңдер, бик еракта калган кадерле хатирәнең ахырын хәтерләгәндәй булдым... Үзем дә сизмичә «Багышлаулар...»ны тавышланып укый башлаганмын... Таң алдыннан кошлар сайравы аеруча яхшы, моңлы һәм зәвыклы була...

Мин үземнең туган телемнән, моңымнан, әдәбияттан, Казаннан ерак... Кәккүк кебек ялгыз... Шуның өчен минем ялгыз бүлмәдән туган тел тавышы, таң алдындагы кошлар сайравы кебек, аеруча яхшы яңгырый. Бигрәк тә сезнең акрын, басынкы, уйларга тирән авыр тавыш...

Нинди хатирә, нинди соң ул югалтканым? Нинди?

Әй, син, исемә төшми...

«Әй, машинист,
Каула паровозны
Уралымны өзелеп сагындым!
Әллә минем уйлар авыргамы
Әкрендегез инде, вагоннар?»

---

[1] Хәсән Туфан (1900–1981) – мәшһүр татар шагыйре, Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты.

Мин бу юлларны 1927 елда «Безнең юл»да укып, дога итеп кабатлап, Казанга килгән идем.

«Урал эскизлары» минем иман шартым булды.

Менә бүген «Багышлаулар...» тагын шул сөекле эскизларны хәтерләттеләр (беренче «Безнең юл» вариантында шатлык түгел, уйлар иде, хәтерем ялгышмаса).

Аларда (гомумән, сезнең шигырьләрдә) ниндидер бер якты моң бар. Ул һаман яңгырап тора.

Һаман, һаман яңгырасын иде, Хәсән ага, ул якты өмет белән тулып, ташып торган илаһи моң!

Рәхмәт, мең-мең рәхмәт сезгә Туфан ага шигырьләр, тылсымлы җырларыгыз өчен. Озак еллар ул җыр яңгырап, дәрт һәм көч-егәр биреп торсын. Сезгә тазалык, озын гомерләр, яңа шигырьләр телим. Үзем исән-сау эшлим, романны дәвам итештерәм.

Сезне, Казанны сагынам.

Ихтирам белән сезнең талантыгыз алдында баш иеп, сәлам белән Ибраһим Салахов.

*1974, 21 сентябрь*

### *Клара Әхмәтҗановага*

Хәерле көн хөрмәтле Заһит әфәнде һәм дә Клара ханым[1]!

Сезгә, туганнарыгызга ихлас күңелдән сәлам. Барыгызга да дәрт, дәрман, сабырлык теләп калам. Сезнең 7 февральдә язган хатыгызны әле бүген генә алдым (почта бәясе күтәрелгән саен тапшыру тизлеге акрыная бара).

Хатыгызны укып чыгып бик шатландым, яшьлек елларыма кайткан кебек булдым. Әле мине хәтерләүчеләр бар икән. Хәйруллага, гаиләсенә чуктин-чук сәлам. Шулай ук, мөмкинлек булса, Галимә укучыма бик күп сәлам. Хәнәфи абый һәм апа мине үз балалары кебек хөрмәт иттеләр, мин киткәндә җылап калдылар алар.

– Улыбыз кебек күргән идек.., – дип. Әйе шул, сез белешкән авыл, мин эзләгән, ул бит хутор иде. Бәлкем аның әле исеме дә булмагандыр. Халык үзе яратып «Гөлбакча» дип йөрткәндер. Сүз

[1] Клара Әхмәтҗанова – ВКП(б) әгъзасы, Буа районы «Яңа юл» газетасы редакторы, Колыма газапларын кичергән Ясәви Шиһап улы Яушев кызы.

арасында, Сарманга бардым, Күтәмәледә булдым, дип сөйләшүләр колакка кереп калган. Бик сагынам ул авылны һәм кешеләрен. Барысына да сагынып сәлам.

Әле генә Т.М. үзәгенең еллык отчет-сайлау җыелышын уздырдык. Буран булуга карамастан, халык җыелды. Күкчәтауда казакъ-төрек лицее эшли. Аның мөгаллимнәре дә җыелышта катнашты, чыгыш ясадылар. Аннан үзебезнең җыр-бию ансамбле концерт бирде.

Сәламәтлек зарланырлык түгел. Рамазан шәриф башлану белән уразага кердек. Әлегә арытмый.

Тагын минем шәкертләр очраса, сәлам әйтеп, адресымны бирсез, бәлки алар да хат язарлар. Сезгә рәхмәт һәм ихтирам белән Салахов.

*(вакыты күрсәтелмәгән)*

*Зәки Нурига*
*1974, 25 октябрь*

Хөрмәтле дуслар: Зәки[1], Ләбибә[2], егетләр!

Хәерле, котлы көн.

Барыгызга да ерак казакъ илендә яшәүче дустыгыздан сагынып кайнар сәлам, тазалык, дәрт, дәрман, егәр һәм илһам теләп калам.

Әльхасиль, Сезгә тагын үткән елларда җибәрелгән хикәямнең төзәтелгән, эшкәртелгән яңа вариантын җибәрәм. Бәлкем инде бу юлы журнал битендә, совет хөкүмәтен урынлаштыру өчен көрәштә корбан –шәһид киткән Кәрим Сутюшевка урын табарсыз дип өметләнәм.

Моннан берничә ел элек Сутюшев К. турында архив документлары җибәргән идем. Шуларны кире җибәрсәгез, яхшы булыр иде, музейдан сорыйлар.

Кабат сәлам һәм ихтирам белән Ибраһим Салахов.

*25.09.1974*

[1] Зәки Нури (1921–1994) – шагыйрь, җәмәгать эшлеклесе.

[2] Ләбибә Ихсанова (1923–2010) – язучы, ТАССР һәм РСФСРның атказанган мәдәният хезмәткәре.

*Әнвәр Әлимжановка*
*1975, 30 гыйнвар*

Добрый день, дорогой Анвар!

Пользуясь приездом Александра Николаевича Сергеева к нам в Кокшетау, хочу передать Вам свой горячий салям и это запоздалое свое письмо.

В 1969 г. году по совету Ж. Молдагалиева я с Татарского Союза перешел на учет в казахский Союз писателей и литфонд. (Я же коренной Кокчетавский жатак...) Все мое творчество посвящено прекрасной Сары-Арке. В данное время работаю над документальным романом о революционном движении в Северном Казахстане.

За два года до своего шестидеятилетия я обращался в Союз писателей Казахстана с просьбой издать хотя бы одно мое произведение (на казахском или руссом языке), хотя бы для того, чтобы я мог получить нормальную пенсию. (Такое в Казани делается по инициативе Союза писателей). Мне ответили: «Сперва необходимо представить перевод, а потом говорить об издании!»

Как вы знаете, я живу в деревне, где я найду переводчиков, да еще квалифицированного. У меня сейчас пенсия 80 рублей. Семья. Приходится продолжать работу и писать роман на работе. Ввиду того, что роман документальный, мне необходимо выезжать в те места (Атбасар, Омск, Петропавловск, Целиноград, Каркаралинский), где происходили эти события. А где брать средства?

После шестидесятилетия я шесть месяцев лежал в больнице (инфаркт), мне бы санаторное лечение после больницы (Ахметов сказал: «Лишних путевок нет»).

За шесть лет как я состою на учете в казахском Союзе писателей ни разу не пользовался путевкой в Дом творчества, хотя татарский Союз мне ежегодно высылал такие путевки (на мои письма Ахметов всегда отвечал «Уже распределены»). Послал я свои произведения в редакции «Жулдуз» – «Простор», ответы не последовало. Уже недалек обрыв...

Видимо я уйду не увидев ни одного своего произведения на русском языке или путном переводе на казахском. Что ж, видимо такая учесть писателя, который живет в деревне.

Желаю Вам крепкого здоровья и новых творческих радостей.

С уважением к вам Ибрагим Салахов.

*30.01.1975 г.*

*Гариф Ахуновка*
*1976,15 июль*
Кызыл Яр

Хөрмәтле Гариф дус[1].

Хәерле көн.

Сезгә, гаиләгезгә һәм барлык каләмдәш дусларга ерак казакъ даласыннан сагынып, сәлам, сәламәтлек, иҗат эшләрегездә яңа биеклекләр теләп калам. Ниһаять, бездән кайтып, «Уф алла!» дип, бераз тынычлангансыздыр.

Мин, үзегез белән күрешкәндә, әйткәнемчә, Төньяк Казагыстандагы татар-казаклары (казачество) тормышыннан әсәр язам. Күп еллар материал җыйдым. Ул бик күп һәм катлаулы булып чыкты. Шуннан мин трилогия язарга ниятләдем (хәере белән очлап чыгарга язсын. Амин.) Менә шул трилогиянең беренче китабын (геройларның балачакларын тасвирлаган өлешен) язып бетереп, сезгә җибәрәм. Үзегез киңәш иткәнгә, аны проза секциясенә тикшерергә – киңәшкә бирергә кирәк. Мин секция җитәкчесе Расих белән сөйләшкән идем бу турыда (ул җибәрергә кушты).

Гариф дус!

Инде сезгә ике үтенеч:

Берсе – монда татарча машинкада баса белүче юк. Үземдә дә машинка юк, шуның өчен мин әсәрләремне Казанга җибәреп бастырып алам. Бу әсәрне дә, элек радиода эшләгән Суфия Гыйззатуллинадан бастырып алдым (75 сум түләдем). Әсәрне күбрәк иптәшләргә укытыр өчен тагын берничә экземпляр бастырырга иде. Әмма миндә акча юк! Инде бу эшне Союз оештыра алмас микән? (тагын да Суфиядан бастыру яхшы булыр иде. Ул текст белән таныш – казакъ сүзләре күп).

Икенче үтенеч.

Бу әсәрне Тат. китап нәшриятенең 1978 ел планына тәкъдим итә алмассызмы икән?

Менә шундый хәлләр.

Төп революцион вакыйгалар II–III китапларда алына. Мин инде, Ходайга тапшырып, шуңа тотынам.

---

[1] Гариф Ахунов (1925–2000) – Татарстан Республикасының халык язучысы, 1974–1984 елларда ТАССР Язучылар берлеге идарәсе рәисе.

Әсәрне укуны Казагыстан-Себер белән таныш иптәшләргә: Нури Арслановка, Шәйхи Маннурга, Расих Атиллага һ.б. тәкъдим итсәгез, яхшы булыр.

Эшләрегездә уңышлыклар теләп, ихтирам белән Ибраһим Салахов.

*15.07.1976*

*Гариф Ахуновка*
*1979, 13 июль*
Кызыл Яр авылы

Хөрмәтле Гариф дус!

Сәлам сезгә һәм барлык каләмдәш дусларга. Бу хат барып җиткәнче, мөгаен, инде мәшәкать узар... (Рәхәтләнеп бер тын алырсыз).

Съезд көннәрендә сөйләшкәнчә, мин «Имәннәр тамыр җәйгәндә» трилогиясен тәмамладым. Инде машинкада бастырырга Казанга җибәрә башлыйм.

1981 елда миңа 70 яшь тула. Бәлкем, шул датаны да истә тотып, Татарстан китап нәшриятының 1981 ел планына бу әсәрне дә тәкъдим итәрсез?

«Күкчәтау далаларында» романын русчага тәрҗемә итү юлында берәр хәрәкәт эшләмәдегезме?

Бу хатны һәм аннотацияне алу турында хәбәр бирсәгез, яхшы булыр иде. Ихтирам белән Ибраһим Салахов.

*13.07.1979*
*Кызыл Яр авылы*

*Гарәфетдин Шәрәфетдиневкә*
*1977, 5 декабрь*

Хөрмәтле Гарәф Низаметдинович[1].

Хәерле көн!

Сезгә, гаиләгезгә күп сәлам, сәламәтлек, эшләрегездә уңышлыклар теләп калам.

---

[1] Гарәфетдин Низаметдин улы Шәрәфетдинев (1929–2012) – журналист, 1973–1987 елларда Татарстан китап нәшрияты директоры.

Переделкинодагы сөйләшкән буенча, мин хәзергә, балалар өчен язылган В.В.Куйбышевның бала чагы турында истәлек-хикәя җибәрәм. Карарсыз. Бәлкем бастырып чыгару мөмкинлеген табарсыз.

Истәлекләр әзер, әмма машинисткага җибәрә алмыйча торам, отпускадан соң акча юк машинисткага түләргә.

Бастырып алу белән җибәрермен.

Үзем трилогияне язуны дәвам итәм. Вакытыгызны алып, комачаулавым өчен гафу үтенәм.

Кабат сәлам һәм ихтирам белән Ибраһим Салахов.

*5.12.1977*

*Малик Фазыловка*
*1978, 8 август*

Хәерле көн.

Хөрмәтле Малик Сабирович[1]!

Салям.

Простите, что отнимаю у Вас время. Вынужден.

В прошлом 1971 году, мне исполнилось 60 лет. Спасибо Кокчетавскому Обкому КП Казахстана и Облисполкому, которые торжественно отметили мой день рождения. Были гости из Татарии. Дарили адреса и почетные грамоты Президиума Верховного Совета Казахской ССР.

На второй день свалил меня сердечный приступ – инфаркт.

Полгода лежал в больнице. Меня страшила не смерть, а то, что уйду не завершив свой новый роман о революционных событиях в Кокчетавском уезде. Ведь эту книгу кроме меня никто не напишет (надо спешить, инфаркт может повториться)

Однако после больницы мне опять пришлось идти на работу. Дело вот в чем, приближаясь к своему шестидесятилетию, я обращался и в Казахский и в Татарский Союзы писателей, с просьбой помочь мне в издании моих новых произведений с тем, чтобы обеспечить мне нормальную пенсию. Татиздат в 1971 году выпустил небольшой сборник – «Төн кызы» (О Кокчетаве) от Союза писателей Казахстана ответа не получал. И вышло у меня так, что

[1] Фазылов Малик (1927–1995) – Казахстанда дәүләт һәм партия эшлеклесе.

среднемесячный гонорар за 1969 год – 180 рублей, а за 1970 год (с которого исчисляется пенсия) всего 110 рублей, что даст пенсию 50–55 рублей.

Кокчетавский обком и облисполком желая создать мне нормальные материальные условия для творческой работы и учитывая долголетнюю работу в общественно-политических организациях ходатайствовал об установлении мне персональной пенсии республиканского значения. Недавно получил ответ – отказать.

В 1937 году, чтобы меня убивать нашлись и законы и статьи, а сейчас – перед смертью завершить начатую книгу не находят закона.

Малик Сабирович!

Простите, что так резко пишу. Ведь Вы знаете хорошо, что меня приглашали в Татарию, но я отказался ради Кокчетава. Еще хуже, я перешел на учет в Союз писателей Казахстана, который и на последнее мое письмо не соизволил ответить (это письмо прилагаю) неужели Советские писатели (инвалид, больной, который все еще старается творить для народа) под старости лет должен обречься на жалкое существование.

Мне стыдно перед народом, перед моими читателями, перед татарской организацией писателей откуда я ушел добровольно.

Будьте здоровы.

Ибрагим Салахов.

*8.08.1978*

### *Жомабаев Әбилмәжингә*
### *1980, 1 июнь*
### с. Красный Яр

Добрый день уважаемый Абильмажин Жумабаевич[1]!

Салям. Желаю Вам здоровья и плодотворной работы.

Вчера я, по телефону, разговаривал с Джубаном Мулдагалиевым по поводу моего семидесятилетия, которое исполняется 30 августа 1981 года.

[1] Әбилмәжин Жомабаев (1929–2013) – язучы һәм тәрҗемәче, «Жазушы» нәшрияты директоры (Казакстан).

До этого на эту тему я разговаривал: Алимжановым, Муртазаевым, Сулеймановым. Все они обещали помощь и до сегодняшнего дня конкретно ничего не предприняли по переводу и изданию моих книг.

В прошлом году я получил письмо Ответ. Секретаря Целиноградского м/о отделения писателей Казахстана Уразова Н. о том, что все произведения для перевода и издания должны пройти через м/о отделения и просил таковых выслать ему.

Я так и сделал, послал для перевода и издания три книги – на татарском языке – роман «В степях Кокчетава» 10 п.л., сборник рассказов «Дочь ночи» 8 п.л., повесть «Стареет ли любовь» 4 п.л. (последняя повесть напечатана в № 3 ж. «Казан утлары»). Сейчас она выходит в Казани отдельной книгой. Сигнальный экземпляр получен.

Уразов ответил, что эти книги получены и послано ходатайство в секретариат С.П. и на этом конец (они эти книги в издательство выслали или нет не знаю).

Вчера Мулдагалиев сказал, что на эту тему он разговаривал с Вами и что решили включить в план издания, пока на казахском языке. Также, Мулдагалиев советовал мне, в дальнейшем обращаться к вам. Вот почему я решил беспокоить Вас. Прошу прощения.

Видимо, издательство должно получить мои произведения, которые предназначены для перевода (они уже с прошлого года находятся в м/о отделения Уразова).

Да, слишком медленно откликается союз на мои просьбы. Что же, на то воля божья (ехать надоедать не могу, болею. Второй инфаркт).

И вот наконец. Я смею надеяться на Вас, Абильмажин Жумабаевич, хотя и с опозданием, Вы продвините это дело, дай бог.

По совести говоря, я не знаю, что от меня потребуется. На всякий случай пишу заявление на Ваше имя и короткие аннотации, на те произведения, которые предлагаю на перевод и издание. Жду Вашего ответа.

Хуш булыгыз.

С уважением И. Салахов.

*1.06.1980*

*Динмөхәммәд Кунаевка*
*1980, 24 ноябрь*
с. Красный Яр

Здравствуйте многоуважаемый Димаш Ахматович[1]!

Примите мой искренний салям. Желаю Вам и Вашей семье здоровья и благополучия.

Извините, что отнимаю у Вас время. Вынужден.

Я родился в Кокчетаве. Живу в Кокчетавском районе селе Красный Яр. Пишу только о Сары-Арке. Состою на учете в Союзе писателей Казахстана.

Я по наивности думал, что, раз живу далеко от столицы, в деревне, Союз непременно обратит на меня внимание (оказывается, это иллюзия).

Я больше 15 лет трудился над трилогией – о революционном движении в Северном Казахстане. В этот период я несколько раз обращался в Союз с просьбой оказать материальную помощь, для поездки в те места, где развертывались события, которые описывались в романе. Также необходимо было разыскать в разных городах республики архивные документы. Но мне в помощи отказали.

В 1981 году мне исполняется 70 лет. В связи с этим я обращался в Союз (лет 5 тому назад) с просьбой организовать переводы моих произведений на казахский, русский языки.

– «Не беспокойся, аксакал, все сделаем» – сказали и забыли.

Да, когда был живой Зиен Шишкин, друг по несчастью – организовал переводы и издание сборника моих стихов «Кокшетау жыры» на казахском языке. И еще один неудачный, наполовину сокращенный перевод был сделан моего романа, об освоении целинных земель в Кокчетавской области – «В степях Кокшетау». И все!

Я жалуюсь? Нет. Жалуется тот, кто чего-то добивается. (Видимо, я уже опоздал.)

А я, нет. Я рад тому, что завершил свой главный труд – трилогию. А переводы моих произведений? Это, видимо, сделает после моего ухода, может даже гораздо лучше, чем при жизни (с предисловием!)

Вот такие дела и думы мои, дорогой Динмухаммед Ахметович.

---

[1] Кунаев Динмөхәммәд (1912–1993) – 1964–1986 елларда Казакстан ССР Коммунистлар партиясе Үзәк Комитетының I секретаре.

Да, трилогия в Казани получила положительную рецензию. Сейчас я готовлю ее к печати.

Хуш булыгыз. Ихтирам белән Ибрагим Салахов.

Примите мой скромный подарок – новую книгу.

*24.11.1980*

*Жобан Молдагалиевка*
*1980, 7 март*

Первому секретарю Союза писателей Казахстана тов. Мулдагалиеву[1] Дж. от члена С.П. Салахова И.Н.

Ассаламагалейкум, ардакты жолдас Жуман!

Примите мой искренний салям и поздравления. Желаю здоровья, успехов в работе и новых творческих радостей.

В прошлом году, наконец, я завершил свой многолетний труд (работал 15 лет) историко-документальную трилогию о революционном движении в северном Казахстане. (Аннотацию послал в Союз) объем 45 п. л., рукопись сдал в Таткнигоиздат. Кроме этого, в этом году, в этом же издательстве у меня выходит повесть «Стареет ли любовь?»

В 1981 году, если аллах досрочно не заберет к себе, мне исполнится 70 лет.

К сожалению, за это долгое время, ни одна моя книга не переведена на русский язык. В татарском Союзе мне говорят, что я состою на учете не у них, а в Казахстане. У них возможности больше, обращайтесь к ним.

В дни прошедшего последнего съезда я был у А. Алимжанова и у других секретарей С.П. по этому вопросу. Сказали: «Аксакал, не беспокойтесь, поможем».

Проходит уже пять лет, а этот вопрос все еще не решается. Я за это время написал четыре письма на имя Алимжанова и, к сожалению, ответа не получил.

Секретарь Целиноградского м/о отделения Уразов сказал, что все вопросы переводов и издания надо решать через нас. Мы сами будем ходатайствовать перед С.П.

---

[1] Жобан Молдагалиев (1920–1988) – казак шагыйре, тәрҗемәче.

Я им послал заявления и три книги:

1. «В степях Кокшетау» – роман.
2. «Дочь ночи» – сборник рассказов.
3. «Стареет ли любовь» – повесть.

Уразов ответил, что ходатайство послано ни имя Мулдагалиева. По получению ответа произведения Ваши вышлем в Алма-Ату. Вот я и жду уважаемый Джуман, очень прошу Вас, окажите мне помощь в переводе и издании моих книг на русский и казахские языки, я ведь коренной казахстанец.

Жду ответа. С уважением И. Салахов.

*7.03.1980*

*Зәки Нурига*
*1980*

Хөрмәтле дуслар: Зәки Нури, Әхсән Бәян[1]!

Сезгә һәм «Казан утлары»ның башка егет-кызларына, ерак казакъ илендәге дустыгыздан кайнар сәлам, барыгызга да сәламәтлек, иҗат сөенечләре, эшләрегездә уңышлар теләп калам.

Мин Казанда вакыттагы сөйләшү буенча – 70 еллык уңае белән «Имәннәр тамыр җәйгәндә» трилогиясенең өченче китабын журналга тәкъдим итәм. Бу трилогияне тулаем сезнең журналның редколлегия әгъзасы Атилла Расих укып чыгып, нәшриятка рецензия бирде. Билгеле, рецензиянең күрсәтмләре буенча, әсәрне төзәтеп, тулыландырдым. Әгәр кирәк тапсагыз, А. Расих журнал өчен дә үз фикерен әйтер.

Мин хәзер шул төзәтелгән нөсхәне җибәрәм. Кульязманы ачуга куркып калмагыз – икенче экземпляр, чөнки монда татарча баса белә торган машинистка юк. Мөмкин булса (минем хәлне исәпләп), шул хәлендә укып чыгып, үз фикерегезне әйтегез. Журналда урын бирә алсагыз, мин бик шат булыр идем. Әгәр инде кульязманы бу хәлендә ала алмасагыз (миңа ярдәм рәвешендә) редакциядәге берәр иптәш аны нәшрияттагы баш машинистка Рәйсә Хафизовага тапшырса икән. Ул басып бирер, аның белән сөйләшенгән.

---

[1] Әхсән Баян (1927–2013) – язучы, Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты, Татарстан Республикасының халык шагыйре.

Билгеле инде, бу редакция эше түгел. Әмма минем нинди шартларда эшләвемне искә алып, рәнҗемичә булышсагыз иде дим. Алай булмаса, бу эшне Нури Арслановка да тапшырып була.

Һәрхәлдә, бу хатны, кульязманы алгач, миңа бер хәбәр бирерсез дип өметләнәм.

70 еллык уңае белән минем иҗат турында кереш сүз кирәк булса, аны Нури Арсланов эшли алачак.

Барыгызны да якынлашып килгән яңа 1981 ел белән тәбрикләп, сәламәтлек, иҗат уңышлары теләп калам.

Ихтирам белән Ибраһим Салахов.

*1980*

### *Солтан Шәмсигә*
### *1981, 5 гыйнвар*

Хөрмәтле Солтан иптәш[1]!

Яңа елыгыз котлы булсын.

Эшләрегездә уңышлар, иҗатыгызда сөенечләр теләп калам, редакциядәге башка иптәшләргә дә бәйрәм сәламе, изге теләкләр.

Яңа ел – яңа өметләр. Минем өчен бигрәк тә – бу елда 70 тулачак. Булган хәтле көчне җыеп, мин шуңа әзерләнә идем.

Менә шул изге ел башында, һич көтмәгәндә, сез мине рәнҗеттегез, кәефне яхшы ук боздыгыз. Аптырагач, бу хатны язарга мәҗбүр булдым.

Мин Казахстанда туып үстем. Әмма милләтемә булган мәхәббәт мине Казанга китерде, каләм бирде. Миңа Галимҗан Ибраһимов үзенең фатыйхасын бирде. Бу фатыйха өчен мин 20 ел сөргендә булдым. Әмма аның өчен Г. Ибраһимовка да, Ватанга да рәнҗемәдем. (Галимҗан аганың соңгы көннәрендә Казан, Пләтән төрмәсендә бергә булдым, озаттым.) 20 елдан соң яңадан әдәбиятка кайттым. (Аягымны, кулымны сындырсам да, иманымны сатмадым – мөртәт булмадым.)

Татар халкы Идел буенда гына түгел, бөтен Союзга (дөньяга) таралган. Октябрь революциясе җиңешендә татар халкының өлеше – фидакарьлеге биниһая. Әмма ул бөек көрәш әдәбиятта

---

[1] Солтан Шәмси (1946) – язучы, тәрҗемәче, мөхәррир. Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре.

чагылмый диярлек. Татар егетләренең казакъ далаларында, төркестан чүлләрендәге совет төзелеше өчен көрәшләре, баһадирлыклары онытыла. Ә еллар үтү белән, аны белүче шаһитләр үлү белән, бу сәхифә бөтенләй күмеләчәк.

Менә шушы хәлгә җаным оеп, мин төньяк Казагыстандагы татарларның революция өчен көрәшләрен терелтергә, дөньяга менә бездә дә Бөек революция өчен көрәшеп газиз башларын салган баһадирлар бар, дип әйтергә телим. Ул фидакарьләрнең барысын да диярлек мин күреп белә идем. Әмма шулай да Атбасар, Алма-Ата, Омск, Петропавел, Күкчәтау архивларын, музейларын актарып, шул чор кешеләрен күреп-сөйләшеп, истәлекләр алып, материал тупладым.

15 ел мин шушы әсәр өстендә эшләдем. Ниһаять, язып бетереп нәшрияткә тапшырдым. Нәшрият аны рецензияләргә А. Расихка бирде (ул бит әле сезнең журналның редколлегия члены). (*ахыры юк*)

*5.01.1981*

## *Казахстан язучылар берлегенә*

В союз писателей Казахстана от члена С.П. Салахова Ибрагима.

В 1981 году (если аллах не заберет) мне исполнится 70.

К 60-летию моему, со стороны Союза ничего не было предпринято. Перевод, издание моих произведений и прочее.

Вот 70!

Я же состою на учете у Вас и пишу о Казахстане. Вот завершил трилогию.

Как быть дальше?

Кто будет издавать?

Кто поможет мне в переводе моих произведений на казахский, русский языки?

За 10 лет, как состою я у вас на учете, помощи или даже внимания пока не чувствовал.

Как будет дальше?

С уважением Салахов.

*(Вакыты күрсәтелмәгән)*

*Олжас Сөләймановка*
*1984, 13 июль*
с. Красный Яр

Ассаламогалейкум, ардакты жолдас Олжас[1]!

Салям.

Только что вернулся из Казани, куда был приглашен на торжество по случаю 60-летия Республиканской пионерской газеты «Яшь Ленинчы», которую я редактировал в тридцатые годы. Потом участвовал на X съезде писателей Татарстана. (Почему то не было представителя от вас, хотя и ждали, очень.)

После, заключил договор с Таткнигоиздатом, на издание моего романа «Когда дубы распускают корни» – о революционных событиях в Сары-Арке объемом 25 печатных листов. Также оставил в издательстве сборник стихов разных лет.

В 1986 году, если доживу, мне исполнится 75 лет. По этому поводу не может ли правление Союза писателей Казахстана проявить инициативу по изданию моих произведений – романа или стихов?

Да, к слову, к моему 70-летию Союз писателей Казахстана не удостоил меня даже рублевой телеграммой, не говоря уже о печатании моих произведений в газетах и журналах Казахстана.

В данное время работаю над повестью о Петро-Кокчестрое. Заодно скажу и о том, бюро пропаганды Союза писателей посылает бригады писателей в нашу область, даже район, но меня не включают в состав этих бригад, хотя я и просил об этом нового начальника бюро.

А лит. фонд, после прихода нового директора, вообще перестал отвечать на мои письма.

Вот такие дела у меня дорогой Олжас Омарович .

Нет, не жалуюсь, слишком мало осталось времени для этого. Однако, просто по-человечески обидно, что начальство забывает своего единственного доморощенного писателя Татарии в Казахстане. Извините за откровенность.

С уважением, ихтирам белән И. Салахов.

*13.07. 1984*

---

[1] Олжас Сөләйманов (1936) – Казакстанның халык язучысы, әдәбият белгече.

*Роза Хафизовага*
*1984, 10 август*

Хөрмәтле Роза ханым[1]!

Хәерле көн!

Барыгызга да сагынып, чуктин-чук сәлам.

Әле һаман сезнең хөрмәт, ихтирам белән яшим. Рәхмәт, археологик батырлык, мәшәкать белән мине казакъ иленнән казып табуыгызга.

Бик сөенеп кайттым, үземнең әле кемнәргәдер кирәклегемне тоеп, сезнең кебек фидаи җаннарның барлыгына сокланып, сөенеп. Инде менә вәгъдә буенча Арсланов Нури турында истәлек җибәрәм, тагын дилбегә булып китте. Бигайбә. Үзегез карарсыз инде. Почеркым бик алама, җибәримме, җибәрмимме, дип икеләнеп йөрдем дә, җөрьәт иттем. Элек Казанда минем почеркымны таный торган машинистка бар иде. Ул китте. Инде менә сезне җәфаларга булдым. Зинһар, түземлек белән шифровка эшләгез инде. Мөдәррискә хат язган идем, нигәдер җавап бирмәде.

Үзегезнең хәлләр ничек?

Барлык каләмдәш дусларга рәхмәт һәм кайнар сәлам.

Ихтирам белән Салахов.

*10.08.1984*

*Олжас Сөләймановка*
*1985, март*

Первому секретарю правления Союза писателя Казахстана тов. Сулейманову О.О.

От члена С.П. Салахова И.Н.

Заявление.

Желая написать роман об освоении целинных земель в Кокчетавской области, я, в начале пятидесятых годов, из Кокчетава переехал в с. Красный Яр (я сам коренной Кокчетавец, родился и рос в этом городе).

То, что задумал – сделал.

Одним из первых в Союзе написал роман о первых годах организации совхоза «Симферопольский», «В степях Кокшетау» – который

---

[1] Роза Хафизова (1929–2005) – язучы. ТАССР һәм РСФСРның атказанган мәдәният хезмәткәре.

по два раза издавался в Алма-Ате и Казани. Кроме этого вышел сборник стихов, рассказов о целине. Почти 15 лет работал над романом о революционных событиях в Сары-Арке, который издается в Казани в 1986 г. В этом году будет печататься в журнале «Казан утлары» – орган С.П. Татарии. Сейчас работаю над романом о Петро-Кокчестрое.

Однако... года идут, дают знать о себе. Последнее время стал часто болеть. Вот, в начале этого года болел гриппом и два раза в день в течении месяца ездил автобусом в поликлинику, в город, на процедуры. В конце концов простудился. Врачи признали воспаление легких, лег в больницу.

Видимо, сейчас мне необходимо перебраться поближе к поликлинике.

Поэтому я обратился первому секретарю Кокчетавского О.К. Казахстана тов. Сагдиеву М.Р. и председателю исполкома областного советов народных депутатов тов. Моисеенко В.И. с просьбой выделить мне в Кокчетаве квартиру 3-х комнатную. Там сказали, еще необходимо ходатайство Союза писателей на имя тов. Сагдиева М.Р., Моисеенко Виктора Ивановича.

Очень прошу Вас написать и выслать по адресатам такие ходатайства.

Надеюсь, что о высылке ходатайства уведомите меня.

С уважением И. Салахов.

*март, 1985*

*Ринат Мөхәммәдиевка*
*1985, 8 март*

Исәнмесез, хөрмәтле Ринат дус[1].

Хәерле көн.

Ерак казакъ илендә яшәүче каләмдәшегездән кайнар сәлам.

Соңлап булса да хәләл җефетегезгә, һәм дә редакциядәге гүзәл ханымнарга, туташларга бәйрәм тәбриге.

Халык көенеч белән сөенеч янәшә йөри, ди.

Миндә дә шулай булды ахры.

Ел башында Петропавловск шәһәренә телевидение һәм радиода чыгыш ясарга чакырганнар иде. Шунда троллейбус астында

[1] Ринат Сафа улы Мөхәммәдиев (1948) – язучы, әдәбият галиме. 1981–1987 елларда «Казан утлары» журналында баш мөхәррир урынбасары.

калып чак кына бакый дөньяга рихләт әйләмәдем. Алай да айга якын шифаханәдә ятып, кичә генә чыктым. Шифаханәдә вакытта Аяз Гыйләҗ хатын укып, минем романны журналыгызда басарга ниятләвегезне ишетеп бик куандым. Бәлкем, менә шушы сөенечле хәбәр мине сырхаудан күтәрде дә, иншалла. Сезгә рәхмәтем зур. Менә шуның өчен, әле хәл дә алмыйча, бүген үк сезгә ихтирамымны белдерәсем килде. Үз ана телендәге дөньядан читтә булу – юксындыра, сагындыра һәм үксез итә.

– Оныталар, – дисең, андагылар.

Юк, онытмыйлар. Хәтта ихтирам белән юл ачалар икән.

– Афәрин.

Бу романны казакълар да басып чыгарырга ашыгалар. Гадәти шарт буларак, әсәрне тәрҗемә итү өчен аның оригиналын үз телендә китап булып басылып чыгуы мәтлуб. Бу – закон.

Әмма Казагыстан Язучылар союзы:

– Татарстан китап нәшрияты бу романның 1986 елда шушы тексты басылачак, дип рәсми справка җибәрсеннәр безгә. Без шул справка нигезендә китап чыкканчы ук романны тәрҗемәгә бирәбез, – диделәр.

Андый справка килде. Роман ике нөсхәдә машинкада басылды. Мин инде Казагыстан басмасына әзерли башлаган идем. Әмма көтелмәгән каза тоткарлады. Инде аны апрель башында Алма-Атага «Жазушы» басмасына алып барачакмын.

Сәламәтлек уртача, кәеф яхшы. Редакциядәге каләмдәш дусларга кайнар сәлам.

Тагын бер рәхмәт, тирән ихтирам белән Ибраһим Салахов.

*8.03.1985*

*Тәүфикъ Әйдигә*
*1986, 9 июнь*
Кызылъяр авылы.

Хәерле көн, хөрмәтле Әйди дус[1]!

Сәлам әниеңә, сиңа, Әлфиягә, кызларга (исемнәрен онытканмын. Инде зур үскәннәрдер мин күргән заманнан), барлык редакция әһелләренә кайнар сәлам.

[1] Тәүфикъ Әйди (1941–2001) – язучы, публицист. ТССРның атказанган мәдәният хезмәткәре.

Үзем әле генә шифаханәдән чыктым. Инфаркт № 2. Чүт-чүт дарелбакыйга рихләт әйләмәдем. Әле дә күп йөрергә рөхсәт итмиләр.

Алай да... ашыгам.

Ходаның хикмәте, бу ел 30 августта без фәкыйрьгә 75 тулу куркынычы бар. Бәлкем журнал да искә төшереп үтәр. Мин элек синең белән киңәшеп алыйм, дидем. Син Ренатка миннән сәлам тапшыр һәм бу темага сөйләшеп кара. (инде миңа әллә кайчан бер әсәр хәзерләп җибәрергә иде, авыру тоткарлады.)

Миндә хәзер сезгә җибәрердәй түбәндәге язмалар:

1. Х. Туфан турында истәлек (реабилитация көннәрендә. 1956 ел. Х. Туфан, С. Рәфыйков вә мин – фото белән;

2. Казакъ тормышыннан хикәя (5–6 бит);

3. «Күкчәтау». С. Сәйфуллин поэмасы. Минем тәрҗемәдә.

Ә минем иҗат турында бәлкем син үзең бер-ике сүз әйтерсең. Үзең күреп торасың, минем почерк бик алама. Кульязманы турыдан-туры редакциягә җибәрә алмыйм. Бу бәладән мине Әлфия сеңлем коткара алмас микән? (Машинкада басып бирсә, әҗерен түләр идем.)

Бу хатны алгач, җавап язсаң әйбәт булыр иде. Ихтирам белән Салахов.

*9.06.1986*

*Николай Полотайга*
*1982, 15 ноябрь*
с. Красный Яр.

Ай да мы молодцы, Николай[1]! Не правда ли? От волка ушли, от медведя ушли. А от…

Нет, видимо и нам пора, совесть знать. Сколько можно торчать, на этой длинной дороги…

И действительно, мы бессовестные, пережили: Николая второго (ты же 1-ый), Ленина, Сталина, Хрущева и вот…

Брежнева.

Сейчас уже без 15 минут 3 ч. дня. (по Москве 11.45.)

Скоро будем проводить деда в последний путь…

Дорогие мои Николай и Изида!

[1] Николай Полотай (1909–1987) – язучы, юмор һәм сатира остасы.

Примите мой искрений салям, завещаю вам жить долго, творить только классику!( Вам это легче, чем мне, так как вы уже у подножья Олимпа)

Благодарю за теплое письмо, за святые пожелания и за Ялту. Если Аллах не заберет к себе, в 1983 году может и окажусь у самого синего- синего моря.

Здоровье пока сносное. Мучаюсь над романом. Вот-вот в Алма-Ате должен выходить сборник – прозы.

Ты пишешь насчет долгов. Да! Обязаны. Я то по своей силе и возможности частично стал погашать эту задолженность. Только… через сберкассу. Наличными не принимают!

Николай, ты бы послал мне свои книги. Моих ты пока не можешь прочесть, они на татарском, казахском языках. Переводить не берешься. Еще раз рахмат и салям. Пиши. Ваш Ибрагим бек.

*15.11.1982*

*Николай Полотайга*
*1986, 5 сентябрь*

Здоровья, тысячи радостей вам дорогие Николай (Полотай) и Изида!

Добрый день.

Примите мой искренний салям и восхищения вашим вниманием. Еще… Примите мое извинение за неаккуратность.

От вас уже 2 добротных писем, а я ни одного.

В эти дни были много шум от нечего.

Выступления. Интервью. Гости.

Вот так нежданно, негаданно – 75. Здорово! Да!

Твои письма все похвальные, последнее – особенно.

Как будто ты подслушал мои мысли…

Я стократ согласен с тобой, только в одном с тобой расхожусь, не стоит унывать.

Мы – выжили.

Мы – творили (и творить будем!)

Если не вышли в знатные, то не наша вина.

Недавно, перед 75-летием меня вызвал секретарь обкома К.П. и говорит:

– У тебя есть в Алма-Ате друг-писатель?

– Есть, а что?

– Ты скажи, (или срочно напиши) пусть он зайдет в СП. И поставить вопрос о награждении тебя, а то они «дальних» забывают.

– Нет, – сказал я, писать могу, но себе награду выпрашивать не могу и ушел.

Зачем? Если хотят, пусть без меня и делают. А, я уже имею награды, письмо от директора Таткниготорга. Я просил его выслать 700 эк. моих книг (романа).

– «К сожалению, в настоящее время удовлетворить Вашу просьбу не имеется возможность. Т.к. данная книга пользовалась большим спросом покупателей и полностью реализована» 10000 эк! За 2 м-ца!

И до этого роман, который издался в Алма-Ате, быстро разошелся (15000 экз). У меня их нет. Хотел (всю собирался) послать и тебе.

Сейчас она переводится.

По-моему, это и есть награда писателю – книги его не залеживаются.

Я думаю так.

А всякие жестянки быстро заржавеют.

Дай бог здоровья и вдохновенья и тебе и мне! Да?

Я, слава аллаху, на здоровье не жалуюсь (сегодня!)

Два сына – Шамиль, Камиль с высшим образованием работают.

Будьте здоровы друзья!

Ваш Ибрагим бек.

*5.09.1986*

*Аяз Гыйлҗевка*
*1986, 11 май*
Күкчәтау, шифаханә.

Хөрмәтле Аяз[1] һәм Нәкыя дуслар!

Сезгә, нәшрияттагы иптәшләргә – Гарәфкә, Яхъяга – күп сәлам.

Аллага мең шөкер, Аяз, синең хатны әле үзем укып чыгарга насыйп булган икән...

---

[1] Аяз Гыйләҗев (1928–2002) – Татарстан Республикасының халык язучысы, Г. Тукай исемендәге дәүләт бүләге лауреаты.

Менә инде айдан артык «түшәмгә төкереп» ятам. Икенче инфаркт. Әле кузгалырга, утырырга рөхсәт итмиләр. (Бу хатны сестралардан яшеренеп яткан килеш кенә язам.)

Билгеле, китап өчен сиңа да, Шәрәфетдиновка да, Яхъяга да рәхмәтем зур. Үзем мин аны Казан шәрифтә «юармын» дип тә уйлап йөри идем. Әмма, бәндә теләр, тәкъдир көләр икән…

Ә бит китап һаман минем кулда юк. «Книга почтой»га заказ җибәргәнгә айдан артык. Арсланов Нурига да хат язып «Книга почтой» га шалтыратырга сораган идем.

Синең әйтү буенча нәшрият җибәргән 5 данәне. Мин улыма Алма-Атага Олжас Сөләймановка, нәшриятның директорына, баш редакторга һәм тәрҗемәчеләргә җибәрергә кушкан идем. Ул Алма-Атага барып, ун көнләп торып, һәрберсенә тапшырган. Ә «Жазушы» нәшриятының элекке җитәкчесе 1990 елга хәтле договорлар төзеп «ишекне ябып» куйган булганнар.

Улым Кунаевка кергән. Миңа бу ел 75 туласын (үлмәсәм), хәзер больницада ятуымны әйткән.

– Аксакалның иҗатын халыкка җиткерергә мөмкинлек табарбыз, – дигән Кунаев. Менә шуннан соң гына китапны казакъ-рус телләренә тәрҗемә итү эше кузгала. Алла язып, үзем аякка бассам, Алма-Атага барып – нәшрият башлыклары белән күзгә-күз сөйләшеп – хәл итеп кайтырмын, иншалла. Билгеле инде, бу йөрүләрнең (былтыр ике тапкыр унар көн торып нәшрият белән сөйләшеп-килешеп йөрүләрнең) расходсыз булмавын искә аласыңдыр дип уйлыйм. Әле малай йөреп кайтты. *(Ахыры сакланмаган)*

*11.05.1986*

*Рафаэль Баһаутдиновка*
*1986, 13 август*

Ассалямугалейкум хөрмәтле Рафаэль[1]! Салям.

Сегодня в газете «Соц. Татарстан» прочел статью о Вашей выставке и очень обрадовался, что наши земляки и на дальних краях радуют людей своим творчеством. Рахмат. Читая статью, я вдруг,

[1] Рафаэль Мәхмүт улы Баһаутдинов (1931) – күренекле рәссам. Репрессия корбаны, ТАССР ВЛКСМ өлкә комитетының I секретаре Мәхмүт Гыйльметдин улы Баһаутдиновның улы.

почему-то, обратил внимание на Ваше имя и фамилию. Слишком уж знакомый казался. И вспомнил… Боже мой, это же сын моего друга Махмута. В тридцатые годы я работал в Казани, в редакции «Кызыл яшьләр», тогда Махмут был первым секретарем обкома комсомола.

После мне пришлось с ним вместе жить в одном номере в гост. «Плетенево», в Казане...

Я – писатель. 30 августа мне исполняется 75 лет.

Если умеете читать по татарский, позже, могу выслать свои книги и могу кое-что рассказать о Вашем отце.

Передайте искренний салям Вашей семье.

Ихтирам белән Салахов.

*13 августа 1986 г.*

*Олжас Сөләймановка*
*1986, 29 гыйнвар*

Первому секретарю правления Союза писателя Казахстана тов. Сулейманову О.О.

Еще в 1984 году я будучи у Вас на приеме просил Вас оказать мне содействие в включение в план переводов издательства «Жазуши» и мой роман «Дубы углубляют корни» – на казахский, русский языки.

По согласованности с Вами, в 1985 году я представил в издательство «Жазуши» машинописный текст романа в 2-х экземплярах, со справкой Таткнигоиздата, о том что роман в этом году принят в изданию. Однако издательство «Жазуши» до сих пор не принял никаких практических мер по подготовке романа к переводу (роман о революционных событиях в Сары- Арке).

Роман в прошлом году печатался 11–12 номерах в журналах «Казан утлары» и отдельной книгой выходит в феврале этого года.

Дело в том, что в этом году мне исполняется 75 лет. Я думал, что союз писателей Казахстана, тоже примет по этому случаю.

Еще одна просьба. Хотя и не прилично самому поднять этот вопрос. Однако решаюсь, в надежде, что до последующего съезда писателей СССР видимо не добирусь... Поэтому может найдете возможность, чтобы на этот раз в составе Казахской делегации я

тоже выехал в Москву. Знаю, это не скромно. Но, что сделаешь, если появилось такое нескромное желание.

С уважением И. Салахов.

*29.01.1986 г.*

*Олжас Сөләймановка*
*1987, 20 сентябрь*

Первому секретарю правления Союза писателя Казахстана тов. Сулейманову О.О.

от члена С.П. тов. Салахова И.Н.

Письмо-заявление.

Ассаламогалейкум Олжас Омарович!

Примите мой искренний салям и пожелания здоровья, творческих радостей. Салям всем друзьям по перу.

За последние 5–6 лет я писал на Ваше имя 4 письма, но письмо-ответа я от Вас не получил. Не знаю или мои письма до вас не доходят, или...

Вот уже мне – 77 лет. Больше 50-ти лет своей жизни отдал литературе. Все мое творчество посвящено Саре-Арке. И к моему стыду, до сегодняшнего дня, у меня нет ни одной книги на русском языке.

В Казани говорят: – Вы стоите на учете в Алма-Ате, пусть они организуют перевод – издание Ваших произведений на русский язык. У них возможностей больше.

– А в Алма-Ате обещают:

– Аксакал, не волнуйтесь, организуем. (Я уже нашел переводчика – Асхата Хамидуллина.)

А практически дела нет. Я уже не знаю сколько ждать. Скоро 80 (дойду ли до этой вершины).

Олжас!

Может наконец к этой дате подготовите перевод, и издание моих произведений на руский язык.

А ведь Азраиль на моих плечах.

С уважением И.Н. Салахов.

*20.09.1987*

*Владимир Нига*
*1987, 30 ноябрь*

Добрый день, уважаемый Владимир Васильевич[1]!

Примите мой искренний салям и извините за беспокойство Вас.

Не в моей натуре писать прошения, упрашивать. Но на этот раз, к сожалению, не писать нельзя – годы уже подталкивают.

Обойденный вниманием Союза писателей Казахстана, я вынужден был написать письмо на имя первого секретаря ЦК КП Казахстана Колбина Геннадия Васильевича, с просьбой оказать содействие в переводе и издании мои некоторые произведения (безусловно, только те, которые достойны этой чести) на русском языке.

По своей наивности, я думал, что Геннадий Васильевич прочтет мое письмо и как-то поможет, единственному в Казахстане писателю – татарину.

– Вышло странно. Работники аппарата ЦК вместе того, чтобы письмо мое вручить первому секретарю, переадресовали на того, на кого я соизволил жаловаться. И соответственно, получил безапелляционный ответ от главного редактора издательства «Жазуши» О. Сарсенбаева: «…Ваш роман в настоящее время (3-й год) переводится на казахский язык и может быть будет включен в план ред. подготовки на 1990 г. и поэтому в ближайшие годы мы не сможем издать Вашу книгу на русском языке»

Вот тебе на! А ведь еще 2 года тому назад О. Сулейманов и директор издательства Скакбаев уверяли меня:

– Аксакал, не волнуйтесь. Ваш роман в 1988 г. издадим на казахском, а в 1990г. к вашему 80-летию на русском языке.

Я ведь безвыездно живу в деревне, а в Алма-Ату выезжаю только по вызову – на съезды, совещания и поэтому начальников своих вижу очень редко и довольствуюсь только их вежливыми обещаниями.

Вот, Владимир Васильевич, дела мои такие, незавидные. Писать повторно письмо на имя Колбина Г.В., сами понимаете, бесполезно. Новые Бекажановы письмо мое не пропустят до адресата. Как же быть? Не знаю. И вот, из-за безвыходности положения,

---

[1] Владимир Васильевич Ни (1933–2010) – Казахстанның күренекле дәүләт эшлеклесе.

я наконец решился обратиться к Вам. Может быть Вы, Владимир Васильевич, что-нибудь посоветуете?

С уважением Ибрагим Салахов.

*30 ноября 1987 г.*

*Марал Скакбаевка*
*1987, 12 февраль*

Директору издательства «Жазуши» тов. Скакбаеву[1] М.С. письмо-заявление.

Ассаломагалейкум жолдос Марал Скакбаевич!

Я 14 лет работал над историческим, документалным романом о революционных событиях в Сары-Арке.

В 1986 году Таткнигоиздат (Казань) выпустило этот роман «Имәннәр тамыр җәйгәндә» («Когда дубы углубляют корни») (отдельной книгой, тиражом 10000 экз., который разошелся за один месяц, даже заказ Кокчетавского книготорга не приняло ввиду распродажи книги).

Еще в 1984 г. Союз писателей Казахстана (где я состою на учете уже 20 лет рассмотрел вопрос о переводе моего романа на казахский и русский языки.

– Не беспокойтесь, ага, сказал тогда Олжас, – постараемся к вашему 75-летию издать Ваш роман и на казахском, и на русском языках. (я тогда им представил роман в машинописи, по тексту принятому Татиздатом.)

А скоро руководство издательства сменилось. Мне пришлось опять выехать а Алма-Ату, обратиться к новому директору. Саин Моратбаков сказал:

– Ага, немножко подождем, пусть Ваш роман выйдет на языке оригинала, тогда немедленно организуем и перевод, и издание.

Роман вышел в Казани в феврале 1986 г. Я его сразу представил в издательство. Приняли. Назначили переводчиков на казахский язык Сексенбаеву Адию, на русский язык Хамидуллина Асхата (бывший гл. редактор издательства «Казахстан»).

Я успокоился, но, оказывается, преждевременно. Меня просто обманывали – роман не включили в план издания издательства,

---

[1] Марал Скакбаев (1938) – казак язучысы

хотя и перевод на казахский язык почти готов, а на русский, даже с переводчиком разговора не имели.

Я инвалид (без ноги) и болею, поэтому не могу поехать в Алма-Ату к вам на прием. Вся надежда – это письмо и Вы.

Марал Скакбаевич, очень прошу Вас, окажите мне помощь – постарайтесь включить в план издательства на 1986 г. и мой роман – на казахском языке.

Примите во внимание и то, что я в СП Казахстана один, единственный, доморощенный татарский писатель, пишущий только на казахскую тему.

Прошу, очень прошу Вашей помощи.

Ихтирам белән Ибрагим Салахов.

*12.02.1987*

*Б.Н. Поповка*
*1988, 2 август*

Добрый день уважаемый Б.Н. Попов[1]!

(извините, что не могу полностью произнести Вашего имени и отчества).

Примите мой искренний салям. Желаю Вам и всем «кавалеристам пера» вашего журнала бодрости, смелости.

Письмо Ваше получил. Благодарю за внимание. По-моему, идея опубликовать в Вашем сугубо полит. теоретическом журнале лит. отрывки хорошая новость. Желаю успехи.

Жаль, что Вы сами не сумеете, наверное, прочесть эти (мои) воспоминания в оригинале. Тогда доверимся Вашим помощникам. Я бы просил Фаяза и Розе, чтобы они, хотя бы бегло, ознакомили вас содержанием каждой главы первой публикации № 4 «К. утлары». Мне сейчас очень трудно что-то урвать с целого. Все же для Ваших читателей, думаю больше подойдет главы, начиная с II – до X–XII.

Примечание. Алкин Рияз вначале был секретарем Бауманского РК., потом горкоме. Его дочь Резида живет в Казане (Сонникова Резида Риязовна).

---

[1] Попов Б.Н. – «Коммунист Татарии» журналының фән һәм мәдәният бүлеге редакторы.

При необходимости можете с ней связаться. Еще в журнале допущено ошибка пред. Совнаркома Абрамов не Каюм, а Кыям.

Вот мои предложения. Еще раз благодарю Вас за письмо, внимание и инициативу. С уважением Салахов.

*2.08.1988*

*Гаиләсенә*
*1990, 17 гыйнвар*

Исәнмесез кадерлеләрем!

Барыгызга да сагынып сәлам.

Үзем һаман Балтачта. Күп кенә авылларда очрашуларда булдым. Рожкида – Хәятләрдә дә булдым. Сәлам әйттеләр.

Здесь меня приглашают во все колхозы-аулы. Вот сегодня в 13. поеду в аул Сосна. Завтра в順Шеншинер – родина моей матери. Был на родине отца – деревне Норинер. Большой дворец культуры был переполнен народом, которые пришли встретиться со мной.

Вчера звонили из Казани – Союза писателей. – Приезжай скорее, ждут в Набережных Челнах (быв. г. Брежнев) и в Казанских вузах. Поэтому, видимо, еще дней десять задержусь.

Читекләргә заказ бирдем, тегәрләр. Почта белән җибәрермен.

Инде барыгызны сагындым. Арыдым. Кайтасы килә. Әхәткә, Гүзәлгә күп сәлам.

Сагынып, этиегез

*17.01.1990*

*Рафаэль Баһаутдиновка*
*1990, 4 март*
с. Красный Яр

Хәерле көн хөрмәтле Рафаэль энем!

Вам, Вашей семье искренний салям. Желаю всем вам доброго здоровья, благополучия, творческих успехов, вдохновения.

Письмо Ваше получил. Очень обрадовался, что не обрываете далекую нить.

Такой перевод романа, по-тихоньку, печатают на машинке. К Вашему приезду из Будапешта, видимо, будет готово. Видимо, я вышлю второй экз. и в одном экземпляре, для ознакомления. После

прочтения (если одобрят) можно уже у вас тиражировать. В прошлой весной у нас в Казахстане (и Кокчетаве) была украинская делегация, среди них поэт Олейник. К сожалению, я забыл его имени-отчества. Подарил ему свою «Колыму», где я пишу и об украинском поэте Полотай Николае, с которым находились в месте в Татистлочь. Слышал, что в Днепропетровской газете вышла статья обо мне. Не он ли написал эту статью? Может позвонишь в союз писателей и узнаешь об Олейнике кое-что (был ли в Кокчетаве).

До своего отъезда напиши мне ответ. Да, Вы переписываетесь ли с братом и сестрой? Знают ли они, что об их отце есть книга (мои воспоминания) скоро выйдет на русском, вышлите им.

Я здесь по горло занять общественной работой. Добился возвращения мечети, которую отобрали еще в 1938 г. Сейчас, в городе, организую областной центр татарской культуры.

Готовимся к областной конференции, учредительской.

Хотя и без ног, но бегаю...

Желаю доброго пути. Хәерле юл и успехов. Ихтирам белән Салахов.

*4.03.1990 г.*

Мөхтәрәм мөхәррир әфәнде!

Газетагыз битендә минем түбәндәге берничә юл рәхмәт сүзләремә урын тапсагыз иде, дип үтенәм.

Казан дәүләт Педагогия институтының тел-әдәбият факультеты укытучылары студентлары үз инициативасы белән мине Татарстанның Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә кандидат итеп тәкъдим иттеләр. СССР Фәннәр академиясе Казан фәнни үзәгенең Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты галимнәре бу тәкъдимне яклап чыктылар. Арча, Балтач, Кукмара һәм башка районнардагы Татарстанның читтә яшәүче әдәбият сөючеләре теләктәшлек хатлары, телеграммалар оештырдылар. Бик күп каләмдәшләр газета, журналларда, радио, телевидениедә чыгышлар ясап, минем кандидатураны куәтләделәр.

Үземнең аңлавымча, минем кандидатураны тәкъдим иткән, куәтләгән коллективлар, аерым шәхесләр, нигездә, минем белән бер чорда, нахак яла белән кулга алынып та, ул фаҗигале юлдан кире әйләнеп кайта алмыйча һәлак булган олы затларыбызны истә

тоталар һәм бу мәртәбәле бүләкне алар рухына дан рәвешендә яклалдылар, дип исәплим.

Бүләк билгеләнгәннән соң, минем адреска бик күп котлау хатлары, телеграммалар килә тора.

Газиз милләттәшләрем, барыгызга да ихтирамыгыз вә иждиһатыгыз өчен ихлас күңелдән рәхмәт. Бу якты көннәргә килеп җитә алмыйча, төрмәләрдә, лагерьларда газапланып дөньядан киткән гали затлардан, татар милләте мәдәниятенең алтын терәкләреннән мең рәхмәт сезгә, кан-кардәшләр.

Тирән ихтирам белән, Ибраһим Салахов.

*май, 1990 ел (газетасы мәгълүм булмады)*

*ТР Мәгариф һәм фән министрлыгына*
*1990, 8 октябрь*

В министерство просвещения Татарстана.

Исәнмесез хөрмәтле министр әфәнде!

Пятнадцатитысячное татарское население Кокчетавской области с радостью приняли известие о провозглашении Татарстана суверенным государством. Афарин!

Мы, проживаюшие за пределами Республики татары, неотделимая часть нации. После Октябрьской революции, в Кокчетавском уезде были открыты татарские школы, клубы, библиотеки. В городе была создана труппа татарских артистов, которые ставили спектакли, вечера, концерты на родном языке.

К сожалению, к сороковым годам, все эти очаги татарской национальной культуры были закрыты. Вследствие этого – большая часть татарской молодежи, сейчас не владеет родным языком, не знают свою литературу, историю, музыку.

Желая как-то преодолеть это трагическое положение, в начале этого года, мы в Кокчетаве организовали областной татарский культурный центр. За этот период мы юридически оформились: есть указ, устав, программа, в госбанке открыт р/счет. Появились спонсоры. Организовали: вечер-встречу татарской молодежи города с татарской музыкой, концертом, в селе Имантау большой-областной сабантуй, открыли татарский этнографический музей, содействовали возвращению-передачи мечети города своего хозяевам-

мусульманам, составили проект-смету на ограждение старого заброшенного мусульманского кладбища. Уже договорились с редакцией Кокчетавской областной казахской газетой «Кокшетау» о выпуске как приложение этой газеты вестника на татарском языке, вначале ежемесячно, а в перспективе- самостоятельную газету. Проводили компанию по подписке на татарские периодические издания. Откроем библиотеку татарских книг.

А в данный пероид наша главная задача – учить татарских детей и их родителей родному языку. Этот вопрос – открытие спец. классов в школах – согласован обкомом и облисполкомом. Однако начать учебу невозможно. Нет учебников, учебных пособий, программ. В этом году мы уже дважды посылали своего представителя в Казань, в республиканский методический центр. Однако от них никакой помощи.

Уважаемый товарищ министр!

Кокчетавский областной татарский культурный центр обращается к Вам с просьбой оказать нам содействие в открытии школ, курсов по изучению татарского языка. Средства у нас есть. Мы в состоянии прибрести все необходимое... Можем еще раз командировать своего представителя к Вам, только окажите конкретную помощь. Надеемся.

Ихтирам белән: президент Кокчетавского областного культурного центра, писатель, лауреат Гос. премии Татарстана имени Габдуллы Тукая.

Ибрагим Салахов

*8.10.1990*

*Зәкия Садыйковага*

Хәерле көн хөрмәтле Зәкия ханым[1]!

Сезгә, гаиләгезгә һәм дә театр хадимнәренә ихлас күңелдән сәлам. Барыгызга да сәламәтлек, дәрт, дәрман, илһам һәм сабырлык теләп калам бу болганчык заманда.

Вәли әфәнде мине сезнең узган хатыгыз белән таныштырды. Минем әсәр турында җылы фикерләрегез өчен рәхмәт.

Билгеле, бу әсәр сәхнәгә чыкса, бик әйбәт булыр иде – татар халкы үзенең фаҗигале язмышы белән танышыр иде.

[1] Зәкия Садыйкова – Татарстан радиокомитеты хезмәткәре, шагыйрь Муса Җәлилнең никахлы хатыны.

Мин инде, моннан берничә ел элек әсәрне сәхнәләштерүгә ташламалар-наброскалар ясаган идем. Әмма мин хәзерге сәхнә кануннарын белмим, гәрчә үземнең әдәбиятка килгәндә беренече әсәрем «Ярату» исемле пьеса булып (1938 ел), Академия театрында куелып һәм аерым китап булып чыкса да. Бу эш төгәлләнгән әсәр түгел. Сез аны («К.х.») нигезендә үзегез өсти һәм кыскарта аласыз, әгәр теләсәгез. Якуповның кульъязмасын укып чыктым, ярый, билгеле, монда да күп эшлисе бар, алынсагыз. Һәрхәлдә – тәвәккәл таш яра. Яһүдләр Гинзбургны әллә кайчан кинога да, сәхнәгә дә менгерделәр. Билгеле, аларның мөмкинлеге башка. Алай да, укып чыккач, миңа кульъязманы кире үземә җибәрүегезне үтенәм, чөнки соңгы нөсхә. Ихтирам белән Салахов.

*(вакыты юк)*

*Айдар Хәлимгә*

Әссәламегаләйкүм мөхтәрәм Айдар әфәнде[1]!

Хәерле көн.

Сезгә, гаиләгезгә, «Аргамак»ның йөгерек толпарларына ихлас күңелдән сәлам. Дәрт, дәрман (хәзер инде зур кирмән, акчасы булса), илһам һәм сабыр кыюлык теләп калам.

Сезнең 18 гыйнварда юллаган хат һәм аргамаклар, бик шәп чабып, Кызыл Ярга бүген генә килеп җиттеләр. Элек бу ара 3–6 көндә үтелә иде. Почта чыгымы артканнан–арта, йөреше...

Әле күптән түгел генә Т.М. үзәгенең еллык (3 ел!) исәп-хисап, сайлау җыелышын уздырдык. Үч иткәндәй, нәкъ шул көнне күзачкысыз буран тузгыды. Алай да халык байтак булды. Җыелышта Төркия мөгаллимнәре катнашты һәм нотык белән чыктылар. Аннан үзебезнең җыр-бию ансамбле зур концерт белән халыкны сөендерде. Бүген «Азатлык» радиосы тапшыруында сезнең М-Мәҗлес утырышында чыгыш ясавыгызны ишеттек. Куандым. Гомумән, татар дөньясы хәлләрен мин (мин генәме) бары «Азатлык» аша гына ишетеп торабыз. Менә инде 3 ел көн саен иртәнге тапшыруларын өзлексез тыңлыйм, сөенеп бетә алмыйм фидаи хадимнәренә. Ә менә кичәге көннән күңелгә курку төште («Известия»дәге хәбәр). Әгәр аны япсалар, без татарлар нишләрбез. «Азатлык» безнең бердәнбер информация чыганагыбыз бит. Бәйләнеш, хәбәрдарлык өзелә.

---

[1] Айдар Хәлим (1942) – язучы, публицист, җәмәгать эшлеклесе.

Бу инде фаҗига.

«Өч аяклы ат» һаман аксый бит әле... Мин үткән хатымда повестьның ахырын укыдым, башын (№ 6) һаман тапмыйм, кемдер алды, китерми бит, дигән идем. Син тагын ахырын «КУ» № 7 санын җибәргәнсең. Менә бит, бер уңмаса... Ат-елкы темасы мине бик кызыксындыра. Ул теманы үзем дә яздым, казакълардан да «Колагир» поэмасын тәрҗемә иткән идем...

Өфедән Кадерле миңа төрле өлкәдә чыга торган газетларын җибәреп тора, рәхмәт яугыры. Менә ул Әстерханда чыга торган «Идел»нең берничә санын җибәргән иде. Шуларның берсендә (1992, № 29 санында) Р.Хасьянов дигән кешенең «С мыслями о «толпе» или почему Фаузия Байрамова ходит по миру, заботясь о нации» исемендә мәкаләсе басылган. Ул миңа ошамады. Аңа җавап хаты яздым. Әмма аны элек сиңа җибәрергә булдым. Русча бәхәсле әйбер. Андый-мондый төгәлсезлекләр булмасын. Син аны укып, рәткә китереп кара да, ошаса «Идел»гә юлла. 414047. Г. Астрахань, 47. ул. Тольятти 10.

Син безгә җәен килеп чыксаң, шәп булыр иде. Төп мәсьәлә – минем архив турында сөйләшү. Ул зур. Аны, билгеле, алып китә алмыйсың. Сүз аның алдагы язмышы турында (басылмаган әсәрләр бик күп, хатлар 5-6 мең). Монда татар мәдәнияте үзәгендә татар тарихыннан лекция сөйләргә кирәк булыр. Магнитофон, язылмаган тасмалар, фотоаппарат һәм татар халык җырлары язылган тасмалар алып килсәң яхшы булыр. Вакытын килешербез, иншалла.

Ихтирам белән Салахов.

*(Вакыты күрсәтелмәгән)*

*Петр Шкрыльгә*
*1991, 28 гыйнвар*

Уважаемый Петр Дмитриевич[1]!

Я с большим вниманием прочитал Вашу статью – «Документы свидетельствуют» – напечатанную в нашей областной газете «Степной Маяк», хотя содержание ее, как Вы сами знаете мне было известно уже давно. Кажется, года 4 тому назад Вы об этом уже писали. Я тогда Вам ответил, что пишу о том, чего знаю хорошо, но не по бумажкам.

[1] Петр Дмитриевич Шкрыль (?–1994) – журналист, туган якны өйрәнүче.

Я – коренной Кокчетавец. Живу на этой благодатной земле уже 80 лет. Поэтому у меня нет никакой необходимости написать куда-то письма, просить выслать выписки или копии документов по истории Кокчетава, в особенности периода Революции и Гражданской войны.

Однако в этой Вашей статье, на этот раз почему-то выпал Ваш основной аргумент, из-за которого Вы взялись за Сабира Шарипова. Ведь Вы в своих ранних письмах на мое имя писали и говорили в своих публичных выступлениях, что Салахов будто утверждает, что Октябрьскую революцию готовили и установили Советскую власть в Кокчетавском уезде одни татары. Упаси бог, это же абсурд! Я писал, что в подготовке Октябрьской революции, в установлении Советской власти в Кокчетавском уезде вместе с русскими, казахами принимали активное участие и татары уезда. Они еще трижды брали в руки оружие и вместе с другими народами уезда боролись за восстановление разгромленную чехославаками, колчаковцами, восставшими белоказаками Советскую власть в Сары-Арке. Где написано или сказано об этом? Нигде! Почему?

Об этом с горечью не раз говорила и Елена Владимировна Куйбышева, младшая сестра Валерьяна, с которой я дружил долгие годы и консультировался когда писал роман о революционных событиях в Кокчетавском уезде под названием «Когда дубы углубляли корни». К сожалению, этот роман не переведен на русский язык и по этому, Вы Павел Дмитриевич, не могли прочесть его. А сами беретесь судить произведение по газетным отрывкам. По моему, это неразумно. Ведь в этом романе действует не вымышленные литературные герои, а живые солдаты революции: Валерьян Владимирович Куйбышев, Адельбек Майкотов, Сабир Шарипов, Карим Сутюшев, Усман Абдрашитов, Роман Войтенко, Кунгурцев Николай и многие другие: русские, казахи, люди разных национальностей.

А Сабир ага Шарипов среди них – глыба. Беспризорник, из Вятской губернии в поисках куска хлеба вначале нашего века появился в казахских степях и только благодаря своим огромным стараниям, стремлениям впоследствии стал – революционером («дважды осужденный к расстрелу колчаковцами и ревтрибуналом Туркестана»), писателем, ученым, дипломатом, государственным деятелем и политиком. И….. и погиб, как враг народа в 1940-м году в сталинских лагерях.

Я хорошо знал Сабир ага. Так как в Кокчетаве мы жили в соседстве с ними. Я дружил с его сыновьями и дочерью Фаридой.

Теперь о главном в Вашей статье – был ли Сабир Шарипов в составе Омской делегации Всероссийского съезда Советов и был ли на приеме у Владимира Ильича Ленина?

Соратники Сабир ага по революционной деятельности в Кокчетавском уезде: Усман Абдрашитов (Имантав), Ади Муфхутдинов и Хусаин Кулаков (Кокчетав) утверждали, что Сабир ага действительно в составе Омской делегации поехал в Москву и был на приеме у Владимира Ильича. Об участии отца на Съезде Советов писала и дочь Сабир ага Фарида Шарипова, которая жила в Москве, с которой я переписывался. К сожалению, несколько лет назад она скоропостижно скончалась от сердечного приступа.

Подумайте, уважаемый Петр Дмитриевич имел ли я права не верить им, соратникам и дочери. Вы, Петр Дмитриевич, пишите, что в биографической хронике Ленина прослеживается не только по годам и месяцам, но и по дням и часам. Верю. Верю и тому, что даже в биографии вождя сейчас обнаруживается «белые пятна», а как Вы смотрите на это? Но однако, это нас не касается.

Ваша покойная супруга Сальма Андреевна долгие годы заведовала партактивом обкома КПК Кокчетава, поэтому Вы имели свободный доступ к архивным документам. Поэтому Вы обнаружили очень интересные документы по истории нашего края. Это очень приятно. Мне и радостно, что вы будущий некоренным кокчетавцем интересуетесь прошлым нашего края и не безуспешно. Дай бог Вам здоровья, продолжайте свои поиски, успеха Вам.

С уважением И. Салахов.

*28.1.1991 г.*

*«Азатлык» радиосына*
*1991, 19 сентябрь*

Ассаламагалейкум дорогие мои сородичи, сотрудники радиостанции «Азатлык»

Ильчан и Фарида ханум!

Хайрутдин Садыйк, Ирек Казанлы, Фатыйх Исхаки, Эхтам Ибрагим, Нури Булат, Фарит Иделле әфәнделәр!

Примите от 15-ти тысячной татарской общественности Кокчетавской области Казахстана искренний салям.

Желаем Вам всем здоровья, благополучия, радости и успехов в вашей благородной деятельности.

Мы каждое утро слушаем вашу передачу. Узнаем голоса каждого из вас и радуемся, что вы находясь на чужбине так хорошо владеете татарским языком. Эферин! Это, безусловно, заслуга ваших родителей, честь и слава им, что они не дали засохнуть татарской нации. Рахмат.

Я – писатель, президент татарского культурного Центра Кокчетавской области. Начиная с января месяца этого года, я написал вам три письма арабскими шрифтами, описав деятельность нашего центра. К сожалению, видимо они так и не дошли до вас. Старался дозвониться до вас, но бесполезно. Каждый раз на телеграфе находят причину и отказываются принять заказ. Я давал заказы: код 89, Мюнхень, радиостанция «Азатлык», а на телеграфе от меня требуют: надо 5-тизначный код, я думаю, что это форма отказа принять заказ. В конце концов я сегодня решил написать вам это письмо на русском языке, чтобы не подозревали, что я передаю шпионские сведения в своих письмах. Если это мое письмо дойдет до вас, сообщите мне в одном из своих передач.

30 августа этого года, мне исполнилось 80 лет, по этому случаю проводится торжественное мероприятие, к вам посылаю 1 экземпляр приглашения на память. Желаем вам, вашему коллективу благополучия и радости. Мы жаждуем вашего голоса.

Ихтирам белен Ибрагим Салахов.

*19 сентября 1991 года*

*Әсма Үтәкаевага*
*1991, 19 ноябрь*
Кызыл Яр авылы.

Исәнмесез, кадерле яшьлек дустым Әсма[1]!

Сиңа, Рәшидәгә, башка кызларга ихлас күңелдән сагынып сәлам. Сәламәтлек, дәрт, дәрман, тыныч, тату тормыш теләп калам.

Алдым-алдым, җаным, хатыңны да, фотоңны да – студент елларыма кайттым. Әй, син, без дә яшь идек:

Бар иде яшь чаклар
Кесә тулы борчаклар.
Ә хәзер... Көчләр юк.

---

[1] Әсма Үтәкаева – И. Салахов белән Казан педагогия институтында бергә укыган.

Алай да Әсма, сиңа мең рәхмәт искә алып язуыңа. Әле башкалар да бардыр, исәннәрдер, тик тавыш бирмиләрдер.

Ә менә миңа да 80 сукты... Һич ышанмыйм. Алай да Казаннан, Уфадан, Алма-Атадан, Чиләбе, Төмән, Семипалат һәм башка җирләрдән 50 дән артык кунаклар килде. Мөхәммәд Мәһдиев, Аяз Гыйләҗев, Шаһинур Мостафин һ.б. язучылар, артистлар, композиторлар.

Юбилей Күкчәтау, Кызыл Яр, Имәнтауда узды: чыгышлар, концертлар, банкетлар белән. Өлкә, шәһәр, район советлары махсус комиссия оештырып әзерләнделәр. Бүләкләр дә бик күп булды. Гомумән, юбилей бик әйбәт узды. Кунаклар бик риза булып, рәхмәт әйтеп киттеләр. Мине тагын декабрь ахырында Казанга чакыралар.

Әлегә менә шул шау-шудан арынып бетә алмыйбыз. Син хатыңны бик матур язгансың. Барыгызга исәнлек, сәламәтлек, тыныч, тату тормыш теләп калам.

Хат һәм фото өчен мең рәхмәт.

Ихтирам белән Ибраһим.

*19.11.1991*

*Роза Туфитуловага*
*1992, 19 август*

Исәнмесез, мөхтәрәмә Роза ханым[1]!

Хәерле көн!

Сезгә, гаиләгезгә, «Сөембикә»нең гүзәл туташларына ихлас күңелдән сәлам. Барчагызга да сәламәтлек, дәрт, дәрман, илһам һәм дә сабырлык (кайчанга кадәрледер) теләп калам.

Менә, язылганнан 1,5 ел соңлап бер очерк җибәрәм. Мин аны 1991 ел башында ук язып, Мәскәүгә, Рәшидәнең үзенә юллаган идем:

– Укы, хаталары булса төзәт, өстә, тулмаган җирләрен тутырып, фикереңне язып кире җибәр. Мин яңадан язып «Сөембикә»гә юллармын. Син – галим. Сүз фән дөньясы турында бара. Монда бер төгәлсезрәк сүз дә авторга һәм редакциягә оят китерергә мөмкин. Шуның өчен бу язманы син тикшермичә, редакциягә җибәрә алмыйм. Тизләт, 1992 ел башында журналда басылып чыгарлык булсын.

Тизләтте.... ниһаять бер ел ярым дигәндә кульязманы һәм хатны алдым. Күргәнегезчә, Рәшидә язмага әллә ни өстәмәгән һәм хаталар

---

[1] Роза Туфитулова (1945) – журналист, җәмәгать эшлеклесе, 1988–2000 елларда «Сөембикә» журналының баш мөхәррире.

да, нигездә, тапмаган. Бары тик хәзер кайда, нинди эш башкаруын язган. Мин аларны тәрҗемә итеп өстәп тормыйча, хатның үзен сезгә җибәрергә булдым. Бердән, минем гыйльми терминнарны бутавым бар. Аннан ул башкарган күп эшләрнең барын да санап чыгу кирәк булырмы? Гәрчә, болар бар да Рәшидәнең шәхси портретын тулыландыра бит.

Ә иң яхшысы мин Рәшидәнең Мәскәү адресын һәм телефон номерын бирәм. Сез үзегез аның белән сөйләшегез. Барысы да ачыкланыр. Мин аның бер фоторәсемен җибәрәм – алар өендә, өстәл янында икебез төшкәнен. Күзаллар өчен генә...

Ә Рәшидә турында «Сөембикә» һичшиксез үз сүзен әйтеп халыкка җиткерергә тиеш, дип уйлыйм.

Ихтирам белән Салахов.

*19 .08.1992*

*«Вечерняя Казань» газетасына*
*1992, 29 декабрь*
с. Красный Яр

Здравствуйте дорогие труженики «Вечерней Казани».

Примите мой искренний салям и поздравления с 1993 годом. Да будет он годом покоя и благополучия. Аминь. Теперь – просьба. Не сможете ли найти возможности напечатать на странице вашей газеты несколько строк слов благодарности двум моим неизвестным адресантам.

Суть просьбы следующее: недавно я получил несовсем обычное письмо. Необычность его начинается еще с адреса на конверте, вот он: (переписываю дословно то, что написано на этом конверте). «с. Красный Яр, ул. Классика казахской литературы Абая. Пис. Салахову Ибрагиму», ниже пометка – «Очень прошу передать» (почти как в рассказе А.П. Чехова «Ванька» – «в деревню к бабушке» не правда ли? Не указана не область, не район, не индекс почтового отделения, нет дома адресанта. А ведь в нашем бывшем Союзе несчесть сел под названием Красный Яр. Вот и поломай голову работника почтового отделения, куда попало это письмо с таким странным адресом, в какой же Красный Яр направить его, чтобы оно попало точно к адресанту. Правда, можно было этот конверт с письмом выбросить в мусорный ящик из-за неясности

адреса. А нет, не бросили, добросовестно искали адресанта и письмо дошло до него. Я получил его. Как здесь не поблагодарить того неизвестного добросовестного сотрудника почтового отделения Казани № 32. Большой искренний рахмат дорогой работник сортировки почтового отделения за твою честность.

Дальше о самом письме. Оно больше. Я приведу здесь только отдельные отрывки.

«Здравствуйте уважаемый писатель Ибрагим Салахов. Сама я из Казани, мне тоже 80 лет. Купила вашу книгу „Черная Колыма". Прочитала ее всю. Так же узнала что делалось на „Черном озере", сколько в Казани погибло писателей и людей погибших ни за что на Колыме. Это просто ужас, страшно поверить, что это у нас, в нашей стране... Читала и плакала... Хорошо что вы написали эту книгу. Пусть люди знают о кошмарах, жестокостях и издевательствах над человеком. Я эту книгу берегу и своим сказала прочитать и беречь эту книгу... Еще раз вам спасибо за эту тяжелую книгу. Поздравляю с Новым годом. Живите сто лет. Я часто заглядываю в эту книгу. До свидания».

В этот конверт была еще вложена цветная поздравительная открытка с новым годом и надпись «Казань. Зовут меня Мария». Значить автором этого письма была Мария. Жаль, что она не указала свою фамилию и свой обратный адрес. Вот почему я был вынужден обратиться за услугой газеты «Вечерняя Казань». Надеюсь, что дорогая Мария, Вы прочтете мое это письмо и примите его как мою искреннюю благодарность за вашу отзывчивость. Большой рахмат.

С уважением Ибрагим Салахов.

*29.12.1992*

*«Азатлык» радиосына*
*1992, 8 март*

Ассаламагалейкум дорогой «Азатлык».

Добрый день многоуважаемые, ханумнар: Рашида Хамит, Галия Шарафи; әфәнделәр: Хайрутдин Садыйк, Ирек Казанлы, Фатих Исхаки, Ахтам Ибрагим и др.

Примите наш искренний салям и благодарность, рахмет за прекрасные передачи. Дай бог вам всем здоровья, благополучия и успехов в столь важном, благородном деле для Возрождения татарской нации. Афарин.

Это мое пятое письмо. В 1992 году я на ваше имя написал 4 письма арабским алфавитом, на латыне, на кириллице – на татарском, русском языках. Почему-то они да вас не дошли. Очень жаль. Пытался я и позвонить Вам по телефону, но, по разным причинам не дали возможность связаться с Вами.

Я – Ибрагим Низаметдин улы Салахов, родился и живу в селе Красный Яр. В Кокчетавской области проживает около 15000 татар. До революции их было гораздо больше. В Кокчетаве и в селах работали татарские светские школы, клубы, библиотеки, мечети. К сороковым годам в Кокчетаве организовали областной татарский культурный центр. С целью возрождения культуры татар города и области, у нас сейчас прекрасный ансамбль песни и танца, который дает концерты по всей области и за перделах. В прошлом году в с. Имантау, после революции впервые, провели Сабантуй. Участвовало больше 5000 человек. Прошел исключительно красочно, радостно, призами, подарками. Открыли курсы по изучению татарского языка, алфавита. Проводим литературные вечера.

Каждое утро всей семьей (не только мы) слушаем вашу передачу, различаем каждого по голосу. И приятно удивлены вашей прекрасной дикции и знанию татарского языка. Видимо это заслуга ваших родителей. Великий рахмат и благодарность им от татарского народа.

Вынужден писать на русском языке ввиду того, что предыдущие письма не доходили до вас. Если это письмо дойдет до вас, сообщите об этом на утренних передачах, чтобы в дальнейшем я мог установить связь с вами.

Ихтирам белән Ибрагим Салахов – президент Кокчетавского областного татарского центра. Писатель. Лауреат Государственной премии Татарстана имени Габдуллы Тукая, заслуженный деятель культуры Республики Татарстан, почетный гражданин города Кокчетава.

*8 марта 1992 года. с. Красный Яр*

*Казахстан, с. Красный Яр.*

Ассаламагалейкум мөхтәрәм Шамсинур әфәнде!

Искренний салям Вам, Вашей семье и всем нашим соплеменникам, так далеко разбросанным судьбой от родных очагов.

Да благославит вас аллах здоровьем и благополучием. Амин. Письмо Ваше получили и очень обрадовались. Дай бог Вам и Вашим детям долгих лет жизни и радости. Иншалла.

Это у меня пробное письмо, дойдет оно до Вас или нет. Поэтому буду кратким. Так же не знаю как Вам легче читать, понять по русски или по татарски, арабским или русским шрифтами. Латинский алфавит у нас был немного иной чем турецкий, поэтому запутаемся. Я сейчас напишу письмо еще арабскими буквами. Если Вы прочтете, в дальнейшем буду писать только так, ибо я все свои произведения пишу на арабском алфавите. 4 года учился в медресе в детстве. Поэтому Вы сообщите мне каким алфавитом Вам легче читать. В 1991 году мне исполнилось 80 лет. Этот юбилей отметила вся Республика. В данное время здоровье, слава аллаху хорошее. Низкий поклон Всевышнему. Очень прошу, не прерывайте со мной переписку. Пишите. Пишите о себе, семье, о наших сородичах.

Можно ли Вам – в Америку посылать мои книги?

Ихтирам белән Ибрагим сын Низаметдина Салахов.

*1.03.1992*

*Туганнарына*
*1992, 16 март*
с. Красный Яр

Исәнмесез, хөрмәтле туганнар: Шәрифә кодагый, Рәшидә кодача, Рафаэль, Исхак кодалар, кодачалар!

Хәерле көн.

Сагынычлы сәлам!

Поздравляем всех вас началом священного месяца рамазан-ураза. Желаем вам здоровья, благополучия. Я в недоумении. В чем дело, Рашида кодача? Ведь, еще в прошлом году, посылая Вам пакет очерка о Вас, просил Вас срочно прочесть, дополнить последними данными о своей научной деятельности и вернуть мне, дабы успеть направить его в редакцию «Сөембике», чтобы они могли включать в план 1992 года. Этого, к сожалению, не случилось. В прошлом году, когда я говорил с Вами по телефону, я опять просил ускорить это. Вы обещали положительно. Вот, опять проходит 3 месяца – молчание. Ведь, этот очерк не реклама (в нем Вы не нуждаетесь), а престиж татарской нации. Пока я приступал к этому очерку, прошло 5 лет. И приступил только после ухода из жизни основного Вашего оппонента. Не знаю, вы тоже ждете моего ухода…

Татарская нация сейчас, как и вы сами видите, плещется как рыба на льду. Надо же нам сказать миру своих талантливых ученых. Ведь нас сейчас не признают даже за нацию.

Вчера, 15 марта РТР, показал московских татар – выступления: Юсупова и одной безбожной татарки:

– Не надо нам суверенитета Татарстана, нам в России хорошо!..

В доказательство оператор показал счастливых татарских детей Москвы, которые играют и поют: «Аерылмагыз». Мы здесь от стыда не знали что делать – в землю провалиться. Боже мой, когда же мы станем людьми? Когда?

Ихтирам белән: Магинур, Ибрагим, Шамиль, Камиль, Гульчира, Ахат, Гузяль.

*16 марта 1992 г.*

*Минтимер Шәрип улы Шәймиевка*
*1992, 15 май*

Ассоламагалейкум мөхтәрәм президентыбыз Минтимер әфәнде[1]!

Хәерле көн!

Вам, вашей семье, всем членам Правительства Татарстана искренний салям. Желаем всем вам крепкого здоровья, здравого мышления, смелости и успехов в вашей многотрудной для нации работе.

Сегодня получил от Вашей канцелярии – официальное уведомление – о присвоении мне почетного звания «Заслуженный работник культуры Татарстана». Бик зур рәхмәт сезгә, Минтимер әфәнде, хөрмәтегез өчен.

Кокчетавский областной татарский культурный центр благодарит Вас за высокую оценку нашего посильного старания за возрождения татарской национальной культуры в Степном краю.

Мы из тех татар, которых «Судьба» разбросала по всему свету. Однако, мы не хотим терять свои благодатные корни далеких предков.

В годы революции в Кокчетавском уезде проживало больше 40 тыс. татар. Были открыты: татарские светские школы, клубы, библиотеки (строили сами), мечети в Кокчетаве, Имантаве, Жильтаве. В городе работала постоянная, профессиональная, татарская театральная труппа.

---

[1] Минтимер Шәрип улы Шәймиев (1937) – дәүләт һәм сәясәт эшлеклесе, Татарстан Республикасының беренче Президенты

Я сам, вместе с Нури Арслановым (известный поэт, лауреат Государственной премии Татарстана имени Г. Тукая) в 1927 г., окончив Кокчетавскую татарскую семилетнюю школу, поехали в Казань для продолжения учебы. Эта – татарская школа воспитатель многих деятелей науки, культуры, искусства и крупных хозяйственных, государственных деятелей страны. К сороковым годам все эти очаги татарской культуры были разгромлены. И результат этого геноцида на лицо – татарская молодежь края уже не владеет родным языкам. И поэтому не знает свою историю, литературу, искусство. А, самое страшное зло это «интернациональные браки» вследствии чего рождаются дети без племени и рода – «Советские» – не татары, не русские – манкурты. И вот, желая как-то отступиться от этой страшной пропасти, в Кокчетаве организовали областной татарский культурный центр, который сейчас объединяет 15000 татар, проживающих в нашей области.

У нас, вот уже второй год работает, постоянно действующий 3-х месячные курсы по изучению татарского языка и алфавита. Договорились с администрацией области, в будущем учебном году, в школах города, где компактно учатся дети татар открывать (для начала) факультативные классы по изучению татарского языка. Мы организовали хороший ансамбль песни и танца из талантливой татарской молодежи города. Они тоже, второй год, своими выступлениями радуют не только горожан, но и выезжают в районы и в город Петропавловск. Выступают на страницах областных газет, по радио и телевидению на родном языке.

Особенно тревожные (стрессовые) дни были у нас перед референдумом в Татарстане. Каждый враждебный стук в Москве в отношении татар Татарстана и Вас, больно отражались в наших сердцах. Слава аллаху, народ Татарстана сказал «да» Суверенитету Республики. Афарин!

Татарстан единственная опора всех татар, где бы они не жили. Однако, еще ему самому надо развязать руки-ноги. Без суверенитета она не в состоянии помочь нам. А Россия все еще, даже после референдума, открыта и скрытно старается припятствовать самостоятельной развитию Республики.

Тимер-корыч булыгыз, Минтимер әфәнде. Мы за вас.

Ихтирам белән Ибрагим Салахов – президент Кокчетавского областного татарского культурного центра, почетный гражданин города Кокчетава.

*15 мая 1992 года. с. Красный Яр*

*Билл Клинтонга*
*1993*

Америка Кушма Штатлары. Вашингтон. Ак йорт.

Әссәламегаләйкум Галиҗәнаб президент Билл Клинтон әфәнде[1]!

Хәерле көн.

Мокаддәс Рамазан шәриф аенда Сезгә һәм барлык Америка халыкларына изге теләкләребез юллап, бәхет, сәгадәт һәм муллык теләп калабыз. Илаһи амин!

Татар халкы дөньяның иң җәберләнгән, кимсетелгән халыкларының берсе. Рус патшасы аның дәүләтен җимерде, җир-суларын басып алды, үтерде, коллыкка алып китте, көчләп чукындырды. Исән калганнар йорт-җирләрен ташлап, күз күрмәгән, колак ишетмәгән якларга качып китәргә мәҗбүр булдылар.

Советлар да безнең халыкның өметен акламады. Алдады да җир йөзендә күренмәгән вәхшилек белән репрессияләр башлап, барлык милли зыялыларыбызны кырды, төрмә, лагерь, сөргеннәргә куып кертеп юк итте. Менә мин үзем дә шул геноцидның могҗиза белән исән калган бердәнбер шаһите (19 ел утырдым). Менә шул бәладән котылу өчен безнең халык төрле якка качарга мәҗбүр булды – тагын чәчелде, тузды, килмешәккә әйләнде.

Менә хәзер, бары тик Казагыстанда гына 400000 гә якын татар яши. Шуларның берсе – мин фәкыйрегез. 30-еллар ахырында монда да, башка төбәкләрдәге кебек татар мәктәпләре, клублар, мәчетләр ябылды. Китаплар яндырылды. Аның өстенә ике тапкыр алфавитыбызның алыштырылуын кушсак, татар халкының ни өчен телен, тарихын, әдәбиятын югалтуының сәбәбе ачыкланыр. Без татар дөньясыннан аерылдык, XX гасырда Робинзон хәлендә калдык.

Ниһаять – яктылык. Ул Төньяк Америкадан! «Азатлык» татарча сөйли башлады һәм без мәрткә киткән җирдән тереледек. «Азатлык» к/с, татарлар өчен, үз халкы турында, үз телендә информация бирә торган бердәнбер информация чыганагы гына түгел, ул үз телен онытырга мәҗбүр ителгән йөз меңләгән татарларга әле үз телендә сөйләшергә дә өйрәтә. Мең рәхмәт Америка конгрессына һәм Америка халкына бу изге эшләрегез өчен! Әмма, кинәт бу арада хәвефле хәбәр йөри башлады – «Азатлык» ябылачак!

---

[1] Билл Клинтон (1946) – Америка Кушма Штатларының 42 нче президенты (1993–2001).

Әгәр, чынында, бу хәбәр тормышка ашса, бу татар халкы өчен тагын зур фаҗига булачак. Галиҗәнаб президент Билл Клинтон әфәнде! Мөхтәрәм конгрессменнар!

Безнең фаҗигадә экономияләнгән, күз яшьле берникадәр миллионнар Америка халкына бәхет-сәгадәт өстәмәс.

Зинһар, бу фаҗигале планыгызны тормышка ашырып, безне «Азатлык» тавышыннан мәхрүм итмәгез, татар халкын тагын караңгылык упкынына ташламагыз. Иншалла!

Ихтирам белән Ибраһим Салахов – язучы, Күкчәтау татар мәдәнияте үзәге президенты, элекке сәяси тоткын. (бу хатны «Азатлык»ның үз хәбәрчесе Р. Вәлиевкә җибәрдем, бүген 3.3.1993 тә).

*В.С. Федоровага*
*1992, 7 июль*
с. Красный Яр.

Здравствуйте, уважаемая Валентина Сергеевна[1]!

Добрый день!

Искренний салям Вам, вашей семье и коллегам по аппарату. Желаю Вам всем здоровья и благополучия.

Ваш подарок – бандероль – диплом, знак и письмо нашего президента Минтимер әфәнде Шаймеева получил. За что ему очень благодарен – зур рәхмәт.

Хотя я тогда и отказался от поездки в Казань, но потом, когда получил от Мухаммета әфәнде Сабирова – премьер-министра телеграмму-приглашение принять участие на Всемирном Конгрессе татар, я решился – приехал в Казань (17–23.04.1992 г.) и остался очень доволен Конгрессом и встречами. Во время приема в Союзе писателей Татарстана я имел честь познакомиться со многими деятелей культуры татарского зарубежья.

Пользуясь этим счастливым случаем, я во время встречи подарил доктору, профессору Нью-Йоркского университета Рифату эфэнде Таби, свой бархатный чапан, сшитый серебряными казахскими орнаментами и национальную Казахскую меховую шапку (подарок казахского правительства к моему 80-летию), а так же

---

[1] Федорова Валентина Сергеевна (1940) – Татарстан Республикасы Президенты Аппаратының дәүләт бүләкләре бүлеге мөдире.

ректору Мармарского университета, доктору Орхан эфэнде Огузу и писателю ученому Надыр эфэнде Давлету свои книги о Колыме.

По приезду в Кокчетав я написал статьи на русском, казахском языках для областных газет, радио, телевидения о нашем конгрессе. Сейчас мы готовимся провести общегородское собрание – центра татарской культуры с отчетом о ходе работы конгресса и о его решениях.

Валентина Сергеевна! Очень прошу вас, передать мою искреннюю благодарность-рахмат Президенту Татарстана М.Ш. Шаймееву и премьер-министру Республики М.Сабирову за награды и за приглашения на столь престижный конгресс. Дай бог им здоровья, смелости и силу в утверждении суверенитета Республики Татарстан.

Да будет мир, покой, суверенитет Республики Татарстан. Аминь. Ихтирам белән Ибрагим Салахов.

*7 июля 1992 г.*

*Минтимер Шәрип улы Шәймиевка*
*1997, 25 июнь*

Президенту Республики Татарстан Шаймиеву Минтимеру Шариповичу.

Хәерле көн! Хөрмәтле президент әфәнде!

Сезгә, гаиләгезгә кайнар сәлам һәм ихтирам!

Я – Салахов Ибрагим Низамович – сейчас единственный татарский писатель, оставшийся в живых после репрессии 30-х годов в Татарстане.

Будучи студентом 3-го курса факультета татарского языка и литературы Казанского педагогического института в 1937 году, я был арестован органами ГПУ за связь с писателем Галимжаном Ибрагимовым (отвез ему в Ялту поздравительное письмо молодых писателей, в связи с его 50-летием). 12 мая 1938 года в Казани выездная сессия Военной Коллегии Верховного Суда СССР по ст. 58-1-7-8-10-17 был приговорен к 10 годам тюремного заключения строгого режима и после отбытия наказания к лишению 5 годам всех гражданских прав. Этот срок я отбыл от звонка до звонка и вышел из заключения инвалидом – без одной ноги, испорченным зрением.

Хотя я родился в городе Кокчетаве (Казахстан), где в ту пору жили мои родители, но мне не разрешили жить в городе и под кон-

воем послали в районный центр с. Красный Яр, где была комендатура НКВД, куда я каждый день должен был ходить на отметку, чтоб не убежал. Реабилитировали меня только в 1956 году. После этого я опять вернулся к литературе. Написал более 20 книг, романов, повестей, рассказов и сборников стихов. За роман «Черная Колыма» в 1990 году я был удостоен Государственной премии Республики Татарстан им. Г. Тукая. Кроме этого мне присвоено почетное звание Заслуженного работника культуры Татарстана, а также присвоено звание Почетного гражданина г. Кокчетава.

В 1990 году в Кокчетаве я организовал областной центр татарской культуры, который очень успешно работает и сегодня. Меня избрали почетным президентом этого центра.

У меня два сына: Шамиль (1949 г.р.) и Камиль (1954 г.р.), оба с высшим образованием. Однако… старшего сына, который работал в бизнесе, постигло несчастье. В результате инсульта мозга его парализовало и у него отнялась речь.

Младший Камиль живет со мной, работает учителем в местной школе. Зарплату не получает в течении нескольких лет.

Я – сейчас полный инвалид – нет одной ноги, после операции левый глаз перестал видеть, перенес два инфаркта. Пенсия у меня 4 тысячи тенге, которую не получаю уже пол года. Книги мои не печатаются, говорят: «Найди себе спонсора». Живя в деревне, где я найду себе спонсора. Обращался за помощью к президенту Назарбаеву. Мое письмо вернулось в областную администрацию, которая с большим трудом выделила мне 3 тысячи тенге (40 долларов) на лекарства. Вот так, не знаю, как быть дальше? Сын Камиль, посоветовал мне обратиться к вам с просьбой помочь нам переехать в Казань на постоянное жительство. Состав нашей семьи на сегодня:

1. Салахов Ибрагим Низамович – 1911 г.р.
2. Салахова Магинур – жена – 1914 г.р.
3. Салахов Камиль – сын – 1954 г.р.
4. Салахова Гульшира – сноха – 1960 г.р.
5. Салахов Ахат – внук – 1981 г.р. ученик 11 кл.
6. Салахова Гузяль – внучка – 1985 г.р., ученица 7 кл.

Уважаемый Минтимер эфенде!

Вы сейчас у меня последняя надежда, помогите нам переехать в Казань и устроиться. Надеюсь, что вы не оставите мою эту просьбу. Ихтирам белән Ибраһим Салахов.

При этом прилагаю:
1. Автобиографию.
2. Список изданных книг.
3. Справка о реабилитации.
4. Хат.

*25 июня 1997г. с. Красный Яр*

*Наилә Гарифуллинага*
*1998, 20 гыйнвар*

Хәерле көн, кадерле сеңлем Наилә[1]!

Сегодня получил Ваше письмо и очень обрадовался, что у нас, оказывается, еще есть молодежь, которая интересуется трагической судьбой нашей многострадальной татарской нации. Слава аллаху, дай бог вам здоровья, упорства в достижении благородной цели. Что от меня зависит, я всегда готов помочь Вам.

Я писал свое хождение по мукам. Там нет никаких художественных вымыслов. Только правда и факты. А, Вы читали эту книгу в русском переводе – «Черная Колыма»? Там кое-что добавлено по татарскому тексту.

Я сейчас, почти слепой. Один глаз после операции совсем перестал видеть, а другой смотрит через туман, поэтому не могу писать много. Кроме этой книги мои воспоминания печатались на страницах газет и журналов. Журнал «Идел» – на русском, татарском языках «Огненная борода».

Журнал «Аргамак» – на русском, татарском языках – август-сентябрь. «Намаз».

Еще у меня хранится «Воспоминание» Яушевой. Я сова, который 15 лет находился на Колыме. Ее дочь Клара Ахметзянова живет в г. Альметьева, ул. Калинина д. 59. Вы можете обратиться к ней. Она может послать Вам воспоминания отца о лагерьной жизни. При необходимости мой № телефона 21-4-39. Жду ответа о получении этого письма. Ихтирам белән Салахов И.Н.

*20 января 1998 г.*

[1] Наилә Гарифуллина – И. Салахов иҗаты белән кызыксынучы, аның иҗатына багышлап диплом эше язучы.

## КҮҢЕЛ ҖЫЛЫСЫН САЛЫП ХАТЫМА...

Исәнмесез, Ибраһим абый!

Яңа ел белән котлап калабыз. (...)

Бик күп борчулар Мәхмүт белән икебезнең башыбыздан үтте, үз гаиләбездә бары да тыныч, татар үзәгенең проблем мәсьәләләре чыгып тора.

Казакъстанда бер генә үзәккә бина бирделәр. Ул да иске, миче юк, җылыту системасын алып киткәннәр. Көннәр салкын, ягучы да, сакчы да юк. Акча да санаулы, ярты елга зарплатага гына җитәрлек.

Бер кооператор белән сөйләшкән идек, беренче этажны арендага биреп күрик дигән идек, ул биргән йортка кызыгып, озак вакыт бездән тартып алырга күп хәйләләр уйлап кына торды. Акчалылар көчле бит, 1-2 ай йокыбыз качты. Йортны кулына төшереп алса, кем гаепле? Мәхмүт сатты, диерләр. Хәзер тынычландык инде. Рәткә керттек. Менә шулай, кай вакытта әйтәм, Мәхмүтне җиңәм, дип каршы чыккан кеше үзе ахмак дип. Җиңәсең дә, саулык борчудан кими бара. Ибраһим абый! Уйлап карагыз әле. Әллә берәр кеше, кем булса да, хәким әфәндегә әйтеп күрегез, безнең облсоветка хат язсыннар. «Галиябану» газетасына отказ бирделәр. «Семей таңы»ның көне начар. Кәгазь кыйммәт, атнасына 3 мәртәбә газета чыга, шимбә газетаның күләме азайды, 8дән 4 биткә калды. «50 мең акча бирсәгез, татарча битне биреп утырабыз», диделәр. Редакциядәгеләр үзләре хат язсыннар, дип акыл бирделәр. «Нигә газетны туктаттыгыз?» дигән сүз кирәк. (...)

Сау булыгыз, *Наилә (Абдулкәримова)*[1]

*29.01.1992*

---

[1] Наилә Абдулкәримова – «Семей таңы» (Казакстан, Семипалат) газетасының кушымтасы булып чыккан «Галиябану» газетасында баш мөхәррир, рәссам; Мәхмүт Абдулкәримов – Казакстанда татар-милли иҗтимагый үзәге рәисе.

Хөрмәтле Ибраһим абый! Сезнең мәкаләне Мәхмүт белән икәүләп укып чыктык. «Бу – дөрес фикер», – диде Мәхмүт. Ләкин Фәүзия Бәйрәмовага сылтарга кирәкми. «Урал буенда Татар Республикасы оештырырга кирәк», ди ул. Минемчә, хәзер үк барып чыга торган нәрсә түгел. Ә көрәшергә кирәк. Белемне, мәдәни байлыкны арттырырга кирәк. Тоташ алганда, телне, культураны үстерергә кирәк, дигән. Дөрес, культура башка халыкта да, татарның үзендә дә югары түгел. Белем аз, сүз күп. Безне һәрбер боерыкны сүзсез үтәргә өйрәттеләр. Эшлимме, юкмы? дип уйлап эшләү, интеллект үстерү булмады. Аң-белем түбәнәя барды.

Семипалат өлкәсенә татар газеталары кичегеп килә. Шуңа күрә без «кич» уянабыз. Ф. Бәйрәмовага таш ыргыту, билгеле, дөрес түгел. Һәркемгә иркенлек бирелде түгелме? Сүз сөйләмәдең, мамак ашамадың дип, акыллы кеше үз баласын да сукмый.

Үз уеңны әйтергә, язырга рөхсәт бирелде. Ф. Бәйрәмова, үзенең татарлар туган телен онытмасын, гореф-гадәтен сакласын, дигән уен белдерү өчен ачлыкта яшәп, җанын фида итәргә риза икәнлеген шулай белдерә.

Туган тел, җырлар, тыйнаклыкка омтылган күңелебез белән генә татар икәнебезне беләбез. Ә балалар? Яшьләр?

Бигрәк тә Татарстаннан ерак яшәгән татарларга авыр. Татар телен мәктәптә укытырга укытучылар юк. Газета чыгарганда, аның хатасын төзәтеп утырырлык корректор юк. Безгә кадрны Татарстан гына хәзерли ала. Ике мәктәптә 200 татар баласы татар телен укый. Бездә иллеләп мәктәп. 10–15 мең татар дәреслекләре кирәк. Иң беренче казакъча мәктәпләргә казакъ телендәге дәреслекне нәшер итәргә кирәк. Аларны да басып җитешмиләр. Кемгә үпкәлибез соң?

Акча ягын әйтсәк, татар җитәкчеләре арттырып бирер иде дә, аларның үз коллективында ветераннар бар. Авырулар, күп балалы гаиләләр. «Милләтчелек»нең ни икәнен белмәгәннәр шул сүз белән дә башлыкны куркыталар. Юк, кече предприятиедән, хуҗалык эше белән аякка басу эше ягын башларга кирәк. Без шулай башладык та. Мәсәлән, кече предприятиедә 5 кенә кеше, 1 кварталда татар үзәгенең счетына 130 сум төшерде. (көлке!) ...ул бит арта бара. Ә икенчесе – 2 мең төшерде. Ул да 1–2 айның хезмәт хакына ярап китә.

*Наилә, Мәхмүт Абдулкәримовлар*
*15.02.1992*

Исәнмесез, хөрмәтле Ибраһим абый!

Хәлегез ничек? Быел безнең Симәй радиосында да, Алматадан да, татарча гына түгел, рус телендә дә сезнең үткән юлыгыз, изге эшләрегез турында сөйләп алдылар.

Бөтен СНГ халкына тарала, ишетеп, укып, сезнең кем икәнлегегезне белдерә башладылар. Бу әле бүгенге хәл. Алда ешрак, күбрәк сөйләрләр. Дәреслекләргә дә керер, иншалла.

Хәзер халык тормыш авырлыгында, сазлыкта йөргән кебек, үз-үзе белән мәшгуль. Сезнең тавышыгызны язсалар иде дип, мин бер язган идем. Запись-тасма, ул инде Казакъстанга җибәрүдән түгел. Сезнең музеегызга кирәк булыр, мәңге яшәп булмый бит. Сез бит эз калдырып китә торган шәхес. Күңелегезгә авыр ала күрмәгез.

Минем үземдә бер папка тулган (газеттан кисеп алган мәкаләләр).

Менә М. Мәһдиев язган мәкаләгә җиттем дә, туктап хәйран булып озак карыйм. Ул бит минем, китабын бик яратып укыган язучым. «Муса Җәлил»ен укып, аңа рәхмәтләр әйтә-әйтә, ничә бит кәгазьне матур әйтемнәре белән, кызыклы җөмлә кисәкләре белән тутырдым. Җитмәсә, аның вафат булуын белми, хат та язып җибәргән идем. Без, Тататстаннан ерак, бер нәрсә белмибез. Кулга төшкән китапны укып риза булабыз. (...)

Ибраһим абый! Сезгә билгеләнгән папканы үземдә саклыйм. Киләчәк ничек булыр? Татар үзәгендә татар музее дип аталган бүлмә бар. Аны әле музей дип атарлык та түгел. Папкада нәрсәләр бар? Сезнең хатлар, «Галиябану»да басылып чыккан мәкалә, радио-телевизордан безнең сөйләгән сүзләр.

Ярый, Ибраһим абый, Маһинур апа, хуш, сау булыгыз. Исәнсаулык теләп калам.

*Наилә Абдулкәримова*

Исәнмесез, хөрмәтле Ибраһим абый!

Күптән язмадым...

Сездә булган көннәрне сагынам... сирәк булса да Сезнең язган мәкаләләрне укыйбыз. Хәзер бу яртыеллыкта Казаннан газет-журнал алмыйбыз. Коммерсантларның берсе ярый, ярый, дип сүз бирде, подписка эшләмәде. Татар үзәгенең счеты (банк) ябылган вакыт иде. Хәзер инде, Мәхмүт, икебез, татар үзәгенең мәшәкатьләреннән

читтәрәк калдык. Габделхак һәм татар үзәгенең советы, татар үзәген оештырып, башлап, бина, җиһаз алып, «Дом дружбы»га хәтле җитүе өчен официально рәхмәтләрен җиткерде. Шулай да арада бер салкынлык, җил, ул 1989 елда ук башланган иде. Әллә ни дуслар кебек эшли алмадык. Эшләп яталар, радио-мәктәп, бар да борынгыча. Татар үзәгендә бер-ике мәртәбә өстәл хәзерләделәр. ..

Иске «Идел», «Наука и жизнь» журналларын кабат карап, укып чыктым. Сезгә язармын дигән журналларны карап искә төшерә алмадым. Берсендә Мәхмүт Бөдәйли: «1918 елда партиягә кердем... үземнең барлык хәятымны Ленин һәм Ленин партиясенә багладым» ди. «Бу партия үзенә ниләр күрсәткән?» – ди автор-мәкалә язучы. Партияме, юк, күрәлмаганлыкмы? Хәзер компартия юк. Без нинди зур хыяллар белән башладык. Поддержка булмады... Әле дә яхшы, 6 ел эшләдек. Җитәрлек! Үзәктән киттек. Ә күңел тыныч түгел...

Кайда булса да һәр эш көрәш белән башлана. 6 ел эшләдек. «5 мәктәптә татар теле» дип күп әйттек. Шулай булса иде. Укытучылар завуч-директор белән сөйләшеп, дәрес урынына факультатив булса да ризалык бирәләр икән. Зарплата гына булсын. Алматада шулай. Безнең бер мәктәптә генә татар теле дәресе – чын дәрес. Мәктәпкә кайчан бармыйсың, татар теле кабинеты ябык, ул шулай факультатив рәвешендә расписаниегә керсә дә, кружоклар кебек эшли, ул «дәрескә» теләгән укучы бара. Зур журналда списоклары да булмый. Үзем барып, карап, журналдан «татар теле» дигән битне таба алмадым. Завуч: «Журнал укытучының үзендә», – ди. Мин 30 ел мәктәптә эшләгән кеше, беләм. Алай булырга тиеш түгел...

Хуш, исән булыгыз.

*Наилә Абдулкәримова*

Здравствуй Казахстанский Шолохов!

Ибрагим! Огромное спасибо тебе за письмо, книгу и газету. Я так и знал, что ты там (?) глубоко, поэтому так долго и молчал. У-у, как хорошо!

А инфаркты и рак это выдумка врачей – помощников смерти. Они это делают из боязни, что их разгонят. Надо же что нибудь-то выдумать в наш век «научно-технического прогресса» – так же как в свое время, акын Джамбул, выдумал:

«По иному солнце
Светит на земле;
Знать оно у Сталина;
Побыло в Кремле…»

Никаких инфарктов – есть общий износ организма, которому нужен покой, сосновый бор с теплым утренним туманом и кумыс курорта «Степной Маяк» – и ты вернешь обратно свои 45–50 лет!

Вот и все!!

Живу я брат посредственно, но с большой революционной зарядкой. Работаю чертовски много, среди молодежи, ветеранов и вообще, среди населения. Должность моя сейчас: «Зав. музеем революционной, боевой и трудовой славы района»

Как тебе нравится?

Дают мене за мою работу 120 рб. в м-ц и оплачивают 50% пенсии – вообще получается около 167р…

Уже второй год пишу «Очерки истории комсомола Заречья» – может и мне удастся вырваться в «историки». «Колыму» – временно забросил, хотя и имею огромное, непреодолимое желание, в любой форме изложения – это описать. Вот я смотрю, в газете твои 37-й год тоже скрыли – ни «гу-гу».

Огромная радость меня охватывает твои творческие успехи. Конечно, я бы советовал тебе не работать на «износ». С твоим «восстанием» сильно не спешить. Ю. Либединский свою «Неделю» писал 10 лет, А.П. Чехов из-за одной небольшой обиды – вообще не писал около 8 лет. Давно уж молчит Шолохов. Подумай браток. Писать надо и даже обязательно, но учесть вдохновение, порыв. Наплыв мыслей, сравнений, метафору и прочее, но учесть и здоровье.

До свидание Друг!

Пиши по возможности почаще. Разумеется, я бесконечно рад всегда получить от тебя хорошие письма.

*Твой Махмуд (Абжалимов)*[1]

*19.03.1972*

---

[1] Мәхмүд Әбҗәлимов – 1967 елда Казан дары заводының Сугыш һәм хезмәт даны музеен оештыручыларның берсе, комсомол оешмалары тарихын өйрәнүче.

Друг мой, Ибрагим!

Виноват, я неблогодарный, что до сих пор заставил тебя ждать ответ на письмо. Черт меня угороздил окунуться в такие дела и заботы, что даже забываешь порой самых близких друзей.

Извини уж, ты мой, всепрощающий!

Закончил 4-ю часть «Очерков истории комсомола», сейчас работаем с Людмилой Асташкиной над последней частью. Выйдет штука в 360–380 машинописных листов. Все четыре части одобрен Обкомом КПСС и ВЛКСМ и дано «добро» на издание в 74–75 годах.

Сейчас очерки находятся на выверке в партархиве и рецензий на кафедре истории КГУ. Вообщем, впереди муки привеликие, и я лично не вхожу «в тялячий восторг» от этого «добро» (т.е. согласия на издание), по прежнему занят текущей воспитательной работой. 19 сентября еду на Республиканский слет победителей похода по «дорогам отцов». Там делаю доклад на тему: «Революционные традиции Заречья – мощный арсенал средств воспитания молодежи». В течение августа заново перестроил и обновил музей, скоро добьюсь присвоения ему звания «народного музея». В этом уверен. Ты давай пришли солидную свою фотографию, кратко свою биографию, перечень изданных книг, и хорошо бы одну с авторской надписью – в дар музею и комсомольцам Заречья и завода, жду, очень жду!

Да, …слет-то, о котором писал, будет в Бугульме, легендарной Бугульме, где мы с тобой сидели в 37 году, в первой, после Казани, пересыльной тюрьме. Помнишь ли ты об этом. А я очень хорошо помню, и даже не забыл уголовника-рецедивиста – Аркашку Караваева, с огромной татуировкой на груди…

…и еще одно серьезное поручение Обкома ВЛКСМ заканчиваем – это глубокая проверка работы газеты «Комсомолец Татарии» к предстоящему пленуму ОК ВЛКСМ. А вообщем всего не напишешь, и делаю это лишь для того, чтобы ты не думал о том, что твой Махмуд-разбойник, совсем тебя забросил…

Ну, хватит наверно, Ибрагим, а то я совсем зарапортовался…

Жму твою могучую, чудодейственную руку и поклоняюсь светлому уму.

*Твой Махмуд*

*Казань, 9 августа 1973 г.*

Адаш!

Исән-саумы, Маһинурның хәлләре ничек?

Синең Яңа ел белән тәбрик иткән открыткаңны алдым, рәхмәт. Открытканы миңа язасың, ә адресын Рафикъка җибәрәсең, әзрәк картая башлаган булырсың, яшәрербез әле җәй җиткәч. Үзем курорттан чирләп кайткан идем, әле дә тазарып җитә алмыйм, салкынын күтәрә алмыйм, картая башлаганмын булырга кирәк, менә 23 августта 70 кенә яшь тула бит, Аллага шөкер…

Синнән хат килмәгәч, әллә минем хатны алгач үпкәләдеңме, дип уйлаган идем. Мин бит чын дуслык белән, чын күңелемнән язам. Казакълар әйтә – дус елатып әйтә, дошман көлдереп әйтә, диләр. Шул дөрес булырга кирәк.

Хат язып тор, Ибраһим!

*Ибраһим (Аблаков)*[1]

*14.01.1980*

Дорогой Ибрагим абый, здравствуйте!

Получил бандероль с Вашей книгой. Очень рад за вас, за то что Вы в полном здравии и в состоянии творчески работать. Сожалею, что не могу читать, писать ответить Вам по-арабски.

Еще больше сожалею, что не могу передать эту книгу Вашему другу-адашу, т.к. его уже нет в живых. Скончался он 18 августа 1989 года. ... зная Ваш преклонный возраст, не стали Вас беспокоить, так что извините за позднее сообщение. Последнее время он ослаб и не вставал с постели... вот такие у нас печальные дела. Если у Вас есть здоровье и возможность приехать, то приезжайте, мы будем очень рады. Вы должны знать, что для Вас двери наши и наши сердца всегда открыты. Вам мы всегда рады. Желаем Вам крепкого здоровья и новых творческих успехов. Радуйте людей новыми хорошими произведениями. А Вашу книгу, с Вашего разрешения, позвольте мне оставить у себя, т.к. передать ее некому – Ибрагима Аблакова нет в живых, осталась одна память.

*С уважением и добрыми пожеланиями Рафик и Рашида Аблаковы*

*19.09.1989*

---

[1] Ибраһим Аблаков – И. Салаховның дусты, Казакъстанның Целиноград (Астана) шәһәреннән, язучы белән 1972 елдан хат алыша. Фондта аның 40 тан артык хаты саклана.

Ибраһим!

Син мине гафу ит инде: хатыңны алуга байтак булса да, җавапны озак көттердем. Моның ике сәбәбе бар: беренчедән, хат язышу мәсьәләсендә мин элек-электән юньсез, сүрән кеше: икенчедән, миңа көн эчендә бик күп язарга туры килә. Йөдәп бетәм, йөдәп! Менә хәзер дә язып утыра идем. Арып киттем, каләмем килеп төртелде. Бераз ял итәргә булдым. Тын алуга сиңа хат язарга булдым.

Син үзең язасың да ертасың икән... Бусы бик һәйбәт дип уйлыйм мин. Ә менә язып-ертып, язып-ертып бер җирдә, ниһаять, үз-үзеңнән өметең тәмам киселеп, туктап калсаң, начар булыр иде. Минемчә, яза торган кеше, гомумән, шулай газап чигә, шулай газаплана торган. Аның алдында, ахыр килеп, юл ачылып китә, шуннан инде аның каләме туктаусыз сыздыра башлый.

Аннары, син әсәреңне коруда берәр төрле ясалма юл алмадың микән? Кайчакта шулай да була бит ул! Син романмы, хикәяме, нәсерме икәнен уйламыйча, менә күңелең ашкынып теләгән нәрсәңне яза башласаң, эшең җайлырак китмәс иде микән? Хәер, моннан торып, барысын да дөрес чамалап булмас. Барыннан да кирәге – кул селтәмә.

Менә шулай, Ибраһим!

Гаиләңә, якын дус-ишләреңә сәлам. Исәнлек, иминлек телим.

Хуш иттек.

*Хатыйп Госман*[1]

*1. 11. 1959*

Ибраһим абый!

Сабырлыгыгызга сокланам, үпкәләр инде бу картлач, дип уйлаган идем. Тәнкыйтьнең файдалысын кабул итүегез әйбәт...

...сезнең шикелле казакъ арасында туып, гомер буе яшәргә туры килмәсә дә, казакъча мин грамоталырак язамдыр. Чөнки мин казакъ телендә шушы графика нигезендә ике ел укыдым. Аннары казакълар белән ара-тирә соңрак та очрашкалап торганга, казакъ хәрефләренең казакъ авазларын белгерткәндә, татарның авазы һәм әлифбасына ничегрәк туры килүен дә беләм. Моның өчен һәр ике милли мәктәптә укуның файдасы тиде.

[1] Хатыйп Госман (1908–1992) – тәнкыйтьче, язучы, әдәбият галиме.

«Акмула» – дигән язылыш дөрес, мин элекке хатта ике «л» теркәгәнмен ахры, механик төстә. Юкса, «мула»ның кабер икәнлеген мин күптән укыган һәм ишеткән идем. Казакъ тарихы буенча китаплар миндә булганлыгын хәтерлисездер.

Димәк, сез уйлаганча, «Акмола» дип язылыш татарча дөрес түгел. «жол» дип язу да шулай ук хата булачак. Ни өчен?

Әйе, казакъның «о» хәрефе һәм татарның «у» хәрефе ике телдә орфоэпия буенча туры килеп бетми. Казакъның «о» авазы татарның «у», «о» авазлары уртасындарак, ягъни урысча «о»га якынрак. Шуңа карамастан, казакъча «о» татарча «у» дип кабул итәргә кирәк, чөнки татар укучысы татар-төрки сүзләрендәге «о»ны кыска вариантта гына укый.

Урыс яки урыс теле аша кергән сүзләрдәге Европа сүзләрен укыганда, киң әйтелештәгесен дә укый: орган, тон, симфония һ.б. менә соңгы сүзләрне әйткәндә, без казакъ «о» авазына якынаябыз да.

Ләкин казакъның «о» хәрефен татарчада «о» хәрефе белән бирү ярамый. Ул чакта төрки телләрнең кардәшлеге, бер тамырдан үсеп чыгуы, охшашлыгы аяк астына салып таптала. Чөнки төп нигез – алфавит түгел (ул алышынырга мөмкин, без инде рун, гарәп, латин, керәшен алфавитларын күрдек), ә җанлы тел. Шул телнең әйтелешенә зыян китермәслек итеп, хәрефләр сайларга тиешбез. Чыннан да, казакъның түбәндәге сүзләрне кол, он, тол – шул көе татар язуына күчерсәк, татар аны «раб», «мука», «вдова» мәгънәсендә кабул итәчәк. Ә бит ул аны «рука», «десять», «заполняйся» мәгънәсендә укырга тиеш. Аның өчен без казакъның «о» авазын татар алфавиты нигезендә тамгалыйбыз. Үзеннән-үзе аңлашыла, кол-кул, он-ун, тол-тул – дип бирелгәндә генә бу сүзләрнең һәр ике телдә бер икәнлеге шик уятмый.

Нәкъ менә шушы принцип нигезендә, казакъ «ж» авазы һәм хәрефен кулланмаса да, «жол»ны «җул» дип кенә бирергә тиешбез.

Казакъның «о» авазы һәм хәрефе урысчадагы шул ук аваз һәм хәрефкә туры килә икән, урыс-европа сүзләрендә бу кулланышта йөри икән, нигә казакъчаны да шул формада гына язмаска, диярсез сез.

Ярамый шул. Чөнки урыс-европа сүзләрен нәкъ русча язу һәм уку туган тел нормаларын җимерә, бу принциплар рухи яктан ассимиляцияләнгән «галимнәр» тарафыннан көчләп тагылган. Халкыбызның чын, хак юлдагы көчләрен тар-мар китергәннән соң

җыелып калган әләм-әтрәкләр шушы спекулятив юлга басып, үзләрен милләтчелектән бөтенләй азат итеп күрсәтергә теләгәннәр...

Һәр халык ят элементны кабул иткәндә, аны үз тукымасына муафыйкъ хәлдә сеңдерер өчен күпмедер үзгәртә. Ләкин сатлыклар урыс-европа сүзләрен нәкъ урысча әйтелеш һәм язылышны көчләп тагып, бу принципны челпәрәмә китерде, туган телебезгә эрозия ясады. Моны колонизацион көчләр бик яхшы аңлап, үсендереп, ыскыртып торды. Әлбәттә, төп максатның ассимиляциягә хезмәт итүен яшерер өчен төтен пәрдәсе җибәрде. Хәзер менә шушы шартларда үз нигезендә тотрыклы утырган халыклар, әйтик, урыслар 31 аваз үзләштерсә, сөйләшер өчен, без туган телдә сөйләшер өчен 34 (шулай бугай) үз авазларыбызны гына түгел, тагын бүтән телләрнең килмешәк авазын кулланырга тиеш.

Менә шушы ахмак принципны кардәш төрки халыклар теле белән элемтәгә кергәндә дә уздырсак, телебезгә, мәдәниятебезгә тагын бер үлем карары чыгару була да инде. Дөрес әйтәсез, «надан мулла дин боза» дип...

*Саулык теләп сезнең Әйди (Тәүфикъ)*[1]

*Казан, 8.02.1980*

Ибраһим абый, исәнмесез!

Әсәрегез басылу уңае белән бездән килә торган хәбәр тансыктыр, шуңа язам.

Әсәр турында инде сүзләр китте. Хатлар килә башлады. Редакция, журналга игътибарны арттыру, 1989 ел таралышына файда бирер өчен, «Тайгак» тирәсендә ажиотаж тудырырга ниятли. Бу эш башланды инде. «Соц. Тат.»да беренче сүз әйтелде. Русча гәзитләргә чыгарга җыенабыз.

Редколлегиянең чираттагы утырышында бу хакта күп сүз булды, чөнки хәзер матбугатка язылу үзенчәлекле. Ярыш китте. Укучы өчен көрәш көчәя. Сезнең әсәр – редакциябезнең өмете, шушы эштә.

Бер кызык хәл: журнал нөсхәсен, чыгуга, партия ӨК-на илтеп бирәбез. 4-санны да илттек. Куратор – матбугат, культура бүлеге инструкторы Әшрәфҗановка. Алган, тиз генә укыган һәм өлкә ко-

---

[1] Тәүфикъ Әйди (1941–2001) – татар язучысы, прозаик, публицист. ТССР ның атказанган мәдәният хезмәткәре. Фондта 30 дан артык хаты саклана.

митетындагы иптәшләренә күрсәтеп чыккан. Андагы һәм бик күп түрәләр «Казан утлары»н алмый, укымый бит. Икенче көнне карасам, Әшрәфҗанов кабинетыннан журналны – «Тайгак кичү»не сукканнар!

– Зинһар, тагын берне табыгыз инде! – дип телефоннан үтенде егет.

Менә хәлләр ничек – урлап укыйлар хәзер «Казан утлары»н. Инде руслар безгә кайчан урысча чыга ул әсәр? – дип хатлар җибәрә башлады. Кыскасы, шаулатачакбыз әле!

Туфан Миңнуллин: «Бик тиз русча чыгарырга кирәк!» диде. Китап нәшрияты ашыгыч бирергә тели китапны. Хәзер директор – үзебезнең «Казан утлары» баш. ред. урынбасары булган Ринат Мөхәммәдиев бит. Әдәбият кешесе. Ул сезнең әсәрне миннән соң укырга тиеш иде – нәшрияткә күчеп өзелде...

Сау булыгыз.

*Сәлам соңында Тәүфикъ*
*25.04.1988*

Кадерле Ибраһим абый!

Яңа еллар котлы булсын! Бер язгач, сезгә гел язып торырга туры килә инде, менә тагын каләм алдым. Гаиләгезне, язмышыгызны, фикерләрегезне һәм сабыр, ягымлы холкыгызны бераз белгәнлектән, ничектер, сезгә яхшылык теләгәнлектән, язасы килде бу хатны. Сез инде хәзер Әйдинең туры сүзле икәнен, шуның аркасында кайбер өнәмәслек реакцияләр дә уятуын үзегез баштан-күздән дә кичердегез. Шунлыктан да бу хатны салкын кан белән укырсыз дип өметләнәм.

Ах инде, шомага, төчелеккә, икейөзлегә әйләнде бу каләм әһле! Тукайның, мин шагыйрь генә түгел, сәясәтче, дипломат һ.б. дигән сүзләрен коралланугa алдылар, әмма ул дипломатлыкның (мин инде Тукай булуның беренче шартын – язучы булуның кирәклеген, мәҗбүрилеген онытуларын әйтеп тә тормыйм!) икейөзлелек тә икәнлеген таныргa теләмиләр. Шөкер, миндә андый дипломатлык юк дәрәҗәсендә!

Әле Ташкенттан бер дус язган: кырым-татар язучысы Черкез-Али сиңа бик каты үпкәләгән, ачуы чыккан, син яхшы белмәгән кешеләргә алай язма, зыян гына күрерсең дигән!.. Соңгысын, бик ихтимал, күрермен дә!!

Эш шунда ки, бу Черкез-Али Ташкент нәшриятының кырымтатар бүлеге мөдире, барлык кырым-татар китаплары аның кулыннан уза, танышкан идек, сөйләшкән идек, берничә тапкыр әсәрләрен тәрҗемә иттерәсе килүен сиздергән иде. «Таңнар кочагында» романын «Советский писатель» һәм Алматы чыгарды, шуны Казанда бастырасы килүен дә белдем. Тукта, Мәскәү эшкәрткәч, бәлки арурак хәлгә килгәндер, дип кабат укыдым. Анализлап, 2–3 ел элек хат яздым. Әлбәттә, аны уку авторга күңелле булмагандыр. Ә быел исә мин аңа ике хикәясен анализлап хат яздым. Аның күчермәсе кулымда. Минемчә, авторга үсеш юлын күрсәтү, дәлилләп ышандырырга тырышу гына анда. Бер кырымлы язучы да аңа кимчелекләрен кистереп әйтмәячәк, дипломатланачак. Аю хезмәте күрсәтү килеп чыгачак. Шулай бара инде ул! Нәтиҗәдә, автор үсми, еллар буе чиле-пешле китаплар чыгара. Ә минем ярдәм итәсе, үстерәсе килә аны. Шулай анализладым, тәнкыйтьләдем дә үзен, бер хикәясен тәрҗемә иттем. «Соц. Татарстан» аны кире каккач, редакторга кадәр барып җиттем, бастырырга кирәклеген төрлечә исбатлап, үземә төксе мөнәсәбәт уятуга да бардым. Чөнки мин шәхси якны кайгырткан дипломат түгел, кешегә дусларча мөнәсәбәт шундый рухта булырга тиеш дип ышанам. Тәнкыйтьлә, әмма булышуны да онытма!

Ибраһим абый, сез беләсездер, Фадеевның «Яшь гвардия»се заманында кискен тәнкыйть ителде, ул аны яңадан язарга мәҗбүр булды. Ләкин поэма шикелле нәфис, матур, кәнфиттән тәмле «тар-мар»дан соң, барыбер «Яшь гвардия» пшик килеп чыкты. Роман түгел, плакат! Схема, идеологик-тарихи очерк. Ни сәбәпле? Чөнки без художник Фадеевны чиновникка әйләндердек, җәмәгать эшләренә күмдек, Сталинның шәхси писере ясадык. Нәтиҗәсе шул: без художникны үтердек!

Язмыш һәркемгә үзенчә кагыла...

Атилла Расих Х. Ямашевка багышлап дилогия язды. «Ямаш», «Айлы төннәр» романнары 25–30 табак җыйналыр. Атилла абый талантлы, җимешле язучы, миңа да ярдәм итте – союзга рекомендация бирде, бер әсәрне чыгаруда булышты. Шуңа карамастан, Бауман урамында бервакыт күрдем дә:

– Атилла абый, мин сезнең әсәрләрне гел кызыксынып укыйм. Әмма «Ямаш» дилогиясе көткәнемне акламады. Күп эзләнгән, күп көч түккәнсез үзе, ә шулай да революцион темага без укыган

әсәрләргә, урыс һ.б. әдәбиятлар аша таныш фикер, тәэсирләргә берни диярлек яңаны өстәмәдегез. Латыш язучысы Янсонның «Глас завущего» романын укыгыз әле сез. 6–7 басма табак кына, әмма күпләрнең кирпеч калынлыгы томнарын бәреп ега, бик гыйбрәтле, дидем.

Чыннан да Янсонның нәни повесте (роман!) Расихның олы дилогиясеннән бик күпкә өстенрәк. Билгеле, берәүгә дә сер түгел, күп язу күпне әйтү дигән сүз түгел әле ул әдәбиятта. Тик без моны һаман аңларга теләмибез, дөресрәге, үз практикабызга кертергә көчебез җитми.

Менә шушында җиткәч:

– Ху-уш, Әйди, инде ни әйтмәкче буласың? – диярсез.

Әйтәбез инде, тотынгач, сез, Ибраһим абый, фаҗигале язмыш иясе. Маннур, Расих, Фадеевлар кебек исән-имин, нормаль шартларда яшәмәдегез, иҗат итмәдегез. Менә-менә мин дә яшьтәшләрнең алгы сафына басам инде, дип җыенганда гына, үскән җирлектән йолкып алындыгыз. Чәчәк сулды, сабак корыды, тамырлар кипте. Ун-унбиш елдан аны терелтергә алыну чын-чыннан зур батырлык иде, әмма аны, бер дә зыян китерелмәгән төсле, яңадан үстерү һәм башка агачлар, зарар күрмәгән агачлар кебек мул һәм татлы җимешләр бирдертү мөмкин түгел эш иде. Ләкин сез шул хәлдә дә таралып, югалып, мескенләнеп калмадыгыз, «Тар-мар»ның соңгы битләрендәге Левинсон кебек, яшәргә һәм көрәшергә кирәклеген тойдыгыз, көч түктегез!

Татар әдәбияты кыен шартларда булса да үсә, һаман үсә килә. Быел «Казан утлары»нда басылган М. Мәһдинең «Торналар төшкән җирдә» романы (повесть дию аз) менә шуны раслый. Туган тел өчен нинди шатлык, горурлык кичерәсең аны укыганда! Татар тормышының гүзәл шигъриятен нинди оста, нинди нечкә итеп тасвирлый бит ул! Шуны укыганда халкыңның яшәвенә, аның үлемсезлегенә ышаныч ныгый. Шул ук вакытта аның белән бер телдә, бер журналда янәшә басылу, бер үк укучы кулына китабыңны тоттыру җаваплылыгы куркыта. Әйе, менә нәрсәләр уята ул Мәһди. Рәхмәт үзенә!

Журналда Аяз, Юныс, Шәфигуллинның дә әйбәт повестьләре чыкты. Укыйсыздыр, уйланасыздыр, дәртләнәсездер. Әмма 70 нең үрен узгач, җиңел түгел, кайбер биеклекләргә күтәрелү мөмкин дә түгел. Хәзер инде шуны истә тотарга, реалист буларак хәрәкәт итәргә кирәктер.

Кыскасы, болай: мин журналда һәм нәшриятләрдә дипломатларны капшагач, сезнең трилогиянең хәрәкәтсез ятуын чамаладым... Алар фикеренчә: әсәр редакцияләүдән алда капиталь рәвештә әдәби эшкәртүне таләп итә. Бу эшкәртү сюжет-композиция ягына да, теленә дә – бөтен буеннан-буена кагыла. Автор, рецензент фикерләрен искә алып, яңалык кертә алмаган, яңадан шул көе китергән. Кирәкле төп аркау өлеше коры һәм үтә кыска, кирәкмәгән җире чамасыз озын һәм тәфсилле язылган. Элекке әсәрләрегез кыска булганлыктан, аларын шундый кешегә хөрмәт һәм теләктәшлек йөзеннән, дип эшләгәннәр имеш. Ә бу тау кадәрле кулъязмага якын да килергә теләмиләр, шунлыктан ята да ята. Ул арада нәшриятның 1983 ел планы да эшләнеп бетте. Трилогия тиешле таләпләргә җавап биргәнче, 1984 ел планы да туларга мөмкин. Ә алар шома, дипломат халык. Әйтерсең И. Салахов 150 ел яшәргә килгән...

Ачу да килде, эч тә пошты. Болай барганда, сезгә байтак еллар көч түккән әсәрне китап хәлендә күрү һәм бераз тиярен алу насыйп булырмы? Автор үзе тере вакытта җимешен күрмәгәч, ничек була инде ул?

...Сезгә ныклык, иминлек телим. Борчылган хәлдә дә, сезгә артык уфтанырлык урын юк. Кулдан килгәнен эшләдегез һәм эшлисез, ходайның язганы дигәндәй. Калганын дөньядагыча хәл итәргә кирәк. Мин уйлыйм, сездә бу нәрсәләрне җиңеп чыгарлык көч тә, акыл да бар. Кайбер якларны йөрәккә якын алмаска, яхшылык көтәргә кирәк.

*Сәлам белән Тәүфикъ энегез*
*Казан*
*26.12.1981*

Ибраһим абый!

«Мәхәббәт картаямы»ны укып чыккач, язарга булдым әле. Фаҗигале язмыш кичергән кешегә бүгенге әдәби казанышларның алгы сафына чыгу бик авыр, аңа ирешүчеләр безнең татар әдәбиятында бер Аяз Гыйләҗ генә булса кирәк. Хәтта Х. Туфан да егерменче еллар биеклегенә яңадан күтәрелә алмады. Аяз исә бик аз вакытка гына аерылып торды, шуңа җиңелрәк кичерде ахры изүне.

Әдәбият күләмендә повестегез казаныш санала алмаса да, үз иҗатыгызда матур сәхифә, күңелле хәрәкәт. Автобиографик

булгангамы, анда тормыш сулышы, кыйратылган язмыш, өзгәләнгән йөрәкләр барлыгы гәүдәләнә алган. Моны мин үз әдәби зәвегымнан чыгып, югары таләп куеп укыганнан соң да әйтерлек саныйм. Әсәрнең канвасы дөрес сайланган, башы һәм ахыры әйбәт уйланган, җыйнак сюжеты да күңелгә хуш. Үзегезгә хас рәвештә тыйнак, әдәпле итеп язгансыз. Әсәрнең журналда чыгарга, укучыларга тәкъдим ителергә хакы бар. Аны укырлар һәм арада яратучылар да табылыр, һичшиксез, табылыр. Мин моның өчен алдан ук сөенеп торам.

Инде үземнең идеалдан чыгып бәяләсәк (әмма прозаик төсендә үзем дә аңа ирешә алганым юк), әсәр бүгенге дөнья әдәбияты казанышларын, аның бай арсеналын эшкә җигеп язылмаган. Повестька күңелләрне әсир итә торган витаминнар кушылып җитмәгән. Автор кыюсыз, тыенкы язып беркатлылык күрсәтә. Бәлки аң агышын кертергә кирәктер? Хисләрнең логикадан чыгуы, куертылуы? Нәфрәт һәм мәхәббәт гиперболасы? Натурадан мөмкин кадәр качарга? Фәлсәфирәк булу? Геройларга күбрәк уйлатырга?

Кыскасы, алгы сызыкка чыгар өчен повесть тагын бер баскыч югарырак күтәрелергә тиеш иде. Әмма... сез инде үз көчегезне, мөмкинлегегезне беләсез, кулдан килгәнчә язгансыз...

Әсәрнең Казагыстанга бәйләнүе, кайбер күренешләрне тасвирлавы әйбәт. Географиябезне киңәйтә. 20–30 нчы еллар Казаны да документаль дәрәҗәдә сурәтләнүе белән яхшы ук кызыклы.

Шулай итеп, Ибраһим абый, повестегез, әлбәттә, хәрәкәт, шәхси егетлек, моның өчен куанмый мөмкин түгел. Әмма 80 нчы еллар татар прозасы, тагын да югарырак таләпләр куелганда, әлегә безне үз тарихына кертергә, мөгаен, ашыкмас. Тик без эшләмәсәк, булган кадәре дә барлыкка килмәс иде, бәлки безнең тырышу да киләчәк гениена зәмин булыр. Шуны аклаган хәлдә, ирешелгәненә дә шөкрана кылмый ярамас. Эшлик!

...Сез инде урага мактамаганга үпкәләмәгез, уйланасы килде. Чөнки үз алдымда да бурыч шундый ук. Реалист булмый ярамый. Әйтергә кирәк, бар яктан килгән татарча әсәр уку кайсы елларда бөтенләй насыйп булмый. Татар прозасы югарылыгы, гомумән, борчырлык. Үтә фарватерда бара. Эч пошырырлык.

*Т. Әйди*

*15.05.1980*

Ибраһим абый!

«Казан утлары», чыннан да, сезнең фотоны урнаштырырга тиеш иде. Нигә бирмәгәннәр – аңлашылмый. Күңелсез.

...Эш күләмле, калын әйбер язуда түгел, яхшы әйбер язуда. Мәсәлән, күптән түгел Каракалпак язучысы Т. Каипбиргәневнең «Каракалпак кызы» романын укыдым. Трилогия дә чыгарды ул, 5 томлыгы басылды. 3 повестен да укыдым. Калган әйберләрен укуның хаҗәте юк. Мин аның 5 томын Арво Валтонның «Хәвефле ачыш» дигән бер хикәясенә тормый, дип саныйм. Хикәя нибары 10 битле генә! Кызыгып, мин аны тәрҗемә дә иттем.

М. Юныс бервакыт «Азат хатын»га шактый ук кызыклы язма җибәрә, ул язма редакциядә 2,5 ел ята, берзаман М. Мәһди әсәре белән янәшә басылып чыга. Үпкәләп йөргән Юныс, Мәһди әсәрен укыгач, кыенсынып хат яза: «Ни өчен озак яткыруыгызны аңладым. Мәһди белән чыгарасагыз юк иде инде ичмасам, оят булды, бер үк укучы укый бит аларны» дип борчылуын белдерә.

Күрәсең, кайвакыт гаепне үзеңнән эзләү дә файдалы.

Монда Р. Мостафин миңа бер тәкъдим бирде әле. «Габдрахман Әпсәләмев турында китап яз, кулыңнан килә, очеркларыңны укып барам. Ул китап 2 телдә дә әйбәт китәчәк, халык бик кызыксына. Син аны кеше укырлык итеп язып идең», ди. Чыннан да, әйбәт уй бу. Әпсәләм рекорд куйды. Китаплары төрле телләрдә 8 миллион чамасы тираж белән басылды, татарны пропагандалады лабаса ул!

Әйбәт тәкъдим, әмма барыбер куркыта, яза башлаган романым ярты юлда, аны ташлап нишләрмен? Кечерәк әйбер языйм дисәм, әле Ташкенттан детектив сюжеты алып кайттым. Бари Шиһабетдинов турында. Кыскасы, мавыктырган нәрсәләр, җыйган материаллар, фикерләр дә бар, тынычлап эшләп утырырга төп шарт – гаиләне туйдырып торырга керем генә юк! Эшли алырлык вакытта безне шул харап итә инде. Картайгач, баш эшләмәс!

Ярый, сезгә уңышлар теләп, сәлам әйтеп, нокта куям.

*Тәүфикъ Әйди*

*21. 01. 1982*

Хөрмәтле Ибраһим абый!

[...] әсәрнең бүлеген укып чыктым һәм бик нык кәефем китте. Ничек инде шул көе кат-кат машинкада басып азапланырга?

Хаталар күп... Ул хаталар морфологик, синтаксик, лексик, орфографик – теләсәң нindиләр... Кеше сөргендә булырга мөмкин, әдәби хәрәкәттән тышта калырга – ләкин ул моңа карап кына ташлама кө тәргә тиеш түгел. Әдәби телне какшату, зәвекъне бозу вөҗданга сыярга тиеш түгел. Бу бит культурага үлем дигән сүз. Нигә инде үзең утырган ботакны кисәргә?

Әмирхан Еники кульъязмасына бездә редакторлар бер сүз өстәргә дә курка – шунда ук гармоник бөтенлек, музыкасы, моңы, ритмы, яңгырашы бозылуы ихтимал. Бәшир әсәрләре дә шулай.

Мине телебезнең зур белгече, остасы Нурихан Фәттах үтә таләпчән булырга өйрәтте. Сүгеп-сүгеп кайтарды, кульъязмаларымны ертып атты. Мыскыл итте, әле дә бер фальш тапса да, утлы табага бастыра. Мин аңа моның өчен мең-мең рәхмәт укыйм. Халкыңа мәхәббәт аның гәүһәре – телен ихтирам итү, кадерләүдән башлана. Жаргон, ватык арбада барган шикелле хис калдырган гарип җөмлә, черек, фәхиш лексика – мондый тел теләсә кайсы намуслы кешенең нәфрәтен уятырга гына лаек...

Билгеле, күләмле әсәрдә (материалы кызыклы гына) бәлки ару урыннары да бардыр. Ләкин андагы чуарлык, дегет бөтен тәмен бетерә... Әдәбиятка хезмәт итү корбан, белем, тырышлык, саф омтылышлар таләп кыла. Язучы исеменә лаек булырга, кайгыртырга кирәк...

...без, әлбәттә, сезгә яхшылык телибез. Ләкин шул хәлдә дә сезне бик нык кисәтмичә кала алмадым. Чөнки сезне якын күрү никадәр олы булса да, әдәбиятка, халыкка тугрылык мине шулай кискен, туры булырга мәҗбүр итә. Кешегә ышанмаска, үзеңә тырмашырга һәм ирешергә кирәк. Язучы бары шул юлдан гына атларга тиеш. Бары тик!

*Сәлам белән Тәүфикъ*
*28.01.1981*

Кадерле Ибраһим абый!

Менә бераз баш-күз алдым кебек, тагын сезгә язарга булдым. Әле шушы көннәрдә сез биреп җибәргән кульъязмаларны укып чыктым. Алар барысы да инде таныш әйберләр икән – «Казан утлары»нда басылганнар. Мифтахетдин турында язганнарыгызны гына шактый кыскартканнар кебек күренә, кульъязмагыз шушы яктан минем өчен арада бәялерәк булып чыкты: тулырак күчермәләр биргәнсез.

Сезнең бу язмаларыгызны укыгач, Лениградтагы рәссамыбыз Фәйзерахман ага искә төште. Ул да бит әллә кая яшәвенә карамастан, үз рухын, халкын ярату тойгысын тулысынча саклаган кеше. Үткән елда Казанда шәхси күргәзмәсен карагач, шулхәтле сөендек: башкалабызга рәсемнәрен генә түгел, Ленинградтагы бөтен татар халкын алып кайткан кебек булды! Ул Ленинградта яшәүче күренекле татарларның портретларын ясап килеп, аларны да күргәзмәгә куйган иде. Мин шундый җаннарга, бик купшы сөйләшә димәсәгез, билләһи гашыйк инде.

Менә Сез дә, Ибраһим абый, нәкъ шундый кеше икән: бүтән телне юньләп белмәгәннән генә түгел, үз халкыгызның улы булганга, бөтен көчегезне биреп әдәби әсәр язасыз. Нәкъ менә шул уллык хисе Сезне җаваплылык тоеп эшләргә, халкыгызны үстерү, туплау, беректерү өчен аның горурлыгын арттыру максаты белән көч түгүгә китерә. Ф. Мифтахетдин, С. Шәрипов, Г. Әбдрәшитов! Шушы өч исем генә дә Төньяк Казагыстандагы татарларны күрсәтү өчен нинди матур дәлил. Рәхмәт үзегезгә!

С. Шәрипов югалмый. Аны казакъ галимнәре тикшерер, инде хәзер үк шактый эш эшләнгән. Габдрәшитов хакында Сезнең язма белән дә канәгатьләнеп торырга мөмкин әлегә. Сез аларны, мөгаен, яңа романыгызда да, ихтимал, искә аласыздыр әле. Ә менә Мифтахетдин фигурасы тагын да кызык бит. Мирасы да чагыштырмача зур. Ул чор язучыларыннан Мәрҗани һәм Насыйри иҗатлары гына күләме белән аныкыннан уздырыр. Ләкин аларның иҗаты саф матур әдәбият түгел бит. Димәк, бу шагыйрь җентекләбрәк тикшерелергә тиеш әле.

Сезнең мәкалә чыккач, байтак вакыт үтте. Аны инде галим, язучы әһеле ишетте, күрде. Шуннан соң Мифтахетдин мирасын әдәби хәзинәбезгә кушу юлында нәрсә эшләнде соң? Менә шуңа җавап бирегез әле, Ибраһим абый. Аның әсәрләре әле һаман бердәнбер данәдә Сездә генә сакланамы? Копияләре дә бармы? Күпме өлеше «керәшен» хәрефенә күчерелде?

Мифтахетдин иҗаты лексик яктан, стиль ягыннан татар-казакъ әдәби традицияләрен күзәтү өчен бик кызыклы материал бирә ала. Халык иҗаты тәэсирен күрү дә кызыклы... Казанның университет китапханәсенә тапшыру уегыз юкмы?

...инде үземнең хәлләргә килсәк, шул Сезнең якларда йөреп кайтуыма багышлап, 150 битләр чамасында сәяхәтнамә яздым.

Беркадәр ит кундырып булса, аның күләмен тагын да үстереп булыр иде әле. Аның өстендә әле шактый утырасы бар. Форматы белән ул китап сорый инде...

Гаиләгезгә иминлек, үзегезгә иҗади уңышлар теләп, сәлам белән хатымны тәгәллим. Хушыгыз.

*Казан. Тәүфикъ*
*27.01.1974*

Ибраһим абый!

21, 23 ноябрьләрдә язган хатыгызны мин дә икесен берьюлы кичә алып укыдым.

Эш болай булды. Ике Ринат: «Моны син генә сыйфатлы, тиз эшли аласың, бик ашыгыч кирәк. Өеңдә утырып ун көндә өлгерт, соңрак шуның өчен ял бирербез», диделәр.

Мин көне-төне унбишәр сәгать утырып редакцияләдем, вакытында өстәлләренә куйдым. Әмма эш эшләнгәч, алар икесе дә сәер рәвештә миңа икешәр смена эшләүне истә тоту кайда, әлеге хәләл 6 көнемне дә ял иттерүдән тайчана башладылар. Аң-таң калдым. Әлеге бер тоташтан ике атна буе унбишәр сәгать утыру күзгә бәрде, анысы – башка. Минем, җитмәсә, хроник төстә кан басымы түбән – менә шулар барысы җыйналып, түшәккә егылдым. Чир бит ул яшькә-картка карамый.

Гаҗәп инде бу түрә халкы: мин сезнең кульязманы басарга әзерләп, «КУ»ның проза бүлеге 2 ай башкара торган диярлек эшне үтәдем. ...ничә кеше эшен башкаруга карамастан, шундый сәер мөнәсәбәт күрсәттеләр.

Р. Мөхәммәдиев миннән соң укып, редакцияләү дәрәҗәсен мактады. Ләкин ул 80 битне укыды да журнал белән араны өзде – китап нәшриятыбызның директоры вазифасына китте. Хәзер яңа кеше килүен көтәбез...

Хатыгызда әйткәннәрне мин аңлыйм, ләкин редактор карашы мин язганчарак була инде ул. Аңа көчәнергә әзрәк туры килгән саен, мөнәсәбәте авторга мәхәббәтлерәк! Ул бичара да иҗат кешесе бит, үз «шәҗәрәсен» пешерүне уйлап йөри, шуңа дәрманы, вакыты аз калуына ачына. Гомер исә уза.

Тик хәзер безнең уртак хезмәт конвейерның бүтән баскычына китте инде. Азагы куанычлы булсын!

Торып-торып сезнең һәм сездәй бүтәннәрнең гомерен кызганам. И язмышлар, и бу адәм балаларының чуарлыгы. Шәфкатьсезлеге! Шундый хәшәрәтләрнең золымына каршы торырлык рухи ныклык, гайрәт һәм куәт бирсен безгә ходай. Әлеге яңа тернәкләнеп килгән яшь көчләр, аларның остазлары барысы да ирекле тормышта омтылган максатларына ирешү мөмкинлеген тотса, сәнгатебез нинди үскән, күтәрелгән булыр иде! Нинди югалтулар, фаҗигаләр кичерә бит асыл кешеләребез. Шундый җәлладлар, кабахәтләр, һәр бармагыннан кан тамган адәм актыклары шәп пенсия алып, әле дә янәшәбездә, кара елан кебек, куеныбызга елышып яшәвен искәргәндә, безгә көрәшергә, әлбәттә, бер-беребезгә ярдәм кулы сузарга кирәк. Тик.... әнә шундый хаин, пычрак җаннарның икейөзлелеге, демагогик ялганы, чамадан тыш ерткычлыгы шактый эгоистик яшь буынны үстереп җиткерде. Алар хәзер әдәбият мәйданыбызга агыла. Оят юк, миһербан юк, пакьлек чамалы. Ярый әле заманы бүтән, юкса яңа күз яшьләре, кан елгалары агыласын көт тә тор.

Сезнең хезмәт бәлки шундыйларга да бераз иман нуры кертер? Түбәнҗанлылык, хыянәт, бозыклык, гаделсезлекнең иртәме-соңмы фаш ителүен раслый алырбыз, бик-бик кирәк эш ич бу.

Ярый, Ибраһим абый, яхшы теләкләрдә калыйк.

*Т. Әйди*
*3.12.1987*

Кадерле Ибраһим абый!

...әгәр кызыксынсагыз, үземнең хәлләр турында да берничә юл язам. Сез Казанга килгән чакта мин эшне ташлап бер әсәргә тотынган идем. Мин ул әсәрне февраль башында төгәлләдем. Машинка күләме 300 бит булган повесть барлыкка килде. Менә шул февральдән бирле әсәрне иптәшләрдә йөрттем-укыдылар. Язучылар союзының проза секциясе бюросы тикшерде, нигездә, уңай бәяләде һәм «КУ»на бирергә тәкъдим итте. Мин аны иптәшләрнең фикерен ишеткәч, бераз төзәткәләгән идем. Шуннан соң Гариф Ахуновның да укырмын дигән вәгъдәсе булгач, редакцияләргә биргәнче, аңа илттем. Әсәр алтынчы ай аңарда ята. Яшьләрне бу кадәр ваемсыз каршы алуга кәефем китсә дә (алты ай фикер йөртү озаграк бит), ахыры зыянсыз булыр кебек: шушы көннәрдә сөйләшербез, укыдым, фикерем уңай, мин бастыру яклы, дип хәбәр итте.

Бер уйласаң, бик гаҗәп тә түгел, татарның хәле шундый инде аның. Мәйдан кысан, сүздә яшь алмаш тәрбиялик дип ах итсәк тә, эштә үтә көтек хәлдә – материал базасы юк бит! Классиклар юньләп басылмый! Г. Ибраһимов әсәрләрен чыгару нинди мөшкел шартларга эләкте, ел саен темпланга керә, кала да кала шуннан.

Бу арада казакъның яшьләрен укып караган идем: Әбеш Кикелбаев, Дөкәнбай Дусҗанов, Сатымҗан Санбаевларны. Шәп язалар лабаса. Дөкәнбайның 30 тулганда 8 китап – шул исәптән 2 се роман язу – көнләшерлек. Татарстанда туса, шик тә юк, мондый бәхет тәтемәс иде егеткә. Материал база, дәрман бар бит. Мораль һәм матди стимул зур. Ә безгә азап белән тырмашырга туры килә.

Инде хәзер менә шул егетләр белән ярышып, роман язу хыялы белән йөрим. Материаллар туплап ятам. Аңа керешкәнче казакъ-татар әдәби багланышлары буенча бер мәкалә әзерләргә булдым. Бу уңайдан байтак казакъ чыганакларын күздән үткәрергә туры килә. Әллә Казагыстанда «кызару» бездәгедән куерак инде шунда, байтак китапларда татарны, һәм, димәк ки, казакъны да XX гасыр башында панисламизм, пантөркизм фәләннәрдә гаепләү, татарны сытып урыска бил бөгү, реверанслар ясау иллә дә мул! Татар теле, дин тәэсирен кызып-кызып штыкка алу һ.б. менә шуларга да кагылырга кирәк булыр.

Планлаштырган эшләрдән тәрҗемә өлкәсендә дә бераз алга китеш бар: Мәшкәр Гомәрев (Алматы татары), Әсгать Мохтар (Ташкент татары) әсәрләрен «аудардым» – кайберсе чыкты да инде. Бер ише әзерләнә, редакция кабул иткән. Уйгыр хикәясе «КУ»да (№ 9, быел), казакъ хикәясе «Соц. Татарстан»да басылырга тиеш. Төрекчәдән (оригинальдән) Г. Нәсинне тәрҗемә иттем. Бер хикәясе инде чыкты.

...эшегездә һәм тормышыгызда уңышлар теләп калучы

*Тәүфикъ Әйди*
*4.09.1975*

Сәлам Чутайдан!

Исәнмесез, кадерле туганыбыз Ибраһим ага һәм Маһинур апа!

Барчагызга да сагынычлы кайнар сәламнәребезне җибәреп, үзләрегезгә таза-саулык һәм озын гомерләр теләп калабыз. Үзеңә Ибраһим ага аерым тазалык һәм аек акыл, иҗади шатлыклы тормыш теләп калабыз!!.

Ибраһим ага! Синең соңгы хатыңны бик шатланып укыдык. Юбилейларың бик матур үткән икән. Рәхмәт андагы җитәкчеләргә һәм җәмәгатьчелеккә, сине тиешенчә хөрмәтләгәннәр һәм зурлаганнар! Бик куандык барыбыз да. Әни бигрәк тә куанды, җылап та алды: «Ибраһим, ичмаса, үзенә хөрмәтне күрә алды исән чагында» диде. Мин әйттем: «Әтиебезне дә хөрмәтләү инде ул», дидем. Шулай бит инде, Син язганнарны олылау, анда язылган кешеләрне дә олылау, хөрмәтләү була ич! Син аларның җан авазын халыкка җиткердең, дөреслекне әдәби тел белән шаһит буларак халыкка җиткердең. Рәхмәт! Әгәр бу әсәреңне чит илләрдә дә чыгарсалар, бигрәк тә яхшы булыр иде. Газеталарда язылган мәкаләләрне укыдым. Бик матур язылганнар. Г. Гришковның «Осень патриарха» дигән мәкаләсе бик әйбәт, тирән язылган. Үзең дә бик тирән җаваплар биргәнсең. Шигырьләреңне укыдым. «Казлар оча», «Күкчәтау» дигәне. Бик матур, моңсу язылган. Татарча, үзебезчә тагын да матуррак, үтемлерәк яңгырар иде.

Ибраһим ага! Нихәлләрдә яшәп ятасыз? Юбилейлардан соң бик моңсу булып китмәдеме? Бирешмә. Әле 90 еллыкны да, 100 еллыкны да каршылап үткәрербез, Алла боерса...

*Сезне хөрмәтләүче һәм сагынып калучы энең Разит, әни һ.б. (Алкиннар)*[1]

*1.11.1996*

Исәнмесез, хөрмәтле Ибраһим ага!

Сезгә хәерле көн һәм ихлас күңелдән сәлам барчабыздан.

Ибраһим ага! Сезне менә кайтырсыз, менә бу якларга килеп чыгарсыз дип көттек-көттек тә тагын хат язарга булдым. Көннәр эссерәк торды шул. Аннан грипп белән дә авыргансыз икән. Бик киң таралган, гади авыру булса да, куркыныч авыру. Тазарып җитмичә йөрү ярамас. Мин үзем дә авырып алдым әле. Шул салкын сулар эчеп авырып киттем. Аннары яшь вакытларда рәтле тәрбия дә күрмәдем инде. Тормыш-үзгәрешләр көннән-көн матурлана баруы, демократия, экономик реформалар, хәзер менә политик системаны

---

[1] Алкин Разит Рияз улы – Татарстанның Балтач районыннан, Татарстан Республикасының атказанган укытучысы, әтисе – Рияз Йосыф улы Алкин – репрессия корбаны.

үзгәртеп кору планнары булачагы яшәгән саен яшисене китерә. Сез дә бирешмәгез. Сез бит шул заманнардагы Ежов-Сталин-Берия палачларының кабахәтлекләренең тере шаһите. Сталинизм иярченнәре илебезне элеккеге юлга төшерү өчен нык тырышалар һәм алар күп әле. Сезнең һәр сүзегез аларны фаш итә, әле газетадан укыдым. Шул чорда Мәскәүдән кешеләрне кулга алырга һәм юкка чыгарырга дип разнарядка килгән. Авыллардан 3000 кешене һәм шәһәрдән күпмедер кешене ликвидировать итәргә. Бу эш өчен Татарстаннан сугышчан совет ордены алганнар бар. Бу бит Сталинның шәхси диктатурасына юл ачкан өчен бүләк?!?!

Ибраһим ага! Бу куштаннарга, бер нәрсә уйламыйча совет кешеләрен кырган башкаручыларга хәзер җәза биреләме икән, юкмы? Бу турыда хәбәр юк... Безнең йомшаклыкка, «барысы да онытылыр әле»гә ышанып эшләделәр бит ул кабахәтләр. Ә хәзер «перестройка» кирәк дип катырак та кычкыралардыр әле...

*Ярый, кабат кайнар сәлам белән Алкиннар гаиләсе*

*22.07.1988*

Сәлам Чутайдан!

Исәнмесез, Ибраһим ага!

Сезгә һәм барлык туганнарыгызга кайнар сәлам!

Сезнең соңгы хатыгызны алдым һәм укып, байтак нәрсә белдек. Туганнарыгыз килеп киткән икән. Әйбәт булган. Туганнар белән очрашу, күрешү, сөйләшү – үзе бер гомер. Күп җирдә кешеләр бу нәрсәне онытыпталар. Туганнар арасында җепләр өзелә. Ә бу гаилә тәрбиясенә суга. Яшьләр проблемалары кыза. Татарлар арасында бу нәрсә азрак булса да, очраштыргалый.

Ибраһим ага! Сезнең китапны башка телләргә дә тәрҗемә итәләр икән. Яшьләр өчен бик гыйбрәтле. Бар бит арада Сталин дип авыз суын корытучылар. Шул чорны мактаучылар бар. Ул режимның кешене ничек мыскыл итүен күрсеннәр өчен бик кирәк китап!

Сезгә хатны больницадан язам. Яшьли бик авырлыклар күрдем инде мин дә. Атнага бер буханка икмәк ашап торылды укыган вакытларда (1948–1950 еллар), аны кибеттән алып булса әле. Ә Казан педучилищесында укыганда (бер ел – 1947–48 еллар) коры сөяккә калдым. Бет, корчаңгы... Аны ташлап, Чепья урта мәктәбен тәмамладым. Мәктәпкә түләргә акча булмагач, 10 нчыда мәктәптән

чыгармакчылар иде. Мәктәп директоры (читтән килгән – авылга сөрелгән кеше) яклап калды. Әтине яклап сүз әйткән өчен дә, сәбәпләре бар иде. Ул әйтте: «Әтиеңне хөрмәт ит, ләкин җыелышларда бу турыда ачык сөйләмә, вакыты бер килер әле», – диде. Мине шул сүзләр өчен комсомолдан да чыгармакчылар иде. Шул директор йолып калды. Тарихтан укыта иде ул. Искиткеч белемле кеше иде, партиягә ышанычны тудырды, партия тарихын ул өйрәтте. 10 нчыны бетергәнче аны тагын каядыр гаиләсе белән озаттылар. Минем аңа рәхмәтем зур!. Һәм менә ул әйткән вакытлар килде...

Ярый, сау булыгыз, кабат сәлам белән сезне көтеп, *Разит.*

*12.09.1988*

Исәнмесез, хөрмәтле Ибраһим ага!

Сезгә ихлас күңелдән безнең барчабыздан кайнар сәлам.

Хатыгызны алып укыдык...

Сезнең китабыгызның басылып чыгуын бик көтәбез. Исеме сезнең тарафтан дөрес уйланган. Ни өчен һаман дөреслектән, үткән тарихтан куркалар?!

«Фаҗига» дөрес исем. Дөрестән дә фаҗига бит, сезнең өчен генә түгел, барлык мәхбүсләр – илебезнең каймагы булган политик, хәрби, совет, хуҗалык кадрлары, гади кешеләр өчен генә дә түгел, сталинизм бөтен ил өчен чын фаҗига булды ич! Аның нәтиҗәләрен ай-һай, ничәмә дистә еллар буе төзәтергә, бетерергә кирәк булыр әле халкыбызга! Ул сез язган лагерьларда-төрмәләрдәге кешенең намусын, кешелеклелеген таптау, кешене хайванга әйләндерү, түбәнәйтү ысуллары коточкыч ич...

Әйе, каршы торучылар – шул заманда рәхәт торучылар да күп шул әле. Чигенеш булмасын иде инде, Ибраһим ага! Алга барсак иде...

*Сезгә ихтирам белән, Разит*

*18.08.1988*

Сәлам Чутайдан!

Исәнмесез, хөрмәтлебез Ибраһим ага!

Сезгә, Маһинур апага, барча балаларыгызга да безнең һәммәбездән кайнар сагынычлы сәламнәр җибәрәбез. Һәм сезнең таза-сау, иҗади тормыш белән матур яшәвегезне телибез!

Мин озак хат яза алмадым. Эшләр дә, борчулар да күп булды... Бәяләр котырынып күтәрелә. Тормышлар кыйммәтләнә бара. Бу хәлләр ниләр булып бетәр дә, кай очка килеп чыгар: социализмгамы, капитализмгамы яки без белмәгән хәтәр төшкәме?

Әйтергә дә куркыныч. Бу Ельцинга ни җитмидер: Горбачевның һәр эшенә каршы төшә. Илебез таралып бетә бит инде! Кая китте бу акыллы җитәкчеләр? Һәрберсе үз амбициясен кайгырта. «Халык өчен» дигән сүз белән Сталин да котырды ич заманында. «Халык дошманы» дигән сүз генә дә ни дәрәҗәдә куркыныч иде. Горбачев шәһәрләрдә тәртип урнаштырырга тели. Ельцин каршы. Демократия бозыла имеш. Демократия белән нишлисең, урамга чыгарга да курыккач?! Җинаятьчеләр ни эшләргә теләсә, шуны эшлиләр. Ә без ирекле дип мактанабыз.

Сез бу турыда ни уйлыйсыз?

Ярый, Ибраһим ага, озак язмавыма гафу үтенәм. Сез безнең өчен бик кадерле кеше.

*Кабат сәламнәр белән, Алкиннар*
*1991*

Исәнмесез, Ибраһим ага!

Сезгә, Маһинур апага һәм башка гаилә членнарыгызга бездән сагынычлы кайнар сәлам!

...Ни хәлләрегез бар, Ибраһим ага? Тазалыгыгыз ничек? Сәламәт һәм таза-сау гына була күрегез, сез безнең гаилә өчен әтиебез кебек бик кадерле, хөрмәтле кешебез. Әле менә язмаларыгыз белән дә безне шатландырып, яшьләрне, халыкны уйландырып торасыз. «Йөрәктәге яралар» дигән язмагыз, дөрестән дә, ямалмаган яра – сарсып-сулкылдап тора. Кайчан ямалсын ул?! Үзгәрешләр бик акрын бара бит, үткәннәрне искә төшерергә яратмыйлар бит «теге»ләр. Йомарга тырышалар, халыкның дөреслекне ахырынача белүеннән, тәмам уянуыннан куркалар. Алар кире кайтуга өметләнәләр әле. Нахакка һәлак булганнарның чын исемнәрен, кешелекле булуларын ачыклап бетерәселәре килми. Шулай да боз кузгалды шикелле, ләкин акрын ага... Сезнең кебек ташкынга юл салучылар, бөялгән урыннарны ватып җибәрүчеләр кирәк. Ташкын шаулап аксын!

Менә мин дә үзебезнең район газетасына бер мәкалә язган идем. Шуның яртысыннан күбрәген кистеләр. Редактор миңа яза:

«Сталинизмны сүгүдән файда юк инде», дип. Соң бит аны яклаучылар күп халык арасында. Аның кылган җинаятьләрен фаш итмәгәч, халык, яшьләр каян белсен дөреслекне! Газеталарның байтагы шулай шомарта әле...

Рәхмәт безне онытмавыгызга. Сезнең язмалар буенча безгә дә иске танышлардан хатлар килә. Исәннәр бар икән әле.

Ярый. Кабат кайнар сәламнәр белән, *Разит*.

*28. 08.1989*

Хөрмәтле Ибраһим ага!

Сезгә нык сәламәтлек, милләтебез өчен армый-талмый хезмәтегезгә дәрт-дәрман теләп, иң изге теләкләрдә калучы Альфред дип белерсез. Сезнең хатыгызны алып укыдым. Халкыбызның азат киләчәге өчен ихлас күңелдән бочылуыгыз миндә Сезгә карата булган хөрмәт хисләрен янә арттырды гына. Кочаклап кысасым килде.

Ибраһим ага! Референдумнар узып киттте. Аллага шөкер, без үзебез дигәнебезгә ирештек. Чын азатлыкны яулап алу юлында бу эш ныклы беренче адым гына. Алда безне тагын бик күп кыенлыклар, сынаулар көтә. Дөньядагы халыкларның бик күбесенә азатлык җиңел генә бирелмәгән бит. Эзлеклелек, батырлык, тәвәккәллек, бердәмлек булса, бөтенесен дә җиңеп чыгарга була. Ә безнең татарда соңгысы җитенкерәми. Милли аң түбән. Сезнең кебек зыялыларыбыздан милли аңны уятуны, аны күтәрүне ихлас күңелдән түбәнчелек белән сорыйбыз. Изге эшләр онытылмас. Искә алучы булмаса да, үкенечле түгел.

Үзебез бер көе яшәп ятабыз. Ялган демократлар халыкның төп өлешен хәерчелеккә төшерде, киләчәккә өметен бетерде. Киләчәккә өметне югалтудан да начар нәрсә бар? Бу бит катастрофа. Халкыбызны туплап, ышандырып торучы көч – ул милли хәрәкәт хәзер. Аны да таркатсалар, нәрсә килеп чыгар? Нәрсә эшләр татар, шуңа күрә милли хәрәкәтебезне күз карасы кебек саклау, аңа ярдәм итү – беренче бурычыбыз.

Язлар җитте. Табигать яшәрә, яңара. Тормышларыбыз да яшәреп, яңарып, матурланып китәр әле. Ышанычсыз бер шайтан, диләр бит.

Казан үзенә тартып тора. Магнит кебек. Шушы арада барып, иптәшләрне күреп килергә исәплим. Барган саен барасы килә,

һәрвакыт беренче барган төсле бу Казанга. Нинди генә серләре бардыр бу Казанның!

*Сезгә иң яхшы теләкләр белән, Альфред (Әлмиев)*[1]
*25.04.1992*

Хөрмәтле Ибраһим ага! Сезгә, барлык гаиләгезгә нык сәламәтлек, эшегездә чиксез уңышлар теләп калам...

Дөнья кайный, кая таба тәгәри, ни күрербез – бер алла белә. Әнә бит милли азатлык хәрәкәтен җимерер, юкка чыгарыр өчен нәрсә генә эшләмиләр. Россияне Татарстан гына куркытмый, империянең бөтенләй юкка чыгу мөмкинлеге куркыта. Халыклар төрмәсен саклап калу бурычын куйдылар бит! Ельцинның «Россия обязательно возродится» шигаре шул бит. 70 ел социалистик милләт тудыру өчен көрәш юкка булмаган. Әнә бит Россия составындагы милләтләрнең милли үзаңнары ничек зәгыйфь. Кызганыч хәтта. Азатлык байрагын әйдәп баручы татарларда да бердәмлек юк, ә барыбер чын азатлыкны күрәсе килә. Милләтнең шаулап алга баруын күрәсе килә. Минем әби халык авыз иҗаты әсәрләрен сөйләргә, көйләргә бик яраткан, шуңа маһир булган. Әти шулай сөйли торган иде. Ул «Сөембикәне озату « бәете әйткән. Анда менә мондый юллар булган: «Тагын да мин кайтырмын, таягымны алырмын». Мәскәүгә заложник булып киткәндә үзен озатырга чыккан, зар елаган халыкны тынычландырган. Никадәр оптимизм! Халык үзе уйлап чыгарган сүзләрме? Хак сүзләрме?

Менә бит безнең халык таякны яңадан алуга ышанып яшәгән. Бөтен авырлыкларга түзгән. «Таягымны алырмын!». Алынса иде шул таяк...

Ибраһим ага! Сезгә кабат нык сәламәтлек, иҗади уңышлар, көр күңел теләп, *Альфред (Әлмиев).*

*1991*

Әссәламегаләйкем хөрмәтле Ибраһим ага!

1–2 февральдә Казанда Бөтентатар корылтае үтте. Бу турыда матбугат азрак язды, танышкансыз. Шунда катнаштым. Никадәр

[1] Альфред Әлмиев – Татарстанның Яшел Үзән районы Акъегет авылыннан. Шул районның Күгеш урта мәктәбендә татар теле һәм әдәбияты укытучысы булып хезмәт иткән.

борчулар, никадәр дулкынландыргыч мизгелләр булды. Сөйләп кенә бетерерлек түгел. Үзең башыңнан кичерсәң генә аңлап буладыр. Татарстанның мөстәкыйльлеген игълан итү үзе генә дә ни тора! Бөтен зал аягүрә баскан, барысы да кул чаба, «Азатлык! Азатлык!» авазлары яңгырый. Кешеләрнең йөзләре шат, күз яшьләре тама. Шатлыктан, күптән көткән шатлыктан иде алар. Бик күп нәрсә алдым үзем өчен. Татар көчле, татар хәтәр! Бәлки сездән дә делегатлар булгандыр... Әле корылтайдан алган тәэсирләрдән аерылып булмый. Үзебез эшлибез, укытабыз. Кыш узып бара. Тормышлар гына җиңеләйми. Яхшырасы күренми дә. Чын мөстәкыйльлек алсак, башкача булыр иде ичмасам.

Корылтайда Фәүзия Бәйрәмова белән Зәки Зәйнуллинга аерым хөрмәт күрсәтелде. Делегатлар бик олыладылар үзләрен. Кул чабып, «Азатлык!» авазлары астында «Коръән» бүләк ителде. Фәүзиягә бөркәнчек бөркәндерделәр. Халык үзенең җитәкчеләрен онытмый.

*Сезгә иң изге теләкләр белән Альфред.*
*20.02.1992*

Хөрмәтле Ибраһим ага!

Сездән җавап алуыма чиксез шат булдым...

Сезнең «Тайгак кичү» «КУ»ында чыга башлагач, исәрләндем бит. Дәвамын ничек көтәргә?

Әллә редакциягә барып сорап карыйммы икән, дим. Бирмәсләр, дидем. Ә сезнең Галимҗан Ибраһимов, Шамил Усманов, Мохтар Мутиннар турында язганнар миңа күптән билгеле. Әтием сөйли торган иде. Ул каян белгәндер, белмим. Усмановның ничек үлүе турында күптән түгел генә яздылар. Әтинең инде үлүенә дә чирек гасыр була, 1966 да үлде. Укытучы иде. Шул авыр елларда педтехникумда укып йөргән ул, аралашмый яшәмәгәндер. Әйе, дөреслекне вакыт кына таба икән. Дөреслекне раслау зур корбаннар сорый икән. Нәрсә генә дисәң дә, дөреслек тантанасы – иң зур бәйрәм. Ә сезнең кебек көтеп алучылар өчен, бик аз шаһитлар өчен нәрсә дә дип атарга да сүз табып булмый. «Колыма хикәяләре»гез өчен рәхмәт сезгә!

*Күп сәламнәр белән, Альфред Әлмиев Хәйрулла улы*
*Акъегет авылы, 25.09.1989*

Здравствуйте, уважаемый Ибрагим Низамутдинович!

С огромной благодарностью и с наилучшими пожеланиями Аминев. Ваше письмо очень и очень меня и вдохновило. Действительно, такие личности, как Салах Атнагулов, не должны быть забыты и наш долг – возвратить культуру нашего народа. Ваши воспоминания о С.Атнагулове и других незаслуженно забытых выдающихся деятелей помогут заполнить то пробел нашей истории, который был ей нанесен культом. Я продолжаю работать над изучением творчества С.Атнагулова и одновременно – его земляке и товарище, вам также должно быть знакомо его имя – Газыма Касымова, в 1917–19 г.г. одного из организаторов советской власти в нашем Белебее, затем – видном государственном деятеле БашАССР, в тридцатые годы – ТАССР. Я был бы Вам очень благодарен, если вы вспомните и о нем. И еще один вопрос – не знали ли Вы Ахата Ахметова, тоже из Белебеевских краев, тоже уехавшего в Татарию?

Извините за обилие вопросов, но без них историку-краеведу не обойтись. Еще раз Вам большое спасибо и всего хорошего.

*Т. Аминев, председатель Совета музеев «Школа и революция» и историко-краеведческого г. Белебея.*

*(Вакыты күрсәтелмәгән)*

Ибраһим дус!

Сәлам сиңа. Гаиләңә сәлам. 23 октябрьдә (1986) язган хатыңны 27 сендә алдым. Менә бүген 29ы җавап язам. Инфарктан котылгансың икән. Инде бик сакланырга кирәк. Мал-туар карарга ярамый инде сиңа. «Күптән күрешмәгән идек, инде менә, ниһаять, үзең килеп кердең...» дип язасың. Ул миннән хат алу турындамы?

Мин хатымда «Книга почтой»га керүем, сиңа китаплар җибәрүне тизләтергә тыруышымны язган идем. Китапларны җибәрделәрме соң?

Аннан: «Газраил бугаздан алган иде, көчкә котылдым, аннан 45», дигәнсең. Синең хатларыңны тиз генә аңлап булмый... Берни дә аңламагач, аптырап язуым, аңлатып яз.

Ә яшькә килгәндә: мин дә бит 1911 елгы, сентябрьдә. Официальный – 1912 дә. Син миннән бер-ике айга олымы, кечеме – анысын белмим. Ел белән кордашлар. Мин аны өйдә генә үткәрәм – 75 не. Официальный киләсе елга була.

Союз хәзер, син әйткәнчә, безнең элекке тулай торак урамында һәм янында. Әле рәте юк. Ремонт булырга тиеш.

Тукай альбомы сатуда да юк. Вакытында алалмый калдым. Атилланы күргәч, әйткәннәреңне тапшырдым.

Көз быел да озак килде. 5–8 градус җылы, кояшлы. Яшелчә, җиләк-җимеш бик уңды.

Тиздән бәйрәм. Ләкин син әйткәнчә, аракысыз бәйрәм булмас инде. «Бәйрәмнәрне аек акыл белән каршыларга насыйп булсын!» дигәнсең. Акылсызның аек килеш тә, эчкәч тә акылы булмый инде аның...

*Күп сәлам белән Нури (Арсланов)*[1]

*Казан, 29 октябрь 1986 ел*

Ибраһим туган!

Күп сәламнәр. Мине белгән дус-ишкә сагынып сәлам. Соңгы хатыңны бер көн элек алган идем. Менә хәзер генә кул тиде. Гаҗәп, бернигә өлгереп булмый...

Син язган хәлләрне мин шулай күз алдына китергән идем дә. Ул киндер орлыгы шундый дефицит әйбергә әйләнгән шул, ярый әле миңа Закирның кызы Клара җибәрде. Ул Львов шәһәрендә тора. Украинада бар икән. Мин бу әйбер белән сине шактый борчыганмын икән, гафу ит.

Син үлгәннәрнең исемен санап, инде чират безгә дигәнсең. Мирсәй Әмир үлгәч, без дә бер 6–7 карт язучылар бер читтә тезелешеп утыра идек. Мәхәммәд Садрый килеп, аптыраганнандыр инде:
– Нишләп утырасыз? – диде. Мин уйлап-нитеп тормыйча:

– Чират көтеп утырабыз, – дидем. И көлештеләр. Шуның кебек син дә көлдерәсең. Үлсәк ни, калсак ни?! Хәзер инде яшен яшәгән, ашын ашаганнардан бит без!

Бу печәнсез кышта мал-мөлкәтеңне саклап буламы? Китабың чыккан икән Алма-Атада, котлыйм. Хак булса, киләсе елга минеке дә чыгачак.

*Ярый, хәзергә саулык теләп, Нури (Арсланов)*

*17 февраль 1983*

---

[1] Нури Арсланов (1912–1991) – татар шагыйре, Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты (1985), И. Салаховның якын дусты, сабакташы. Фондта 80 гә якын хаты саклана.

Ибраһим дус!

Хатыңны алдым. Больницадан язгансың. Тагы ни булды? Сакланмыйсың бугай. Безнең хәлләр хәзер саклануга бәйләнгән... Нишлисең, вакыттыр шул инде.

Син хатыңда элекке кирелегеңне саклап, мине орышкандай, миңа үпкәләгәндәй итеп язгансың, фәлән-төгәннәр белән чәнечкәләгәнсең. Моннан куркып торырга, бу мәсьәлә моннан берничә еллар элек хәл ителгән нәрсәләр дип уйлый идем мин. Чөнки мин аның сәбәбен синңа сөйләп күрсәткән идем, ышанмаган икәнсең. Монда бит мин түгел, баш каһарман – Клавдия Тихоновна. Мин теге вакытта: син – дус, ә Клава – хатын, ул синең бездә булуыңны кабул итми. Мине ике ут арасында калдырма, дип әйткән идем шул. Шул турыда күпме сүз булса да, хатын-кызны җиңеп буламыни?! Менә шуңа күрә, син минем бу хәлемне яхшы беләсең дип уйлап, сиңа киңәшләр язганмын икән, ләкин бу киңәшләрне язганда мин элекке аңлашуны бер дә истә тотмаган идем, чын-чынлап дөрес киңәш, файдалы киңәш дип уйлаган идем. Син аны башкача аңларга тырышкансың. Кызганыч!..

Ничә еллар буена шул бер балык башы!..

Ярый, сәламәтләнеп чык, юк-барга борчылма. Минем дә үз хәлем үземә җиткән. Элекке көр күңелле, шат Нури юк инде диярлек. Ялгызлык, җан бушлыгы һәм төрле авырулар борчып тора. Менә ярам ачылды, көн дә бәйлим. Гаҗәп, 40 елдан соң ачылыр икән... Диабет, аденома авырулары. Хәтта яшәүдән дә туйдым инде... Зарланып язуым түгел, ни булган байлыгымны язуым. Менә шулар.

*Сәлам белән, исәнлек теләп Нури (Арсланов).*

*Казан*

*13 декабрь 1986*

Ибраһим дус!

Күп сәлам. Гаиләңә сәлам диярсең. Язган хатыңны алдым. Казанда йөрәк авырттырып, Күкчәтауга кайтып төзәткәнсең икән, шәп булган. Төзәлгәч, ярый инде. Моннан соң бераз саграк кыланырсың инде.

Кичә Казанда Кол Галинең 800 еллыгы үткәрелде. Академия театры шыгрым тулы иде. Бик шәп үтте. Аның хакта Юнеско зур мәкалә чыгарып, бөтен дөньяга тараткан икән. Мәскәүдә дә юбилей

уздырылачак, ди. «Кыйссаи Йосыф»ны русчага тәрҗемә итәләр. Ул китап хәзер быел Казанда үз телендә, хәзерге татар телендә һәм рус подстрочнигы белән чыгачак. Ә шигыре тәрҗемәсе, әлбәттә, соңгарак чыгар инде.

Ә теге Аяз әйткән минем шигырьләрем – мин аларны телевизордан үзем сөйләдем. 40 минутлык чыгыш булды. Күпләр котлап шалтыраттылар, хатлар яздылар, әйбәт, диделәр. Аллага шөкер!

Менә хәзергә шулар, сәламәтлекләр теләп, *Нури Арслан.*

*Казан*
*13 октябрь 1983*

Ибраһим дус!

Барчагызга күп сәлам. Хатыңны алдым. Сездә яңгырлар икән. Бездә дә яңгырлар быел аз булмады! Ләкин сездәге кебек үк түгел. Үзебез Ригага ялга китәргә җыенабыз. Ничек булып чыгар!.. Врачлар ни әйтер?.. Син Рөстәм Мингалимов турында сорагансың, ни дип әйтим: хәзерге заманның әйбәт кенә шагыйрьләреннән берсе. Сиңа кире рецензия язгандыр инде, белеп торам. Алар бик таләпчән: үзләренә дә шулай булсалар, бик әйбәт булыр иде дә бит... Нишләмәк кирәк... Башка төрле хәлләребез дә бу арада булып алды: секретаребез Вәлиев, пропаганда бүлеге мөдире Мусиннар пенсиягә китте. Хәзер яңа кешеләр.

Үзем Гомәр Хәйам робагыйларын 1986 елга кертергә ирештем – 9 елдан соң. Аны Шәүкәт Гали яткырды. 10 табаклык үз шигырьләремне бирдем, ничек булыр?! Сәламәтлек ярыйсы.

*Нури Арслан.*

*Казан*
*4.09.1984*

Ибраһим!

Сәлам. Мин 27 сентябрьдә кулъязмаларны машинкадан алып Күкчәтауга җибәрдем. 28 сентябрьдә синнән хат алдым. Шулай итеп, кулъязмалар сине монда түгел, ә өеңдә, Кызылъярда көтеп ятачак. Элекке гадәт буенча, югала-нитә күрмәсен дип, бер экземпляр (машинкада басылганын) үземдә калдырдым. Нигә соң миңа Переделкинога китәсеңне әйтеп хат язмадың?! Ул чагында мин

барлык экземплярларны да үземдә тоткан булыр идем... Узган эшкә салават...

Нәшрият белән минем араларым бозылды... Мин анда бер хакка да күренәсем дә, сөйләшәсем дә килми. Синең китабың чыгып җитсә, тоткарлык булмас, акчасын бирерләр. Бу мәсьәләдә минем әллә ни кирәгем дә юк. Үзең килгәч сөйләшерсең яки турыдан-туры Шәрәфетдинов Гарәфкә хат яз, бәлки файдасы тияр. Атилла хәзергә өендә юк әле. Кайчан кайтасын белмим. Бәлки син килүгә ул да кайтып җитәр.

Бездә хәзергә исәнлек. Минем хәлем түзәрлек. Тора-бара тагын нишләр. Күңел тыныч түгел: карчыкның бозылып китү мөмкинлеґеннән куркам. Нишләмәк кирәк?! Әле һаман үзем теләгән теге зур эшемә тотынырга туры килмәде, шулай да буш утырмыйм – шигырьләр язам.

Нәшрият елдан-елга планнан сызып-төшереп аптыраткач, өйгә кайтып, шигырьләремне укып, аралап утырганда, китап кырыена бер экспромт язып куйдым:

Шигырьләрем әйбәт булгач
Җаным тыныч!
Акчасы булмаса-булмас
[...]
Менә шулай хәзер минем хәлләр.

*Күп сәлам белән, дустың Нури (Арсланов)*

*Казан, 29 сентябрь*

Ибраһим дус!

Син мине ялкаулыкта гаеплисең. Билләһи, хат язу түгел, шигырь язарга да вакыт юк!

25 мартта съездга чакырганнар үзеңне, менә шунда барысын да белерсең. Фатихның 60 еллыгы әйбәт үтте, татар театрында. «Казан» ресторанында банкеты булды.

Синең Әбдрәшитов абзый турындагы очеркың чыкты. «Ук җитмәс» киләсе саннарның берсендә чыгачак. Ә «Иртә»не бездә кабул итеп җиткермәделәр ахрысы. Хикәя дә түгел, очерк та түгел, дип аптыраган булалар. «Азат хатын»нан белешермен, анда ничек икән.

Зәки иҗат йортына түләрлек кенә акча бирергә әзер. Шулай булгач, Литфонд белән генә сөйләшәсе калды. Син монда 25 нә

килсәң, 3–4 көн съезд булса, димәк 1–2 апрельләргә путевка кирәк булачак. Ялта сиңа обязательно түгел бит.

Безнең редакторның ярдәменә өмет итә күрмә. Ул әйберләреңне бастыру турында әйтергә теләгән, бары шул гына.

Хәзергә менә шулар.

*Сәлам белән Нури Арсланов.*
*15.03.1988*

Ибраһим дус!

Сәлам! Гаиләңә күп сәлам әйт. Котлавыңа рәхмәт. Бик күп бәйрәмнәр бергә килеп, башлар әйләнсә дә, әлхәмдүлиллаһ, үз урынында калды! Тантана бик тантаналы узды. 26 апрельдә, шигырь бәйрәме митингысы вакытында, Тукай һәйкәле янында котладылар һәм миңа сүз бирделәр. Митингтан соң әзерләнгән өстәлгә җыелып утырдык. Мин көтмәгән кызыклы чыгышлар булды. Барысы да: «Күптән кирәк иде!» – диделәр. Ләкин нигә күптән үк бирмәгәннәренә тәки төшенмәдем. Хәерле булсын!

Саклау кассасында акчам беркадәр булса да, мин аны срочный итеп салганга күрә, ваклап алып булмый. Бөтен маяны куптарырга туры киләчәк иде. Әлеге лауреатны юар өчен инде. Шуннан нишләргә? Минем күмәргә һәм поминка үткәрергә дип конвертка салып куйган акчам бар иде. Шул искә төште. Шуны алдым да, «за упокой» урынына «за здравие» эшләдем – лауреатны юдым. Шуннан мондый робагый да яздым:

Җыйдым акча мине җирләү өчен дип,
Белеп булмый үлем-җитем эшен дип;
Диде дуслар: юыйк без лауреатны,
Ә юк-барны оныт, җилгә очыр!, дип.

Бу ике айда мин 80 нән артык робагый яздым. Гомәр Хәйамның варисы булырга телим. Шулай, минем турында барлык газетлар русча һәм татарча мәкаләләр язып чыктылар. Мин сиңа да газета җибәргән идем. Аны үзең укыгач, теге безнең музейлы мәктәпкә бирерсең, дигән идем. Тапшырдыңмы? Бу хакта берни дә язмагансың. Шигырь бәйрәменнән соң май бәйрәме. Аннан 9 май бәйрәме! Шулай итеп бәйрәмнәр күп иде. «Аккош күле»ндә зур банкет булды. Нигездә ветераннар мәҗлесе иде.

Кырык еллык бәйрәмгә медаль бирделәр. Орден да бирәчәкләр: мин яралы, миңа беренче степень булачак. Көзгә таба булыр, диләр.

Әле Тукай бүләге медален һәм акчасын алганым юк. Ул да көзгә таба, диләр.

Менә шушы айның 11 ендә карчык белән ялга китәргә җыенабыз, аннан июльдә генә кайтырбыз инде.

Көннәр бездә дә, сезнеке кебек булмаса да, бик алама. Һаман салкын. Бакчага барганым да юк. Барасым да килми.

Сәламәтлек ягыннан хәлләр ярыйсы гына. Мин үземне хәзергә әйбәт сизәм.

Романыңны Алматада тәрҗемәгә калдыруың турында мин котлап, сиңа яңа уңышлар теләп хат язган идем. Тагын бер кат котлыйм. Уңыш телим.

Казанда Туфан Миңнуллин – язучылар союзы рәисе булды. Ахуновны алдылар. Бүтән әллә ни яңалыклар юк дисәм дә була. Менә хәзергә шулар.

*Ихтирам белән Нури (Арсланов)*

*9 июнь 1985*

Ибраһим дус!

Үзеңә һәм Маһинурга, балаларга күп сәлам. Бер-бер артлы килгән бәйрәмнәр белән котлыйм. Некролог-фәлән эзләмә газетлардан, мин әле ул хәлдә үк түгел [...] Журнал миңа килде, мин аны бер утыруда укып чыктым. Минемчә, әллә ни кеше кулы тимәгәнгә охшый. Бик кирәкле әсәр! Журналны киоскларда кулга төшерү бик кыен, үземдәге бер генә нөсхәне Мәскәүгә җибәрергә уйлыйм. Рәшит Әхмәтханов сиңа бер журнал җибәргән. Мин аңа ул әз – бер-ике сан җибәр, дидем. Белмим, булдыра алырмы. Ул «Казан утлары» редакциясендә эшли. Хатыны шунда яза. Лучше поздно, чем никогда, диләр бит. Мин дә эләктерә алсам, җибәрермен.

Син: «Мин сиңа абый кеше», дип язгансың. Икебез дә 11 елгы бит. Син кайсы айда?

Истәлекләреңне тәртипкә китерүең яхшы эш. Мин дә истәлекләр, төрле мәкаләләремне туплап бер китап әзерлим һәм бик күп шигырьләр тәрҗемәсеннән китап нәүбәт көтеп тора.

Онытмас борын сорыйм әле, теге следователь Бикчәнтәевнең исемен белмисеңме? Хәйретдин түгелме? Мине бер мәсьәлә

кызыксындыра. Аннан китабыңда минем «күрәзәчәлегем»не ник эләктереп китмәдең. Мин бит сиңа: «Ибраһим, кит син моннан. Газетада исеме чыккан (каралып) кешене кулга алалар. Син гаепсез кеше, уголовник түгел, ә гаепсезне эзләп тормаслар, кит Казаннан» дигән идем бит. Мин үзем шулай эшләдем бит. Төркестанга, Закир янына киттем, бәлки мине алмаслар да иде (партиясез кеше идем), ләкин киттем. Син Мәскәүлеләрне орышыбрак язгансың. Ярый инде, картаялар бит алар да... җәйдә күрешербез дип өметләнәм. Сәламеңне тапшырырмын. Аңа кадәр бәлки үзең дә элемтәгә төшәрсең әле.

Газизәләргә һәм башка таныш-белешләргә сәлам.

*Үзеңә уңышлар теләп, Нури (Арсланов)*
*Казан, 16.04.1988*

Хатыңны бүген алдым, бүген җавап яздым. «Тайгак кичү» белән молодец!

Исән бул.

Һәр ни теләсәң, шул кабул булсын! Амин!

Ибраһим дус!

Сәлам. Синең белән бергә «Ирек» авыруларын бергә кичергән Маһинурга күп сәлам!

Ниһаять, 6 санны алып, синең «Тайгак кичү»еңне укып чыктым. Журналны көтеп алалар. Менә ул «халыкка кирәк» әйберне язу! Син аны, әлбәттә, «Тайгак кичү» дип калдырма. Ул Сәкен Сәйфуллин язган китапны хәтерләтә. Берәр башка исем тап, бәлки «Тиран типкесендә» диярсең. Уңышыңа шатланганга күрә, мин беренче хатны, үзең әйтмешли, «бик оператив» яздым. Инде китап булып төгәл чыгуын көтәм. Ни әйтсәң дә әйбәт булды әле бу дөньяларның үзгәреп китүләре.

Сиңа күп хәер-дога белән яңа уңышлар теләп калам. Әле бит синең бу хроникаль материалыннан башка бик күп эпизодларың бар. Син алар турында уйла һәм кечкенә хикәяләр итеп яза башла. Кирәк әйбер – халык күбрәк белсен. Аларда гыйбрәтле дә, кызыклы да, фаҗигале дә күренешләр күп булырга тиеш. Шулардан бер ун гына хикәя язсаң да, зур уңышың булыр! Һичшиксез!

Ярый, дус. Хәзергә шулар. Исәнлек теләп Нури.

Үзем бик каты авырыйм. Больницада аяклар белән ятып чыккач, хәл бетүләр көчәйде. Бернигә дә ярамыйм, икенче катка көчкә менәм. 5 кило әйбер дә күтәрә алмыйм. Авыргач, хәлсезләнгәч, кызыл авызларның берсенә дә кирәкмисең икән... Карчыкка инде 80 тулып китте...

*Сәлам белән Нури (Арсланов)*
*Казан. 10 июль 1988*

Бездә коточкыч эссе. Качар урын юк. Җил әсәре юк. Көн дә 30–37 С.

Мөхтәрәм Ибраһим!

Бу хатны ничек башларга мин бераз аптырап калдым. Ибраһим иптәш, дип язсам, как-то это официально эндәшү, Ибраһим дус дип язсам, безнең арада дуслык әле тулы мәгънәсе белән тумаган. Үзара хат язышсак, бәлки дуслык та туар. Ибраһим туган дип башласам, безнең арада туганлык каны да юк. Ибраһим әфәнде дип язсам, шулай ук килешле түгел, чөнки әфәнде дигән сүз господин дигән сүзгә күп ошый. Шуңа күрә Ибраһим мөхтәрәм дип башлыйм. Мөхтәрәм дигән сүз уважаемый, многочтимый мәгънәсендә булырга тиеш. Сезгә күптән-күп сәлам. Шулай ук сезнең иптәшегез Маһинур ханымга бездән күп сәлам. Сезләргә тулы сәламәтлек, матур көннәр теләп калабыз. Сезнең 22 февральдә язылган хатыгызны алдык. Зур рәхмәт. Казан, Алабуга һәм башка шәһәрләр һәм районнарга барып, күп халык белән очрашкансыз. Безнең татар халкының әдәбиятка зур әһәмият бирүләре безне бик шатландырды. Ерак җирләргә барып, поезд, самолет, автобус, машиналар мәшәкатен үткәрүләр сезгә бик җиңел булмагандыр. Сезнең зур мәшәкатьләр белән юл йөрүегезгә без, бер яктан, восхищаемся, икенче яктан, горурланабыз...

Сез мине гафу итегез: сезнең «Колыма хикәяләре» дигән әсәрне мин укымадым. Гөлия төннәр буенча укып, аның эчтәлеген миңа күп сөйләде. Аннан башка да Сталин белән бәйле булган хәл-әхвәлләрне мин күп ишеттем. Ләкин эш башкада. Роман татар телен боза-боза рус хәрефләре белән язылган. Анда сезнең гаебегез юк. Замананың соравы шулай. Тик менә шундый романнарны, әсәрләрне укырга күңел ятмый. Татар журналларында, татар газеталарында чын татар сүзләрен бозып, рус хәрефләре белән

язалар. Шул романнан берничә мисал китермәкче булам. Мәсәлән, кадак дигән сүзнең мәгънәсе юк. Әгәр дә аз гына үзгәртеп қадақ дип язылса, аның мәгънәсе һәркемгә мәгълүм. Тагы да бер мисал: кул дип язылган сүз «рука», то ли это «озеро» яисә аерым язылган «кар» – бу ни дигән сүз. Әгәр дә қар дип язылса, каждый знает, что это снег.

Шулай ук غ хәрефен گ гә алыштыру да мәгънәсез. Бу хакта казаклар татарга караганда күп уздырганнар. Казак телендә ک һәм ق хәрефләре үз урынында. Сыер дуласа, аттан да уздыра, дигән мәкаль бар. Шуның шикелле безнең татар галимнәре татар телен рус теленә якынлаштырып, кирәгеннән артык узып киткәннәр булырга ошый, (минем уемча). Татар телендә *ы* хәрефе юк. Татар сүзләрен рус хәрефләре белән язганда *ы* хәрефе кулланыла. Мисал өчен, бардым, килдем. Не зная специфики татарского языка, попробуйте правильно произносить эти слова.

Шәһәр халкы арасында туган тел – татар теле юкка чыгып бара. Яшьләр, күбесенчә, татар телен белмиләр. Соңгы көннәрдә өйрәнергә тырышып яталар. Язуны рус хәрефләре белән түгел, гарәп хәрефләре белән өйрәнергә тырышалар. Миңа да көтмәгәндә бер эш табылды. Аларга дәреслекләр төзеп маташам. Күкчәтауда газеталарда басылып чыккан әсәрләрне безгә җибәреп торалар. Димәк, сезнең иҗат белән без күптән таныш...

Хатта кайбер урыннарда русча язылды. Гаеп итмәгез, мин бала чакта татарча дини мәктәптә укыдым. Аннан ары һәрдаим русча укырга туры килде. Башта төрле курсларда, институтта, 2-3 ел армиядә руслар арасында булырга туры килде. Бер вакыт рус телен укытып та маташтым, шуңа күрә рус теле якынрак булып күреләә. Гәрчә татар телен бик яратсам да.

Элекке татар мәктәбен, клубларны яңарту һәм мәчет төзүләр турында язасыз. Безнең шәһәрдә дә татар халкы бик күп. Яшь муллалар бар дип сөйлиләр, хәзерге заманның дин башлыклары зур укыган кешеләр, диләр. Шәһәрдә зур мәчет салмакчы булалар. Мәчетнең, аның каршында татар мәктәбе һәм башка биналар салдыру проекты төзелгән. Мәскәүдән рөхсәт килгән, диләр. Заманнар хәзер үзгәрде. Һәрхәлдә, татарның һәм русның дин башлыклары яхшылыкка өндиләр. Хәзерге вакытта начарлык эшләүчеләр күбәеп китте. Алладан да, шәйтаннан да курыкмыйлар. Төрле җинаятьләр кылу еш була башлады. Безнең законнар көчсез булалар. Чиркәү,

мәчетнең өндәүләре бик кирәкле булып чыкты. Ярар, хәзергә җитеп торсын, юк-бар сүзләр белән сезнең башыгызны катырдым ахры. Гаеп итмәгез.

*Сәлам белән Габдулла (Арсланов)*[1]
*3.03.1990*

Мөхтәрәм Ибраһим һәм Маһинур ханым!

Сезгә күп сәлам. Сәламәтлек телибез. Яңа ел тормышыгызга зур уңышлар китерсен. Язган хатыгызны һәм яңа ел белән тәбрик открыткасын алдык. Безне онытмый язып торыгыз. Сезгә зур рәхмәт. Безнең тормышта үзгәрешләр юк. Бер көенә торып ятабыз. Көн уза, чабата туза, дигәндәй, дөнья хәлен күзәтеп йөрибез, әле исәннәрбез...

Безнең шәһәрдә аена бер мәртәбә радиодан татар телендә чыгыш була. Тыңлыйбыз. Бер чыгышта безнең мулла кычкырып коръән укый. Икенче чыгышта Омскида салыначак мәчет турында күп сүз булды. Аннан соң бер чыгышта Харбиннан күчеп килгән бер татар карты 500 дән артык татарча китапларны васыять итеп калдырган, шулар арасында Ф. Әмирхан, Г. Тукай, С. Рәмиев, С. Сүнчәләй, Г. Ибраһимов, Г. Камал, К. Тинчурин һ.б. атаклы татар язучылары әсәрләре, гомумән, зур байлык булган. Шул китапларны рәткә китерүче, теләгән кешеләргә бирүче библиотекарь кирәк, дип сөйләделәр.

«Умырзая», так называется татарский ансамбль, работает на общественных началах. Слава им!

Ансамбль ара-тирә концертлар да бирә икән. Халыкка бик ошый дип язалар. Миндә үзем дә катнашырга тырышкан булып берничә җыр яздым (уйлап таптым). Шул җырларны русчага тәрҗемә иткән булдым (шуточный перевод). Мәсәлән:

Ике куян печән чаба су буенда инештә,
Шатланыр куян халкы, булыр печән дус-ишкә.

Тәрҗемә:

Две зайчишки косят сено у речушки – инештә
Рады зайцы: без талона будет сено дус-ишкә.

[1] Габдулла Арсланов – Омск шәһәреннән, милләт җанлы шәхес, фондта 10 нан артык хаты саклана.

Ике килен-килендәш, икесенә бер киңәш
Икесенә бер киңәш: ниләр булыр кич килгәч.

Тәрҗемә:

Две невестки – килендәш, одна забота, бер киңәш.
Одна забота, бер киңәш – ой, что будет кич килгәч.

Шундаен тәрҗемәләр, җырлар утыздан артык. Бу көннәрдә на злобу дня берничә җыр яздым. Мәсәлән:

Аклы ефәк күлмәгеңне кигәнеңне күрмәдем
Көпә-көндез зур урамда салдырдылар күлмәгем.

Аннан урманда үткән сабан туе турында да берничә җыр яздым. Мәсәлән:

Притащили мишке меда, шоколада, мармелада.
Ждут должностей высоких и повышений оклада.
Волк с волчицей лихо пляшут у народа на виду
Если любишь – признавайся, в лес тебя я уведу.
Выпил чарку, выпил вес – расхрабрился наш косой
Не боюся я медведя и волчицу с лисой.

Юк-бар яза дип гаепләмәгез.

Күкчәтаудан еш кына хат-хәбәрләр алып торабыз, баҗа язып тора. Күкчәтауны без бик сагынабыз:

Күкчәтауда киң урамнар, анда тора туганнар,
Бар туганнар тигез килгән, бар туганнар уңганнар...

Шуның белән хатым тәмам. Хуш, сау булыгыз. Хат язып торыгыз.

*Зур сәлам һәм ихтирам белән Габдулла Арсланов*
*8.01.1991*

Мөхтәрәм Ибраһим кардәш, мөхтәрәмә Маһинур ханым!

Сезләргә күптән-күп сәламнәр юллыйбыз. Шат-сәламәт булыгыз. Шәүкәт Шакиров аркылы җибәргән газетаны алып укыдык. Сезгә зур рәхмәт. Безнең тормышта артык үзгәрешләр, яңалыклар юк диярлек. Тормыш тәгәрмәче үз нәүбәтендә тәгәри бирә. Без авырып торабыз, ахрысы картлык баса килә. Мин үзем артык чыгып йөрмим, бөтен авырлык Гөлия җилкәсенә төшә, гәрчә кызлар да

килеп ярдәмләшәләр. Аларның да үз гаиләләре, шуңа күрә артык мәшәкатьләргә теләмибез аларны. Кемнең кай җире авырый, ул шул турыда сөйли дигәндәй, мин дә үзебезнең авыру турында язам. Безне тын кыса, Гөлиянең башы әйләнә, аяклары авырый. Дәваланабыз. Азык-төлек яклары хурларлык түгел, мохтаҗлык юк. Иртә иртәрәк барсаң, сөт, каймак, куе сөт һәм башкача тәгамнәр булып тора.

Сезне үткән гает бәйрәме белән тәбрик итәбез...

Бер картлыкта, бер яшьлектә дигәндәй, мин төрле хикәяләр яза башладым. Үзем өчен язам, чөнки алар басу өчен ярамаячаклар.

Названия рассказов интригующие, на мой взгляд. Например, «Краешек счастья», «В порядке исключения», «Смотри ты у меня», «Самый», «Верный петух», «А кони его кусают» и другие.

Хикәяләрне мин рус телендә язам. Вакыты белән татарчага да тәрҗемә итәргә уйлыйм.

Көн-айлар июньнең яртысына кадәр бик эссе булды. Җирләр корыды. Бакча җимешләре сусап торсалар да, төрле яшелчә, җиләкне ашап торабыз.

Бездә аена ике мәртәбә радиодан татар телендә чыгыш була. Безнең шәһәрдә татар телендә гәзит чыгармакчы булалар. В добрый путь! Хәерле булсын! Әле кайчан гәзит чыгара башлавы мәгълүм түгел. Вакыт тапсагыз, Күкчәтауда татар мәдәниятенең үсүе турында бәлки язарсыз. В порядке обмена опытом.

Шуның белән тәмам. Хуш, сау булыгыз.

*Зур сәлам белән «без» (Габдулла Арсланов)*
*24.06.1991*

Хөрмәтле Ибраһим ага!

Сезгә багышланган шигырьнең бер иҗеген бозып басканнар, аның мин язганы болай иде:

Ибраһим Салаховка.

Себерләргә-сөргеннәргә барып,
Салкын баракларда өше дә,
Йөрәк янып, йөз кат алданып,
Ышанасы килә кешегә.

Халык бәхете өчен көеп-янып,
Колымага чаклы барып та,

Туң далада бер ялгызың калып,
Ышанасы килә халыкка!

Сезне зурлап-олылап язылган шигырь, бер дә хафаланырлык түгел, кешегә ышану, халыкка ышану ул – бик зур, изге тойгы. Шул тойгы күңелдә булган өчен дә Сез ул тәмугтан исән чыккансыздыр, Ибраһим абый.

Бу да мәгълүм булсын: Сезнең романда дүрт юл шигырь китерелгән, Дәрдемәнднең шушы шигырен яратам, дип әйтелгән. Ул шигырь Дәрдемәнднеке түгел, ә Сәгыйть Рәмиевнеке. Тагын бер биттән соң, бу төрмәдә Петрошевич та утырган, дигән җөмлә бар. Ул революционерның тулы фамилиясе Буташевич-Петрашевский.

Сезнең хезмәтегезгә яңа уңышлар теләп, сәлам вә ихтирам белән, *Гамил Афзал*[1].

*13.03.1990 ел. Әлмәт*

Өлкән кордаш һәм чордашка – Ибраһим дустыбызга күптин-күп, чуктин-чук сәлам. Казан язы җылысын кочаклап кабул ит!

Мине бу яз да үз астмасы белән аяктан ега язды, больничныйда (өйдә, докторлар көтеп, укол чәпчүче кызларны күрмәскә тырыша-тырыша күз йомып диярлек…) ятам.

Сабир бабай китабы өчен зур рәхмәт. «Базар» тәрҗемәң өчен - аннан да зуррагы!. Мин күптән инде редакцияләп куйдым. Тагын Әйди – үзе эшләгән бер тәрҗемәне китерергә тиеш. Проза бүлегебез кереш сүзне кыскартып эшли, чөнки әсәрләренә урын кирәк. Журналдан калган хәтлесен газеталарга 100 еллык датасы уңаеннан бирерсез. Мин ике хикәяне быел ук (синең белешмәле кыска керешең белән!) бирергә кирәк табам, чөнки читтә, еракта яшәп бүтән телләрдә иҗат иткән якташларыбыз иҗатын бергәрәк итеп сыйдырыр өчен бер санны багышларга булдык.

«Мәхәббәт картаймый» журналга инде керде, дөньяга да инде чыгып ята. Үзеңә кирәк хәтле санны Казандагы бөтен чыганакларыңнан эзли һәм эзләтә башла. Иң беренчесен, әлбәттә, миннән көт! Ниһаять, инде алдым дип сана!

---

[1] Гамил Афзал (1921–2001) - Татарстанның халык шагыйре. Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Дәүләт, ТР Язучылар берлегенең Р. Төхфәтуллин исемендәге бүләкләре лауреаты.

1980 елда журналга 80 мең генә планлы тираж бирелгән иде, ә подписчикларыбыз 94 мең булып чыкты. Акчаларын кире таратып чыгарга кирәкле 14 мең кешене эзләп торуның кирәк түгеллеген исбатлап күп тырыштык һәм ЦК КПСС (без бит обком нәшрияты кешеләре, журнал акчасы – партия кассасына) шул фактик 94 меңне раслады (димәк, өстәмә кәгазь бирде! Ә кәгазь проблемасы хәзер нәкъ энергия һәм ягулык проблемасы кебек үк җитди). Гыйнвар аенда киоскларда сату өчен тиешле процент тираж да бирелгән иде (3000 данә), ә хәзер ул киселде һәм булмаячак. Бары тик подписка, подписка һәм подписка гына кала! Киләсе елда да шулай булачак. Димәк, подписка турында инде хәзердән үк уйларга вакыт. Син бит әле журналның пропагандисты да.

Һәр эшеңдә, һәр адымыңда уңышлар, бары тик уңышлар гына теләп, *Әхмәт Зәкиулла*[1].

*14.04.1980*

...Ибраһим әкә!

Сиңа ни истәлек, ни бүләк итеп җибәрергә яңа бер нәрсәм дә юк. «Шагыйрь китапханәсе»ндә калын тупланма быел көзгә генә чыгачак – киләсе декабрьдә абзагызга да 60 тула бит.

Менә ун ел тирләп-пешеп чүпләүләр нәтиҗәсе – яңа «Күңелле китап». Үзем дәваланып йөргәндә чыккан, атна-ун көн эчендә сатылып та беткән, үземдә хәтта китабы да юк, версткасын типографиядә алдым. Шуны булса да алып тор, хәлеңне беләм: син читтә, еракта һәм ялгыз. Күңелсез чакларың да буладыр. Үзем гел елмаерга яратучан буларак, сиңа да кайчакта елмайгалап алырга киңәш тәртибендә шуны булса да тәкъдим итәм. Әле тагын шундый ике китаплык запасым бар. Укучыларның берсе буларак, кирәк тапсаң, Казанга үзеңнең фикерең-уйларыңны, карашың-фикереңне, теләк-таләбеңне язып җибәр. Әдип турында әдип, китап турында китап язучы кеше әйткән сүз, минемчә, кирәк! Шундый ниятең була калса – хәбәр ит, матбугат мәйданы табышырга булышырмын.

*Ихтирам белән Зәки (Зәки Нури).*

*(Вакыты күрсәтелмәгән)*

[1] Зәки Нури (1921–1984) — татар шагыйре, публицист. 1964–1971, 1974–1982 елларда «Казан утлары» журналының баш редакторы.

Хәерле көн, хөрмәтле Ибраһим ага!

Сезнең миңа язган хатыгызны алдым. Сезгә бик зур рәхмәт. Дөресен әйткәндә, мин алай тиз җавап алырмын дип көтмәгән идем. Сезгә хат язучылар мин генә мени.

Озак хат язмыйча торуның сәбәбе шул: без әти авылына кайтып килергә идек, андагы хәлләр белән дә сезне таныштырасы килде.

Иптәшем Заһит белән бер атна кунак булып кайттык. Әти хакынадыр инде, безне бик олылап кунак иттеләр. Авылда Мамадыш районы Урта Сон дигән җирдә, төп йортта әтинең абыйсының малае яши...

Авылда әле подряд, аренда, кооператив юк. 100 ләп йорт булган колхозда 500 баш сыер фермасы. Колхозда эшләүче яшьләр күп булмаса да, булганнары бик тырышлар, әдәплеләр. Авылда кибет, мед. пункт, 200 урынлы клуб, спорт залы, балалар бакчасы һәм мәктәп бар. Мәктәптә 3 класска 17 бала укый. Калган олылары 2 чакрым Түбән Сон дигән авылга йөреп укыйлар.

Ибраһим ага!

Сезнең әти белән очрашмау гаҗәп түгел. Әтинең дәфтәреннән:

«...28.11. Владивостокка илтеп җиткерделәр», «...без барында бу төрмәдә 40 меңнән артык кеше утыра иде», «...монда блатнойлар дөньясы иде», «...1938 ел. 10.12. безне Колымага озаттылар. Минем фамилиямне Яушев урынына „Душев“ дип язулары аркасында, 8 меңлек колоннаның ахырында идем.» Шулай итеп ул Казан, Бөгелмә, Уфа төрмәсеннән бергә барган иптәшләреннән аерылган. Шулай да Колымада Әлмәттән Идрисов Ильяс һәм Шөгердән Ильясов Камил белән очрашканнар. Алар 1940 елда шунда калганнар. Әти Магадан пересыльный төрмәсендә блатнойларга тунтиредән бияләй, носки тегеп тамак туйдырган.

Ярый, хәзергә шулар, күп яздым, гафу итегез.

*Сәлам белән Клара (Әхмәтҗанова)*

*1989*

Хәерле көн, хөрмәтле Ибраһим ага!

Мин сезгә бик зур ихтирам белән карыйм.

Казанга барып кайттык. Анда сезнең иптәшегез белән килеп киткәнегезне ишеттек. Сез язган «Колыма хикәяләре»ен алып кайттык. Кабат укыйм. Анда 1927 елда, сез Ялтада Г. Ибраһимов

торган йортта булгансыз, диелгән. Без Заһит белән Ялтага баргач (алтмышынчы елларда) ул йортны эзләдек, ләкин бер белүче дә булмады, тапмадык.

Казанга Заһит эш белән барды. Ул Әлмәтнең «Совет ветеранов войны и труда»ның председателе, шуңа җаны-тәне белән бирелгән.

Ә мин туганнарны күрергә бардым һәм Ленин музеенда Татарстаннан 1927 елда Мәскәүгә XV съездга баручы бер төркем фотодагы рәсемгә № 9 астында Яушев дип язылган. Ләкин ул этигә туры килми. Чөнки эти, 1926 ел октябреннән башлап, 1928 ел сентябренә кадәр Томский шәһәрендә ВКП(б)ның татар секциясе секретаре булып эшли. Шәһәр советы депутаты. Әти ул чорда Мәскәүгә бару турында бер сүз дә язып калдырмаган. Ул аны язмыйча калдырмас иде.

Ибраһим ага!

Сез этинең язмалары дөнья күрсен иде дип язгансыз. Әти үзе исән булса, үзе кайсысын кирәк дип тапса, шунысын күрсәтер иде. Ул каләм тибрәтергә ярата иде. Мин үзем аны булдыра алмыйм. Кызыксынучыларга бирәсем килми. Алар бит аны барыбер чынбарлыкны үзгәртмичә язмаячаклар. Ә инде бу бәлане үз башыннан уздыручылар эти дәфтәренә мохтаҗ түгел, дип уйлыйм. Бәлкем ялгышамдыр.

Хәзергә шулар.

*Сәлам белән Клара Ясәви кызы (Әхмәтҗанова).*

*5.06.1989 ел*

Хөрмәтле Ибраһим ага!

Хәерле көн, нык сәламәтлек теләп хат язучы Клара.

Әтинең үзе язган автобиографиясен күчереп җибәрәм. Кайсы еллары кирәк булыр. Әти, мәрхүм, кайткач, бөтен документларын архивлардан соратып яңарткан булган. Бәлки пенсия алырга кирәк булгандыр.

Ә инде Шәрәф Мәхмүтнең тормыш юлларын эти сөйләве буенча гына беләм. Заманында гаиләләр дус булганнар. Бу хат белән бергә Шәрәф Мәхмүтнең улына хат яздым, әгәр адресы үзгәрмәгән булса...

Әтинең автобиографиясе:

«Я – Яушев Ясовей Шигапович родился 22 апреля 1895 г. в семье среднего крестьянина, в деревне Средний Сун, бывшей

Казанской губернии Мамадышского уезда, ныне ТАССР, где проживал с отцом до 15 лет.

В детстве учился в медресе в деревне Малые Суни. С 1911 г. по 1914 год работал рабочим на Уральских золотых приисках и на постройке железной дороги Пермской губернии.

С 1915 по 1918 г. служил в царской армии в кавалерии рядовым солдатом, с 1918 года по 31 мая 19212 г. в рядах РКК рядовым бойцом, активно участвовал на фронтах гражданской войны на южном фронте против Врангеля и по ликвидации банды Махно.

С 1922 г. по 20 августа 1928 года на Ленских золотых приисках, сначало работал рабочим на лесозагрузке, затем по выдвижению на профсоюзной работке председателем кустового комитета лесозаготовок. С 15 января 1925 г. по 20 августа 1926 г. инструктором Бодайбинского УКома ВКП (б) Иркутской губерниии. Там же в 1924 году во время Ленинского призыва Бодайлинской организации был принят кандидатом в члены ВКП (б), с апреля 1926 г. член ВКП (б), с 7 октября 1926 г. по сентябрь 1928г. в городе Томск работал секретарем Татарской секции Томского окружкома ВКП (б) с сентября 1928 г. по 27 марта 1932 г. учился в городе Казани в татарском коммунистическом университете (ТКУ)

С 27 марта 1932 г. по 16 мая 1932 г. работал заведующим заочного отделения ТКУ.

С 16 мая 1932 г. по 2 сентября 1934 года работал ответ. редактором газеты «Динсезләр» органа республиканского совета безбожников и председателем республиканского совета безбожников в г. Казани.

С 4 сентября 1934 г. до сентября 1935 г. работал редактором районной газеты «Коммунар» Дрожжановского района ТАССР.

С 1 сентября 1935 г. по май 1936 г. работал зав. РОНО там же в Дрожжановском районе. С 15 мая 1936 г. по 5 сентября 1937 г. работал ответ. редактором рай.газеты «Яңа юл» Буинского р. ТАССР.

Работал честно и добросовестно. Всегда все партийные поручения выполнял аккуратно. Парт. взысканий не имел.

5 сентября 1937 г. в г. Буинске ТАССР будучи ответ. редактором райгазеты «Новый путь» я стал жертвой клеветы. Меня исключили из рядов ВКП (б) за участие в вымышленной контрреволюционной организации в районе.

23 сентября 1937 г. органами НКВД был арестован, 21 октября и 4 ноября 1937 г. выездной сессией Верховного суда ТАССР был осужден по 17-58 ст. на 15 лет тюремному заключению и 5 ти лет поражению политических прав, как врага народа. В решении суда было сказано: решение окончательно, обжалованию не подлежит.

В тюрьмах и лагерях отсидел 14 лет 4 месяца. Из них более 13 лет на Колыме в Магаданской области. Из лагеря освободился 18 января 1952 года, до октября 1954 г. находился в ссылке в Магаданской области. С декабря 1954 г. по 11 апреля 1956 г. состоял на учете Ленинградской спец. комендатуре МВД ТАССР (один раз в месяц отмечался, как ссыльно-поселенный).

Определением судебной коллегии Верховного суда РСФСР от 2 апреля 1956 г. реабилитирован за недоказанностью предъявленного мне обвинения.

Решением бюро обкома КПСС от 9 января 1957 г. восстановлен в ряды КПСС с сохранением прежнего стажа 5 марта 1957 г. г. Альметьевск. (с декабря 1954 г. не работает, живет в г. Альметьевске ТАССР, с октября 1956 г. пенсионер, активный пропагандист, лектор, скоропостижно скончался 4 октября 1963 года в г. Альметьевске ТАССР на партийном собрании).

Менә шулар.

*Сәлам белән Клара*
*4.01.1991 ел*

Сәлам Казаннан.

Хөрмәтле Ибраһим ага! Сезнең язган хатыгызны алып укыдык. Тәкъдимегезгә бик шат булдык. Хатны алгач, бер иптәш белән сәфәргә дә чыгарга җыенып йөрдек, ләкин инде ачыкланды. 1990 ел командировкалар өчен чыгымнар тотылып беткән. Шунлыктан Сезнең янга 1991 елның язына таба барырбыз инде, Алла боерса. Бу хакта Сезгә өстәмә рәвештә хәбәр итәрбез.

Үзегезнең хәлләр ничек? Сезгә сәламәтлек, иҗат уңышлары теләп калучы *Марсель Әхмәтҗанов*[1].

*Казан.*

*4.11.1990*

---

[1] Марсель Әхмәтҗанов (1939) — әдәбият галиме, археограф, текстолог, филология фәннәре докторы.

Здравствуйте, многоуважаемый Ибрагим абый Салахов!

Извините заранее за время, которое у вас отнимаю, но не написать Вам я не могу. Пишет Вам дочь писателя Суббуха Рафикова – Сания.

Однажды я слушала радиопередачу из Казани и позднее отрывок из телепередачи, посвященной встрече с Вами, там Вы несколько раз упоминали имя моего отца, и мы узнали, что в годы Вашей молодости, во времена сталинских репрессий Вы сидели в тюрьме вместе с моим отцом. О его прошлом, его несчастной, тяжелой молодости знаю очень мало. Тогда не принято было об этом говорить, даже дома.

Я родилась в 1949 г. в пос. Норильск Красноярского края, когда папа еще был в ссылке, без права выезда с крайнего севера. Что знаю из короткой автобиографии отца: «...с октября 1937 г. по октябрь 1947 г. находился в местах заключения на крайнем севере. По 1954 г. находился в ссылке. Реабилитирован 9 мая 1956 г. Военной Коллегией Верховного Суда СССР...»

В 1958 г. мы всей семьей переехали в Татарию в Заинск.

Папа умер 21 ноября 1971 г.

И мы, его дети, мама, никак не можем смириться с утратой. Мы все его очень любили, он был чуткий, добрый, интересный, душевный, несмотря на все перенесенные им невзгоды, был для нас Человеком с большой буквы.

В этом году исполнится 18 лет после его смерти, умер он от кровоизлияния в мозг. Мама с тех пор живет одна. Я окончила Казанский инженерно-строительный институт, личная жизнь устроена, у меня двое детей, дочь и сын. Взрослая дочь просит расссказать о дедушке, о тех временах, но я почти ничего не могу ей ответить.

Я слышала, что Вы работаете над книгой «Тернистый путь», где описывая то страшное время беззакония и культа личности, которое напрямую пересекло Вашу и папину судьбу.

Если сможете, вышлите нам, пожалуйста, Вашу книгу с автографом. Эта книга станет нашей семейной релеквией. Мы сможем прочитать ее маме. Пока она жива.

Извините, что писала на русском языке, с детства окружали русские дети, русская школа, институт. На татарском языке разговариваю.

С искренним к вам уважением и пожеланиями всего самого доброго, *Сания*[1].

*7.08.1989*

Дорогой Ибрагим абый, Махинур апа!

Вот, наконец, могу ответить на все письма и вопросы полученный одновременно...

«Карлыгач» передали в журнал «Идель» на русском языке. К сожалению они к 30 авг. не сумели ее выпустить. Видимо журнал комплектуется заранее.

«Фаҗига» – мы передали его Фариту, но он сказал, что он работает над своим вариантом, обещал его посмотреть и видимо свое мнение напишет сам. Теперь он разговаривал с Насыбуллиным (председатель кино), который не против снять кино о Вашей жизни с последующим показом по телевидению. Но Фарит не знает как ему быть? Возможно он сам бы поехал с сценаристами, но должен знать точную дату проведения юбилея. Вы ему заранее телеграммой сообщите эту дату. Но насколько все это у него реально, не знаю. Он сейчас занят строительством-реконструкцией бывших лабазов какого-то купца под студийный театр на Булаке во дворе театра «Тюз». Эти бывшие склады построены были до революции в античном стиле. Если Фарит сумеет осилить всю эту нагрузку, думаю получится хорошая студия для нашего города. Он сам очень и очень настроен сделать о Вас фильм. Я еще раз Фариту сказала, что надо торопиться. Ведь возраст 80 лет – это не 40 и не 50 и даже не 60!

А за этими годами прожито столько горьких тяжелых испытаний. Каждый день, каждый час дорог. И дорог пока человек есть. Услышать из его уст правду тех страшных лет. А теперь несколько слов о сценарии «Фаҗига». Ибрагим абый, вы в первом письме просили мнение о сценарии. Мне, например, очень трудно дать такую «рецензию», но если не обидитесь на меня, я скажу свое мнение. К сожалению, весь тот ужас пережитых лет в застенках «Черного озера» и на Колыме, он как-то сплачивается. Ведь когда читаешь книгу, то находишься в слезах. Что-то здесь не хватает и

[1] Сания Әхтәмова – язучы Сөббух Рәфыйковның (1913–1971) кызы.

второе то, что очень мало женских ролей. Это мое мнение, может я не права. Я думаю, надо было обязательно тот эпизод, где Вы в тюрьме встретились случайно на прогулке во дворе тюрьмы с мамой Сарвар Адгамовой и как ее избивая прикладом в спину уводят в камеру – показать небольшим фрагментом. Это бы усилило весь трагизм положения заключенных. А тем более ее мужество – «держись Ибрагим!», «молодец Ибрагим», двойное мужество и Ваше тут раскрывается. Дальше я обязательно увековечивала бы память о Махинур апа, ведь на ее долю выпала не меньше испытаний. Она – мужественная, преданная, любящая. А ведь в то время, когда Вы писали эту книгу, могло по-разному обернуться к Вам судьба. А она простая женщина оказалось Вашим союзником, помощником и по силе своего духа, она не меньше героиня…

Наверное, на этом хватит. Крепко Вас обнимаю, *Сания (Ахтямова), Тансык (Нежметдинов)*[1].

*13.08.1991 г.*

Дорогие Ибрагим абый, Махинур апа!

Хоть и с опозданием, но всех вас поздравляем с новым годом, всем доброго здоровья, благополучия и покоя!

Вот уже более недели, как вернулись из Москвы, а я все никак не могу сесть за ответ на Вашу просьбу о поездке в Москву. Я просто очень устала за все это время не только физически, но и от моральных переживаний… боялась, конечно, и переживала, соберется ли народ. Ведь в Казани было очень мало народу. Хоть и объясняют всякими волнениями в городе, тяжелой подорожавшей жизнью, что не только на папины и к остальным, к тому же Х. Такташу еще меньше было народу, Джаудату Файзи, Алишу, когда мы пришли в окружной дом офицеров, где проходил юбилей, мы поразились тому, что зал был полон народу. Встретили нас аплодисментами на сцене. Посадили в президиум. Кругом цветы. Много было творческой интеллигенции. Там было совсем по-другому организовано. 2 часа доклад, воспоминания и 2 часа концерт. Здесь в Казани преимущество в том, что читали произведения самого папы. На сцене

---

[1] Тансык Нәҗметдинов – танылган татар язучысы һәм җәмәгать эшлеклесе Кави Нәҗминең (1901–1957) улы.

был очень большой и красивый портрет папы. Сделал его художник Карим Шарипов – москвич. В перерыве к нам подходило очень много народу, было много пожилых, которые помнили и знали хорошо Кави Наджми.

Мы думали, торжества будут только один день. На следующий день народу было еще больше… В общем никакого сравнения с организацией в Казани. В Москве культуры значительно больше. А главное нас поразило, что зал был полон…

С 1 января у нас ввели еще купоны, помимо талонов. Теперь даже нас ограничили в хлебе и молоке, и овощах. Купонов очень мало… На душе тошно, как же будем жить? Цены подняли на недосягаемую высоту. Пенсия 132 рубля, у Тансыка в месяц около 400 рублей. По нынешним ценам мы даже не смогли уложиться в талоны не то, что прикупаться в «дарах природы» Татсоюза. Там тоже теперь цены кусаются…

Всем огромный привет.

*Сания и Тансык*
*9.01.1992 г.*

Хөрмәтле Ибраһим ага!

«Көкшетау даласында» исемле казакъча китабыгызны алдым. Котлыйм! Казакъ дуслар арасында озак еллар яшәгән язучының казакъча китабы чыгу бик сөенечле хәл.

Сезгә озын гомер, сәламәтлек телим.

Үзебез исән-сау.

Безне сораган барлык иптәшләргә сәлам әйтерсез.

*Ихтирам белән Гариф Ахунов*
*6.05.1983*

Хәерле көн, Ибраһим абый.

Онытып та бетергәнсездер инде, мин Актаныш районы Такталачык урта мәктәбе организаторы, атаклы авылдашыбыз Мохтар Мутин музеен оештырып йөрүче Ахунов Рәшит булам.

Ниһаять, Ибраһим абый, максатыма ирештем шикелле. Мохтар Мутин музее ачылуга әзер. Музей үзенең эчтәлеге белән бик кызыклы килеп чыкты, бик күп экспонатлар тупланды. Музейда Мохтар Мутинның Такталачыкта, Уфада, Казандагы тормышын

чагылдыручы экспозицияләр эшләнде, шулай ук шул чордагы крестьян өенең эче, шул чордагы эш кораллары, гражданнар сугышын чагылдырган стендлар да бар. Казан скульпторы В.И. Рогожин Мутинның бюстын эшләп бирде, ә музейның иң кыйммәтле экспонатларының берсе – «Гамлет»та уйнаган һ.б. киемнәре. Боларны Г. Камал исемендәге Академия театры бирде. Шулай ук музейда Мутин туганнарының хатлары, сезнең хатлар, сезнең китап һ.б. бик күп фотографияләр тупланып күргәзмәгә куелды.

Икенче атаклы авылдашыбыз Гамил Афзалга, Риза Ишморатка багышланган стендлар, аларның фотографияләре, автографлары куелды.

Ибраһим ага, бүләкне сорап алмыйлар инде аны, гафу итегез, сез дә үзегезнең фотокарточкагызны, китабыгызны автограф белән җибәрә алмассызмы?

Академия театры артистлары Рәшидә Җиһаншина, Һидият әфәнде Солтанов Мутинны күреп, аның белән бергә театрда уйнап, күреп йөргән кешеләр. Аларны да музей ачарга чакырган идем, килербез дигәннәр иде.

Күп сүзгә китеп, Сезне котларга да онытып торам, Тукай премиясе белән. Дөреслек беркайчан да югалмый, моңа еллар шаһит.

Исән булыгыз, сәламәт яшәгез.

*Ахунов Рәшит*[1]

*Актаныш районы, Такталачык авылы.*
*20.10.1990*

Ибраһим ага, Сезгә, гаиләгезгә күп сәламнәр белән Харис әле бу.

Хатыгызны алдым, сезнең китаплар да шәт барып җиткәндер...

Сезнең татар китабын читкә тарату турында фикерләрегез дөрес. Бу мәсьәлә белән, мәшәкатеннән куркып, сәүдә оешмаларының да бик шөгыльләнәсе килми. Җитмәсә, алар шундый шарт куйганнар, җибәрелгән татар китабы бәясенә үтемле рус китабы җибәрсәләр генә договор төзүгә ризалашалар. Ә урыннардагы урысларга татар китабы кирәкмени... Татар китабы обмен нигезен-

---

[1] Рәшит Ахунов – Татарстанның Актаныш районы Такталачык авылы мәктәбендә артист, режиссер, тәрҗемәче М. Мутин (1886—1941) музеен оештыручы.

дә түгел, сатарга бернинди шарт куймыйча җибәрелергә тиеш. Бу хакта безнең дәүләт органнарына читтәге иптәшләр бер дә язмыйлар, протест белдермиләр, ә шуңа Г. Исхакый, Ә. Еники һ.б. авторларыбыз сатылмыйча ята, ә читтә алар юк.

Димәк, бу эшне җайга салу читтәге иптәшләрдән дә тора.

*Сезгә уңышлар, тазалык теләп, Х. Әшрәфҗанов*[1]
*1991 ел*

Многоуважаемый Ибрагим Низамович!

К Вам обращается сын первого секретаря Обкома ВЛКСМ Багаутдинова Махмута Гильмутдиновича, расстрелянного в 1937 г. Рафаэль Мустафин в письме сообщил, что вы в романе упоминаете и моего отца.

Я был бы очень Вам благодарен, если бы Вы мне смогли сообщить о последних днях моего отца, вы может быть последний свидетель. Спасибо вам большое, что Вы нашли мужество, честность, совесть сохранить многие имена жертв тирании и произвола.

Моему отцу было тогда только 32 года, я через 4 года буду в два раза старше.

Сам я вырос во всевозможных колониях и детских домах: Украины, Кавказа, Средней Азии. Окончил Казанское худ. училище, Киевский худ. институт, живу в г. Киеве, в 1986 г. привозил свою персональную выставку в г. Казань. Музеи Казани приобрели восемь моих работ.

Долгих Вам лет жизни.

*Багаутдинов Рафаэль Махмутович*[2]
*г. Киев.*
*1.09.1989 г.*

Многоуважаемый Ибрагим Низамович!

Во-первых поздравляю Вас с наступающим Новым годом! Долгих еще вам лет жизни.

---

[1] Харис Әшрәфҗанов (1943) – галим, журналист. 1989–1998 елда Татарстан китап нәшрияты директоры

[2] Репрессия корбаны, ВЛКСМ өлкә комитетының I секретаре Баһаутдинов Мәхмүт Гыйльметдин улының улы.

Вас беспокоит Рафаэль Багаутдинов. Во-первых, прошу Вас извинить меня за столь долгое молчание, во-вторых, большое Вам спасибо за книгу и письмо, для Вас, как я понял, ясно, что я не владею татарским языком и очень об этом сожалею, моей вины тут нет и еще вам открою секрет, вашу книгу я передал моему товарищу писателю, он пишет обо мне и о нашей семье книгу, вернее повесть (документальгого характера) и все куски из вашего произведения, вернее часть повествования о моем отце, он будет цитировать, пишет он на украинском языке. В печать он сдаст в этом году, но предварительно даст мне прочитать.

О себе я Вам сообщаю некоторые сведения: после ареста отца и матери мы с братом были отправлены на Украину, во время войны эвакуированы на Кавказ, потом в Ср. Азию, в 1947 г. снова на Украину в г. Киев, брат остался, а я поехал на родину в г. Казань учиться в худ. училище. Отслужив в армии я по окончанию Казанского худ. училища вновь вернулся в г. Киев и поступил в худ. институт и окончив в 1963 г. остался в г. Киеве, правда, были попытки вернуться в Казань, но там я ни кому был ненужен. Еще 2 раза я приезжал в Казань по сбору материала к диплому посвященному Мусе Джалилю (1963 г). и в 1986 г. я привез в г. Казань свою персональную выставку. Брат уехал в США в 1972 г, а сестра так же уехала в США в 1988 г., вот так разбросала нас – детей Махмута по белому свету. Мама освободившись из заключения в 1946 г. вскоре вышла замуж, родила и воспитала троих детей. Умерла в 1980 г. Дети живут в г. Казани. Творческая судьба моя сложилась неплохо, невзирая на то, что меня фактически преследовали всю жизнь – сначала за отца, потом за брата, отняли очевидно не один год жизни, но слава аллаху. Как говорят мои коллеги, что жизнь твоя (моя) состоялась, во многих музеях Украины хранятся мои произведения, в одном из престижных музеев г. Киеве – Русском музее, 14 работ. в Казанском музее – 8 работ и т.д. Участвовал в более чем 50 ти выставках республиканского и союзного значения, а так же провел 6 персональных выставок. Еще раз большое спасибо вам за все. Ваш скорбный труд не пропадет... Если вы что-то сообщите мне об отце, я буду очень благодарен. Книга ваша сейчас переводится, может книгу вообще издадут на Украине.

*С уважением и благодарностью Рафаэль Багаутдинов*

*14. 01. 1990 г.*

Уважаемый Ибрагим Низамович! Наверное, Вы и так получаете много писем, но у меня тоже возникла необходимость в получении от Вас сведений. Я пытался поймать Вас в Казани, но не успел...

В настоящее время рассматривается вопрос о реабилитации Марьям Музафаровой – она закончила Казанский педагогический институт (раньше училась в Германии), затем преподавала в КГПИ, поступила в аспирантуру Московского института им. Бубнова. Была арестована в Казани во время приезда к сестре 29 авг. 1937 г., была осуждена 14 ноября 1937 г. на 10 лет, дальнейшая судьба пока неизвестна (или привлечена повторно и расстреляна, или же скончалась в местах лишения свободы).

Мы планируем подготовить публикацию о ее судьбе в одной из республиканских газет или журналов. Насколько мы располагаем материалами, это была одаренная личность, любила музыку, была близка с Салихом Сайдашевым, к ней был неравнодушен проф. Камай, директор КГПИ Биктагиров.

Очевидно, Вы знали Музафарову – или как студентку, или как преподавательницу КГПИ. Если Вам не трудно, напишите мне свои впечатления про Музафарову – что Вы запомнили про нее.

Второй вопрос: кто жив из студентов тех лет, которые знают об обстоятельствах привлечения к уголовной ответственности целого ряда студентов и преподавателей КГПИ, ихние данные и адреса – я с ними тоже хотел бы переговорить насчет Музафаровой, да и по ряду других вопросов.

Далее, если вы будете в Казани, я бы хотел увидеться с Вами, побеседовать. Я давно работаю по этой теме, по службе сталкивался с рядом уголовных дел тех лет, сделал ряд публикаций о судьбе репрессированных лиц в газетах и журналах...

*Следователь по особо важным делам прокуратуры Татарской АССР – Флер Нуретдинович Багаутдинов*[1]

*29.06.1989 г.*

---

[1] Флер Нуретдин улы Баһаутдинов (1958) – Татарстан Республикасының атказанган юристы.

Ибраһим әкә!

1994 елда «Казан утлары» журналында очрашканнан соң, сине башка күрә алмадым. Бик тә аяныч булды бу. Икәүдән-икәү генә гәпләшеп утырасым килгән иде. «Дуэль» китабы миндә сакланган, син «халык дошманы» булсаң да, минем авылда сакланган ул. Үзеңә тапшырасым бик тә килгән иде.

1994 елда «Мөртәт» дигән 12 табаклы романымны «Казан утлары» басып чыгарды. Күңелем күтәрелеп китте. Бүгенге көндә «Сөюләрем хак булса» дип исемләнгән повестем әзер. Аннары «Кан» романым бар. Әмма ләкин аны бик күп эшкәртәсем бар әле. Исән-сау булсак (миңа 76 яшь була быел 12 декабрьдә) күрешербез әле, алла боерса. Казанга килсәң, мине күрмичә калма.

Гүзәл җәй айлары. Шунысы кызганыч, Татарстанда яңгырлар юк дип әйтерлек. Сирәк тамып киткәли, ләкин икмәкләргә, бәрәңгеләргә ул бик аз. Коеп яусын иде.

Ф. Миңнуллин, Җ. Тәрҗемановлар ак дөньядан җир астына җирләнделәр.

Сәлих Баттал да 90 яшен тутыра алмыйча (4 ай җитмәде) янып-төтенгә тончыгып үлгән. Аны 14 мартта татар зиратына җирләдек.

Рәшит Әхмәтҗанов та 5 гыйнварда кинәт кенә вафат булды. Менә шулай, дөнья хәлләре.

Сау бул, хөрмәтле Ибрагим.

*Локман (Бадыйкшан)*[1]
*Казан*
*22.06.1995*

Ибраһим каләмдәш!

Көтеп алган хатың килеп җитте. Казанда матур җәй. Ләкин шунысы күңелсез, язучыларыбыз үлә башладылар.

Мартта Салих Баттал – 12.03.1995, 1 июль – Ибраһим Нуруллин.

Мартта Җәвад Тәрҗеманов, аннан да элегрәк Рафаэль Төхвәтуллин, яшь язучы Рәкыйпов (Шамил Рәкыйповның энесе), Мәһдиев тә үлде, бүгенге көндә Атилла Расих, Фатих Хөсни бик авыр хәлдә яталар.

---

[1] Локман Бадыйкшан (1919–2015) – язучы.

«Шәһри Казан»да әле шигырьләреңнең очына чыга алмадым. Таба алмыйлар. Табылгач, ачыклык кертермен.

Бик күңелсез хәбәр язгансыз. Бер күзеңнең хәле турында, нигә кирәк булды операциягә керергә!?

Яңалык язам: Казанда «Мәдәни җомга» – 24 битлек булып чыга башлады. Сөенәбез барыбыз да бик тә. 2 санында минем Салих Баттал турында истәлегем чыга. Инде кул куелган, кыскартылган.

Җитәр, *Локман Бадыйкшан.*

*26.07.1995*

Исәнмесез! Хөрмәтле Ибраһим абый! Сезгә сәлам белән тазалык, саулык теләп хат язучы Лениза дип белерсез.

Ибраһим абый, үпкәләмәгез, мин сезне абый диеп дәшкәнгә.

Ибрагим абый, менә нәрсә турында сорарга уйлыйм мин сездән.

Әти хатында язган булган, сезнең белән бер төрмәләрдә булганын. Ибрагим абый, сез безнең әти белән Казанның Пләтән төрмәсендә үк бергә булгансыз, бәлки сез хәтерли торгансыздыр. Минем әти Бариев Абдулхак Бариевич 1907 елгы (без Габдулхак дибез), акланган. Ул Норлат районы Айдар авылында туган. Яшьләй ятим калып, балалар йортында тәрбияләнеп, шунда укыган. Укып чыккач, Арчага эшкә җибәргәннәр. Аннан Күлле-Киме авылында колхоз төзергә җибәргәннәр. 1927–1928 елда, 1929 елда әтине Күәм дигән авылга мәктәп директоры итеп куйганнар. Ибрагим абый, бәлки сез безнең әти турында берәр нәрсә беләсездер. Әгәр сез аны белсәгез, безгә бер-ике җөмлә генә хат юллап салмассыз микән. Әти 1937 елда кулга алынгач, әнине дә эшеннән чыгарып ташлаганнар. Ул өч бала белән (иң зурысы абый 1931 елгы), шулай авыр тормышта яшәгәч, безне олы уку йортларына алмагач, без авылны калдырып Үзбәкстан якларында яшәдек. 1959 елда Казанга кайтып урнаштык. Менә шул элекке, әни әйткәнчә, кара сакал һаман безнең арттан ияреп йөри әле. Без әти белән бергә утырган кешеләрне эзләп карадык, тапмадык.

Менә безнең бәхеткә диюем инде, сезне күрдек, бәлки ярдәм итәрсез... Без – өч бала сездән җавап көтеп калабыз.

*Бариева Лениза*[1]
*Казан, 31 май 1989 ел*

---

[1] Репрессия корбаны Бариев Абдулхак Бари улының кызы.

Дорогой Ибрагим Низамович!

Обращаюсь к Вам с большой просьбой.

Подошлите мне, пожалуйста, в редакцию две-три книги своих – можно и на казахском – с добрыми пожеланиями нашему подшефному Нуреку («В интернациональную баруздинскую библиотеку «ДН» («Дружба народов») в героическом Нуреке от…» и т.д.).

Хорошо?

О нашей уникальной коллекции книг с автографами в Нуреке Вы, видимо, наслышаны? О ней много пишут и говорят. Сейчас она насчитывает уже около 11 тысяч томов и по мнению специалистов не имеет себе равных в мире. Свои книги нурекчанам подарили Л.И. Брежнев, другие члены Политбюро ЦК, включая Д.А. Кунаева, не говоря уже о большинстве казахских писателей.

Очень бы мне хотелось видеть в этой библтотеке и Ваши книги.

Буду ждать!

Заранее блогадарен Вам!

Счастья Вам и благополучия!

*Ваш С. Баруздин*[1]
*27.04.1980 г.*

Здравствуйте, уважаемый Ибрагим ага!

С большим вниманием и волнением прочитал ваш «Тернистый путь» в журнале «Казан утлары». Потрясен прочитанным, вашим духом, стоицизмом. Великое спасибо, что так ярко и жизненно высветили черные страницы нашей истории. Я стал реально представлять то, с чем вы столкнулись и что перенесли. Какова была обстановка в описываемый период. Очень нужный роман. Этот роман-напоминание всем и последующим поколениям, что необходимо сделать все, чтобы подобное больше никогда не повторилось.

Я стал лучше представлять и отца, хотя хорошо помню и воспоминание мамы. Когда я прочитал строки про него, он являлся ко мне, как живой. А ведь я его никогда не видел. После возвращения из тюрьмы отец сказал маме, чтобы я его не видел в таком неприглядном виде. Выпустили его уже совершенно больным. Как вспоминает мой старший брат Марат, когда на медицинской комис-

[1] Сергей Алексеевич Баруздин (1926–1991) – язучы, 1965–1991 елларда «Дружба народов» журналы редакторы.

сии врачи заявили, по словам отца, что он все равно скоро «сыграет в ящик»...

На этом я заканчиваю. Будете в Казани, обязательно заходите. Всегда Вам рады. До свидания!

*Рафаэль Басыров*[1]

*1988 г.*

Уважаемый Ибрагим Низамович!

В последнее время я серьезно занялся вопросами творчества: исследую его как бы изнутри – сам я писатель, пишу более двадцати лет – серьезно с 1970 года (для прозаика необходим достаточный жизненный опыт), но пока не удалось пробиться через издательства.

Точно не знаю, в какую материальную форму кристаллизуется мой последний интерес: ограничусь ли монографией о творчестве или напишу художественное произведение о творцах – заранее сказать трудно, вернее всего – второе.

Надеюсь, Вы проявите любезность и проконсультируете меня по интересующим вопросам: хочу избежать субъективных суждений.

Удовлетворяет ли писателя многотрудная судьба? Если бы Вы пожелали и смогли заново начать поиск пути в жизни, выбрали бы творчество или удовлетворились иной профессией?

Что Вас больше всего привлекает в писательстве: возможность высказаться, появить свое личное «я», – оно насыщает честолюбивые побуждения, приносит известность, предоставляет определенные материальные и иные привилегии, позволяет самостоятельно распоряжаться своим временем… Возможно, творчество – своеобразная форма проявления страстей, подсознательный акт, призвание или обычная профессия. Какую часть в писательстве занимает «чистое творчество», сколько времени тратится на «технику»?

Конечно, нельзя заранее перечислить все побудительные мотивы творчества.

Желаю Вам доброго здоровья, всего доброго!

*М. Бельферман*[2].

*(г. Киев). 05.1981*

---

[1] Рафаэль Басыров – репрессия корбанының улы.

[2] Моисей Бельферман – язучы.

Исәнмесез, Ибраһим ага!

Сезгә бу хатны Татарстанның Түбән Кама каласыннан бер яшь журналист яза. Зур дулкынлану, кызыксыну һәм әрнү белән «Тайгак кичү» романын укыдым, журнал вариантын әлбәттә. Әсәрнең әдәбиятыбызда нинди урын аласы турында сезгә күп әйткәннәрдер инде, мин дә хуплауга кушылам. Әмма минем сезне борчуымның сәбәбе башкарак иде шул.

Романны укыган вакытта ук мин аны күңелдән рус теленә тәрҗемә итеп бардым дисәм дә, әллә ни күпкә арттыру булмас. Бәлки инде сезне бу мәсьәлә белән борчып, туйдырып та бетергәннәрдер, шулай да сездән тәрҗемәгә рөхсәт сорарга уйладым. Бер өзекне эш арасында гына тәрҗемә дә иткән идем, сезгә җибәрәм, шуннан чыгып бәяләгез.

Кыскача гына үзем турында: исем-шәрифләрем – Әхтәм Билялов[1], Түбән Кама шәһәр газетасында авыл хуҗалыгы бүлеге мөдире булып эшлим, газетабыз рус һәм татар телендә чыга.

Уңаймы, тискәреме – сезнең җавабыгызны көтеп калам. Әсәрегезнең әсире.

*5. 08.1988*

Хәерле көн, Ибраһим ага!

Сезгә уңышлар, исәнлек-саулык теләп хат яза Әхтәм. Менә тагын ике кыска бүлекне тәрҗемә итеп бетердем кебек инде, сезнең хөкемгә җибәрергә булдым. Кызганыч, әлегә кадәр җибәргәннәре турында фикерегезне белә алганым юк.

Минем коллегалар, ни белән шөгыльләнгәнемне белеп, һәрдаим эшнең торышы белән кызыксыналар, хәтта машинкага биргәнне дә көтмичә, укый башлыйлар, бәялиләр. Бернинди арттырусыз әйтәм, әсәрегезне бик яратып кабул итәләр һәм миңа, бернигә карамыйча, тәрҗемәне дәвам итәргә кушалар. Олылар сүзенә колак салмый ярамас инде.

Бүгенге көндә «Юл башы» һәм «Алла йортында» өстендә эшлим. Бер атна ярымда башкарып чыгарга өметләнәм. Аларына да сезнең объектив бәяне алырмын дип уйлыйм.

---

[1] Әхтәм Билялов (1960) – журналист.

Бу ике бүлектә баш исемнәрен, озак уйлаганнан соң, бераз үзгәртергә кыюлык иттем, чөнки башкача русча яңгырамый.

Тагын сезгә үтенечем бар: әсәрдәге географик атамаларның русча формасын язып җибәрә алмассыз микән? Мәсәлән, Пләтән төрмәсе турында мин беренче тапкыр романны укыганда гына белдем, моңарчы русча түгел, татарча исемен дә ишеткәнем юк иде.

Ярый, исән булыгыз, Ибраһим ага.

*Изге теләкләр белән: Әхтәм Билялов*
*16.09.1988*

Хәерле көн Ибраһим ага!

Сезгә һәм якыннарыгызга исәнлек-саулык теләп хат язучы Әхтәм дип белерсез. Шактый вакыт хәбәр бирми торуым өчен гафу итегез берүк, аның сәбәбе бар иде. Бар дүрт бүлекне дә Казанга, Рафаэль Мостафинга җибәргән идем, бәя бирсен дип. Көтә-көтә көн артыннан көн үтте. Ниһаять, бүген телефоннан гына файдаланып, элемтәгә керә алдым. Тулаем алганда, уңай фикерләр әйтте: шактый төгәл тәрҗемә, диде. Шул ук вакытта кайбер төгәлсезлекләр дә юк түгеллеген аңлатты. Берәр тәҗрибәлерәк тәрҗемәче белән хезмәттәшлек итәргә киңәш бирде. Чегән хатыны турындагы бүлекне Казанда русча газеталарга тәкъдим иткән, алдылар, ди. Бәлкем, башка бүлекләр дә шундый ук бәхетле (минем өчен дә) язмышка «дучар булыр» дип өметләнәм.

Аннан соң ул шуны әйтте: автор нәшрият исеменә конкрет фикерен җиткерсен – әсәрен тәрҗемә итүне миңа яисә Ә. Хәмидуллинга тапшыру турында. Аңлавымча, рус телендәге вариантның язмышы бераз төсмерләнә башлады. Барысы да сезнең җавапка бәйле. Билгеле, мәсьәлә минем файдага хәл ителер дип уйламыйм, шулай да, өметсез – шайтан, диләр бит. Эшләр менә шулай тора.

Ярый, Ибраһим ага, мин кыска гына хатымны тәмам итәм.

*Сезгә исәнлек, уңышлар теләп, Әхтәм (Билялов)*
*Түбән Кама.*
*21.10.1988*

Исәнмесез, Ибраһим ага! Гафу итегез, хатыгызны алуга җавап җибәреп булмады: «Линькольн приискасында» да әлегә әзер түгел,

ике-өч көнлек эше бар, Ринат абый белән дә тиз генә сөйләшеп булмады, ул ялда иде.

Менә, ниһаять, аны да туры китерә алдым. Дөресен әйтим, аның җавабы сезнең хаттан соң үсеп чыккан канатларымны кискәндәй булды. Бердән, ул әлегә эшне туктатып торырга киңәш итте, янәсе, эшегезне кабул итмәвебез бар, әрәм булыр (күрәсең, тәрҗемәгә керешер өчен кимендә Язучылар Союзы әгъзасы булырга кирәк). Алай да атна-ун көн эчендә Казанга килеп китәргә кушты. Шулай эшләрмен дә бугай.

Икенчедән, ул әсәрне башка берәү – сезнең якташ – тәрҗемә итә башлаган, диде. Ә романның рус телендә чыгуы әле сорау астында, ди. Мәскәү үзенә алыр ахры бу эшне дип аңлатты.

Менә шундый хәлләр. Ни булса да, сез сораган бүлекне эшләп бетереп җибәрермен, үземә дә яхшы сабак булыр. Тәҗрибә практика белән килә бит...

Ярый, Ибраһим ага, шуның белән хатымны тәмамлыйм, ситуацияне аңлагансыздыр инде дип уйлыйм.

*Сезгә исәнлек-саулык теләп, Әхтәм Билялов*
*30 август 1988*

Ибраһим абый!

Сезгә күп сәламнәр җибәреп, тагын да иҗатыгызда зур уңышлар теләп калучы авыл кызы Гөлнәзирә.

Мин сезнең язган хатыгызны һәм фотогызны алдым, әйтерсең лә үземнең этиемнән килгән, шундый сөендем, чөнки мин сездән хат көтмәгән идем, сезгә хат язучы мин генә түгел бит. Мин сезнең шундый олы йөрәкле кеше икәнегезне беләм инде әлбәттә, чөнки сез күргәнне күреп исән калу ул үзе бер зур иҗат (?) – сезгә нинди исем бирергә дә башкача мөмкин түгел, «тимер» сез дияр идем, тимер тутыга, «чуен» дияр идем ул да эри, «корыч» дияр идем аны да бөгеп була, сез нинди булгансыздыр, әйтүе авыр, сезне берничек тә җиңә алмаганнар.

Сез язасыз «минем яшьлекне күрмәдегезме, кызым», дип. Абый! Яшьлек бит ул кемгә килә язгы ташкын кебек ургылып, сезгә бит ул фәкать үткән читтән генә карап, сугылып...

Әле шул Сезнең кебек иптәшләрнең – хайваннары, исән-сау кайтканнары бар икән. Ләкин балалары бар – язуы кыен, моны сез үзегез дә беләсез...

Ярый, абый, сау булыгыз, озак яшәгез, әле дөньялар көннән-көн яхшыра бит.

*Гөлнәзирә*[1].
*Башкортстан, Бакалы*
*3.02. 1988*

Сәлам Алабугадан!

Исәнмесез хөрмәтле Ибраһим абый һәм Маһинур апа!

Сезгә кайнар сәламнәр җибәреп, эшегездә һәм тормышыгызда уңышлар теләп калалар: Тәбрис, Вәсимә.

Язган хатыгызны күптән алган булсак та, җавапны хәзер язам инде.

Кыска вакыт эчендә бик күп яңалыклар булды инде. Татарстанга суверенитет алу август аенда, ләкин хәзерге вакытта сүлпән бара. Халык аз гына туктап калдымы яки алга ни эшләргә белмичә калдыкмы? Бик аңлап булмый әле. Урыс халкы бик каршы әле һаман да.

Ибраһим абый! Казанда очрашкан чагында Исәнбәтнең язган язуын, копиясен укыткан идегез. Шуны үзебезнең «Социалистик Татарстан»да чыгарып булмас микән. Әгәр дә миңа җибәрә алсагыз, аны редакциядә сөйләшеп карар идем [...]. Сез үзегез ничек уйлыйсыз?

Үзегезнең тормышлар ничек бара, тазалыкларыгыз ничек? Нинди эшләр, нинди яңалыклар? Сезнең хәбәрләрне үзебезнең Татарстан газетасында бик яратып укыйбыз. Вакытыгыз булса, ешрак булса да бик яхшы булыр иде.

*Хөрмәт белән энегез Тәбрис (Вагыйзов)*[2]
*11.10.1990*

Исәнмесез, Ибраһим ага!

Сезнең хатны алганга да шактый вакыт узып бара. Ул арада ашыгыч кына Мәскәүгә командировкага барып килергә туры килде.

Каты авырып алгансыз икән. Инде үзегезне сакларга карагыз. Хәзер көннәр матур, табигатькә яңадан җан керде. Сезгә күбрәк һавада булырга кирәк инде.

---

[1] Вәлиуллина Гөлнәзирә – И. Салахов иҗатын хөрмәт итеп, аның белән хәбәрләшеп торучы. Башкортстан кызы.

[2] Тәбрис Вагыйзов – «Социалистик Татарстан» хәбәрчесе.

Безнең кебек баш эшендәге кешегә һавада булу кирәклеген үзебез дә соңгы елларда сизә башладык. Соңгы дүрт-биш елда безнең нәшрият, язучы халыклары шәһәр читендә, Идел буенда бакчалар утыртып мәш килеп беттек. Вакытны күп алса да, эше башта бик авыр булса да, хәзер бик шатланабыз, чөнки мәҗбүриләп дигәндәй һавада булабыз, хәзер бакчабыз да матур гына булып үсеп килә. Бер ягында нарат урманы, икенче ягында – Идел...

Сезгә әнә шундый табигатьтә ял кирәк иде. Тормыш, китап ыгы-зыгысын бер читкә ташлап...

Ибраһим ага!

Сез, ничектер, хатыгызны минем алда бурычлы булып калган кеше кебек итеп язгансыз. Зинһар, хафаланмагыз! Минем күңелдә сезгә карата ихтирам гына калды. Эш вакытында төрлечә булгандыр. Мин үзем «Күкчәтау далаларында» повестен редакцияләп чыгаруымнан бик канәгать булып калдым. Мин китап начар булып чыкты дип уйламыйм. Сезгә кайбер төзәтмәләр белән килешүе авыр булгандыр, билгеле, чөнки һәр сүзе сезнең күңелдән чыккан иде бит. Ләкин минем дә теләк сезнең әсәрне әйбәт итеп чыгару иде. Китап турында, чыккач та, начар фикер ни матбугатта, ни укучылардан ишетмәдем. Шулай булгач, эшебез начар нәтиҗәгә китермәгән дигән фикердә калдым. Сезгә карата да олы ихтирам урнашып калды.

Өй җәмәгатьләрегезгә дә сәлам әйтеп, сезгә сәламәтлек, озын матур гомер теләп, кабат ихтирам белән *Фәния (Гайнанова)*[1].

*Казан*
*15.06.1972*

Иптәш Салахов!

Мин сезнең «Имәннәр тамыр җәйгәндә» дигән тарихи романыгызны шулкадәр дулкынлану белән укыдым. Бер өлешен укыгач, икенчесен түземсезлек белән көтеп алдым.

Романны укыганда, анда тасвирланган хәлләрне үз башыңнан кичергән кебек, үз күз алдымда узган кебек буласың. Бик күп тарихи хәлләрне эченә алган, шулкадәр җиңел телдә язылган бу әсәрегез.

---

[1] Фәния Гайнанова (1929–2007) – тәрҗемәче, РСФСРның атказанган мәдәният хезмәткәре.

Романның миңа бик ошаганының тагын бер сәбәбе бар. 8 яшемдә 21 нче елгы ачлыктан котылу өчен мине укытучы абыем авылдан алып китеп, без Атбасарда 4 ел яшәгән идек. Гомерем буе шул Атбасарга барып, яңадан күрәсем килеп яшәдем. Бала вакытта күргәннәр күңелгә бик нык сеңәләр бит. Абыем укытучы булып, без бер ел казахның кышлагында, җәйләвендә дә яшәдек. Сезнең әсәрне укыгач Атбасарның без белгән бөтен кешеләре, урамнары, нардом, бакчалары күз алдымнан үтте. Яшьлегемә кире кайткан кебек булдым. Казахстанның далалары, куй, дөяләре дә бик нык таныш иде безгә.

Мин, сезнең әсәрне укыгач алган тәэсирләремне, күңелемдәгечә язып аңлата алмыйм әлбәттә.

Минем өчен тагын бер яңалык: үз гомеремдә бик күп (5 яшемнән) әдәбият укыган булсам да, татарларның ул якка китеп урыс-казагына әйләнүләрен белми идем.

Салахов иптәш, шушы кадәр эчтәлекле, әһәмиятле, кызыклы, гыйбрәтле романыгыз өчен сезгә зур рәхмәтләр әйтәсем килә. Сезгә бик нык сәламәтлек, эшегездә, иҗатыгызда зур уңышларга ирешү телим.

Романның икенче китабын түземсезлек белән көтәм. Исән чагында уку бәхетенә ирешә алсам иде, дим.

Миңа хәзер 72 яшь. Зинһар өчен тизрәк язып бетерергә тырышыгыз. Үтенәм сездән.

Яңа ел белән тәбрик итәм, яңа бәхет, яңа уңышлар телим.

Гафу итегез. Журналда корректура хаталары бик күп. 1914 урынына 15 дип, папканы – капка, таныштыны – тынышты һ.б. тагын бик күп хаталар. Корректорларга әһәмият биреп укырга киңәш итегез.

*София Гайнетдинова*[1]

*24.12.1985*

Исәнмесез! Сәлам сезгә!

Ибраһим! Нәкъ бер айдан, сезнең романны укыгач, картымның рөхсәте белән, Сезнең исемгә «Казан утлары» редакциясенә хат язып җибәргәнемә бер ел тула. Гадәттә, редакция җавап җибәрмичә

[1] Суфия Гайнетдинова – И. Салахов иҗатын яратып укучы, аның белән хәбәрләшеп торучы. Фондта С. Гайнетдиновадан килгән 150 дән артык хат саклана.

калмый иде. 3 айга якын вакыт узгач, шуның эчендә зур хәсрәткә дә юлыккач, ул турыда бөтенләй оныткан идем. Март ахырында Казахстаннан хат килеп төште. Ачып укыганчы төрлечә уйладым, кемнән булыр, нинди хат? Конвертны әйләндерә-әйләндерә карадым. Чыннан да миңамы?

Ул хат сездән булып чыкты. Мең рәхмәтләр Сезгә. Хатта бер дә гаҗәпләнерлек сүзләр булмаса да, күзалдым яктырып китте. Чөнки хат редакция җавабы кебек кәҗүнни түгел, туганнарча язылган. Картым үлгәнне әйтеп язган икенче хатыма каршы, хәсрәтемне уртаклашкан кебек юатып язылган җавап килде. Бу хатлар миңа зур поддержка булды. Шуннан соң үткән 11 айда сез минем хатларымны җавапсыз калдырмадыгыз. Тагын бер кат мең рәхмәтләр Сезгә! Бик нык сәламәтлек белән озын гомер телим һәм мине хатларыгыздан өзмәвегезне башымны иеп сорыйм. Мин хәзер сезгә шул кадәр ияләшәм, бертуган абыем дип сизәм сезне.

Бик күп еллар узса да, сез әле «Бакыр бабай» бакчасын хәтерлисез икән әле. Минем дә ул бакчада булганым, «бакыр бабай»га карап торганым бар. (ләкин аның кем булуын хәтерләмим)...

Ибраһим! Очрашуларга чакырганда «барасы килмичә» түгел, шатланып барыгыз. Гаепсезгә гаепләнеп уздырган газаплы елларыгызны искә төшерегез дә, хәзерге почет белән яшәвегезгә бик канәгать булып йөрегез (акыл сатучы табылды димәгез инде), ул елларның сөреме миңа һәм гаиләбезгә кагылмаган булса да, искә төшергәндә йөрәк әрни, күңел сыкрана. Гаеп белән күтәргән авырлык җиңелрәк тоеладыр, ә яп-яшь, гаепсез көйгә... Әле генә радиодан Блюхер турында тыңладым (нинди кыйммәтле кеше булган бит)...

Ялтада бик авыр хәлендәге ирен (Г. Ибраһимовны) ташлап киткән хатыны Мөхәммәдова «Казан утлары»ында аның турында повесть яза. Укыйсым да килми хәтта. Ничектер, начар фикердә мин ул 83 яшьлек карчык турында, күреп белмәсәм дә (гафу итсен)…

*Хатны язучы Суфия Гайнетдинова*
*28.11.1986*

Исәнмесез Ибраһим! Без «күптәнге танышлар» бит инде, шулай дәшүемне гаепләмәгез. Сезгә күптән-күп сәламнәремне язып, бик нык сәламәтлек, озын гомерләр, бик яхшы эчтәлекле, тирән

мәгънәле, минем кебек карчыкларда да тирән эз калдыра торган әсәрләр иҗат итеп бастырырга өлгерүегезне чын ихлас күңелем белән теләп калам. Теләкләремне хатымның башында ук язам...

9 нчы июньдә композитор Сара Садыйкованы актерлар йортында булган соңгы юлга озату митингында булдым. Бик зурлап озаттылар. Күп язучыларны, артистларны, композиторларны күрү бәхетенә ирештем һәм үземнең культура дөньясыннан бик артта калганымны аңладым.

Тукайның 100 еллыгына карата Тукай урамын матурладылар. Йортлары шул ук булса да, бик матурлап буядылар. «Тукай» (элекке «Чаткы») киносы тирәсенә плитәләр җәйделәр. Кинога каршырак бик матур йортта Тукай музее ачылды. Бик кечкенәдән ятлап, 80 гә таба барганда да онытылмаслык булып күңелгә сеңеп калырлык шигырьләр язган Габдулла Тукайны болай зурлаулары күңелне бик шатландыра. Юбилей хөрмәтенә төрле кичәләр уздырдылар, телевизорда да Казан тапшырулар бирә. Мәңге онытмаслык шагыйрь шул.

Бакчада җиләкләр-викторияләр пешә башлады. Сезне дә шул җиләкләр белән сыйлыйсым килә. Картым белән икәү утырткан идек, аңа ашарга насыйп булмады. Моңа кадәр бездә көннәр бик коры, эссе булды. Бу бер-ике көндә яңгырлар явып, көннәр суытты әле.

Тагын менә нәрсә: Татарстан районарында гына тегелә торган бите чиккән чүәкләр матур да, җиңел дә, коры вакытта кияргә бик ныклар да. Сез миңа карчыгыгызның һәм кызыгызның аяк размерларын язып җибәрсәгез, мин бандероль итеп сезгә салыр идем. Безгә магазин да, почта бүлеге дә якын, минем өчен бернинди мәшәкать тә булмаячак. Сезгә хөрмәтем йөзеннән бүләк эшләргә теләвемә каршы килсәгез, бик нык үпкәләрмен...

Ачлы-туклы торып институт рабфагында укыган яшьлегемне мин дә бик бәхетле елларым дип саныйм. Укып бетерәм дигән елда гына кудылар һәм хыялларым җимерелде, ләкин тырышлыгым аркасында алай хурлык күрмәдем. Безнең яшьлек шундый чорга туры килде. Картлыгыбыз тынычлык белән тәмамланса икән инде.

Түземсезлек белән сездән хат көтәм. Хат эчендә нәрсә язылуда эш тормый, хатың килүе кадерле.

*Хуш, исән булыгыз, София (Гайнетдинова)*
*18.06.1986*

Ибраһим! Сезнең тәкъдимегезнең кызулыгы белән, күп уйлап тормыйча, «Истәлек» язып җибәрдем. Анда телгә алып сөйләрлек, кәгазьгә язып укырлык бер нәрсә дә юк. Гади тормыш. Бер кешенең дә гомер юлы йөрәге кушканга гына узмый бит. Күп, бик күп хатын-кызларга караганда минем тормыш бәхетлеләрнеке шикелле булган. Безнең чор хатын-кызлары яшьтән калып гомерләрен ирсез-тол уздырдылар. Мин ничек булса да 50 ел ир белән торган бит әле. Ярату, сөю белән яшәүчеләр меңнән бер генә буладыр. Кыйналып, сугылып уздыручылары да күп.

Ибраһим! Минем истәлекләрдән берәр нәрсә оештырып чыгаруга кыйммәтле вакытыгызне әрәм итмәгез. Минем сезгә киңәшем шул.

Минем гомер дә, тормыш юлым да озын булды. Аның эчендә нәрсәләр генә булмагандыр.

«Истәлек» сез әйткәнчә язылмагандыр. «Тиз пешермәсәм дә» шуннан артык яза алмас идем. Язу эше белән шөгыльләнмичә 74 ел узган.

Тышта буран үкерә. Көн азрак җылыткан, ләкин каты җил, җирдән себерә торган буран. Ярый әле өйдә «буран» юк. Анысына шөкер.

Ибраһим! Сез торган якта бигрәк матур җирләр, күлләр, таулар бар икән. Рәсемнән генә булса да сокланып карый торган. Минем хәтергә Атбасар тирәсендәге тигезлек, далалар гына иде кебек булып калган. Хәзер ул далалар барысы да сукаланган инде. Казакъ җәйләвендә торганда ат белән ике көпчәкле биек арба белән тизәк җыеп йөргәнемне хәтерлим. Ә кыш көне мулда әкәгә дип саламнан салынган, кибеп җитмәгән, юеш стеналы өйдә торганыбыз хәтеремдә бик нык калган. Без казакълар арасында бер җәй, бер кыш яшәдек. Ятим балалык еллары онытылмыйлар, ә хәзер кичә нәрсә ашаганыңны да онытасың.

*Сезгә зур ихтирам белән, Суфия (Гайнетдинова)*
*1.02.1987*

Исәнмесез! Узган хатымны язып бетергәч кенә сезнең керәшен хәрефен яратмавыгыз исемә төште. Безнең чор халкына (татарларга) алфавит алышыну кыенлыгын гына үткәрергә туры килдемени соң? Сезгә хат язганнан соң, кайчандыр, кайдандыр «Мәхәббәт

картаямы?» повестен укыганым исемә төште һәм узган еллардагы «Казан утлары»н актарып табып яңадан укыдым. Моңа кадәр хат белән сезнең семья хәлләрегезне, бала-чагаларыгызны сорарга уңайсызланып йөрсәм дә, бу повесть беркадәр аңлатты кебек. Бик матур язылган, сезнеке икәнен белеп укыгач, бигрәк яхшы күренде ахры.

Шәйхи Маннур белән, сезнең кебек, башта заочный танышкан идем. Аннары минем картым белән бер палатада больницада ятканда очно да танышкан идем һәм озак кына сөйләшеп торган идек. Аның бик якын дуслары Хак Максудов (Мәскәү язучысы Мәхмүд Максудовның энесе), безнең дә бик якын дус. Бәлки сез дә аларны беләсездер.

Кызыл балчыклы тау башын гөл бакчасы иткән картым 3 айдан бирле җир куенында ята (тагын зарлана башлады диярсез инде). Менә ни өчен шундый авыр көннәремдә сездән хат алу һәм сезгә хат язулар, ягъни сезнең белән сөйләшү) миңа мораль көч бирде. Көннәр теге яки бу эш белән үтә, ә кичләрен (сездән хат килмәсә) үземне кая куярга белмәгән минутларымда шундый озын хатлар язып, сезнең белән сөйләшәм. Һәм хатлары туйдырды, бүтән язма, дигәнгә кадәр, үзегездән килсә, һаман да язачакмын.

Сез монастырь бинасында торып, педтехникумда укыган елларда, Гайния Галләмова һәм Әминә Вафина дигән кызлар да укыган иде. Ул «кызлар» хәзергә кадәр минем дусларым. Сез белгән булсагыз да оныткансыздыр әлбәттә...

Бездә көннәр бик коры тора әле. Авыл кешеләре шушы көнгә кадәр бәрәңге дә тишелми дип зарланалар. Көннәр җылынып җитте ахры инде.

Җитеп торыр ахры. Юкса, укып арырсыз.

*Суфия (Гайнетдинова)*

*8. 06.1986*

Исәнмесез!

Хат һәм рәсемнәрегезне алдым, чын күңелдән рәхмәт сезгә. Х. Туфанны күреп тә, шигырьләре буенча да яхшы белә идем. Язучылар белән «Казан утлары»нда басылган әйберләре бик ошаганнарына хат язышу гадәтем бар иде. Мәсәлән, Шәйхи Маннур белән («Агым суларга карап» дигән повестьны укыгач). Ул да юк инде хәзер. Сезнең исемгә «Казан утлары»на язып

җибәргәндә картым исән иде әле. «Татарча укымаганыгыз аркасында нинди матур язылган әйберләрдән мәхрүм бит син» дип шелтәләгән дә идем. Картым да, өч малаем да, чын татар булуларына карамастан, татарча укый белмиләр. Шуның аркасында мин дә «Казан утлары»нда басылганнардан башка, күп язучыларның әсәрләрен укый алмадым. Картымның, картая башлагач, китаплар укырга вакыты да калмый иде, чөнки «Правда» белән «Советская Татария»не от корки до корки укый иде, ә мин газетаның дүртенче битен генә карыйм дип әйтерлек. Политикадан артта калган карчык.

Менә шулай итеп Сезнең нинди яхшы китапларыгызны укымый калганмын. Кулыма төшкән китапларны хәзер дә укыйм, ләкин элеккечә су урынына эчеп булмый инде, күзләр дә арый, баш та картларча гына эшли.

Безнең күршедә бер карчык, сугыш вакытында ФЗОга китеп, күп еллар югалып торган малаен тапты. Минем дә, күптән югалткан абыемны таптым бит әле, дип әйтәсем килә, ләкин моңа хакым юк. Безнең бит әле танышлык та заочно гына. Анысы да ялгыз карчыкка бераз поддержка булсын дип кызганып хат язышу гына. Моның өчен мин сезгә чын күңелдән рәхмәт әйтәм.

Татарстанда һәм Казан шәһәрендә апрель, май айлары буена бер тамчы да яңгыр яуганы юк. Авылларда икмәкләр, бәрәңгеләр тишелми, диләр. Җәйгә чыккач һаман борчылып яшисең: я яңгыр юк, я бер туктамый яңгыр ява, икмәкләр чери һ.б. Ул яктан өең җылы, күңелең тыныч булса, кыш яхшы. Кыска җәй, кешенең яшьлеге кебек, күз ачып йомганчы уза да китә. Безнең яшьлекләр бигрәк әрәмгә уздылар.

Мин дә бит, хәтта мулла әтием үлгәндә 1 яшьтә генә калсам да, «чыгыш» дигән нәрсә аркасында бераз каһәрләндем. Югары белемсез калдым, яраткан эшләремнән мәхрүм ителдем. Алар барысы да матур яшьлекне күрми калуга сәбәп булдылар. Картлыкта тынычлыклар насыйп булсын инде һәркайсыбызга да.

Сезнең хатларыгызны укыйм да Нәби Дәүлинең «Син кайда идең, син кайда булдың» дигән җырын искә төшерәм. Моннан берничә ел элек танышкан булсак, карт белән без сезгә (ул да Казагыстаннан иде), сез иптәшегез белән безгә барышып, якын дуслар булып йөрешер идек. Минем картым бик тәртипле, әдәпле, ягымлы кеше иде. Сезнең дә шундый булуыгызга шигем юк.

Авырып торам әле дип язасыз. Зинһар, үзегезнең сәламәтлекне саклагыз, авырмагыз, чын күңелемнән сезгә бик нык сәламәтлек, озын гомерләр телим...

*София (Гайнетдинова)*
*29.05.1986*

Исәнмесез!

Ибраһим! Сезгә нинди рәхмәтләр языйм да, нинди теләкләр телим инде. Берьюлы ике хат, бу бит минем өчен зур шатлык. Сез минем йөрәгемә бик якын дус булып кереп утырдыгыз. Шуңа күрә хатларыгыз белән сөйләшү барлык булган котсыз тормышымны оныттыра (гафу итегез, хискә артык бирелеп киттем).

Кичә котырган, күзачкысыз буран кичтә, татар театрының иске бинасында Мирсәй Әмирнең 80 яшьлек юбилеен уздырдылар. Бер дустым почта белән шунда чакыру билете җибәргән иде. Яртысын трамвай белән, яртысын җәяү шул кичәгә бардым. Ярый, азрак күңел күтәрелеп кайтты. Яңа театр эшли башлады. Халык йөри. Бу айга билетлар сатылып беткән инде.

Тагын «Казан утлары»ның беренче санында басылган Миргазиян Юныс дигән язучының повестын укый башладым. Миңа бик ошый. Яңа ел кергәннән бирле укыган бер әйберләр дә юк әле. Йөрәгем яшь, үзем картайдым.

Ибраһим! Сезнең Күкчәтау күренешегез минем гомерем буена онытмыйча, барып күрү теләге белән йөргән өметләремне кузгатты. Атбасарда 4 ел торуыбызны язган идем бугай (21–24 еллар) андагы ятим балалык еллары нинди авыр булган булсалар да, нигәдер гомерем буе истән чыкмадылар. Тормышым шундый булды, бара алмадым. Хәзер инде ул турыда уйлый да алмыйм.

Шигыремгезнең өзеген генә түгел, тулысы белән җибәрсәгез иде. Нинди матур язылган, гомердә күрмәгән җирне күз алдына китереп бастыра.

Тәкъдимегез өчен зур рәхмәт. Язып булса, начар булмас иде әлбәттә. Яшь вакытта язу мәсьәләсендә способность дигән нәрсә бар иде, ләкин аны үтерделәр. Хәзер язып карасам да барып чыкмастыр. Шулай да сез миңа киңәш итеп ничегрәк, нинди якларга күбрәк әһәмият бирергә, балалык елларын да алыргамы һ.б., ярату-яратылу мәсьәләләрен дә эләктерергәме. Язып җибәрсәгез, талпынып карармын.

Гомумән, мин үземнең гомеремне җилгә киткән дип саныйм (тагын шыңшый башладым). Кайвакытта үзегезне күрсәм, барысын да сөйләп бирер идем дип уйлыйм. Мин болай да сезгә бик күп нәрсә яздым инде.

Минем яшь вакытым картларча узды. Картайган саен күңелем белән үземне яшьләрчәрәк хис итәм.

Быел кыш без бала вакыттагыча булды. Салкыны да, бураны да, кары да җитәрлек...

Ярый, хушыгыз. Бик ерактагы, бик якын дустым сез минем.

*София (Гайнетдинова)*
*27.01.1987*

Исәнмесез!

Сезнең каршыгызда башымны түбән иеп гафу үтенәм. Сезнең 17 июльдә язган хатыгызны алган идем. Шуннан соңгы ара бик озак булып тоелды. «Заочно» укучыгызны бөтенләй ташладыгыз ахры дип курыктым. Иҗади эшегезгә комачаулап, хат язуым зур мәгънәсезлек икәнен яхшы аңласам да, һаман язам шул. Ни өчендер, сез миңа туган абыем кебек якын булдыгыз.

Роман һәм повестегызны (үзем укыганнарын) күп кенә кешеләргә укыттым инде. «Мәхәббәт картаямы?»ның китабын да табып укыдым. Ильясның бөтен тормышын аның белән бергә переживать иттем. Йөрәккә үтеп керә, күзгә яшь китерә торган итеп язасыз сез. Укырга бик яратсам да, җәй көне көндәлек газеталарны карап чыгудан башка нәрсә укып булмый. Сезнең язганнарны укырга вакыт табар идем анысы, кыш көне, күзләр отказ итмәсә, әдәбият укырга вакыт күп булыр. Алдагы елга барып җитеп булса, миңа да 74 булачак. Картлык үзенекен итәргә мөмкин. Сезнең яңа әсәрләрегезне укырга насыйп булсын иде.

Татар академия театрында Сибгат Хәкимнең 70 яше тулган көндә, аның шигырьләре белән зур концерт булган икән. Шуны карадым (телевизордан). Анда бер дә картаймаган Сибгат аганы да күрсәткәләп алдылар. Сара Садыйкова да үзенең көен пианинода уйнады. Терелеп кайтканнар диярсең.

Казанда кайсы елларда булгансыздыр. Сез күргәннән соң күп үзгәрешләр булгандыр. Мәсәлән, Татарстан урамы хәзер бик матур, киң. Ике яклап 9 этажлы йортлар һәм башкалар. Килә алсагыз, үзегез күрерсез әле.

Быел көннәрнең торышы әллә нинди. Каты җил, салкын, бер көнне җылы булса, иртәгесен тагы суыта. Кая китте икән без яшь вакыттагы җылы матур төннәр. Яңгырдан соң җирдән пар күтәрелә, салават күперләре чыга торган көннәр?! Безнең белән бергә табигать тә картая ахры...

Ибраһим! Мин сезгә хат язганда каршыгызда утырып сөйләшкән кебек хис итәм. Каршымда утырсагыз бу кадәр сүзләр сөйләшергә җөрьәт итә алыр идемме, белмим.

Сезнең язучылык дәверегездә минем кебек бәйләнчек укучыгыз булганы юк идедер. Нишләмәк кирәк, шундый вакытка туры килде бит...

Тагын бер кат сезгә сәламәтлек, озын гомер теләп калам. Тормышыгызда зур тынычлык та булсын. Анысы да бик әһәмиятле.

*Суфия Гайнетдинова*

Исәнмесез!

Ибраһим! Сезгә нинди теләкләр теләсәм дә, нинди рәхмәтләр әйтсәм дә аз булыр. Исәнлегегез артсын.

Шул кадәр сәфәрләрдән соң, арган хәлегездә мин ятимне шатландырып хат язуыгызга мең-мең рәхмәтләр сезгә, ерактагы якын дустым минем.

Мин шулай үзгәрешсез яшәп ятам (картлыкның иң хәтәре – ялгызлык). Моңарчы мин, ялгызлык, дигән бәхетсезлекнең мәгънәсен аңлап бетермәгәнмен.

Ярый әле сездән сирәк булса да хатлар килә, алар минем картлыгымның бер кадәр өлешен алып ташлыйлар (аларның – сезнең хатларның тукталуыннан куркып яшим).

Дөрес, карчыкларым, дус бабаем килгәлиләр. Алар белән сөйләшеп азрак юанып калам. Малайлар килеп хәл белеп китә. Киләләр дә китәләр, мин һаман ялгыз калам (тагын шыңшый башладым инде, җитәр!).

«Казан утлары»нда Әмирхан Еникинең «Соңгы китабы» миңа бик ошады. Элеккеләре бер дә күңелгә ятмаган иде. Бусы Казанның миңа бик таныш еллары, хәлләре турында язылгангадыр, яратып укыдым. Вакытыгыз булганда сез дә укырсыз әле.

Ибраһим! Һаман сәфәрләрдә йөрергә сез бик яшь кеше түгел бит инде. Аннары бер дә язу эшенә утырырга вакытыгыз

калмый. Җитмәсә, безнең кебекләр хат язу белән никадәр вакытыгызны ала.

Мин бит сездән һәркөнне хат көтәм. Почта ташучыны да аптыратып бетердем. Иртәгә булыр, язалар инде дип көлеп китә, ачуланмый. Ә минем борыным салына. Сездән хат килгән көнне әллә нинди шатлыкларым булган кебек йөрим.

Күп язам, җитеп торыр.

Йомышым төшеп Ленин (безнең заманда Чернышевский иде) урамына барырга туры килде. Ул урамда мең ел булмаган идем (Казанда торам имеш). 4 ел буена Яңа бистә кадәр җирдән килеп укып йөргән рабфагым яныннан узганда күңел тулды. Туктап озак карап тордым. Эчкә керергә җөръәт итмәдем (хәзер анда Филиал акад. наук).

Кая китте ачлы-туклы булуга әһәмият бирмичә, һәрвакыт шат күңел белән уздырган яшьлек. Әмирхан Еники бу турыда бигрәк матур язган: «Яшьлек саф, пакь, гөнаһсыз яшьлек. Таң алдыннан күргән кыска төш кебек кенә булып калды» («Соңгы китап» – актыккы абзац).

«Семен Дежнев» дигән кинокартинадан Колыма елгасын күрдем. Сезнең шунда уздырган авыр елларыгыз искә төшеп, йөрәгем бик уңайсыз калды. Минем йөрәк болай да башка кешеләрнеке төсле түгел ахры. Сез мине шат күңелле дип уйлыйсыз. Кая киткәндер шат күңелле елларым, мин яшь вакытта чыннан да шат күңелле, күп көлүчән идем. Тормышка чыкканның икенче көнендә үк иптәшем: «Күп көләсең» диде. Шул көннән соң минем авызым йомылды.

Ибраһим! Минем уйлавымча, сезнең күчтәнәчегез каклаган үрдәк иде. Искиткеч тәмле, ашаганда телеңне йотарга мөмкин. Кызганычка каршы без монда (хәтта авылда да) болай эшли белмибез. Ачуланмасагыз, шундый тәмле итеп ничек эшләвегезне язсагыз икән.

Сезгә бик нык сәламәтлек, тормышыгызда тынычлык телим.

*Хат көтеп, Суфия (Гайнетдинова)*

*11.04.1987*

Ибраһим, исәнмесез! Хатыгыз килүдән өметем өзелеп бетте дигәндә, 27 се килеп җитте. Зур шатлык булды миңа. Улым Илгизәр дә миндә иде. Кычкырып укыдым. Сезгә нинди рәхмәтләр әйтсәм

дә әз булыр. Минем бар шатлыгым хатлар килүдә һәм Илгизәрдә бит инде.

Ләкин көтелмәгән югалтуларга тап булуыгызга йөрәгем бик әрнеде. Нишәмәк кирәк, язмыштан узмыш юк бит. Соңгы вакытта сезне сагынгадыр инде «Черная Колыма»ны укып чыктым. Сезнең күргәннәрегезне барысын да йөрәгемнән үткәрдем. Адәм балалары ниләр күрмәделәр, шуңа күрә исән калганнары бармак белән генә санарлык булды бит. Алары да берәм-берәм китәләр. Мин сезгә чират көтәргә рөхсәт итмим. Кабатлап әйтәм, әрәмгә узган гомерләрегез өчен дә сез әле бик озак яшәргә тиеш. Аннары дөньяда мин фәкыйрегез дә бар бит әле, хатларыгыз белән сез миңа яшәү көче бирәсез бит.

Сез белгәнсездер инде, Мәхмүд Хөсәен озак азапланмыйча гына больницада йөрәк белән үлгән икән. Бик җәл. Урыны җәннәттә булсын...

Бу арада радио-телевидениеда да референдум белән баш миләре кайнады. Татарстан халкы бик ашыкмый гына баргалап 22% булган ахры...

Ибраһим! Сездән хат килүне түземсезлек белән көтәрмен. Май бәйрәме белән тәбриклим.

*София (Гайнетдинова)*
*27.04.1993*

Мөхтәрәм Ибраһим ага!

Мин июньнең 18 ендә (быел, билгеле) Сезнең китабыгызга рецензия язып, «Советский писатель» нәшриятына тапшырдым.

Рецензиядә уңай фикер әйттем, бастырып чыгарырга тәкъдим иттем. Кулым җиңел булып, әсәрегез бу нәшриятта чыкса, мин бик шат булыр идем. Сез моңа бик тә лаеклы!

Исегезгә төшерим. Сез май аенда корылтайда Җәмил Мостафинга китабыгызны биргәнсез. Ул Мәскәүгә кайткач, китапны нәшриятка тапшырган. Нәшрият исә, миңа фикер язарга кушты. Мин инде эшне тиз тоттым һәм июньдә рецензияне илтеп тә бирдем.

Мин үзем СССР Язучылар Союзында эшлим. Монда без бик җаваплы комиссия төзедек (репрессиягә эләккән язучыларның язмышын өйрәнү буенча). Мин шул комиссиягә Сезнең турында һәм әсәрегез хакында күп сөйләдем... Белеп торсыннар дип. Бик кызыксындылар.

Менә шундый яңалыклар...

Ярый, шуның белән тәмамлыйм. Исән-сау булып торыгыз! Сезнең турыда элек тә белә идем, ә романны укыгач, күк капусы ачылган кебек, бөтен биографиягез яктырып китте, бөтен фаҗигаләре белән.

Күптән түгел Казанда Шәүкәт Галиевнең юбилей кичәсендә президиум өстәле артында бергә утырган идек. Сезнең белән янәшә – мин сулда, сез уңда идегез. Бәлки исегездә калгандыр...

*Күп сәлам белән Виль Ганиев*[1]
*(Мәскәү)*
*3.08.1989*

Хәерле көн, хәерле тормыш Ибраһим абый Салахов!

Менә сезнең «Тайгак кичү» романыгызны уку бәхетенә ирештем, 4–5 нче саннарын укыдык, 6 нчы санны көтәбез түземсезлек белән. Укып чыккач, бик әрнешеп елап алдым. Ләкин бу елауны сез тоймыйсыз да, күрмисез дә. Минем сезне кочаклап үксі-үксі елыйсым килде. Ерак бит, бәлки якынрак булсагыз, барып яныгызга уйларымны тормышка да ашырыр идем. Я раббым, адәм баласы ниләр генә башыннан кичерми икән. Кече яшемдә әбием, һәркөн иртән, хәтта көнгә берничә мәртәбә – хагыннан, нахагыннан үзең сакла, дип кабатлый иде, күрәсең шушы хәлләр халык арасында таралган булгандыр. Сөйләмим – кем белә, ачмыйм – кем күрә, ди татар мәкале. Бик тә дөрес сүзләр бит болар. Без әйтәбез, арестовать иттергән дә аттырган, дибез. Җиңел генә ике сүздән торган җөмлә. Ә ул ике сүздә 10 еллык җәфа чигүләр яисә коточкыч аттыру. Исән, таза, саф, белемле, акыллы, аңлы кешене бернинди гаепсезгә ату, яисә төрмәгә ташлау. Я раббым, җир бу кайгыларны, бу җәзаны ничек күтәрә алган, убылып төшеп китмәгән икән.

Мескен халык нихәл түзгән, якын кешеләреңне югалту – билгесез югалту. Көрәкләр, сәнәкләр күтәреп бөтен Россия халкы күтәрелеп чыкса да җиңә алмаслар иде микән. Икенче яктан уйлаганда, бу мисез, аңсыз кешеләр Сталин һәм аның галош чистартучылары гына түгел, төрмә надзирательләре – меңнәрчә мисез, аңсыз, тупас, котырган канлы ике аяклы тигрлар – бигрәк күп булганнар

[1] Виль Хәлим улы Ганиев (1934–2005) – шагыйрь, әдәбият белгече, тәрҗемәче.

бит алар. Бәхетсезлеккә каршы, ул каһәр суккан затлар әле дә күп. Адәмгә кайгы ясап, шуңа сөенеп яшәүчеләр.

Ибраһим абый, тагын ниләр күрдегез икән, билгеле инде, сезне гөлләр кебек чәчкә аткан язмыш каршы алмагандыр. Минем әтием сезнең яшьләрдә, 1910 елгы иде. 1970 елда 60 яшендә дөнья куйды. Ул 3 сугышта катнашкан кеше – фин, герман, япон сугышында бик күп җәфа чигеп, күп тапкыр яраланып, авыр тормыш юлы узарга туры килгән әтиемә. Сугыштан соң җимерелгән дөньялар, җимерелгән хуҗалык. Әнием белән икесе көне-төне эшләделәр. Носилка белән алып киткәнче эшләделәр... Инде сезнең язмышны укыгач, әтием турында борчыган уйлар бераз җиңеләйде. Әтием бит ул кадәре мыскыллаулар, җәберләүләр күрмәгән, сөйгән хатыны, яхшы балалары, әти-әнисе булган, ничек авыр булса да исән кайтып аларны куандырган, үзе дә куанган. 24 ел тыныч итеп гаилә шатлыгын күреп яшәгән, налогларны отменять иткәч, өстеннән гимнастеркасын (ямаулы) салып, ситсы күлмәк кию бәхетенә ирешкән, сезгә караганда әтиемне бераз бәхетле саныйм...

Ибраһим абый, хәзер менә тормышка нәтиҗә ясап, шигырьләр язам, әлбәттә, үзем өчен, үземнең якыннарым, туганнарым өчен, газета-журналларга язып караганым юк, анда минем гади генә юлларымнан көләрләр дип уйлыйм.

Ярый, хушыгыз, тормыш иптәшегезгә күп сәлам.

*Күп яхшы теләкләр белән сезгә Нәсимә Галиәхмәтова*[1]

*(Октябрьск шәһәре)*

*1.04.1988*

Хәерле көн, хәерле тормыш, хәерле көнкүреш!

Ибраһим абый. Менә бик озак югалып торгач, тагын калкып чыккан кебек Нәсимә сеңлегез тавыш бирә.

Хатыгызны алдым, зур рәхмәт.

Быел яз иптәшемнең әти-әниләренә авылга кайттык, сыер асрыйлар, без кайтып ярдәм итеп торабыз. Көтүдә чират. Менә без иптәшем белән көтү көтәргә чыктык. Шул көнне мин шигырь

---

[1] Нәсимә Галиәхмәтова – И. Салахов иҗатын яратып укучы, Башкортстанның Октябрьск шәһәреннән.

чыгардым. Шәһәргә кайткач, дәфтәр алып язарга утырдым. Мин шигыремне «Көтүче» дип атадым. Менә шул шигырьне сезгә дә җибәрәм әле.

Көтүче.

Көтүченең чыбыркысы
Шартлатыр өчен кирәк
Ә таягы көтүченең
Я, әйт, ни өчен кирәк?
Кара таңнан кара төнгә
Көтүче аяк өсте.
Күп галимнәр, язучылар
Көтү көткәндә үсте.
Алтынчы дистә куганда
Мин дә бер һөнәр алдым.
Чиратыбыз җиткән көнне
Көтү көтәргә бардым.
Яңгырлар явып торганнан
Үләннәргә чык төшкән,
Кошлар да инде уянган
Чык-су эчәргә төшкән.
Язның шундый матур таңы
Никтер, кошлар сайрамый.
Яланнарны агулыйбыз,
Кош язмышын уйламый.
Күккүк тавышы ишетелми
Ул каядыр югалган.
Әллә икмәкле якларга
минем кошым юл алган.
Әнә кояш күтәрелә,
Җиргә нурларын сибә.
Чык сулары җемелдиләр
Яшел үләннәр кибә.
Ашыга-ашыга кимерәләр,
Малкайлар яшел үлән.
Карап торам – аларда да
Кеше образы күрәм.
Әнә берсе усалланып
Куды икенче малны.
Аның урынын алды ул
Тапты ла инде җайны.
Көтүче хезмәте миндә
Бик зур тойгы калдырды.
Көне буе бер моңлы уй
Йөрәгемне яндырды.
Җилкәсенә капчык асып,
Чыбыркысы иңендә.
Хәсән Туфан шулай йөргән
Ерак Себер җирендә.
Ишектән чыккач та шул уй
Килде минем күңелгә.
Күзләремә яшьләр тулды
Ничек соң яшерергә.
Күз яшьләрем тамчы булып,
Чык суларына тамды.
Эх, илкәем, соң аңладың,
Гөнаһсызга кылган хатаңны.
Кимсетүләр, рәнҗетүләр
Сындырмаган Туфан йөрәген
Үзе белән һәрчак йөрткән ул
Шигырь белән тулы дәфтәрен...
Әнә, кояш байый, көтүченең
Килеп җитә соңгы сәгате.
Маллар алдан бара, үзе арттан,
Шундый инде аның гадәте.
Тик соңгы сәгатьләрендә
Атламыйлар икән аягы.
Менә кайчан кирәк икән аңа
Үзе белән алган таягы.

Ибраһим абый! Тазалыгыгыз ничек? Нинди яңалыклар бар? Сезгә озын гомер, шул мөлаем апага да озын гомер телибез.

*Сеңлегез Нәсимә*
*май, 1989*

Исәнмесез, Ибраһим абый!

Бик күп сәлам белән Сезгә Фоат Галимуллин хат яза. Хатыныгызга, балаларыгызга күп сәлам, матур теләкләр җиткерсәгез иде.

Ибраһим абый, сез беләсездер инде, безнең (сезнең туган уку йорты) институт тәкъдиме буенча, Сез Г. Тукай бүләгенә тәкъдим ителүчеләр исемлегендә игълан ителдегез. Инде газеталарда Сезнең файдага кайбер фикерләр күренгәләде. 11 февральдә К. Тинчурин театрында митингка җыелган халык (бу мәҗлес татар теле язмышы турында сөйләшү өчен җыелган иде), Фәрит Хәбибуллин исемле режиссер тәкъдиме белән, бүләкне Сезгә бирүне хуплады.

Мин 14 февральдә Кукмара районы Зур Сәрдек мәктәбендә булдым. Анда «Колыма хикәяләре» буенча укучылар конференциясе уздырылды. Бик җылы, тирән эчтәлекле узды. Мин дә чыгыш ясадым. Анда катнашучылар да бүләкне Сезгә бирергә кирәклеген әйтеп, хат язарга дип килешенделәр.

Мин, Ибраһим абый, Сезнең хатны, фотогызны, басылган китаплар исемлеген алдым, аларны Министрлар Советындагы Минһаҗев исемле кешегә илтеп бирдем. Тагын 2 данә китабыгызны сорадылар, анысын да алып барып тапшырдым.

Шулай булгач, иншалла, бүләк Сезгә бирелә дип өметләнәм.

Без бер көе яшибез. Яшьләр, студентлар белән мәш килеп көн үткәне сизелми дә.

Сезгә саулык-сәламәтлек, кояшлы апрель көннәрендә шатлык килүен теләп, матур күрешү өмет итеп,

*Фоат энекәшегез (Галимуллин)*[1]
*Казан*
*28.03.1990*

[1] Фоат Галимуллин (1941) – әдәбият галиме, тәнкыйтьче, филология фәннәре докторы, Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы.

Исәнмесез, Ибраһим абый!

Сезгә хатыгыз, кунакка чакыруыгыз өчен, ихлас рәхмәт. Без инде монда күңелебезне 30 августка барырга дип көйләп куйган идек, әмма тормыш дигәнең кайвакыт үзенең төзәтмәләрен кертә шул. Инде октябрь аенда күрешүләр һәм Сезне котларга, шатлыкларыгызны уртаклашырга насыйп булсын. Ник дигәндә, 80 яшькә каләмне кулда нык тоткан хәлдә җитү бәхет түгелмени? Шушы гомернең алты дистәдән артыгы иркенлек шартларында узган бит. Ул алтмыш елда мәшәкатьләре белән бергә бәхетле вакытлар да аз булмагандыр.

Ибраһим абый! Бу арада сезнең барлык диярлек (1957 елдан соңгыларын) китапларыгызны укып чыктым. Чөнки иҗатыгыз турында җыеп бер сүз әйтәсем килде. Өч роман, повесть, хикәяләр, истәлекләр, шигырьләр – байтак зур иҗат. «Имәннәр тамыр җәйгәндә» үзе бер казаныш! «Тайгак кичү» турында әйтеп тә торасы юк! Сезнең иҗат гаять үзенчәлекле (Казакъ яклары белән бәйле), татар әдәбиятында үз йөзе, үз темасы, үз сәнгать чаралары булган иҗат. Зур гына мәкалә язып, «Социалистик Татарстан»га илттем, анда Г. Ахунов миңа кадәр бер мәкалә китергән икән. Бәлки, икесен дә баса алырбыз дип алып калдылар. Кукмара, Балтач район газеталарына да мәкаләләр җибәрдем. Сезнең бу төбәкләр белән дә бәйләнеш бар бит.

30 август көнне Казан телевидениесе Сезнең Индус Сирматов белән әңгәмәгезне күрсәтте, радио исә Сезнең Эльза Гобәйдуллина белән әңгәмәгезне һәм «Колымские рассказы» (русча) бер өзек бирде. Шулай итеп, Татарстан туган көнегезне билгеләп үтте. Мин Язучылар союзына, Сезнең турыда буклет чыгару өчен, текст язып бирдем. Шаһинур Мостафин шуны бастыру хәстәрен күреп йөри.

Мин, 23 сентябрьдән 18 октябрьгәчә, Кырымда иҗат йортында булырга җыенам. Аннан кайткач, Сезнең тантанага барырга исәп, Аллаһы боерса.

Тагын очрашуга кадәр.

Сезгә саулык-сәламәтлек, бәхет, шатлыклар телим.

*Хөрмәт белән Фоат Галимуллин*

*Казан.*

*01. 09.1991*

Хөрмәтле Ибраһим ага!

Бүген мин Кисловодск шәһәренә санаторийга китәм. Путевкам 19 ыннан башлана. Һәм бүген иртән уртак эшебезнең 200 нче битен тәмамлап, җыеп куйдым. Эш мин уйлаганга караганда мәшәкатьле, авыр һәм четерекле булып чыкты. Кульязма начар укыла, икенче нөсхә, күп битләр сукыр. Аннары, бөтен сүзләр, терминнар, атамалар, казакъча сүзләр буталып-чуалып беткән. Бер биттә болай язасыз, икенче биттә үзгәртәсез... Бөтен җирдә игътибарсызлык. Сюжетта күп нәрсәләрнең очы-очка ялганмый. Әйтик, Госман бер җәй сборга барып кайтты. Ә Маша белән икенче җәйдәге Сабан туенда гына очрашалар. Кайда булган Маша, нишләгән! Эзләгәнме аны Госман, юкмы?.. Сез кешеләрнең язмышын кулда тота алмагансыз, адәмнәр күренәләр дә югалалар. Мисаллар бик күп, артык күп булганга санап та тормыйм. Минем 200 бит булды, сезнең текстта мин 407 нче биткә җиттем. Димәк, алдан чамалаганымча, роман 500 битләр чамасы булыр дип уйлыйм. Аз гына артык яки ким булуы бар. Мин ялдан январь урталарында кайтам. Әнә шул ялдан соңгы ике айда эшне бетерергә иде...

Съезд майның актыккы ункөнлегендә, әлбәттә, сезне чакырырлар. Исән-аман ул көннәрне күрергә язсын. Шунда без договорны да төзеп, эшне законлаштырып куярбыз. Юкса, мин бит кәҗә паспорты тотып кына эшләп утырам. Сезнең характерны белгәнгә күрә, тагын бер тапкыр үтенеп сорыйм: әгәр минем үзгәртүләр сезгә ошамаса да, сезгә берсүзсез килешергә туры киләчәк. Мин романга яңадан әйләнеп кайтмам, бу турыда ике сүз булмасын! Сезнең вариантның басылып чыгарлык хәлдә түгеллеген аңлагансыздыр дип беләм. Дөньяда төрле хәлләр, төрле могҗизалар булып торганга, бу турыда бүгеннән әйтеп куям... Бар, бик матур яңгыраган юллар бар, әмма мин бик нык, тамырдан үзгәртеп барам, кыскартам. Мин соавторлыкка дәгъвәләмим, китап сезнеке булып калыр, алай да үзгәртүләргә әзер булыгыз. Әйе, мин романны өч нөсхә басып утырам, бер данәсен журналга биреп карарбыз. Нәрсә диярләр. Өзеп кенә бер сүз дә әйтеп булмый әле. Яхъя Халитов әйткәндәй, «аның соңгы главалары тагын да буталчык»... Алда күз күрер. Миңа ачуланмагыз, сезгә ихтирам зур, эшебез уң булып тәмамлансын! Хушыгыз!

*Исәнлек-саулык теләп, Аяз!*

*Казан.*

*декабрь, 1983 ел*

Кадерле Ибраһим ага!

Җәйгә кердек, җылы гына күргән юк. Май гел салкын булды, ай азагында гына бераз җылытты, кичә-бүген тагын шыксыз һава, яңгыр, җил дә җил (моны шуның өчен язам: мин табигатьнең хәленә бик бәйле җан! Көннәр начар икән – эш аксый башлый!)

Романны редактор Яхъя Халитов укып чыкты. Искәрмәләре байтак булса да, мин аларның байтагысын кабул итмәдем. Мәсәлән, ул «казакъларда „җ“ хәрефе юк, мишәрләр дә „й“ белән сөйләшкән» дип бөтен әсәр дәвамыннан «җ»ларны алып ыргытуымны сорады. Ризалашмадым. «Имәнтау» саф мишәр авылы түгел, анда төрле халык яшәгән!» дип, аны да ышандырырга тырыштым. Рус сүзләрен дә бик нык киметергә туры килде. Дүрт бит яңа текст яздым, яңалык шуннан артмады...

Кулъязманы тизлек белән машинкага бирделәр, хәзер басалар, эш әзер булуга романны нәшрияткә төшереп тә җибәрергә җыеналар. Димәк, аның быел ел ахырына басылып чыгуы да ихтимал. Быел кайбер кулъязмалар кереп җитмәгәнгә, аларның планнарында чак кына үзгәрешләр безнең файдага булуы да бик ихтимал. Инде тираж мәсьәләсенә килсәк, ул як әлегә караңгы… Гарәф Шәрәфетдинов белән бу арада еш очрашсак та, ни ул, ни мин тираж хакында сүз кузгатмадык. Көйләнерме? дигән ышаныч беләнрәк яшим. Әле китапның тышлыгы эшләнмәгән, 5 нче номерлы тышлык бирәләр, шуннан да яхшыны көтеп булмый (иң кәттә тышлык 7 нче номерлы, минем аңа ирешә алганым юк!).

Инде типографиягә төшеп китүгә, акча ягын кайгыртып, сиңа җибәртү хәстәрен күрермен. Ике-өч көн элек кенә «Казан утлары»нда Рашат Низамиев белән сөйләштем. Алар хәзер 9 нчы санны әзерләп яталар. Романның 10 нчы санын басарга планлаштыралар. Инде андый-мондый хәл генә килеп чыкмасын, тьфу-тьфу...

Бу арада бәйрәм-сәйрәмнәр дә еш булып алды. 7 нче майда Бөек Җиңү көне уңае белән язучы-ветераннарыбызны котладык. Һәр өлкән язучы турында яшьрәкләрдән берәр кеше сүз әйтте, мин, гадәтемчә, остазым Әмирхан Еникине зурлап чыгыш ясадым. Аннан «Нарат» дигән ресторанга барып күңелле генә мәҗлес үткәрдек... Вакыйф Нуруллинга 50 яшь тулды, бөек галимебез Әбрар Кәримуллинга 60, аларның юбилей кичәләре дә тантаналы гына узды. Шушы арада миңа да бәхет елмайды әле, РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе дигән дәрәҗәле исем бирделәр. Документларны

элегрәк җибәргәннәр иде, указны шактый көттек. (Минем төрмә документларын да соратып алып, вак иләктән дә иләп уздырганнан икән!)

Яхъя Халитовка да романыгыз ошады. «Нык эшләгәнсез», дип әйтеп торды. Һәр җәһәттән дә эш уңай гына бара. Русчага тәрҗемә итү мәсьәләсен кайда кузгатабыз? Казагыстандамы? Анда тизрәк һәм өметлерәк булмасмы? Ул хакта да уйлаганда чит булмас...

Алма-Атадан язган хатыңны алдым. Шактый нык расходланырга һәм мәшакать чигәргә туры килгән икән…

Үзем бер хәлдә яшәп ятам...

Бер-ике көнлек вак-төяк эш калды. Аннары ныклап яңа романга утырсам кирәк. Җәмәгать эшләре бик күп, артык дәрәҗәдә күп. Алардан баш тартып та, читләшеп тә булмый. Язучы тормышка якын, бик якын яшәргә тиеш. Арбадан төшеп калуың бар. Ул хәтәр нәрсә.

Яңалыклар бетте дә кебек инде. Тазалык кына әлләкем түгел. Соңгы анализларны 12 нче майда ясаткан идем, харап!..

Хуш булып тор, Ибраһим ага! Үзеңә, Маһинур ханымга күптин-күп сәлам.

*Ихлас күңелемнән иң изге теләкләремне озатып калам, Аяз*
*Казан. 3 июнь, 1985 ел*

Хөрмәтле Ибраһим ага!

Кичә «Казан утлары»ның 2 нче саны килде, романның бер өлеше басылган... Бүген төнге дүрттә кар яктылыгыннан уянып киттем дә пыр тузып уйлап ятам. Әлерәк кенә газетада сезнең тавыш яңгырады: «казакъ» милләтенең исемен дөрес языйк!» Мин илткән кулъязмада да ул шулай иде. Әллә редакторлар төзәткән, әллә корректорлар артык акыллы, монда тагын «казах», «Казахстан» дип сырлап чыкканнар... Инде авыз ачып сөйләшерлек телең дә калмасын инде! Кардәш халыкның исемен язарлык алфавитың да булмасын».. Ни уйладылар икән безнең язу кагыйдәләрен өйрәнеп яңа шрифт кабул итүчеләр?!

Китапта роман сез әйткәнчә 3 кисәктән тора, журналда кисәкләргә бүлеп тормадым, ахырдан: «Беренче китап тәмам» дип кенә куйдым, борчылмагыз, ярыймы?.. Мин тәкъдим иткән өлешне шактый «кыркыганнар», Сабирның хатирәләре төшеп калган,

тагын шактый урыннар. Өч журналга бирсәләр дә ярыйсы иде дә... Нәби Дәүлинең язмаларын нигә ике урынга басарга иде? Әле «дәвамы бар» дип куйганнар иде, укучылар шаулый башлагач, өченче номерга басарга ук базмадылар... Их-хи-хи!.. Юк проза, юк! Җыен әтрәк-әләмнең кырга да, урманга да сыймаган иске-москы фикерләрен бастырып ятабыз...

Ярар, хәерле булсын. Ике санга эләгеп калуына да куанырга кирәк. Китап турында әлегә ләм-мим. Үзем дә сораштырмыйм, Фәрваз ялда, Гарәф Низаметдинович авырый, аны Мәскәүгә үк алып киттеләр. Китап декабрьләрдә чыкмасмы дип йөрим, әле корректурасы күренмәде. Тизләтәсе булыр, керергә туры килер. Романның башлавында «әшһәде әннә...» дип башланып киткән азанны төшереп калдырганнар, куркаклар! Үзенә бер колорит биреп тора иде ул! Ышанудан түгел, мәгәр без милли характерны бирергә теләсәк, үткән заманга багышланган әсәрләрдә коръән, диннән башка беркая да бара алмыйбыз лабаса!.. Марксизмны белмәгән, беләдә алмаган татар халкы нигәдер инанган ич! Халкыңның нәрсәгә инануын белмәгән килеш аның җанына ничек үтеп кермәк кирәк?! Мин дә дингә ышанмыйм, әти мулла улы иде, әнием коръәнхафиз кызы, икесе дә дингә ышанмау түгел, актив дәрәҗәдә атеистлар иде, безгә дә шул тәрбияне бирделәр...

Эшләр менә шулай. Сиңа бер-ике журнал алып җибәрермен. Кирәк дисәң, тагын табарга да булыр. Роман тулаем басылмагач, журнал белән күрше-күлән алдында гына мактансаң инде... Э-эх!

Бездә кыш башланып маташа...

Кар ятты. Һава сафланды. Кичләрен аяк табаннары кызыша – йөрисе килә. Синнән күптәннән хат алган юк: ни хәлләрдә?.. Саулык яклары ничегрәк? Атка менеп казакъ даласында сызгырып йөреп буламы-юкмы? Бер кунакка да чакырмадың инде, байгыш!..

7 нче декабрьдә РСФСР язучыларының съездына кузгалабыз. Бездән тулы бер отряд – утызга якын кеше: делегат һәм кунаклар. Отряд бара – корал гына иске, күгәргән сөңгеләр, атмый торган мылтыклар. Отрядка өч хатын-кыз дә тыкканнар. Татар язучылары әдәбиятның какшаган бинасын хатын-кыз белән терәтеп куярга ният тота башлаганнар әле... Нишлисең – йомшаклар заманасы.

Хат яз. Ихлас күңелдән саулык-сәламәтлек теләп калам,

*Аяз (Гыйләҗев)*
*Казан. 26 ноябрь, 1985 ел*

Хөрмәтле Ибраһим ага!

Кичә хатыңны алдым, рәхмәт!

Кичә менә җитешеп романның корректурасын укып бетереп илттем. Өзә-төтә тапшырдылар, хаталар байтак, гарәп-казакъ сүзләрен нык ук бутаганнар, бөртекләп укырга туры килде. Яңа елны каршылау көннәре шул зарурый мәшәкатьләр белән узды. Ике елга якын вакытымны алган китапны хәзер чит күз белән укыгандай укыдым да яраттым. Көч бушка китмәгән, роман әйбәт укыла. Роман яшәячәк, синең исемне әдәбият тарихында беркетеп калдырачак. Шигем юк!.. Ходай насыйп итсә, истәлекләреңне дә бер карап узармын. Бәлки аларына кул тыгасы да булмас!? Документаль фактик матерал буларак аларның үз бәһасе табылыр.

Корректура килгәч тә редакторыбыз Яхъя янына кердем, тизрәк укуын үтендем, ул Фатих Әмирхан томын әзерләп утыра икән, «20 числоларга кадәр тотына алмыйм» диде. Димәк, китап январьда чыга алмый, февральгә кала. Әлбәттә, сигнальныйлар килүгә үк сезгә җибәрү ягын карармын!.. Кызганыч, Гарәф дус ике тираж бирә алмады! Матди ягы күңеллерәк булыр иде!

Казан юбилейлар белән кайнап яши: 13 нче январьда Фатих Әмирханның 100 еллыгын Академия театрында билгеләп узачакбыз. (докладчы Туфан Миңнуллин). Ниһаять, татарның бөек улы булган Фатих Әмирхан үзенә лаек хөрмәтне ала башлады. Кызганычка каршы гына түгел, оятыбызга каршы, шул азамат ирнең гүзәл иҗатын дөнья мәйданына чыгара алганыбыз юк, бу йөз еллыгында да шул эш насыйп булмаган икән... Аннан ел Тукай 100 еллыгы белән туп-тулы булачак. Җәлилнең 80 еллыгын да зурлап үткәрү планлаштырыла. Әле яңа бинага күчә алганыбыз юк, санэпидстанция бинадан яңадан-яңа гаепләр таба тора, күчү кичегә...

Быел Казанда чын, борынгы кыш. Кар, бураннар, юллар адәм улларын адаштыра... Гаҗәп хәлләр очрап кына тора! Шәһәрара юлларында автобуслар карга күмелеп калып, Яңа ел алдыннан 32 автобус казага тарыган, үлүчеләр дә байтак булган икән...

Үткән хатыңда Нури Арсланны телгә алган идең. Исән-сау, сирәк-сирәк кенә союз коридорында күрешәбез, без аның белән аралашып яшәгән кешеләр түгел. «Хаклык өчен көрәш башланса – мин ике куллап», дигәнсең. Рәхмәт! Үзеңне көчле итеп тоясың икән әле! Озак яшә, син бит «соңгы могиканнарның берсе!», хәтерең

тере, зиһенең ачык чагында истәлекләрне барлап, туплап калдырсаң иде! Мин шулай уйлыйм...

Гаиләңә кайнар сәлам!

Сиңа тазалык-саулык, илебезгә-көнебезгә иминлек теләп калам.

*Дусларча сагынып, Аяз*

*Казан. 8 январь, 1986 ел*

[...] Китабыгыз чыкты, кулыгызга керде, ике ай дәвамында сездән хәбәр-хәтер юк!.. Коры кашыкның заман символы түгеллеген бик яхшы белгән хәлдә, сездән беркем берни өмет итми иде. Ул хакта хафаланмаска да була. Мәгәр кош теле хәтле хәбәр салу, директор белән редакторга аз-маз каз мае сөртү әдәплелек, олылык һәм чын ихтирам була иде. Мин шуны күздә тотып яздым. Рәхмәт, хәбәр салгансыз, хатларыгызны алганнар, канәгатьләр. Сезгә саулык теләп калалар...

Әгәр мин вак-төяк өчен көя башласам, әллә кайчан бетәр идем, юк, Ибраһим ага, мин мондагы әтрәк-әләмнәр, буш куыклар белән көрәшә-көрәшә кискенлеккә дә, усаллыкка да өйрәнгән кеше. Мин икеләнү дигән нәрсәне белмим, ялагайлануны кабул итмим, икейөзлеләрне тирәмә якын да җибәрмим. Шулай яшәдем, шулай яшәрмен. Авырып киткәнсез икән, монысын белмәдем, 7 нче майда сезгә хат юлладым да, 8 ендә үзем дә больницага кереп яттым. Арылды. Хәл калмады. Чир-чорлар да ябышырга гына тора. Беребез дә тимер түгел, еллар бөгә, уйламагыз, сезнең яшькә җитеп булмас, сезнең яшькә җитеп булса, үкенеп утырырга да риза. Черт с ним!..

«Бу хат, иншалла, югалмас» дигәнне укыгач, гафу итегез, көлеп җибәрдем. Сез һаман оптимист булып каласыз икән!.. Кайчан да булса бер безнең хатларны табып, укып-өйрәнеп, алардан гыйбрәтләр табарлар дип ышанасызмы?! Ай-һай... Ай-һай... «Инкыйраз» дигән сүзне мин беренче мәртәбә сезнең авыздан ишеттем... «Ике йөз елдан соң инкыйраз» дигән кеше турында да тикшеренүләр, фәнни хезмәтләр басылды. Зур белгеч-галим Әбрар Кәримуллин «Ә без әле хәтта Тукай хәтле Тукаебызның нинди китаплары басылуын да юньләп белмибез. Һәм аларны барлау, эшкәртү, саклау, халыкка җиткерү өчен бер генә фәнни учреждение дә, бер генә китапханә, бер генә музей да планлы рәвештә эш алып бармый», дип әрнеп язды... («Соц. Татарстан, 7 июнь, 1986 ел).

Тукайга сан булмаган чакта, кая инде!..

Әйе, миңа язган хатларыгыз югалмас. Минем өч улым да татар халкына ихтирам белән үсәләр...

Үкенмичә яшик. Үкенмик!.. Без төзәтә алмаганнарны тарих үзе ипләр бәлки?..

Мин сезгә һичбер кинә сакламыйм, хөрмәтем кимемәде, мин сезгә бары тик саулык кына телим.

*Ихтирам белән Аяз*

*Казан. 11 июль, 1986 ел*

Хөрмәтле Ибраһим ага!

Сезнең бик күп кайнар учакларда янып, төрле сандалларда чүкелгән саулыкны белгәнгә, үткән хатлардагы «инфаркт» дигән хәбәргә дә алай егылып төшмәгән идем, 7 сендә язган хатыгызда «тагын больницада...» дигәнне укыгач, чынлап хафага калдым... Нишлисең, бәла аяк астында йөри. Язмыш аны эзләтә, тормыш барып таба. Үзем дә соңгы елларда саулыкка туймыйм, «диабет» дигән татлы явыз муенга уралды, һич кенә дә ычкындырмый. Менә бүген иртәдән бирле диярлек урында уһылдап ятам, әллә картлык, әллә шул «сөйкемле шикәр» хәлне ала... Ашыгыч тәмамлыйсы эшләр бар иде, арада берсе себер татарлары турында роман... Якуб Занкиев дигән хөрмәтле бер адәм ун елдан бирле күтәреп йөргән кулъязманы үз өстемә алган идем, ярты юлда тукталды да калды… Инде кеше эше алмам, бусы соңгысы! дип антлар эчә-эчә тотынган идем, очы-кырые күренми...

Ишеткәнсездер, Сибгат ага Хәкимне җирләдек. Җаны якты иде мәрхүмнең, чаялыгы, кыюлыгы заманга җитеп бетмәсә дә, мондый буталчык вакытта, кешеләр үз шакшыларына батып, пычранып йөргәндә ул безнең арада якты шәхес иде! Тыныч, сабыр, ипле, игътибарлы, нечкә күңелле шагыйрь иде. Яшьлеккә тартылды, яшьлек белән үзен урады, яшьлеккә йөз тотты. Бик күп гарип заманнарны кичереп тә җаннары ватылмыйча калган өлкәннәр безнең арада аз, шуларның берсе Сибгат абый иде... Олылап озаттык, алай да халык без көткәндәгечә ишле булмады... Ни сәбәп?.. Кем аңлаган да, кем аңлата алган?.. Кичә язучыларның партоешма секретаре Р. Мостафин, «Казан утлары»ннан Ренат Харис телевидениедә озак чыгыш ясадылар, сорауларга җавап бирделәр. Аларны тыңласаң әле

XXVII съезд булмаган, алар әле генә СССР язучыларының давыллы 8 нче съездында булмаганнар да кебек... Җитәкчеләр шул юнәлешне сайлаган икән, ничек үссен ул татар әдәбияты, укучысы ничек арт-сын?! Тоташ битарафлык, тоташ ялган мактау, кәефләнү... (Гафу ит, боларны җаным үксеп җылаганга гына кыстырып киттем!)

Августта сезгә 75 яшь тула.

«Ничек үткәрәсез?» дип сорарга кыймыйм...

Еллар имин торса, әллә бер барып чыгаргамы дип йөри идем, хәзер булмас инде. Авыру чакта тантаналар күзгә күренми. Хәзер иң мөһиме тынычлык, саулык. Һәм ... абынмаска! Абынгач егыл-мый була ди мени?!..

Һәм мин сезгә нәкъ менә шул иң кирәген – саулык, җан ты-нычлыгы теләп калам.

Берәрсе ашыгыч рәвештә матбугатта күрсәтеп, сөенечне уртак итәрме дигән идем, бүгенге татар язучылары татар китапларын ачып та карамыйлар шул, сезнең роман турында әлегә ләм-мим...

Хуш булып торыгыз, өй эчегезгә сәлам.

*Ихтирам белән, Аяз*
*Казан*
*22 июль, 1986 ел*

Хөрмәтле Ибраһим ага!

Мин 4 нче ноябрьдә, уравыч юллар аша, Грозный дигән аэро-портта интегеп кунып, көч-хәл белән өйгә кайтып җиттем. Ниш-лисең, Казанны томан чолгаган иде!..

Бәйрәм тантаналарын уздырып җибәреп, бүген «уянгач беренче эшем» (!) сиңа хат язам...

Пицундадан Ренат Харис исеменә хат язып, ашыгыч рәвештә синең кулъязманы эзләп табуын һәм һичкичекмәстән журналга кертеп җибәрүен үтенгән идем. Сүз дәлиленә, фикерем ныклыгына Мәскәү журнал редакторларының алдынгы ел планнары хакында сөйләгәннәренә игътибар итүен дә сораган идем. О, дөнья чыннан да үзгәрәдер, хактыр бу, Ренат Харис җитезлек күрсәткән, синең кулъязманы эзләп алган, укып чыккан, журналга планлаштырган әсәрләрне алдагы айларга чигереп, синең кулъязманы «Казан ут-лары» журналының 4 нче саныннан бастыруны планлаштырган. Хәзер редакция хезмәткәрләреннән бер иптәш кулъязманы өендә

бикләнеп редакцияләп утыра. Котлыйм һәм сөенәм! Исән яшәгез, бәлки сезнең гомернең таҗы булырлык китап менә хәзер дөнья күрәдер. Хаксызга җәзаланган чордашларыгыз арасыннан исән калган бердәнбер язучы буларак, сез вөҗданыгыз, намусыгыз кушканны башкарып чыккансыз, бернинди данга, материал байлыкка өметләнмичә, еллар буе күз нурыгызны ак кәгазь өстенә түкәнсез. Ренат Харис йөгерә-чаба кульязманы журналга тәкъдим итә!.. Тик сезгә зур бер үтенеч: (Ренат та шуны сорады!) бу хакта әле Казан кешеләренә, беркемгә дә белдермәгез. Үзгәрешләрне яклаучылар белән рәттән аларга аяк чалырга маташучылар да җитәрлек, әсәр басылып чыкмыйча торып, бу хәбәрне редакция хезмәткәрләреннән тыш беркем дә белмәсен! Килештекме?..

Хәбәр, таралган тәкъдирдә дә, синнән-миннән чыкмасын. Әгәр яңалыклар була калса, үз тәртибендә, мин аларны сиңа хәбәр итә торырмын. Каршы төшүчеләр булса без дә тик ятмабыз, шул җөмләдән мин үзем тешем-тырнагым белән кульязмаңны китап итеп тә чыгарырбыз дип ышанам. Нәшрият директорыбыз һаман юк, Г. Шәрәфетдиновның авырып пенсиягә китүе колагыңа чалынгандыр инде, ул җаваплы урынга, теләсә кемне китереп куярга обком да базмыйчарак тора. Кем килер, кем? Чор бик җаваплы, эш авыр, егетлек, кыюлык, гаделлек таләп итә торган эш...

Кайттым...

Эш муеннан...

Кайсы төшеннән тотынырга белгән генә юк...

Сау булып тор, Ибраһим ага, сиңа сәламәтлек, көр күңел теләп калам. Хәзер сиңа яшәргә дә яшәргә кирәк инде! Чир-чорларга баш бирергә ярамый.

Өй эчеңә сәлам.

*Ихтирам беллән, Аяз!*
*Казан.*
*9 ноябрь 1987 ел*

Кадерле Ибраһим ага!

Котлауларыңны алып торам, рәхмәт!

13 ендә редколлегия утырышы булды. Ренат Харис җыелган халыкка: «Үзебез өчен искиткеч кызыклы, мәгънәле әсәр баса башлыйбыз, ул – Ибраһим Салаховның романы, дип белдерде.

Утырыштан соң Салих Маннапов синең романның икенче зур гына өлешен миңа биреп җибәрде, кичә кич, соң гына, өйдә ялгыз утырып, кулъязмаңны укып чыктым (әле бөтенесен түгел). Егетләр ипләп кенә редакцияләгәннәр, кабатланган урыннарны белеп-чамалап кына кыскартканнар...

Аллаһы боерса, әсәрең укылачак.. Мин аерыла алмыйча бер тында укып чыктым. Укучыбызга бик тә, бик тә кирәкле әсәр! Татар укучысының күзен татарча басылган җитди әсәрләр дә ачарга тиеш! Халкыбызның язмышын үзебез язып, әдәбиятта беркетеп калдырмасак, бүгеннән дөнья тәртәсе арасына җигелергә торган киләчәк буын, телебезне ярым-йорты гына белүче буын, безнең татарча кайгырганны, татарча сагышланганны, татарча сөенгәнне, татарча көенгәнне аңлый алырмы соң? Бәби тапканда хатыннар әнкәләре телендә ыңгырашсалар, читен чакларда ирләр үз телләрендә дога укыйлар, диләр ич...

Хәзер, иртәнге чәйне эчәм дә, редакциягә синең кулъязманы илтергә йөгерәм...

Бирсен Ходай, бирсен!.. Яшик әле, яшик... Кичә берәү нәшриятта очратты да, кочаклаган була, премия белән котлый... Кабахәт кеше. Хәзерге үзгәрешләргә карап тешен шыкырдата торган бәндә югыйсә, мине мактый! Элек сөйләшергә дә теләмичә борын җыерып үтә торган иде... Яшисе иде әле!

Синең каторга юлы бөтенләй үзгә булган. Без бүтәнчә яшәдек, бүтәнчәрәк... Сау булып тор, Ибраһим ага.

*Яратып, ихтирам белән, Аяз!*
*Казан*
*15 январь 1988 ел*

Хөрмәтле Ибраһим ага!

Хатың тиз килде, рәхмәт! Күңелле хәбәрләреңне укып куандым, № 3 нченең һөҗүмен ишетеп, моңсуландым. Сиңа озаграк яшәргә иде әле! Әле сиңа килгән хатлардан зур гына бер өлеш төзеп, аны «Казан утлары»нда бастырып чыгарасы иде. Мөгаен, хатлар арасында моңарчы без белмәгән, белә алмаган, тарихчыларның күзеннән читтә калган газиз милләттәшләребезнең – Сталин тәбеләрендә һәлак булганнарның исемнәре, якты гамәлләре бардыр. Сиңа килгән хатлар, романда телгә алынган исемнәр кебек үк,

кадерле исемнәрне дөньяга чыгаралардыр дип ышанам. Алар синең архивта сүзсез калмасыннар иде инде. Гомумән, егәрең барында син бу җәһәттә үтәргә мөмкин булганнарның барын да башкарып чыга алсаң иде!..

Романның исеме... Гади генә, «Фаҗига» дип калдырганда ифрат эчтәлекле һәм тирән буласы икән дә... Хәзерендә соңга калмадык микән? Алай да мин нәшрият директорына хат язып, синең бу теләгеңне җиткерермен, сине яклармын. Кызганыч, Фәрваз сентябрь башыннан Дубултыда, ай азагында гына кайтачак. Нигә китап исемен авторның теләгенә каршы килеп үзгәрттеләр икән алар, аңлап бетермим. Дөрес, Фәрваз миңа нидер аңлатып маташкан иде, төбенә тоз салырга минем дә акыл җитмәгән! Менә хат язышмый торуның нәтиҗәсе!..

Аннары, син көчеңдә чагында, «Сайланмалар»ны чыгару турында сүз кузгатсаң шәп булыр иде! Дөнья күргән проза әсәрләрен туплап, ничәдер томны киштәгә тезеп куйганда начар булмас иде бит! Бу хакта кайчан сүз кузгатсаң да соң түгел, мәгәр, сүз башта үз авызыңнан чыксын иде! Син хәзер безнең халыкның милли герое, һәр тарафта синең сүз үтәргә, үз биеклегендә йөрергә тиеш.

Эшләргә дип бик нык ярсып килгән идем, башлангыч көннәрдә уйларыма тугры калдым, туктаусыз эшләдем, Литвин белән языла торган романның өченче китабын нык кына алга җибәрдем, хәзер исә эшем сөрлекте, соавторым үзенә тиешлесен үтәмәде, утырам хәзер теге як ярга чыга алмыйча як-ягыма каранып... Әллә бу эшне куеп торып, әллә кайчаннан күңелдә чүпрәсез дә күпереп йөргән бүтән әйбергә ябышыргамы? Бүген-иртәгә Литвиннан хат-хәбәр килеп җитмәсә, мөгаен, шуңа тәвәккәлләрмен дә...

Килгән хатларның аерата мөһимнәрен сайлап, аларның копияләрен алып журналга әзерли башларга кирәк. Хәзер «Казан утлары»нда кулъязмалар букчасы шактый калын, язучыларда әрсезлек җитәрлек, кораллары сыек булса да армиябезнең саны арта тора, эте-бете союз ишеген шакый, кабул итү комиссиясенең рәисе сыйфатында миңа күп нужалар чигәргә туры килә. Бу иптәшне алмас идең, таланты юклыгы күзгә чекерәеп кереп тора, бер чакта да юньле язучы чыкмаячак, ә союздагы «теге группировка» вәкилләре аны яклый... Төркемнәргә таркалган союз – союз түгел инде ул! Аерылганны аю ашар, бүленгәнне – бүре, дигәннәр, хәзер безнең таралган вактөякләрне ашау өчен күсе дә җиткән, аю-бүреләргә эш калмады!..

Монда килсәң кызык булыр, шәп булыр иде, әй!

Зәки Нури монда, күрше, янәшә бүлмәләрдә яшәп ятабыз, тик аралашмыйбыз, җирлек юк, уртак уй-фикер табылмый, ул ямьсез картая, өсте-башы таланган, үзе өшәнгән, хәтере чуалган да кебек күренә.

Ә көз бик матур килә: кояшлы, җылы, тыныч. Кеше артканлыгы да тора-бара сизелми башлады, күнектек. Һәркем үз дөньясында, үзе чыгарган давылларда яшәп ята. Өйдән хатлар сирәк булса да килә. Сау бул, Ибраһим ага, озак, сәламәт яшә. Гаиләңә сәлам. Мин 9 октябрьдә бер срокка Пицундага китәм, аңа кадәр синнән хат алып өлгерермен әле.

*Тирән ихтирам белән, Аяз*
*Переделкино.*
*11 сентябрь 1988 ел*

Хөрмәтле Ибраһим ага!

Яңа елда беренче хатым сиңа, кабул итеп ал! Исән-аман кайтып җиткәнсең икән, шәп булган. Үзең булмасаң да Казан синең белән яши, безнең очрашуны телевидение аша тагын бер кат һәйбәтләп күрсәттеләр, Яңа ел кичендә дә синең сөйкемле елмаюың балкып безгә исәнлек-саулык теләде. Рәхмәт, үзең дә сау бул, бирешмә! Телефоннан әледән-әле синең адресны сорап алалар, татарлар гына түгел, руслар да сорый, кызыксына. Әле бүген дә сиңа хат язарга утыргач, бер ханым шалтыратты: «гарәпчә бик яхшы укыйм, машинкам да бар, алдагы эшләренең һәммәсен хәзерге язуга күчерермен», дип хат язарга булды. Шәт-иншалла, хәбәрләшерсез.

Мин һаман элеккеге ыгы-зыгылар белән көннәрне озата торам. Әллә ни эш тота алган юк дисәң дә ялган түгел, «кайчан Переделкино аулагына барып, тынлыкка һәм тынычлыкка ирешермен?» дип, көн туса хыялланам. Анда ичмасам ашавың харам түгел, эшләнә! Фәрваз бу атнаны авырып йөри, китабыңның ни рәвешле икәнен әйтә алмыйм, инде озакламас, чыгар, халкыбыз кулына барып та керер. Шулай да онытып бетерергә ярамый, «Сайланмалар» хакында әледән-әле нәшрият агайларының колагына төшерә торырга ярый, үзең беләсең, сорамаган татарга имчәк бирмиләр. Күңелле хәбәрләрнең берсе, ниһаять, «Идегәй» китап булып чыкты. Мин аны сиңа бүген-иртәгә салырмын. [...] Бүген нәшрият директоры

янына кереп, рәхмәтемне әйтеп чыктым. «Идегәй»не зур, бәйрәм форматы белән, рәсемләп, калын ак кәгазьгә, сувенир-бүләк китап итеп чыгарып булмасмы, дип сүз кузгаттым. Әгәр халкыбыз күңеленә нур үткәрергә теләсәк, һәр татар йортында «Йосыф китабы» белән «Идегәй» сакланырга тиеш! Тукай, Такташлар турында әйткән дә юк анысы!..

Татар бик авырлык белән уяна. Балтач районындагы бәрәкәтле очрашуларны сагынып искә һәм телгә алам. Нинди бөек затлар яши әле ул якта! Казан артын сакларга кирәк безгә, ул төбәк безнең телебезнең сакчысы!.. [...]

*Аяз*
*Казан.*
*6 гыйнвар 1989 ел*

Кадерле Ибраһим ага!

Хатлар төргәге килеп җитте, исән-аманнар! Синең китапның социаль әһәмиятен, югарылыгын ача торган хатлар азрак икән, нишлисең, татар укучысы яңалыкны акыл белән түгел, хис беләнрәк кабул итә шул! Телевидениедән уртак чыгышыбыз уңае белән миңа да хатлар күренгәләде, берәү – Галимова дип кул куеп, өлкән ханым булса кирәк, «яшьләрне котыртып ятмагыз, без бүген дә Сталин рухына дога кылабыз», дип икебезгә дә каһәрен укыган. Лениногорскидан бер хат бар, анысын ун ел төрмәдә утырган Таҗиев дигән кеше язган, әгәр теләгәнебез барып чыкса, сиңа килгән хатларга төпле генә күзәтү оештырсам, бу язмаларны да телгә алып китәрмен. Бер нәни генә эшем бар иде, дүшәмбесишәмбеләрдә шуннан котылсам, сиңа килгән хатларга тотынырмын.

Почтаны беләсең, уведомлениене ябыштырып миңа китерделәр, хат язарга ниятләгәч, аны салып та тормыйм.

Казан бер килеш, кыш матур гына ныгып килгәндә, биреште, тагын җебеп акты. Йорт түбәләрендә кар калмады да диярлек. Союзга бик сирәк кенә барып кайтам, анда шул ыгы-зыгы, съезд алдыннан җылы урыннарны бүлә алмыйча качып-посып та, күзгә-күз чәчрәп кереп тә талашалар. Ай «җылы урын» боза кешеләрне!.. […] Тәүбә, тәүбә!.. Мин кешеләрне элек тә аңлап бетерми идем, хәзер тәмам чукрак вә сукырга әйләнгәнмен икән.

Ни хәлләр? Саулык ничек?.. Китабың март башларында чыга, аны Тукай бүләгенә тәкъдим итәргә, дип сүз кузгатып торам,

конкурентың да бик лаеклы кеше – Нурихан Фәттах. Аның «Сызгыра торган уклар» романының икенче китабы басылды, күп еллык олы хезмәте тәмам, бүгенге үзгәреш, борылыш чорында тарихыбызны бәян иткән китапларның бәһасы чиксез зур, монда бер нәрсәне исәпкә алсак инде... Син сиксәнгә җитеп киләсең, романың заман рухына ипләнде, журналыбызның тиражы унбиш меңгә диярлек артты... Башкортстанга барып, «без ут күршеләр, туганнар» дип, кочаклашып, учны учка бәреп, «халыклар дуслыгын ныгыткан идек», Башкортстанда журналның тиражы бөтенләй артмаган, Казан-Чаллы шәһәрләрендә тираж меңәрләп өстәлсә, тегеләрдә юк дәрәҗәсендә. Башкорт экстремистлары татарларны тагын да ныграк кысканнар дигән сүз. «Агыйдел»нең дә тиражы артмаган, киресенчә, кимегән. Димәк, эчке көрәш бара, кыза. Бүген радиодан Тәүфыйк Әйди чыгыш ясады! Һай, Ибраһим ага!.. Мин инде аның шикелле кыю, төпле, нигезле була алмыйм! Егет көчле, әзерлекле, кулында саннар-цифрлар, документлар, фикерләр. Авызын ача икән – саннар, төгәл искәрмәләр, без белмәгән, белергә бик ашкынмаган да фикерләр! Үзебезнең сыртның сынык икәнен бер кат уйлап, уфтанып яттым. Гомердә булмаганны, бүген Мөсәгыйть Хәбибуллин дигән кеше дә һич курыкмыйча, җиребезне басып алган русларның татарны канга батыруы, һәлак итүе һәм аңа күпсанлы ялган бәла-казалар тагуы турында ачынып сөйләде. Авызымны ачтым да калдым. Бәрәкалла! Халыкны уятырга юнәлтелгән ярты сүз дә безгә бик кадерле ич!.. Без аренадан китеп барабыз, Тәүфыйк төсле яшьләребез килсен берүк!

Шундый хәлләр. Язманы әзерләгәч бер нөсхәсен сиңа салырмын. Син анда, давай, тәмле ит калҗалары ашап, кымыз эчеп тик кикереп йөр, чир дигән явызга баш бирмә! Гаиләңә сәлам!

*Сагынып, Аяз!*
*Казан.*
*14 гыйнвар 1989 ел*

Саумы, кадерле Ибраһим ага!

Шәт, иншалла, шифаханәдән кайтып кергәнсеңдер, шулай булсын, тәңребез сине ярдәменнән мәхрүм итмәсен!.. Кичә яныма Нәкыя килеп төште, мәкалә басылган газетаны алып килгән, аннан алда синнән хат алып сөенгән идем. Мәкаләне бераз кысканнар,

күләме зуррак күренгәндер, алай да кыю гына бастырып та чыгарганнар. Мин «халкыбызны халык итеп саклап калуда күп вакытлар бердәнбер терәк булып калган мөселман дине», дигән фикерне явызланып сызып ташларлар дип көткән идем, шөкер, калдырганнар. Хәзер шушы фикерне бездән соң килә торган әдипләр әдәби әсәрләр аша халыкка да җиткерсәләр... шәп булып иде! Тарихи дөрес фикер...

Бүген монда соңгы көнебез. Иртәгә, чәйдән соң, китәбез дә дүрт көнгә Минскидагы танышымда тукталабыз, килгән-килгән Белая Русь белән дә әз-мәз танышасы килә. Әдипләре «милләтебез бетә!» дип йомгак ясасалар да, радио-телевидениеләрдә, газеталарда милләтне коткару ягына караган сүзләрне ишетмәдем, күрмәдем дә. Милли һәлакәтләре белән әллә килештеләрме болар дип борчылып уйлыйм. Хәзер, әгәр нәни генә милләт тә ил составында бетә икән, бу факт бүтән милләтләрнең, шул җөмләдән, татарларның да соңын якынлаштырачак...

Нык эшләдем, нык! Литвин белән уртак романның өченче китабын бик ашыгыч бетерәсе бар иде, аны тәмамладым. «Нигә әле болар бүген, агымга каршы барып, чека турында язалар?» дигән тәнбиһле сорауларга фаҗигале өченче китап җавап бирергә тиеш иде, ниһаять, мин аннан котылдым. Җиңеләеп калдым. Өч-дүрт ел кулны тотып, зиһенне биләп, уңдырышлы кырымнан тиешле уңыш алырга ирек бирми торды. Бер тотынгач, азакка җиткерәсе килә иде...

Куанам, синең алдагы бурычларым үтәлде, биргән вәгъдәләрем җиренә житте. «Имәннәр тамыр җәйгәндә»не эш иттек. Игътибар гына бирмәделәр: роман яши-яши әле үз урынын алачак! Бу темага синнән башка берәү дә йөрәксенеп тотына алмаган кебек, миннән башка кеше аны тәмамлап, дөньяга чыгара алмый иде! Мактана дип күрсенмә, мактансам да урынлы: шәп әсәр югалмады, халык кулына барып керде...

Литвин белән уртак романны тәмамлаганнан соң, былтыр Переделкинода яза башлаган повестема тотындым. Атнадан артык кинәнеп, рәхәтләнеп яздым ки, дәртем Белоруссия урманнары, сөйкемле Ислочь елгасы өстеннән шашып-очып йөрде, фикерләрем артыннан җитешә алмадым, машинкамның хәрефләре язгы ташкын булып ыргылдылар. Килгән шәпкә вак-төяк ыгы-зыгылар аякка ияргән иде, эш дәвамында аларны кагып төшердем. Сизәм,

шәп әсәр язам! Чын әсәр, уйлы әсәр, кызыклы язмышлы кешеләр белән шыплап тутырылган яңача әсәр...

...Яшисе дә яшисе генә иде лә, авырып ятмагыз әле, тынычсабыр булыгыз, көяләнүләргә баш бирмәгез...

*Ихлас хөрмәт белән, Аяз*
*Минск-Ислочь*
*19 март, 1989 ел*

Хөрмәтле Ибраһим ага!

Хатларың килә – рәхмәт! Хат языла икән, күңел тормыш белән арасын өзмәгән дигән сүз. Хат – күңел сере!..

Менә, Аллага тапшырып, соңгы атнага да кердем, егерме бишендә сәфәр. Өй сагындырды, монда рәхәт булса да, җан өйгә тартыла, балалар катына, хатын янына. Эш тизлеге һәм тигезлеге дә шул хисләргә буйсынып үзгәрә, сүзләр бик тирәннән, авырлык белән табылалар, фикер йомыла төшә, килгән шәптәге егәр, кыюлык һәм дәрт калмый. Алай да өстәл яныннан китәргә ярамый, гомер җебе кыскара. Аның аргы очы кайсы елга барып җитәсен кем белгән? Ә язасы, өстә намус бурычы булып килгән әсәрләр әле бар, бирәү генә дә түгел!..

Бара торгач без, татарлар, монда ишле булып киттек: башта Вакыйф Нуруллин, соңрак Рәдиф Гатауллин килеп төштеләр. Һәркайсы үзе белән яңалыклар, хәбәрләр алып килде. Арада сөенечлеләр дә, кайгыга калдырганнары да бар. «Кичке Казан» газетасы татарча чыга башлый икән, бу – бер. Университет катында, зур планнар белән шәрыкъ факультеты ачылачак. Бусы иң куанычлы һәм күңелле хәбәр! Улым Искәндәрне дә шул факультетка эшкә чакырганнан гына түгел, университет һәр тарафка татар кадрларын әзерләячәк. Үзбәк теле кафедрасы да оешып, безнең балалар үзбәк халкы белән якынаячак. Казакъ кафедрасы да ачылыр дип өметләнәм, Көнчыгышның ике зур халкы белән якынаю, «тел-лөгать» алмашу һәр барчабыз өчен файдалы һәм нәтиҗәле булыр дип ышанам. Югыйсә, йоклап ятабыз бит, нидер көтеп, суйлакланып, университетта җанланыш бара икән, әдәбиятта моның мисалларын китерү авыр... Вакыйф Нуруллин моңа дәлил дә алып килгән! Синең китапка, сиңа килгән хатларга фикер өстәп язган «Җан авазы» мәкаләсе язучыларга бер тамчы да ошамаган икән! Алай гынамы сиңа, алар

мине эт итеп сүккәннәр! Идарә утырышында булган бу хәл, кемнәр чыгыш ясагандыр, кызыксынмадым, мәгәр Туфан кыздыргандыр дип уйлыйм (аның миңа кадала торган чагы), җыелганнар да бер авыздан: «Аяз Аяз булып кала инде, теләсә ни сөйли, «Тайгак юл»-ны нигә мактамыйсыз дип тәнкыйтьчеләрне кырып үткән, ә үзе әсәрне мактамаган!» дип, «Җан авазы» мәкаләсенә ябырылганнар. Татарстанда миңа үпкәләмәгән тәнкыйтьче калмаган, имеш.

Я Алла, дип өзгәләнде күңелем боегып, тәнкыйтьчеләрнең мактавын сорадым мыни мин?! Халык арасында бүгенге көндә иң зур резонанс алган әсәр «Тайгак кичү» булды. Ул әсәрне утызынчы ел корбаннарыннан бердәнбер исән калган намуслы зат иҗат итте. Сез шушы әсәр аша бүгенге үзгәрешләргә, үткәндәге афәткә һәм фаҗигале хәлләргә мөнәсәбәтегезне белдерә аласыз ич, дип кенә яздым ләбаса! Берәүнең дә бер ел дәвамында әсәргә мөнәсәбәтен матбугатта белдермәве мине гаҗәпләндергән иде. Инде хәзер, мәкаләм аларга рәнҗеш һәм нәфрәт уяткач, минем элекке шикләрем расланды... Авыр булса да икърар итәргә туры килә, синең әсәрең аларга аңлашу юлы ачасы урынга, аларга комачаулык кына китергән икән! Юк чагында акыл сатып йөрү җиңел иде, «менә ни бит, татар әдипләре бу темага керә алмадылар, бездә «Арбат балалары», «Зубр», «Ак киемнәр» кебек әсәрләр языламы соң? «Фәлән-төгән», дип, иңбашын сикертеп, күзне күккә күтәреп акыллы булып йөрү аларга ифрат рәхәт булган икән. Әсәр язылгач – фикереңне халыкка чыгарырга, әсәр күтәргән проблема аша үзеңнең кемлегеңне белдерергә, пәрәнҗәне салырга, маска-битлекне ыргытырга туры килә! Юк дип әйтә алмыйлар, әсәр бар, һәм мин «Тайгак кичү»нең ил халкы алдындагы популярлыгын син алган асыл хатлар мисалында җиңел раслый алдым. Хәзер әдәбият әһелләре үз сүзләрен әйтергә тиеш иде: кем яклы сез, хөрмәтле акыл ияләре? Ибраһим Салаховның хатирәләренә ничек карыйсыз?..

Дәшмәделәр. Мин аларның исемнәрен атап газетада фаш иткәч, әлбәттә, бу аларга бер дә ошамаган. Тәнкыйтьчеләребезне күз алдымнан тезеп үткәрәм: шуларның кайсына кирәк иде Сталинның фашистик битлеген салып ташлау?! Кайсысына кирәк иде торгынлыкның серләрен халыкка ачып бирү? Менә үзгәрешләр чоры башлануга дүрт ел үтеп бара, безнең язучыларның кемлеген әле берәү дә әйтә алмый. Ялгышып та җыелышларда ачык сүз әйткәннәре юк аларның. Илгә, көнгә, үзгәрешләргә мөнәсәбәтләрен

әйткәннәре юк. Әдәби үткәннәребезне шул яссылыкка куеп анализ ясаганнары юк, чөнки бу эш берсенең дә кулыннан килми әлегә, чөнки бүгенге тәнкыйтебез вәкилләре, асылда, каһәр суккан Брежнев-Черненко чорында аякланган, ныгыган һәм шул чорның агулы һавасы белән авызланган шәхесләр ләбаса! Үзгәреш һәм гласность чорының килүенә синнән, миннән кала бер Әмирхан Еники шатлангандыр! Ләкин ул да сак кеше, кылычы үткен, туры, ләкин ул кылычын кынысында тота. Андый-мондый хәлләрдә кылыч сабына тотына, кылычын суырып чыгара башлый, кылычның үткер йөзе ялтырап ала, куркытырга шул да җитә дип исәпли безнең пәһлеван һәм коралны кире кынысына, ышыкка урнаштыра. Бер нәрсә бар – Еники кулында чын кылыч, чын корал! Ул, заманабызның туклары кебек, бизәкле кынысына агач кылыч, муляж тыгып йөрмәде!..

Тагын кем көр тавыш белән торгынлык елларына ясин укый алды? Кем? Моңарчы авыз ачарга җай тапмаган вәкилләребез синең әсәрне укып, аның халык арасындагы ролен билгеләргә һәм шул уңайдан үз йөзләрен дә ачарга тиешләр иде бит! Мин әнә шул битарафлыкка, аларның һаман иреннәрне ябыштырган йозакны алып ыргытмауларына ачынып язган идем бит ул мәкаләне! Язучылар, сез дәшмисез, ә халык богауларын салды, чишелеп китте, аның авызында зур сүзе бар, колак салыгыз дип, сиңа килгән хатларның асылларын мәкаләмә теркәгән идем! Куркыныч булып китте. Идарә сандугачларының бертавыштан ничек сайрауларын күз алдыма китердем! Сандугачлар карга булып кычкырырга тотынганда җан өши. Яз бит, яз! Яз килде. Тыңлап торам, агачларга сарылган каргалар да тавышларын үзгәртеп, моңлырак кычкырып үзләренә пар сайлыйлар! Каргаларның тавышы да үзгәргәндә, безнекеләр үз сайрауларын онытып карга булып каркылдыйлар! Ник арадан берсе заманга, заман күңеленә үтеп керергә тырышып карасын! Уйларым съездга барып ялганды… Анда да нәкъ шушы сүзләр булачак бит: «нигә эшчеләр темасы соңгы елларда татар әдәбиятында таррак урын алды?», «ник нефтьчеләр хакында әз язабыз», һәм башка, шуның ише сафсаталар күп булыр. Кайчан чын юлга төшеп, гадел, хак сүзләрне авыз тутырып сөйләшә башларбыз без?! Ярый, безнең чор вәкилләренең йөрәге мүкләнгән дә, ди. Ярый, минем чордашларның күкрәк уты сүрелгән дә, ди. Без, тырышып тел яшерә-яшерә, үзебездән соң килүче яшьрәк буын вәкилләренең рухын таптап, иреген үтереп бетердек мени?! Идарәдә бездән яшьләр дә бар лаба-

са! Алар да минем мәкаләмнең чыннан да «җан авазы» булуын чамаламады мыни?.. Бездән соң да сукыр, саңгырау һәм телсез буын җирдә калырмы?.. Ни аяныч! Монда Мәскәүдә, бүтән өлкәләрдә шундый җанланыш үрнәкләрен мисалга китереп сөйлиләр ки, бер мәлгә үзеңнең татар икәнеңне онытып, бүтәннәргә ияреп алга ыргыласы килә. Ияреп китеп булмый, күңел сынган... Тирә-ягыма карыйм да, «әллә бу съезд дигәннәренә бөтенләй катнашмаскамы? Кан бозудан бүтәнгә ирешеп булмас барыбер!» дигән хыянәтчел, икеле-микеле уйлар килә.

Кичә Мәскәүдә язучыларның җыелышы үтте. Тбилисидагы хәлләргә үзе шаһит булган «Лит. Газета» хәбәрчесе Юрий Рост Грузиядәге аянычлы хәлләрне минуты-секунды белән вакыйгаларның чынын сөйләп биргән. Сапер көрәкләре белән унбиш яшьлек кызларны тураклаган икән безнең совет армиясе комсомоллары! Унбиш яшьлек унбиш кыз, бер яшь ханым һәм бер карчык һәлак булган. Грузин халкын шул юл белән куркытырга теләгәннәрме? Ә нәтиҗә? Нәтиҗәләр күңелсез, иң күңелсезе шул: халыкны кырырга боерык биргән кеше табылмаячак һәм җәзасыз калачак... Хәлләр монда, Ибраһим ага, каннар катарлык... Егерме бишендә Пленум буласы икән, халык дулкынланып шуны көтә. Яхшылыкка булсын, яхшылыкка!..

Менә шундый хәлләр. Әлегә хушлашыйк, үзеңә, гаиләңә күп сәлам юллыйм, сау-сәламәт яшә, борчылма. Сүзләр йөрер дә үләр, ә яхшы әсәр калыр. Безнең иман шул булсын!

*Тирән ихтирам белән, яратып Аяз*
*Переделкино.*
*20 апрель 1989 ел*

Хәерле көн, Ибраһим ага!

24 нче мартта язган хатыңны алдым, ихлас рәхмәт! «Мин һәрвакыт уйлыйм, мөгаен, Хак Тәгалә үзе сине минем белән очраштыргандыр. Изге эшләр өчен...» дигәнсең. Зур сүз әйткәнсең, олы сүз. Синең кебек якты шәхес авызыннан мондый зур бәяне ишетү, үзең әйткәндәй, мөкафәт. Янәшә яшәргә, уй-фикер алмашып гомер итәргә язсын. Яктылыгыңны саклап озак яшә, бирешмә!..

Нәкыя белән Минскидагы дусларда дүрт көн кунак булдык. Шәһәрне, шәһәр тирәләрен, зиратларын, Хатыньны карадык,

тәэсирләр бик зур булды, кая карама гыйбрәтләр бар, халыкларның күңеле җылына, каршылыклар, черек киртәләр һәр якта очрап торса да, Яңарыш, киләчәккә омтылыш сизелә. Белорус театрында спектакльне генә түгел, белорус тамашачысын да карап сөенештек. Йомшак теле, үткен фикерле әсәрләре, сак һәм сизгер тамашачысы бар халыкның. Язучылары «беттек-беттек» дисәләр дә, баштарак мин аларга кушылып борчылсам да, Минскида булганда күңелем күтәрелде диярлек. Халык яшәргә тиеш! Аннан Мәскәүгә кайттык, гостиницада бер кич кунып, җанга якын Переделкинога килеп төштек. Монда һава үзебезнеке, сукмак-юллар күңелдәгедәй, агач-куаклар таныш, кешеләр шул ук, чал башлар, елтыр башлар, гамьле башлар. Дүрт-биш көнгә эш өзелеп торгач, Нәкыя абыстай Мәскәү яны шәһәрләренең кайбер бәрәкәтле урыннары белән танышып, хуҗалык мәсьәләләрен хәл итте, ул бит укытучы гына түгел, безнең ишле гаиләнең «эзләп табу министры»да...

Хатыңнан күренгәнчә, син дә эшсез утырмыйсың, молодец! Зиһен ачык чакта уйлаганнарны язып калдырырга кирәк. Басылганы басыла торыр, әлегә дөнья күрмәгән нәрсәләр дә, тора-бара үз буразналарын ярырлар. Өмет белән яшәргә кирәк. өмет белән! Кайткан шәпкә, кар бетеп килә икән, дип сөенгән идем, бүген һава үзгәрде. Иртәдән бирле тоташ кар агыла, күктән юеш кар бөртекләре ак томан ясап ишелә. Каеннар янәшәсендәге наратлар да агарды, каршымдагы юкәдә оялаган саесканнарның коерыгы гына кара килеш калды: дөнья ап-ак! Әбәдкә кадәр кар ишелүен яратып, төрле ямьле уйлар уйлап, күзәтеп яткан идем, хәзер ялыктырды. Кайчан туктар инде бу ташкын, дөньяны туфан басачак дип пошынып уйлыйм, һавага чыгарлык түгел...

*Переделкино*
*2 апрель, 1989 ел*

Хөрмәтле Ибраһим ага!

«Тора-тора торҗыйгун» дигәндәй, минем башка бер уй төште бит, әй! Әлмәт театрында баш режиссер булып байтак еллар Гали Хөсәенов дигән иптәш эшләде. Татар дөньясын ярата торган, сәнгатькә, театрга фанатикларча бирелгән сәеррәк бер кеше инде ул. Бала-чагалыктан чыгалмаган сыйфаты да бар, үпкәчел дә ул, җылак та. Әмма театр аның тормышы, ул театрдан башка яши дә ал-

мый. Юк кына нәрсәләр өчен үпкәләп, ул моннан байтак еллар элек Ташкент каласына китеп барган иде, хәзер, әнә, түзмәгән, талагы ташып кире кайткан. Ул югында театр бик бетәшкән, таралган иде, юньлерәк актерлар бетте, юньсезләр юньле булып кыланып, эшне тәмам актык чиккә китереп җиткерделәр. Хәзер Әлмәт театрына зур бина бирделәр, бу актерларның иң зур хыялы иде. Димәк, ташлап киткән актерларның да әйләнеп кайту ихтималы бар, чөнки театр ярым шәһәр театры булып эшләячәк. Гали Кәримовичның яше өлкәнәеп китсә дә, әле дәрте-дәрманы бардыр дип уйлыйм... Менә шул иптәшкә синең «Колыма хикәяләре»н биреп карарга кирәк тә! Син, озак тотмыйча, Гали Хөсәеновка җылы гына бер хат яз, үз ягымнан мин дә хәбәр ишеттерермен, әгәр режиссерның ризалыгы алынса, романнан сәхнә әсәре оештыру читен мәсьәлә түгел, үзем тотынырмынмы, берәр яшь иптәш табарбызмы, анысы икенчел проблема. Син ни дисең? Әгәр мәслихәт күрәсең икән, Әлмәт театры белән багланышка кер.

Мин Күктүбәдә. Ямьле җәй азагы, көннәр җылы, таулар сихри, базарда җимеш-яшелчә арзан, ярылганчы аша, Нәкыя белән килгән идек, атна элек әбиебез – Нәкыянең әнкәсе 87 яшендә дөнья куеп, ул әнкәсен җирләргә кайтып китте... Иртәгә килә, аллаһы боерса. Төртенмеш повестьны тәмамлый алмыйча газап чигәм. 24 ендә өйдә булам, аңынчы җавабың килеп өлгерсә күңелле булыр иде. Гаиләңә сәлам!

*Тирән ихтирам белән, яратып Аяз*
*Күктүбә.*
*10 сентябрь 1989 ел*

Кадерлебез Ибраһим ага, саумы! Оялып йөрим – хатың килде, җавапны һаман кичектерәм, Шаһинур белән Гәрәй Рәхимнең эзенә төшә алмыйча интектем. Бүген, ниһаять, Гәрәй Рәхим белән сөйләштек. Сәламнәр тапшыра, исемеңне ишетүгә авызы ерылды, «шигырьләрен алдык, берсүзсез басабыз, атнага ике генә чыкканга күрә, моңарчы урын тапмадык», диде.

Үзеңнең урыныңны таба алмагач, дөнья буталышына гел шаккатып, аптырап, баш иңкеп карап торасың икән, агай. Сөенәм, син үзеңә ныклы урын таптың, эшең бәрәкәтле, сукырлар өскә чыккан заманда ачык күз белән карау бөтен бәндәләргә дә насыйп түгел.

Мин рухи буталышта: бер яктан ил, халык, милләт өчен әллә ниләр эшлисе килә, «татар!» дигән сүз чыгуга җанның бөтен кыллары чыңлый, зарлана, сыкрый... икенче караганда, татар гамәлләре белән күзгә-күз очрашканда, канатлар сынып, сәлперәеп төшә. [...]

Бәлки, милли сатлыкҗаннарга отпор бирерлек буын алда әле туар... Ярый, син язып салгансың, ди. Бәлки ярсуларың басылып та чыгар. Мин андый күтәрелеш-ярсуларны нәтиҗәсез дә димим. Кемдер укып аһ итәр, милионнан берәү хак юлга төшәр... Ләкин система үзгәрмичә, татар язмышы өмет дигән сукмак күрмичә, бернинди аһ-зарлар да яшәвәбезгә җиңеллек китермәс. Мин нәкъ менә мондый хәлдә нишләргә кирәклеген аңлый алмый интегәм. Әсәрләрем аша халыкка дәшеп карыйм, чукрак ул татар, сукыр, телсез. «Җомга көн, кич белән...» повесты буенча спектакль телевидение аша күрсәтелгәч, ике йөздән артык хат килде. Хат авторлары карчык-корчык, карт-коры, җөмлә дә төзи белмәгән төркем булып чыкты. Тоташ наданлык! Сирәк хатларда гынаерактагы яшен кебек фикер чаткысы ялтырап киткәләде... Мин тораташтай катып калдым. Чөнки халыкның аңга ия катламы күптән урыслашкан. Без урыслашкан татарның ничәнче буыны белән эш итәбез икән? Һәм бу буын, моннан элегрәк урыслашкан буыннардан кай ягы белән аерыла икәнен безнең уйлаганыбыз юк. Урыслашкан дип, авыз тутырып әйтүе дә кыен. Чөнки урыс милләте үзе дә эчке җимерелү кичерә. Империяләр милли хәрабәләр өстендә генә яши ала, без дә әнә шул милли җимерелүләр чорына кердек. «Боланның аягы йөгерек булсын өчен бүре тырышкан» диләр ич... Ләкин юл кай якта? Ничек эзләп табарга аны? Якты башлар хәзер шул уйлар белән газаплана.

Син, хөрмәтле Ибраһим ага, тай кадәрле газапларны иңең, башың аша үткәрсәң дә, бәхетле кеше. Чөнки син татар дигән халыкның барлыгын күреп калган азамат. Әле хәзер дә син чордашларың белән янәшә картаясың. Ә мин бер чакта да татар халкының барлыгын сизә алмадым, безнең чор – татарның инкыйраз дәвере, бетүе иде. Гади генә мисал: безнең заман язучыларыннан кайсыларының баласы татарча белә? Ярый, ипилек-тозлык пупаласыннар да ди. Берәвесенең баласы татарча укыймы, үз этисенең яки әнкәсенең әсәрләрен татарча укый аламы? [...]

Хәтер көнендә, бер мәйданнан икенчесенә татар акканда, артымнан бастырып куып җиткән яшьрәк язучылар: «Аяз абый ни

уйлый икән хәзер?» дип, ярым шаяртып сорап куйдылар. «Аязның ни уйлавын белү кыен түгел, янәшәбездәге унбиш мең татар ни уйлый? Шуны беләсе иде!» дидем сызланып. Кызганыч, халык аңын белә торган мөмкинлек бездә юк. Һәм якын араларда булмас та кебек...

*Аяз*

*Казан. 13 декабрь 1990 ел*

Хөрмәтле Ибраһим ага!

Хат язышмаганга байтак – ни хәлләрең бар? Саулык, иминлекме? Нәкыя хәбәр итте: Нури ага Арсланов вафат икән. Урыны оҗмахта булсын, яхшы кеше иде, әдәбиятыбызга, бигрәк тә соңгы елларда, ихлас хезмәт итте, ленинизм сөременнән үз вакытында арына алды, хак юлга төшәргә үзендә көч тапты. Өлкәннәрнең, электәге кызыл авызларның күпчелеге авызын йомды... Нури ага исә, яшьләргә игътибарлы булды, булышты. Ачык йөзле иде Нури ага, язгы гөрләвектәй күңелле көлеп җибәрә иде!

1 нче майда икенче срогымны тәмамлап өйгә кайтырга җыенам. Ике срок үткәрсәм дә әллә ни эш кырып булмады, алай да вактөяк мәшәкать, килгән шәптә Ямиль Мостафин белән очраштык, беренче сүзем итеп, синең китапның язмышы белән кызыксындым. «92 нче ел планында ныклы рәвештә тора, чыгачак!» диде. Бәрәкалла! Шулай булсын кана. Хәзер нәшриятлар үз планнарын ашыгып-ашыгып алыштыралар, хәзерге заман исән авторларның җыелган наборларын таратып ташлыйлар. Безгә читен заманалар килде! Әле шуңа сөенәм: Марсель Зариповның тәрҗемәсе яхшы, диде Ямиль… үзе эшчән, ихлас, тырыш һәм галим кеше ул Марсель. Синең урысча чыккан яңа китабың татар әдәбиятының йөз аклыгы булачак. Шуны да онытмыйк: туган теле булырга тиешле татар телен онытырга мәҗбүр ителгән миллионнар арасында, юк-юк та, милләткә тартылу уянып алгалыйдыр әле. Шундый минутларда андый бәндәләр ничарадан-бичара урысча чыккан татар китапларына тартылачак. Бу яктан караганда, безнең урысча басмаларның зарурияте бермә-бер арта, Казанда татар язучыларының иң мөһим әсәрләрен, беренче чиратта классиканы, зур тиражлар белән, яхшы кәгазьдә бастырып таратуны алдагы көннәрнең планында күздә тотарга кирәк. Урыс китаплары аша – татарга,

татар тарихына, милли горурлыкка! Бүтәнчә телсез татарларга, буынсыз буынга ничек тәэсир итә алабыз? Телне оныткан татарлар арасына әдәбиятыбызның үтеп керү нәтиҗәләрен фәнни нигезгә салып өйрәнергә кирәк. Урыслашкан татарларны ашыгып сызып ташларга ярамый. Бу җәһәттән синең китабың искиткеч зур урын алачак!..

Гаиләңә күптин-күп сәлам. Сиңа иминлек, көч вә куәт теләп калам.

*Аяз*

*Переделкино. Иртә.*
*23 апрель, 1991*

Көпә-көндез.

Кадерле Ибраһим ага!

5 майда язган хатың тугызында килеп җитте. Рәхмәт! Хат бик вакытлы килеп иреште, эш шунда ки, «Казан утлары»ннан синең хакта өч-дүрт сүз әйтүемне үтенгәннәр иде. Тормышың, газаплы көн күрмешең милләткә нык таныш, китабың, журналлар, газеталар аша халык сине, күңеле мөнбәренә менгереп, төрле яктан танышкан иде инде. Мин синең рухи ныклыгың, какшамас иманыңның бүген дә күпләргә мисал, өлге булырлыгын әйтергә җыена идем. Хатың – тел ачкычы булды, Ходама шөкер. Синең хатларың, бүгенге яшәешең, баш бирмәвең мине һәрдаим сокландыра, шушы хәлне халык белән, укучы белән уртак итә алсам, миңа да зур куаныч булыр иде.Пәйгамбәр тормышына багышланган китаплар күземә күренсә, әлбәттә, юллап салырмын. Үз чиратымда мин Олжас Сулейманов китабы хакында синнән үтенгән идем, Күкчәтауда күзеңә чалынмадымы?

Карчыгы Нури ага Арсланны урыс зыярәтенә күмәргә нык талпынган икән, Гариф Ахунов йөреп кенә аяп алган. Татар зираты татарныкы инде ул, юк дигәндә дә бер урап кайтасың, танышларның исемен яд итеп баш орасың... Безгә үлгәч тә таралырга ярамый!

Гаяз Исхакыйның «Зиндан» исемле күләмле җыентыгы дөнья күрде, бәясен бераз кыйбатрак куйганнар, 8 сум, китап кибетләренә кереп белешеп йөрим, алай ук, без көткәнчә, ябырылып алмыйлар икән. Акча санаулыга калды шул, нихәл итмәк кирәк!

Ширияздан ага Сарымсаковның 80 еллыгын билгелибез, 18 ендә театрда тантанасы. Барырга җыенып торабыз. Союзда

искитәрлек яңалыклар юк, шаккатырлык романнар язылмый, картлар туңкайган, яшьрәкләр муртайган. Татарстан Югары советы «суверенлык!» дип нык кына торып маташа, алда тагын ниләр булыр. Кискенлекне алга чыгарып, урыс белән якага-яка килүдән Ходай сакласын! Бу җәһәттә мин Әмирхан аганың «Идел» журналында басылган мәкаләсе белән тулысынча килешәм…

Ике ай читтә торып кайткач Татарстандагы үзгәрешләр нык ук күзгә чалына. Үзгәрешләр байтак! Татар ирек даулый, кыю рәвештә даулый һәм шушы кыю хәрәкәткә яңадан-яңа милләттәшләрне тарта. Газета-журналларның тавышы ныгый, эндәшләр конкрет төсмер ала. Азау теше яралган егетләр кыюлана, менә бүген «Шәһри Казан» газетасында элеккеге обком секретары Г.И. Усмановның йөзен ертып халыкка күрсәттеләр, кырмыска түмгәгенә салгандай боргалангандыр Усманов! Аны үзгәртеп, телен чүкеп, ми тартмасына акыл тутырып булмас, мәгәр исәннәргә, хәзерге җитәкчеләргә уйланырга урын бар! Милләт белән сак булырга кирәк җитәкчеләргә, сүзне бөердән чыгарып сөйләшергә һич ярамый! Соңгы вакытларда Әмирхан ага егетләнеп китте, татарлар турында игелекле хезмәт язды, башкорт экстремистларына дәлилле отпорын бирде [...]

Үзеңдә ни хәлләр? Ни яңалыклар? Юбилейны ничек үткәрергә җыенасың? Ходай шул көннәрдә дә сиңа саулык, җан тынычлыгы бирсен. Карчыгыңа һәм үзеңә күптин-күп сәлам.

*Сагынып, Аяз.*

*16 май 1991 ел, Казан*

*Көндез*

Хөрмәтле Ибраһим ага!

Сиңа күптән хат язарга кирәк иде, бик күптән! Озак дәвам иткән авыр тынлыгым өчен кичер! Нишлим соң, яман хунтаның күтәрелешеннән соң халкым белән, аерым-аерым шәхесләр белән, ахыр чиктә, дуслар, белешләр белән тагын бер тапкыр очраштым да һушсыз, өнсез, тынсыз тәгәрәп егылдым. Менә соңгы бишалты елда мине газаплаган сорауларга кырыс чынбарлык ап-ачык, төп-төгәл җавап бирде. Без, татарлар, необольшевизмны сагынып яшәүче ярты акыллы коллар икәнбез!..

Бүген китап нәшрияты директоры янында булдым. Кара кайгыга батып утыра. «Акчасыз, ярдәмсез татар китабы яши алмый», дип аптырашта калган. «Сайланмалар»ымны чыгарырга йөри идем,

планда «50 мең тираж» каралган иде, хәзер тиражны унбиш меңгә калдырдылар. «Хәлебез юк, бөлдек, бу бәла-каза ыкрыгының азагы күренми» дип, әйткән бер сүземне ега торалар. Нишлим, килешми хәлем юк. Димәк, татар китабының язмышы кыл эчендә! Китабың укучыга барып җитә алмый икән, бу инде инкыйразның иң ачысы! Татар – китапка мәхәббәте белән танылган милләт иде. Инде бөтен милли сыйфатларыбызны югалтып, әрәм-шәрәм итеп бетергәндә китап белән арадашлыкны өзсәк, милли сыйфатларыбызны тарихның кайсы тирән катламнарыннан эзләп табарбыз да, ничек итеп халыкның суык җанын җылытырбыз?! Шулай сүнә икән милләт, шулай сыеклана икән... «Милләт иреге, милләт ирегe» дип тел астында сүз тәгәрәтүдән ни файда? Бу дөньяда милли сәрмәясез, экономикасыз милләт яши ала диме?!..

Беләм, аңлыйм. Синең сөенечле көннәрең! Төрмәләрнең тимер ишекләрен, төньякның коточкыч туң катламнарын, язмышның адым саен корып куйган капкыннарын үтеп, җиңеп, күңел югарылыгыңны көнгә алып чыккан, 80 яшьне тутырган бәхетле дәверең! Бүген сиңа җиңел канатлы хәбәрләр генә илтәсе килә, «Яши татар, Яшибез!» дип сөенче аласы иде дә... Күрәсең, дөнья һаман безне кыса, изә, милләтнең офыгын тарайта, үзебез дә һич ипкә килә алмыйбыз, иртәгеге көнебезне юрап алга өндәрлек асыл затларыбыз юк, милли лидерлар мәйданга чыкмый, шундый чакта ни эшләргә? Ни кылырга? Беркем белми. Бүгенге «Шәһри Казан»да Әбрар Кәримуллинның «Йомшак җәеп, катыга утырту» исемле мәкаләсе басылган. Әбрар, гадәтенчә, нигезле, төпле итеп бүгенге хәлебезне аңлата, гади кеше күзенә күренеп бетмәгән хәйлә киртәләрен ачып сала. Әлегә шушы хакыйкатьне булса да кабул итәрлек халкыбыз бармы? Менә хикмәт нәрсәдә...

Шулай менә, күктән пилмән яуганны көтеп, Кабан күле суының спиртка әйләнүен сагалап ятабыз..

Синдә ни хәлләр? Туган көнең белән котлап телеграмма сукмадым, юбилей тантанасы көненә хәбәр юллармын, иншалла. Газет-журналларга язылу бара, дер калтырап шуның нәтиҗәләрен көтәм. Ул җәһәттән дә егылырмы милләт?!

Сау яшә, бирешмә. Алдагы елларда нинди китаплар чыгарырга ниятлисең? Хәзер бик иртә аяк киенә башларга кирәк...

Күп сәламнәр, тирән ихтирам белән, Аяз.

*(Датасы юк)*

Мөхтәрәм Ибраһим ага!

Хатың килеп иреште, зур рәхмәт! Үзем хат язулардан туктабрак тордым, күңелемнең әйле-шәйле чаклары күп була, кулдан эш төшеп китә. Бар аның сәбәпләре, бар! Казан этләре тешләсә нык тешли, казанлы чаяннар аяп тормый, нык чага. «Казан утлары» журналы тирәсендә төйнәлеп алган пиратларга юеш борын көчекләр дә иярә. Егарга тырышалар, көнчелекләре түздерми тегеләрне...

Сиңа бер зур үтенеч! Хәтереңдәме, кунакханә алдындагы мәйдан уртасына әлегәчә хуҗа булып утырган тазбаш Ленин һәйкәле янына басып, мәйдан тирәли кулыңны йөртеп, болай дигән идең: «Бу урын Күкчәтау татарларының үзәге иде... менә бу урында фәлән байның йорты иде, арырак фәлән бай каралты-курасы иде... бирге башта атаклы фәлән бай яшәп ята иде...». Хәзер, уең белән шул мәйдан уртасына кайт та, мәйданда сөйләгәннәреңне кыскача гына язып җибәр әле. Җитешеп мин дә нәни генә бер хатирә язарга җыенып йөрим, «татарныкы төштән соң!», хәзер син искә алган истәлектән башка эшем алга бармаслыгын сизәм. Гомумән, бер-ике сүз белән генә Күкчәтауда татарларның эзе-буразнасы хакында яңачарак сүз кыстырып җибәр әле! Язып чыккан хәлдә мин сүзләреңне үземнеке итеп түгел, синең кебек абруйлы, затлы шәхестән отып алдым дип беркетеп китәрмен. Хезмәтең югалмас.

Син Казан ыгы-зыгыларыннан читтә торасың, җаның тыныч. Тәңре синең көч-куәтеңне алмасын да, дәрт-дәрман өстәсен.

Бер эш кырмыйча, суйлакланып ятып кыш узды, яз үтеп бара. «Кыйбат! Кесә сай!» дип, Переделкинога бармаган идем, хәзер зарыгам, анда ичмасам, дөбердәтеп эшләп кайта идем. Ничек булыр, дөнья кайсы як кабыргасы белән безгә борылыр. Ходабыз шәфкать ирештерсә, Аллаһы боерса, көзен бармый да ярамас. Эшне чак кына ашыктырасы иде! Хуш булып тор. Гаиләңә күптин-күп сәлам. Тукай көннәре якынлаша, казан астына учак кабызган гына юк.

*Сагынып, Аяз!*
*Казан.*
*20 апрель 1992 ел*

Здравствуйте, Ибрагим Низамович!

Пишет Вам студентка 5 курса филологического факультета Казанского университета. Дело в том, что тема моей дипломной

работы – «лагерная проза». Исследую я ее на материале Ваших «Колымских рассказов».

В ходе изучения темы я обращалась ко многим произведениям «лагерной прозы». В результате выяснилось, что она далеко не однозначна, а, напротив, очень разнообразна и многопланова. Меня заинтересовала, прежде всего, проблема свободы и ее художественное воплощение в структуре текста. Знакомясь с различными книгами, в основу которых положена «лагерная» тематика, я столкнулась с разными, порой противоречивыми точками зрения на эту проблему.

В своем произведении, как мне показалось, Вы делаете акцент на факте несломленности человека, который в самых ужасных обстоятельствах способен не только выжить, но и остаться человеком. Я думаю, это не что иное, как внутренняя свобода, свобода на уровне духа. А поскольку в своих рассуждениях и выводах я основываюсь исключительно на собственных домыслах, мне хотелось бы знать, действительно ли так Вы решаете непростую проблему свободы?

Кроме того меня интересует вопрос: что для Вас было важнее – донести до читателя достоверный материал, либо художественно воплотить его? Ваш ответ поможет мне решить проблему соотношения вымысла и реальности в «лагерной» прозе. А это, в свою очередь, позволит выяснить то, как же все-таки необходимо относится к подобным произведениям – только лишь как к «литературе факта», как считают некоторые исследователи, или это полноценная литературная форма с определенной жанровой спецификой?

Прошу извинить меня за беспокойство, но я была бы очень признательна Вам, если бы Вы ответили мне.

Заранее Вам благодарна.

Буду с нетерпением ждать Вашего письма. До свидания.

*(Наиля Гарифуллина)*[1]

Здравствуйте, уважаемый Ибрагим Низамович!

Большое спасибо за Ваш ответ. Мне было очень приятно, что Вы, известный писатель, откликнулись на письмо простой студентки. Я Вам очень благодарна. Это ценный вклад в мою научную ра-

---

[1] Наилә Гарифуллина – И. Салахов иҗаты белән кызыксынучы.

боту, тем более что возможность личного контакта с писателем – большая редкость. Поэтому, пользуясь возможностью, хочу ознакомить Вас с основными тезисами своего исследования.

На основании Вашего письма, а также некоторых других источников, я пришла к выводу, что «лагерная» проза и, в частности, Ваша книга – это прежде всего исторический документ, который рассказывает нашему поколению о недавнем прошлом. Но в каждом произведении «лагерной» прозы неизменно присутствует и авторская биография, то есть это не просто беспристрастное повествование, а рассказ об эпохе через отдельную человеческую судьбу.

Кроме того, я считаю, что Ваша книга не только документально отражает пережитое, но и сожержит глубокие философские размышления о природе общества того времени, и что самое главное – заставляет задуматься о нравственной силе человека, оказавшегося в экстремальных обстоятельствах лагеря.

Если учитывать Вашу главную установку – «только правда и факты», то можно сказать, что Ваше сочинение по жанру – художественная документальная автобиография, цель которой объяснить не только время, но и человека в этом времени.

Таковы общие выводы, к которым я пришла в результате анализа Вашей книги. В дальнейшем я хочу продолжить работу над темой. Поэтому, если у Вас есть какие-то замечания или дополнения, мне было бы очень интересно ознакомиться с ними.

*С уважением Наиля (Гарифуллина)*

*24.02.1998*

Ибраһим дускай!

Сезгә барыгызга да миннән, туганнардан сәлам. Синең 3.03. тә язган хатыңны алдым, рәхмәт. Минем туганнарга, күршеләргә синең сәлам һәм яхшы теләкләреңне тапшырдым. Рәхмәт әйтеп үзеңә дә изге теләкләр теләделәр.

Мин исән-сау эшләп йөрим. Бу март ае минем өчен бик мәшәкатьле булды. Көн дә диярлек бер мероприятие. Барысына да әзерлек кирәк. Инде 23–29.03 сендә булачак «Театр атналыгы» уздырып, аннан соң 31.03–2.04 ләрендә өлкә буенча үткәрелә торган культура работникларының семинарын үткәреп җибәрсәк, смотрлар үтеп китсә, эш бераз җиңеләер.

Син Колыма турындагы язмаларыңны миңа җибәр. Мин аларны ашыкмыйча гына, җитешкән саен күчерермен. Аларны ашыктыручы юк бит.

Безнең Бардадан да сез йөргән җирләрдә йөрүчеләр булган. Алардан берәү исән йөреп кайткан иде. Тик кайткач озак тормады, үлде. Ул кеше безгә кода тиешле кеше иде. Исеме Габдерәхим (күбрәк Рәхим диләр), фамилиясе Хәлилов. Ул үзе Сараштa туып үскән кеше. Шуннан Барда мәктәбендә директор булып эшли иде – шул вакытта алганнар. Ул да Колымада эшләгән. Шунда эшләгән вакытларын гел сөйли торган булган. Ул исән вакытта кунакларда очраша торган идек. Ләкин ул үзенең йөргән җирләре турында сөйләгән вакытка туры килмәдек. Син ул язмаларны җибәргәч, безнең туганнар арасында ишетергә теләүчеләр булса, аларга укырга рөхсәт булырмы?

Аннан соң син миңа тагын Яхинның «Урман кызы» дигән кульъязмасын җибәрмәкче идең. Анысын онытма. Мин аннан күчереп алырмын да кире үзеңә җибәрермен (китап күчерү эшенә өйрәнеп җиттем бит инде). Шафикадан Казанга кайткач хаты юк. Мин дә бу арада аңа яза алмадым.

Бу арада хатлар бик озак йөри башладылар әле. Юллар бик начардырмы, элек 6–7 көн эчендә килеп җитә торган иде, хәзер хатлар 10–12 көн киләләр.

*Сәлам белән Гайшә*[1]

*21.03. 1980*

Ибраһим дускай!

Сезгә барыгызга да миннән, туганнардан күп сәлам.

Юлда әле тагын сиңа язган бер хат булуга да карамастан, бүген үзеңнән алгач та җавап хаты язырга утырам. Чөнки күптән түгел генә бер календарьда «хат язгач озак җавап язмый тору, беренчедән, тәртипсезлек булса, икенчедән хат язган кешене борчылырга мәҗбүр итү, кайгыга салу була» дип язылган сүзләр укыдым. Болай булса, хатлашу тәртибен бозарга ярамас, дип уйладым.

Синең истәлекләрне укыганнан соң язылган минем бер җөмлә сиңа бик ошап җитмәгән икән. Мин бит аны синең язганнарга

[1] Гайшә Гыйззәтуллина – И. Салаховның сабакташы, Пермь краеның Барда халык театрында эшли, язучының күп әсәрләрен гарәп графикасыннан кириллицага күчерүдә зур ярдәм итә.

шикләнеп караудан түгел, артык гаҗәпләнүемнән генә язган идем (гаҗәпләнерлек хәлләр бар шул анда. Бүген мин төшемдә синең миңа үпкәләгәнеңне күргән идем. Шушы хатны алырга булган икән). Бер дә шикләнмимен, барысына да ышанамын (үпкәләмә). Теге картинаның эчтәлеген укыдым, аңлашылды. Бик авыр хәлләр булган икән шул – бигрәк тә яшьләр өчен.

Бу арада Ленинның тууына 110 ел тулуга багышланган күп кенә мероприятиеләр булды. Бик зур итеп тантаналы кичә үткәрдек. Икенче көнне бөтен район пионерлары сборы булды. Безне дә чакырдылар. Шул көнне бик күп балалар пионерга керделәр. Аларга без галстуклар бәйләдек. Безне дә пионер ветеран итеп, безгә дә галстуклар бәйләделәр. Кичә тагын Ленин һәйкәле куелган мәйданда Ленин һәйкәленә чәчәкләр куйдык. Шунда ук районның беренче секретаре Ермолаев район ярышларында җиңеп чыгучы алдынгы хезмәткәрләргә мактау грамоталары тапшырды. Шулар арасында мин дә бар (культура работникларыннан өч кеше булдык). Җан-фәрманга тырышып эшләүчеләрне күрә беләләр, кадерлиләр, рәхмәт инде.

Хәзер тагын алдагы бәйрәмнәргә хәзерләнәбез. 9 май – җиңү көнен үткәреп җибәрсәк, миңа эш җиңеләя инде. Кайбер эшләрне караштырып, бакча утыртылса – эш бетә.

Синең Казанда башланган сәяхәтеңне ахырына кадәр укып чыгыйм инде, калган икенче кисәген җибәрерсең. Синең язган әсәрләр нинди авырлар булса да, җиңел укыла. Укыганда ялыктырмый, тизрәк укып чыгарга тырышасың. Миңа гына шулай микән дисәм, әле башкалар да шулай яратып сөйлиләр. Элек чыккан китапларны укучылар да бик яраталар, мактыйлар иде. Мәхмүд Хөсәенев Бардада булган вакытлары турында сөйләмәдеме соң? Ул Барда турында җыр язып калдырган иде, хәзер җырлап йөрибез.

Хәзергә бетерәм.

*Сәлам белән Гайшә (Гыйззәтуллина)*

*23.04.1980*

Ибраһим!

Барыгызга да миннән, туганнардан күп сәлам.

Синең терелә башлагач язган хатыңны алдым, рәхмәт. Кулъяулыгыңны кулдан төшерү өчен, тройной одеколон белән мамыкны

чылатып, борынның тышкы ягыннан бераз баскаласаң, шул җитә. Бер мәртәбә эшләгәндә бетмәсә, берничә көн кабатларга кирәк. Одеколон җылыта да, салкын тигәнне бетерә. Мин үзем шулай эшләүнең файдасын күрәм. Син трилогиянең өченче китабын карый башлагансың икән. Алдагы ике китапны да карарга кирәктер бит. Син инде бу юлы Расих язганнарның барысын да төгәл эшләргә тырыш. Анда, башыннан ахырына кадәр (кайсын арттырырга, кайсын алып ташларга, кушылган иде шикелле) карап чыгарга, дип әйтелгән иде түгелме? Артык ашыкмый гына бик нык игътибар белән эш итәргә тырыш инде.

Мин дә синең «Ат җене» хикәясен яза башладым. Сиңа моннан алда язган хатымда әйтеп язган идем, хатны салгач та яза башлыймын дип, һәм шулай эшләдем дә, яртысын яздым инде. Синең бу хикәяңдә дә шулкадәр матур итеп язылган җирләре бар, кулым язып бара, ә үземнең күз алдымнан бөтен булган вакыйгалар (телевизордан караган кебек) тезелеп үтеп баралар. Әйтерсең, шул хикәядәге хәлләрне бер почмактан карап, үзем күзәтеп тораммыни. Синең искиткеч матур итеп тасвирлаган далаларда, җәйләүләрдә йөргән атларны Өлфәт белән син генә күзәтмәдең, алар арасында мин дә булдым. Турсаеп бүләкләрне алмый торган Өлфәтне дә «күрдем».

Аннан соң хикәядә берничә аңламаган сүзләр булды: (атлар турында язганда) «...аяклар чак кына озынча, орчык кебек *акланган*» (бу сүз шулай язылган). «Гәүдә артык тулы түгел, *сыгылган,* җиңел». Болардан аз гына алдарак, шул ук биттә «көзге салкыннар белән бераз *куара* төшкән кылган белән өртелеп». Тагын шул ук биттә айгыр турында «бүре көтүен әллә каян сизә, ачулы *кычкыра*». «айгыр авыз-борыныннан күбекләр чәчеп, кычкырып...» – мин боларны кычкыру сүзләренә охшатам, ләкин шикләнәм.

Менә шушы asларына сызылган сүзләрне вакытың булса, ачыграк итеп язып җибәр әле. Үзегез яктагы сүзләр белән язасың да, мин, аңламагач, белмәгәч, ялгыш язып куярмын, дим. Мин аларның урыннарын буш калдырып киттем.

Тагын бер нәрсә турында язмый кала алмыйм: бер җирдә шундый җөмләләр бар: «мин гомердә тартмаганны, шкафтан папирос эзли башладым». Балалар өчен язылган хикәядә, бу җөмләнең кирәге булыр микән. Балаларда кайгылы, авыр вакытта папирос тарту җиңеллек китерә икән, зарары юктыр» дигән фикер тудырмас микән, дип куркам.

Син инде минем мондый киңәшләр белән язу эшенә кысылуыма ачуланма. Минем ул фикеремне әйтми каласым килми. Хикәяне озакка сузмый гына язып бетереп, аны салганда «Төн кызы» китабын да салырмын. Бәлки үземдәгесен җибәрермен, алай бик кирәк булгач...

Хәзергә җитеп торыр.

*Сәлам белән Гайшә (Гыйззәтуллина)*

*17.11.1980*

Ибраһим дускай!

Сезгә барыгызга да миннән, туганнардан күп сәлам. Хатыңны алдым, рәхмәт. Миннән еш хат килсә дә, син еш куркып китәсең икән әле. Мондый ашыгыч эш эшләгәндә синнән хат килгәнне көтеп торып булмый шул. Сорар сүзләр күп була. Әле бу хатың килмәсә дә, сиңа үзем хат язармын дип тора идем, чөнки тагын язар сүзләр булып китте. Мин кичә кич синең романыңны күчереп бетердем. Тик әле китапханәгә барып, съездлар турында караштырып, теге буш калдырган җиргә дөрес фактларны язып куярга кирәк булыр. Мин ничек булса да эзләп табарга тырышырмын. Ә партия съезды түгеллеген дә, советларның да 1921 нче елга кадәр булган съездлары турында сүз барганын да мин бик яхшы аңлыймын. Менә шул съездның (Сабир Шәрипов катнашкан съездның) кайсы елда булуы, нинди мәсьәләләр каралуы турында белергә кирәк безгә. Шул съезддан соң икмәк хәзерләүләр китә һәм шул икмәкләреннән аерыласы килмәгән байлар, казаклар баш күтәрәләр. Болар барысы да аңлашыла.

Ибраһим! Мине тагын бер мәсьәлә уйландыра әле. Мин бу хатка шуны да язмакчы булам, тик ачуланма гына.

Мин романны күчереп бетердем. Ләкин миңа аның финалы ошап бетмәде. Анда язылган берничә җөмләне китерәм:

«Пехота сәнәк, пика белән генә коралланган булса да, үзенең күплеге белән (арттан казакларның кысырыклап-куып килүләре аркасында, яртыдан күп кешеләрен югалтып булса да) кызылларны станицага таба кысырыкладылар.

Ул арада, уң һәм сул флангтан, дәһшәтле кызыл пикаларын алга сузып, ялангач кылычларын баш өсләренә күтәреп, сотнялар кызыллар өстенә ташландылар...»

Тагын бер җирдә болай языла – арада сүзләр бар, барын да язмыймын.

«...һәм атаман Красников, үзенең җирән биясендә бар көченә чабып, кылычын югары күтәреп, кызыллар тупланган аланга таба ыргылды. Аргы яктан, казаклар куып килгән крестьяннәрнең – пехотаның шау-шулары ишетелде.»

Шуннан соң Госманның атаман артыннан килеп аны атуы һәм атаманның аты өстенә авып төшүе языла һәм шуның белән тәмам була. Бусы ярый, күңелгә хуш килә. Ә менә кызыллар шулай төрле яктан чолганып җиңелеп калалар микән алар. Казакларга каршы көрәштә көчләре, отпор бирүләре күренми кала кебек. Атаман үлү белән генә кызылларның җиңүен халыкка аңлатып булыр микән. Укучылар арасында да минем кебек уйлаучылар булмас микән, дим.

Кызылларның алга барып казаклар атаманнарының армиясен кысрыклап куып (атаманнар тарафыннан көчләп кызылларга каршы сугышка алып киткән крестьяннарның да кызылларга кушылып, атаманнарга каршы сугыша башлаулары да булса), станицаларны азат итә башлаулары да күрсәтелсә, минемчә, яхшырак, тулырак булыр иде кебек. Син үзең дә уйлап кара әле.

*Сәлам белән Гайшә (Гыйззәтуллина)*

*24.01.1980*

Ибраһим дускай!

Сезгә барыгызга да миннән һәм туганнардан күп сәлам. Бик озак көттергән хатыңны һәм бәйрәм белән котлап язган шигыреңне алдым, рәхмәт. Шигырь бик матур чыккан, миңа бик ошады, катлы-катлы укыдым.

Минем ул хат бик озак барган икән шул. Почтаның теләсә ничек йөрүеннәндер инде. Кайвакыт 12 көн эчендә җавап хаты килеп җитә. Әле минем юлда тагын бер-ике хатым булырга тиеш. Үзең сораган «Рамай» җырларын язып җибәргән идем, алгансыздыр инде.

Син романның өченче китабын тулысы белән миңа җибәрәсең калган. Яисә мин Казанда вакытта рәтләп карап чыгарга иде. Ул вакытта бик ашыктык шул. Ашыгып эшләп, яңадан шул эш өстендә кабат утырганчы, берьюлы ашыкмый гына дөрес итеп эшләү яхшырак та соң, кайвакытта шундый эшкә акыл җитми кала шул. Мин ул 66 бит эчендә үзең язганнары бардыр, дип уйламадым, барысы да басылган битләр генәдер дип уйладым. Миңа җибәргән өлешендә дә берничә басылган битләр бар иде. Алар арасында үзең өстәп язганнарын бергә кушып мин күчергән идем. Мөмкин кадәр маши-

нисткаларга җиңелрәк булсын дип, булдыра алган кадәр ачыграк язарга тырышкан идем. Аларның да эшләре күп бит, бик төпченеп утыра алмыйлар. Аларны да гаепләп булмый инде.

Икенче кисәген мин күчереп бетерү белән Казанга җибәрдем. Анда аны Шафиканың кызы Венера алу белән нәшриятка илтеп биргән. Ул миңа шул турыда хат язган иде. Аны анда Арслановның кызы дип уйлаганнар.

Быел тагын кыш үтеп китте. Җәй аннан да тизрәк үтәчәк инде. Менә шулай йөгергән атналар, айлар, елларны да бик ашыктыралар шул. Элек без яшь вакытларда гомер ул кадәр тиз үткән кебек түгел иде, ул вакытларда да гел эш белән мәшгуль идек, хәзергегә караганда да күбрәк эшләнә иде. Шулай да көннәр бу кадәр тиз йөгермиләр кебек иде. Яшь гомерләрнең генә үтеп китүе җитмәгән кебек, карт гомерләр дә үтеп бара инде. Нишлисең, тормыш шулай корылган бит. Шушы калган гомерләребезне дә исән-сау булып, халыкка хезмәт итеп яши алсаак, «гомеребез әрәмгә узды», дип әйтерлек булмас иде.

Бәйрәм бик күңелле узды. 6.03. тантаналы җыелыш һәм аннан соң зур концерт булды. Мин нәфис сүз белән катнаштым. Культура йортында эшләүче хатын-кызларны бәйрәм белән котладылар. Истәлекле бүләкләр тапшырдылар...

Без хәзер Мирсәй Әмирнең «Тормыш җыры» дигән китабы буенча май аенда булачак смотрга спектакль куярга хәзерләнәбез, вакыт бик аз, тиз хәзерләнергә кирәк. Безнең халык театрының артистлары төрлесе төрле җирдә эшләүчеләр, менә аларның вакытларын табуы бик авыр. Репетицияләргә барысы да берьюлы килеп, бөтен пәрдәләргә дә репетиция ясап булмый, килгән кешеләр белән эшлибез, килмәгәннәрен икенче вакыт чакырырга туры килә. Шул ягы авыр булмаса, башка ягына түзәргә була.

Ярый, бетерәм.

*Сәлам белән Гайшә (Гыйззәтуллина)*
*10.03.1980*

Ибраһим туган!

Сезгә барыгызга да миннән, туганнардан күп сәлам. Мин исән-сау авылга кайтып җиттем. Мәскәүдә нәкъ бер ай тордым. Мәскәү буенча экскурсиягә йөртә торган автобус белән Мәскәүнең истәлекле урыннарын карап йөрдек. «Бабай» белән саубуллашу һәм күмү

вакыйгаларын телевизордан гына карый алдык. Ул урыннарга бар кеше өчен дә юл ачык булмый икән (шулай булуы дөрес тә инде, юкса шулкадәр кеше арасында бернәрсә дә күреп булмас иде.)...

Кичә безнең театрның режиссеры Разия ханымга 55 яшь тулды. Аны пенсиягә озату тантанасы үткәрелде. Ә тантана өлеше беткәннән соң барыбызны да үзенә кунакка чакырды. Мин юлдан бик арып кайтканга бармаган идем. Бүген яңадан чакырып, бик үтенгәч барырга мәҗбүр булдым. Кичә була алмаган берничә кеше белән кунакта булып катйтым. Бик күңелле утырдык. Разия ханым пенсиягә чыкса да, бездә эшли әле. Театрга бик бирелгән, театрны бик ярата торган көчле артистка ул.

4 нче декабрь көне Пермьдә халык театрларының смотры була. Без «Ташкыннар» спектакле белән барачакбыз, шуңа күрә минем тиз кайтуымны сорап Мәскәүгә дә шалтыратканнар иде.

Син бер хатыңда «чыннан да синең зарланырга хакың бар», дип язгансың. Минем хатлар да зарлануга охшаш нәрсәләр язылганы булмады кебек, һәм зарланганым да юк. Хәлемнән килгән кадәр сиңа булышам икән, ул үзе минем өчен зур сөенеч. Яхшы нәтиҗәсен күрергә генә язсын. Минем бөтен теләгем шул. Мин бу ярдәм өчен бернәрсәгә дә өметләнмимен. Ул вакытта ул бурычка эшләү булыр иде, ярдәм итү булмас иде. «Ярдәм-булыш» сүзләрен мин шулай аңлыйм. Шулай булгач, үзеңне бурычлы итеп санамаска тырыш, мин дә сине бурычлы дип санамыйм. Пакет мәсьәләсенә килгәндә, мин аны бик кадерле нәрсә итеп карыйм. Кулъязмалар иң кадерле әйберләр алар. Аларга җил-яңгырлар тияргә тиеш түгел. Андый нәрсәләрне килде-китте генә эшләргә яратмыймын мин. Шуңа күрә бик ныклап төрәмен. Менә шулай туганкай, сәркатибең вакчылрак кеше булыр. Шафиканың сәламәтлеге әйбәт, Мәскәүдә көн дә диярлек йөреп, күп җирләрдә булдык, алай сәламәтлегенә зарланмады. Барган җирен бик яраткан, ванналар алган, киләсе елга бергәләп барыйк дип, миңа да киңәш бирде әле. Путевкасыз барсаң да врачлар белән танышып дәваланырга була икән...

Башлаган эшләреңне акрынлап эшләп чыгарсың әле, бер дә борчылма. Әллә нинди иләмсез уйлар белән дә баш ватма. Көннәр бозылган саен иләмсез уйлар уйлый башласаң, башың арып бетәр. Ул уйларны башыңнан чыгарып ташла, бер сәбәп тә юк...

Хәзергә бетерәм. Сәлам белән: *сәркатиб Газизә (Гыйззәтуллина)*

*27.11.1982*

Ибраһим туганкай!

Сезгә барыгызга да миннән, туганнардан күп сәлам. Синең 5.01.дә язган хатыңны алдым, рәхмәт. Бәйрәм арасында хатлар озаграк йөри шул. Минем котлау открыткам бик озак барган икән.

Ул открыткада язылган шигырь кисәге ул кадәр үк мактауга лаек түгел инде. Шаярап кына язасың син. Яхшы шигырь язу өчен чын шагыйрь булырга кирәк бит. Ә миндә чын шагыйрь таланты бөтенләй юк. Уйлаган уйларымны исемә төшкән саен шигырь юлларына теркәп куям, бары шул гына. Менә сиңа тагын бер җавап:

Шигырь язам – шагыйрь булмасам да.
Язмыйм аны һич тә дан өчен.
Һәр хезмәтем минем ватан өчен,
Чиксез матур тыныч таң өчен.
Туган илнең тиңсез матурлыгын
Аңлатырлык сүзләр табалмыйм,
Партиябез биргән гүзәл тормыш
Бизәкләрен күреп туялмыйм.
Шагыйрьләрчә әйтеп бирә белмим
Күңелемдәге матур сүзләрне.
Дәрт булса да белеп булмый икән
Шагыйрьлекнең нечкә серләрен.
Шагыйрь кешеләрнең шигырьләре,
Тиз арада дөнья күрәләр.
Мин язганнар бу бәхеттән мәхрүм,
Дәфтәремдә тамыр үрәләр.

Менә шулай Ибраһим туган, үзем өчен генә булса да, уйлаган уйларымны дәфтәргә язып куямын да, берникадәр вакыттан алып укысам – үземнең җүләрлегемнән үзем көләм.

Мин Мәскәү хәлләрен элекке хатларда яздым шикелле. Театр эше дә әйбәт бара. «Әлдермештән Әлмәндәр» әсәренә хәзерләнәбез. Бик кызыклы комедия. Ул Казанда берничә ел бара инде, бәлки күргәнсеңдер. 91 яшьлек Әлмәндәр картның яратып өйләнергә йөргән 70 яшьлек «кызы» Хәмдебану ролендә – мин, ә Әлмәндәр карт ролен күршебез Габдуллахан башкара...

*Сәлам белән сәркатиб Гайшә-Газизә (Гыйззәтуллина)*
*14.01.1983*

Ибраһим абый!

Сезгә барыгызга да барчабыздан да күп сәлам. Синең 10.08 дә язган хатыңны алдым, рәхмәт.

Мин бүген Шафикага хат яздым әле, күптәп хәбәрләшкән юк иде. Бәлки вакыт тапса, үзе дә хат язып салыр.

Синең теге шигырең миңа чынлап та ошады. Чын күңелдән язам. Синең хатыңда язган сүзләрең дә укып туймаслык була, катkат укыйм – барысы өчен дә рәхмәт. Минем кечкенәгенә ярдәмләшүне шулай зур итеп исәпләгәч, минем өчен дә бик зур сөенеч. Эшләребезнең нәтиҗәсе дә әйбәт килеп чыкса, барыбыз өчен дә зур куаныч булыр иде.

Минем сиңа бер үтенечем бар иде, әгәр вакытың булса, шуны эшләп җибәрә алмассыңмы икән. Мин сиңа үзем язган берничә шигыремне җибәрсәм – син шуларны карап җибәрәр алмассыңмы? Мин аларны бу хат белән салмыйм, синнән рөхсәт килсә генә җибәрермен. Кайбер кешеләр район газетасына бирергә киңәш итәләр, минем болай гына бирәсем килми. Бездә шигырьләр тәртибен аңлаган кешеләр юк. Шуңа күрә синең белән киңәшләшәсем килә иде. Хәзерге вакытта эчүчелек белән көрәш барганда бик файдалы шигырьләр булыр иде, дип уйлыйм инде үзем. Агитбригада белән колхозларга чыгып йөргәндә укырга дип язып алганнар иде, анда кулланалар. Нәтиҗәсе ничек булыр тагын.

Кичә безнең культура йортында Мәсгуть Имашев белән очрашу кичәсе булды. Ул – безнең районның бер авылыннан чыккан үзешчән композитор. Аның көйләре бик матур. Хатыны белән килгәннәр, хатыны җырчы икән. Узе дә җырларга ярата. Икесе дә җырладылар. Халык бик яратып калды.

Бу арада озак кына аяз булып, көннәр матур торган иде, шулвакыт эчендә кешеләр печәннәрне хәзерләп бетерделәр. Әле менә кичәдән башлап көн дә азлап кына тагын яңгыр ява башлады. Иртәләрен-кичләрен көзнең якынлашканы сизелә инде. Хәерле булсын, тагын җәй үтеп китте.

Быел балалар да кайтып китә алмадылар.

Хәзергә бетерәм.

*Сәлам белән Гайшәбикә (Гыйззәтуллина)*

*17. 08.1985*

Ибраһим туганым, абый!

Сезгә барчагызга да миннән, Розадан, башка туганнардан күп сәлам. Синең бик озак көттергән хатыңны алдым, рәхмәт. Казаннан килгән хат белән таныштым. Бик матур итеп, бик яратып язганнар. Бу барыбыз өчен дә сөенечле хәл. Сине Казанга чакырулары да бик урынлы, бик вакытлы дип уйлыйм. 19.05 ендәге юбилей бәйрәменә барып җитсәң, язучылар съезды да май ахырында булса, икесен дә үткәреп кайта аласың. Әле бит синең Аяз Гыйләҗев белән дә эшең булачак. Шулай булгач, сиңа Казанда бераз торырга туры килер...

Чирәм җирләрне үзләштерүнең 30 еллыгы вакытында сиңа да мөрәҗәгать итәрләр әле дип мин уйлаган идем. «Күкчәтау далаларында» дигән романың казакъ телендә әлерәк кенә чыккач, бик күп кеше укыганнардыр инде. Гомумән, синең китаплар укучылар өчен кызыклы, мавыктыргыч, бар кешеләрне дә җәлеп итәрлек язылган була.

Безнең хәлләргә килгәндә, бер көе, исән-саулардбыз. Роза эше белән Пермьгә барып кайтты. Хәзер эшләп йөри. Театр эше дә әйбәт кенә бара. Һаман авылларда спектакльләр куеп йөрибез.

Быел, 1984 елда Сахип Җамалның рус телендә бер китабы чыккан. Аны Мәскәүдә хәрби нәшрият чыгарган. («Когда осыпались тюльпаны» дигән китабы). Ул китапта Алжир халыкларының француз колонизаторларына каршы көрәше тасвирланган. Укырга бик җиңел, матур итеп язылган.

Хәзергә бетерәм.

*Сәлам белән Гайшәбикә сеңлең (Гыйззәтуллина)*
*16.03.1984*

Ибраһим дус!

Сезгә барыгызга да миннән, туганнардан күп сәлам. Мин йөреп кайткач, бер хат язган идем, алгансыңдыр. Менә синең 14.07дә язган хатыңны алдым, рәхмәт.

Мин бер көе исән-сау гына эшләп йөрим. Өйдә дә, бакчада да эш җитәрлек. Ярый әле туганнар бар, алар килеп булышкалыйлар. Хәзер бакчада җиләк-җимешләр өлгерә башладылар. Азлап булса да җыеп, төрлесен төрлечә эш итәргә кирәк.

Синең язу эшеңдә минем кечкенә генә шушы ярдәмемә зур бәя биргәнеңә рәхмәт инде.

Трилогияңне тәмамлавың яхшы булган, барыбыз өчен дә бик зур сөенеч. Күп еллар буе хәзерләсәң дә, элек язар өчен вакытың да аз булган бит, ул да комачаулагандыр. Инде киләчәк язмышында куанычлы булып, озакка сузылмый гына дөнья күрергә насыйп булсын. Кызыксынып укучылар күп булыр. Бездә дә ул китап турында сораштыра башлаганнар иде инде. Мин дә кулдан килгән кадәр ярдәм итәргә тырышырмын. Бу арада бик озаклап утыра алмасам да, көн дә азлап романыңны күчерәмен. Калган кисәкләрен үз җаең белән җибәрерсең...

Быел көннәр узган елга караганда яхшырак. Яңгырлар да вакытында ява, аяз, җылы көннәр дә бар. Киләсе айларда ничек булыр тагын.

Гастроль вакытлары ничек үткәнен элекке хатымда язган идем шикелле. Өч атнадан артык вакыт эчендә бик күп җирләр йөреп кайттык. Барда авылының Чернышевкага бара торган җиреннән чыгып киткән идек, Саратовка бара торган ягыннан әйләнеп кайттык.

Хәзергә бетерәм.

*Сәлам белән Газизә (Гыйззәтуллина)*
*23.07.1979*

Хөрмәтле Ибраһим ага, исәнмесез, саумысез!

Гаиләгезгә, дус-ишләрегезгә, фикердәшләрегезгә ерак Татарстан республикасы Менделеев (Бондюг) каласында яшәп, эшләп, иҗат итеп ятучы Марсель Гыйльфан улы Гыймазетдиновтан эчкерсез сәламнәремне, изге теләкләремне һәм яңа ел котлауларын ирештерсәгез иде.

И, хөрмәтле Ибраһим ага! Түбән Камада узгарган мизгелләрне онытасым юк, гел истә алар. Башта зур мәдәният сараеның олы сәхнәсендә кул кысышып, бер-беребезне кочаклаулар, аннан соң җиңел машинада килкә балыклары кебек төялеп (күп кеше утырдык ич) Азат әфәнделәргә китүебез, Азат әфәнделәрдә чәй артында сөйләшеп, уйлашып, фикерләшеп, пианинода сеңелкәшнең уйнаулары күз алдымда мәңгелек хатирәләр булып торалар. Җырладык та ич әле!

Ибраһим ага! Күптәннән хат язмакчы идем. Кулым җитмәде, сәбәбе дә әллә ни юк иде. Сезнең исән-сау, сәламәт икәнлекне ишетеп торганлыктан, сезне хатларым белән борчыйсым килмәде. Менә, җомга кичен, ягъни 11 гыйнвар көнне «Әллүки»дә Сезнең рәсемне

күреп һәм Татарстан Язучылар берлегенә ачык хатыгызны укыганнан соң, кулыма каләм алырга булдым. Бигрәк тә «Мин бүген ышану һәм шундук икеләнү белән сезгә мөрәҗәгать итәм. Бәлкем, бусы инде соңгы тапкырдыр...» дигән юлларны укыганнан соң тетрәп киттем бөтен гәүдәм белән. Юк, соңгысы түгел, соңгысы гына була күрмәсен! Әле мин Сезне, баштан ашарлык газаплар кичерсәгез дә, нык ихтыярлы, нык сәламәт күңелле кеше итеп күз алдыма китерәм.

Түбән Камада мин Сезне кочагыма алгач, физик яктан да әле нык икәнегезне тоеп, күңелемнән бик сөенгән идем. Хәтта, безнең белән булган Зөфәр Шәкүровка: «Нык абзый әле, 110 килолы гәүдәм белән көчкә кузгаттым урыныннан» дип горурланып әйтеп куйган идем. Так что, Ибрагим абый, май азакларында сабантуйларга Сезне үзебезгә чакырырга җыенабыз әле...

Ибраһим ага, мин политикага бирелеп китәргә җыенмыйм, шуны гына әйтәм: суверен Татарстан хәзергә сүздә генә әле. Беркем дә бирергә теләми. Кан коеп алыр заманнар түгел бит инде ул бәйсезлекне.

Илдәге кебек үк бездә дә үзгәрешләр чоры. Тик безнең Татарстанда тынычрак, милли тойгыларга бирелмичә, кан коешсыз бара. Көрәш партия белән Советлар арасында, аннан соң власть алу өчен бара. Хәтта безнең районда да бара ул көрәш. Күбесе районы, халыкның тормышын алга этәрү өчен түгел, карьера өчен көрәшә. ..

1991 елның 1 гыйнварында Татар телевидениесе 2 яңа җырымны тапшырды. Бүгенге көндә «Әнисә», «Аккош канат кагына», «Әйләнеп кайт әле авылга», «Килмисең син көлеп».... дигән җырларым җырлана инде.

Үземне Менделеев районы Советы рәисе урынбасары итеп сайладылар апрель аенда. Колхозны калдырырга туры килде. Эшләр бик күп...

*Сәламәтлекләр теләп, Марсель Гыймазетдинов*[1]
*14.01.1991*

Хөрмәтле Ибраһим ага!

Хатыгызны, ерак юллар үтеп килгән, минем, безнең өчен бик тә кадерле булган хатыгызны алу бәхетенә ирештем.

---

[1] Марсель Гыймазетдинов (1943–1993) – шагыйрь, җыр текстлары авторы.

Мине онытмавыгыз һәм хат язуыгыз өчен үземнән һәм дусишләрдән, шулай ук минем дус – Шәкүров Зөфәрдән – фикердәштән олы сәлам һәм рәхмәт...

Ни эшләптер бу араларда гел күңелем нечкәреп, нигәдер ашкынып тора. Һәм гел Сез искә төшәсез.

Әле 14 апрель көнне районыбыздагы 10 классс тәмамлаучылар белән очрашуда Сезнең хатыгызны укыдым. Тын да алмыйча тыңлап утырдылар татарлар, руслар, мари, удмуртлар.

Сәламәтлекләр кай тирәдә, Ибраһим ага. Юл йөрүләр үзе кызык нәрсә, дөнья күреп, илләр гизәсең. Туган яктан ераклашкан саен, тарту көчен күбрәк сизәсең. Арылгандыр, юл йөрүләрдән кайткач, ял итәргә кирәк инде.

Ибраһим ага, мин бүгенгесе көндә райисполком председателе урынбасары. Председатель булырга да тәкъдим иттеләр, әмма каршы килдем... Зам булуның кирәге: культура, халык мәгарифе һ.б. белән эш итәм. Халык арасында татар культурасын, татар телен, татар мәктәп-ясле-бакчаларын булдыру өстендә эшлисе иде.

«Ядкарь» әдәби берләшмәсенең эшен яңартып җибәрдем. Татар театрының эшен көчәйтәсе бар. Менә шулай, эшләргә тырышып ятабыз, әмма бик кыен бездә татарны кузгатуы. Руслашып беткән. Киләсе атнада гает бәйрәме. Ураза тәмамлана. Кайбер районнарда мәчетләр салалар. Казан телевидениесеннән гарәп теле укытыла, имамнар, муллалар чыгыш ясыйлар. Кешегә дин, әхлак, миһербанлылык турында сөйлиләр. Бик азы кеше тарафыннан кабул ителә. Алга таба ниләр булыр, болгавыр чак, болганчык чор. Бик күп болгатучылар, эшләүләре авыр.

Менә шундый хәлләр, Ибраһим ага. Сездән хат көтәм.

*М. Гыймазетдинов*

*20.04.1990*

Здравствуйте уважаемый и дорогой Ибрагим Низамович!

Прочитал заметку о Вас в газете и знаете, очень обрадовался, что все становится на свои круги. Радует то, что Вы не уподобились большинству, которые требуют льгот для себя и считают, что им все должны, может в чем то они и правы, осудить их трудно, общество должно вернуть им за моральные и материальные убытки, однако есть категория людей «непокоренных», которые не прима-

зывались к славе, не искали ни льгот, ни почестей, они жили и живут для людей. Ведь если кто-то и не прочитал «Черную Колыму», он увидит фильм, увидит жизнь непридуманную, это не может не сказаться на мировоззрения человека видевшего фильм. Это зерно засеянное в душах людей взойдет тогда, когда надо будет участвовать в выборах или высказать свое мнение о будущем своей Родины. Люди не будут бездушно отдавать свои голоса, ибо они видели во что превращается жизнь с одинаковым мышлением.

Я очень рад за Вас, за то что Вы ведете такой активный образ жизни. Дай Вам крепкого здоровья и счастья...

*А. Дейчук*[1]

*г. Мукачево*
*2.04.1992*

Здравствуйте уважаемый и дорогой Ибрагим Низамович!

Совершенно неожиданно получил Ваше письмо, единственная добрая весть за последнее время, которая вызвала у меня бурю эмоций положительных и радостных. Я очень рад, что Вы живы и здоровы, и неменьше Вашего рад за то, что наша переписка, как маленькая тоненькая ниточка не оборвались. Спасибо Вам!

Время действительно очень-очень тяжелое и для всех нас и для меня в частности. С огромными трудностями пришлось столкнутся с 10 декабря минувшего года. Перед тем, как идти на голосование за своего президента и статус суверенной Украины, я получил телеграмму, что в течении 15 дней должен освободить квартиру, люди стали безжалостными и в итоге среди зимы меня с семьей выселяют на улицу.

Жить негде и определенно по сегодняшний день никто ничего не поможет, поэтому приходиться уповать только на милость всевышнего.

У нас очень много бурных перемен, ввели новые купонные деньги, цены не то, что кусаются, а вводят в шоковое состояние, особенно страшным был их первый скачек, сейчас появляются товары, цены падают только на пищевые продукты. Думаю, что все постепенно образуется, но вот каким образом даже не знаю. Трудно

---

[1] Александр Дейчук – Украинаның Мукачево шәһәреннән, И. Салахов белән командировкада танышып, хәбәрләшеп торалар.

что либо предсказать, сколько людей – столько и разных мнений. Теперь их нечему и некому объединить в единую общность – советский народ, да и стоит ли? Мы разрушили старый дом – не построив нового, и поэтому страдаем от политических, экономических и погодных стихий под открытым небом. С кем я? Я, как и Вы вместе со своим народом, со своей Родиной, разве можно по-другому. По телевизору транслируют самое черное, как с одной, так и с другой стороны, в действительности очень сильно отличающееся от сути.

Когда на верху раздел власти происходит, внизу все это переносят на своих плечах. Я и многие, почти все сослуживцы надеемся, что этот процесс раздела и размежеваний не разъединит народы, так нельзя! Я всегда уважал всех солдат независимо от национальностей, о многих остались добрые и теплые воспоминания. Я очень уважаю Вас, человека, который за несколько часов совместного пребывания в одном купе вселил в меня такой оптимизм и веру в жизнь, которого я не чувствовал ни от кого. Я рад, что доброй памятью этой встречи осталась Ваша книга, поверьте, что я сохраню ее и покажу тоже детям своим.

Я верю в торжество справедливости и еще как и Вы верю в бога. Верю и надеюсь, что он даст Вам еще долгих лет жизни, крепкого здоровья, счастья Вам и всей Вашей семьи.

Об экономике пишу сознательно очень мало, так как первые дни анализу не поддаются… На этом заканчиваю.

*С огромным уважением к Вам ваш Сашко (Дейчук)*

*г. Мукачево.*
*17.01.1992 г.*

Дорогой Ибрагим абый!

Заказную бандероль получил – большое спасибо. Содержание и оформление книги меня радует, выпущено со вкусом. Будем ждать, когда выйдет книга на русском языке. В Казанский магазин «Книга-почтой» я отправил заказ. Только вряд ли пришлют, что-то не уверен – в последнее время они неохотно выполняют заказы иногородних татар.

Я хорошо понимаю Вас, мы, татары, проживающие вне Татарии, в особом, в более трудном положении. Скажем, вот я. Родом их Пензенской области, родился в 1947 году. Жил в русско-

татарской деревне. Отцу-то немного удалось учиться в татарской школе, а мне – нет. Я учился, как и мои сверстники, только на русском языке. И я не виноват в этом, мне всю жизнь хотелось учиться в родной школе, изучать родной язык и литературу. И что же? После института приехал в Оренбуржье, здесь женился на татарке-учительнице. Я самостоятельно изучил татарский язык, татарскую литературу. Сейчас могу читать, разговаривать вполне сносно. Работаю ответственным секретарем райгазеты. Кроме того, в русских газетах Оренбурга, Казани и Москвы пишу статьи, очерки о книгах татарских авторов, статьи об их творчестве. В июле этого года была моя статья о Маджите Рафикове в газете «Советская Татария», в июле или августе этого года – очерк о башкирском поэте-фронтовике Кадыре Даяне в уфимской газете на татарском языке «Кызыл тан».

Должен сказать, Ваши книги нравятся читателям, их читают с особым интересом.

Дело моей жизни: продолженние поиска новых материалов о Мусе Джалиле, о его соратниках, товарищах, об их дружбе, борьбе. Кое-какие успехи есть. Обрадуюсь, если вы пришлете обещанные воспоминания о встречах с Мусой Джалилем. По возможности пришлите, очень прошу.

Добрые пожелания семье, с уважением *Равиль Енакаев*[1].

*(Оренбургская обл., п/о Илек).*
*1991 г.*

Дорогой Ибрагим абый! Как Ваши дела, здоровье? Пусть у Вас все будет хорошо.

Что касается меня, то, как редактор райгазеты, вступил в конфликт с властями. Стали учить меня. Как и о чем писать. Я показал Закон о печати: вмешательство в деятельность редакции не допускается. Стали орать, швырять Законом... В итоге ему ничего, а я перенес инфаркт в свои 45 лет. Уйду с редакции наверное. Не могу работать с такими рвачами и перевертышами. Что творится?!

---

[1] Равил Енакаев (1947–1993) – журналист, Оренбург өлкәсе Илек район газетасында эшли, туган якны өйрәнүче.

К власти пришли люди злые, завистливые. Горько и обидно...Слово «демократия» превращается в «дерьмократию».

Пишите. Добрые пожелания семье.

*С уважением Р. Енакаев*
*9.07.1992*

Уважаемый Ибрагим!

Поздравляю Вас с Новым годом, желаю Вам доброго здоровья и хорошего настроения.

Прочитала ваш роман «Тернистый путь» и заплакала, вспомнила своих близких погибших в сталинские времена.

Мой дядя Еналеев Давид Абейдуллович 1889 г. рождения, педагог пед.ин-та, был репрессирован в 1937–38 гг., находился в тюрьмах НКВД. В начале 1939 г. был осужден на пять лет и этапирован в Свердловскую обл.

До 1942 г. мы держали связь, а в конце 1942 г. связь от него прекратилась.

За это время умерла его жена и погиб трагически его единственнный сын.

Из близких родственников осталась одна я, и мне теперь 74 года.

Второй мой родственник (двоюродный дядя) Еналеев Сулейман Бикмухаметович 1895 г. рождения, врач по образованию, быший ректор Каз. мед. инс.-та. Был репрессирован в 1938 г. О нем вообще ничего нет, кроме справки о реабилитации.

Я обращаюсь с просьбой, не знаете ли что-либо о них.

Понимаю, Вы не «справочное бюро», напрягать память тяжело. Во имя измученных невинных погибших, пожалуйста, извините меня.

*С приветом Сара Еналеева (Ахтямова)*[1]
*Казань*
*28.12.1988 г.*

Ибраһим кордаш!

Хатыңны алдым – рәхмәт! Минем соңгы әйбергә карата әйткән җылы сүзләрең өчен тагын бер мәртәбә зур рәхмәт! Мин инде,

[1] Сара Еналеева – Казаннан, репрессия корбаннары булган туганнары хакында белешергә теләп, хатлар юллый.

билгеле, кулымнан килгән кадәр тырышкан булдым, ләкин күңелем бер дә тыныч түгел иде. Ничек кабул итәрләр, нәрсә әйтерләр? Бу сораулар безне өзлексез борчып торалар бит инде. Тора-бара ни булыр, әмма хәзергә әсәрне яратып укыйлар кебек – моны ишеткәләргә туры килде. Ләкин шулай да тынычланырга иртәрәк әле – тәнкыйтьчеләр сүзен ишетәсе бар. Ә тәнкыйть ул бик хикмәтле нәрсә, фокусник шикелле төрлечә китереп чыгарырга мөмкин. Тик бер хакыйкать бар: яңа әсәрне халык яратып кабул итсә, аны инде бернинди тәнкыйть тә юкка чыгара алмый. Шуңа ышаныйк!

Син дә, Ибраһим, зур эшләр башкарып ятасың икән. Алла куәт бирсен!.. Роман ул – синең жанр, әлбәттә син аны әйбәтләп очлап чыгарсың дип ышанам! Кат-кат эшләү, билгеле, зур чыдамлык (һәм батырлык) сорый, әмма ни чара? Язу – энә белән кое казу инде ул, брат!

Хуш!

Үзеңә һәм гаиләңә күп сәлам!

*Әмирхан Еники*[1]

*24.11.1975*

Сәлам Казаннан!

Исәнмесез, Ибраһим ага! Сезгә зур сәламнәр юллыйм. Исәнлек-саулык телим. Үзегезгә һәм гаиләгездәге башка якыннарыгызга.

Хатымны гафу үтенүдән башлыйм, Ибраһим ага. Сез җибәргән барлык хатларны алдым дип уйлыйм, ләкин шушы көнгәчә берсенә дә җавап язмадым. Әсәр өстендә эшләгәндә вакыт табып булмады, аннары ялга китеп бардым. Менә ялдан чыгуыма фоторәсемнәр белән янә бер хатыгыз көтеп торган.

Әсәрегез июль аенда производствога төшеп китте. Инде менә кайбер оттискалары да килә башлады, карарга җибәрәм. Әле текстның корректурасы юк. Килүгә, әлбәттә, сезгә җибәрербез. Исемен алмаштыра алмадык, «Колыма хикәяләре» буларак ул темпланда басылып, темплан сәүдә оешмаларына җибәрелгән булган. Ләкин «Фаҗига-хроника» дигән искәрмә белән бирдек. Миңа калса, алай отышлырак та булды. Фоторәсемнәрегезнең берсе дә ярамады.

[1] Әмирхан Еники (1909–2000) – Татарстан Республикасының халык язучысы, Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты.

«Татар-совет язучылары» китабында чыккан рәсемегезне табып, зурайтып бирдек. Ничек килеп чыкканын карарга җибәрәм. Кире җибәрү кирәкми, артык нөсхә ул.

Китап яхшы булып чыксын өчен кулдан килгәннең барын да эшләдек дияр идем. Басылып чыккач, үзегез тагын ни диярсез. Рәсемнәрегезне кире җибәрәм. Берсен үземә истәлеккә аласым килсә дә, алмыйм. Бәлки, үзегез язып җибәрерсез әле дигән якты өмет белән калам.

Иң изге теләкләр телим. Хушлашмыйм, вакытлыча саубуллашам.

*Шәмсия Җиһангирова*[1]
*Казан*
*29.08.1988*

Хәерле көн һәм хәерле сәгать Ибраһим ага!

Сезгә олы ихтирам белән саулык-сәламәтлек, озын вә бәрәкәтле гомер теләп хат яза Шәмсия. Сәлам «Кемнән ул хат?» диеп кызыксынучыларга. Үзем вак вә эре хуҗалардан сәлам әйтеп тормыйм. Чөнки официаль хат булып чыга. Болай гына, якын итеп, яратып кына язып салыйм әле. Чөнки (сер итеп кенә әйткәндә) кешеләр белән чын күңелдән сөйләшү һәм язышу (никадәр генә замана хәбәрдар булмасын) рөхсәт ителми торган бер эш булып кала килә без хезмәт күрсәтә торган урында. Беренче хатны да тикшереп, «Ихтирам белән баш иеп» вә шуныңише күңелгә җылы сүзләрне сыздырып ыргыттылар (сыздырып түгел әле, үз куллары белән сызып). Түрәләрнең бөтен вазифасы – адәм баласында сакланып калган кешелек сыйфаты билгеләрен тамырына кадәр корыту, бетерүдер кебек тоела миңа кайвакыт.

Хатыгыз, фоторәсемегезне алдым, бик зур рәхмәт сезгә. Сәмруг кош тоткандай сөендердегез.

Кулъязмагыз турында, чыннан да, хәбәр бирергә онытканмын. Аны, мин редакцияләп бетергәч, Фәрваз абый үзенә алган иде. Теге Рәмзия атлы ханым минем янга килгәч, хатыгызны күрсәткәч, Фәрваз абый урынына калган иптәшкә кереп, аңлатып, Рәмзиядән кулъязманы Дәүләт музеена алганлыкка рапсписка алып калып, карта вә барлык фоторәсемнәр белән кулъязманы төпләнгән, исән

[1] Шәмсия Җиһангирова (1951) – язучы, шагыйрә.

килеш музейга дип биреп җибәрдем. Зинһар борчылмагыз. Теге «Казан утлары» төшереп калдырган берничә бүлекне (машбюро кызлары белән килешкәннән соң) шул китап хәлендәге кульязмада килеш кенә редакцияләп (ботарламас һәм сездән өстәмә чыгымнар чыгармас өчен), машинкада бастырып алган идем. Шул бүлекләр бераз пычранган иде инде. Анысы да музей өчен бик ярый дип уйладым. Әле нәшриятның үзендә дә шул сезнең нөсхәне калдыру турында сүз булмады һәм булмас, сезгә өстәмә борчулар артмас дип өметләнәм. Теге сез искә алган Евгения Гинзбургның «Крутой маршрут» дигән әсәрен «Вечерняя Казань» газетасында тулысы белән бастырып яткан көннәре. Газетаның 171 номереннан башлап 211 номерга кадәр чыкты инде. Әле дәвамы һаман да басыла (ишетмәгән булсагыз дип язам). Ике нөсхәдә төпләп салам. Тагын бер кабат сәламәтлек телим һәм очрашуга зур өмет белән калам.

*Шәмсия (Җиһангирова)*
*14.09.1988*

Хәерле көн, хөрмәтле Ибраһим ага!

Сезгә Татарстан китап нәшриятыннан күп сәлам юллыйбыз, нык сәламәтлек, уңышлар телибез.

Сезгә хат язуның сәбәбе шул – нәшрият шушы июль аенда сезнең «Колыма хикәяләре»н (журнал вариантына таянып) производствога төшереп җибәрергә уйлый. Шул нәүбәттән, сезнең белән ачыклыйсы берничә мәсьәлә бар.

Журнал әсәрегезне «Роман-хроника» дип бастыра. Кульязмада сез «Юл истәлекләре» дип аласыз. Бәлки «Документаль повесть» яки «Повесть-истәлек» дип алу отышлырактыр?..

Журнал вариантыннан сез тулысынча канәгатьме (булмасагыз, кай урыннары күңелегезгә ошамый?)

Китап вариантына Аяз Гыйләҗев кереш сүз язачак. Сез ризамы?

Китапка бирергә бездә уңышлы фоторәсемегез юк икән. Бәлки, үзегез берәр рәсемегезне салырсыз. Зуррак форматта (16х10 см). Ак-кара сурәттә.

Әсәрнең журнал вариантында «Казан утлары» өстәмә бер бүлек бирергә җыена икән. Кайтканнан соң Казанда очрашу турында дип ишеттем. Моңа сез ризадыр бит?

Гомумән, әсәргә нинди өстәмә, төзәтмә, искәрмәләрегез бар – шуларның барысы турында да уй-фикерегезне озакка сузмыйрак кына безнең белән бүлешсәгез иде.

Сездән хат көтеп, әсәрегезнең нәшрият буенча редакторы

*Шәмсия Җиһангирова*
*Казан*
*13.07.1988*

Хөрмәтле Ибраһим абый!

Җибәргән хатыгызны һәм «Фаҗига» пьесасын алдык. Бик зур рәхмәт.

Фикеребезне турыдан-туры әйтергә рөхсәт итегез. «Фаҗига» пьесасы бу килеш берничек тә театрда куела алмый, Ибраһим абый.

1. Пьеса бәләкәй (25 бит), бу 50 минутлык материал, спектакль итеп куяр өчен кимендә 45–50 битлек текст кирәк. Күренешләр бәләкәй, 5 минут саен сәхнә алышына, катнашучыларның саны күп. Бу яктан караганда пьеса киносценарийга тартым. Ләкин иң мөһиме болар түгел.

2. Пьесада эзлекле сюжет юк, Ибраһим абый. Тамашачыны тотып тору өчен вакыйгаларга үрелеп бара торган сюжет кирәк, чишелеш кирәк. «Колыма хикәяләре»н йотылып укыйсың, чөнки анда саллы сюжет ярылып ята, ә биредә бары фрагментлар гына, алар да бер-берсенә бәйләнмәгән, дөресрәге, бәйләү формасы табылмаган.

«Фаҗига» пьесасы атаклы романның шактый көчсез копиясе генә, ул сәнгать әсәре буларак өлгермәгән.

Ялгышмыйм микән, дип, берничә кешедән укытып карадым, барысы да сүзгә-сүз шул ук фикерне әйтә.

Ибраһим абый, әгәр рөхсәт итсәгез, бәлки без сәхнә кануннарын яхшы белүче яшьләрнең берәрсенә заказ биреп карарбыз, чөнки «Колыма хикәяләре» безгә бик кирәк, чөнки безнең өчен бу тема – әле кеше аягы басмаган утрау, ачылмаган ишек, җырланмаган җыр. Зинһар, үпкәләмәгез. Сүзегезне миңа язып җибәрегез.

Бары тик үпкәләмәгез генә. Үтенеп гафу үтенеп, хөрмәт белән,

*Шамил Закиров*[1]
*17. 04. 1991*

---

[1] Шамил Закиров (1945–2012) – театр эшлеклесе, Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре, 1985–1992 елларда Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театры директоры.

Исәнмесез, хөрмәтле Ибраһим Низамович!

Хатыгызны алдык. Безгә Пермь җирендә гомер итүче татарларга игътибарыгыз өчен рәхмәт, газетабызның бер битен Сезнең тормышыгызга һәм иҗатыгызга багышладык. Ул санын безгә якын булып киткән Кызыл Яр авылына юллыйбыз.

Казакъстан минем күңелгә, чыннан да, якын. Малай чакта, илленче елларны, Павлодар, Кустанай, Акмолла далаларын гизәргә туры килде.

Ибраһим ага! Без сезне «Халык чишмәсе»нең хәбәрчесе итеп шатланып алабыз. Вәгъдә иткән язмаларыгызны түземсезлек белән көтәбез.

Сәламәт булыгыз!

*Мөхәррир И. Закиров*[1]

*8.03.1992*

Исәнмесез, хөрмәтле Ибраһим ага!

Сезгә кайнар сәлам һәм ихтирам белән Тәлига яза.

Ибраһим ага, сезнең хатыгызны алганга шактый вакыт үтте. Хатка җавапны «Китап укучылар конференциясе» үткәч, нәтиҗәне әйтеп язырмын, дигән идем. Ул безнең озаккарак сузылды. Конференцияне 30 апрельдә үткәрдек. Завклуб бик каты хәзерләнгән иде. Сезнең портретны зурайтып, сәхнә түренә элгән. «КУ» журналының рәсемен дә (тышын) зур итеп ясап, портрет белән янәшә элгән иде. Кунак итеп, ветеран укытучыларны да чакырганнар. Үзе бик матур итеп ачып җибәрде, әдәбият укытучысы биографиягезне сөйләде. Бик күп, бик күп чыгышлар булды. Тыңлаучылар бик канәгать булып таралыштылар. Кат-кат рәхмәтләр укыдылар. «Һәр чыгышны энә өстендә утырган кебек тыңладык», диделәр. Сораулар бик күп, бик күп булды. Сорауларның бик җитдиләре дә булачагын алдан уйлап, завклуб колхоз парторгын да, ведущий историкны да чакырган иде. Алар менә мондыйрак сорауларга җавап бирделәр.

1. Сталин заманындагы вәхшилекне политик яктан ничек аңларга була? Төзәлә алмаслык шундый хаталарга ни өчен юл куелган?

2. Хәзерге вакытта тоткыннарның тормыш шартлары ничек икән?

---

[1] И.В. Закиров – Пермьдә чыгучы «Халык чишмәсе» татар газетасының баш редакторы.

3. Илебездә бу хаталар яңадан кабатланмасмы? Гарантия биреп буламы?

Ибраһим ага! Сезгә кагылышлы сораулар бик гадидән катлаулылары да бар. Мин ул сорауларга җавап бирергә өстемә алдым.

Менә мондый сораулар:

1. Автор бүгенге көндә иҗат итәме икән? Нәрсә яза икән?

2. Пенсия күпме түлиләр, тормыш шартлары уңайлымы икән?

5. Тоткында вакытта бергә булган кешеләр белән элемтәдә торамы?

6. Зәйтүнә исәнме икән?

7. Тоткыннарны җәзалаучылар берәрсе исәнме икән? Аларны судка биреп, ачык суд ясап, телевизордан да күрсәтсеннәр иде...

Сораулар бик күп, шушылар җитеп торыр.

Сәлам бездән барлык якыннарыгызга. Сезгә сәламәтлек, тыныч тормыш, иҗади уңышлар теләп, *Тәлига Заманова*[1].

*3.05.1989*

Исәнмесез, хөрмәтле Ибраһим ага!

Сезгә, гаиләгезгә дусларча кайнар сәлам.

Ибраһим ага, хатыгызны алдым. Бик зур рәхмәт. «Юбилей кичәләре узмыйча , яза алмас», дигән идем. Иллә мәгәр, бигрәкләр дә аккуратный кеше инде үзегез. Сезнең кешеләргә карата шундый игътибарлы булуыгыз мине чиксез сокландыра. Үзем дә сезгә охшарга тырышам. Бу сыйфатыгыз (бу гына да түгел) белән Сез безне (яшьләрне) тәрбиялисез, рәхмәт. Әй, бар кеше дә шулай булсачы!..

Казаннан телевизор аша да, радиодан да Сезгә багышланган берничә тапшыру булды. 31 августта сезнең тавышны ишеттек. «Колыма хикәяләре»ннән өзек тә бирделәр. Җаннар тетрәнеп китте. Мондый җанөшеткеч афәтләр яңадан кабатланмасын иде инде.

30 август көнне Сезгә матур-матур теләкләр тели-тели, Сезне искә алып «Җомга көн кич» белән тапшыруын карадык...

Сезгә җан тынычлыклары, тән сәламәтлекләре теләп, зур ихтирам һәм хөрмәт белән, *Тәлига Заманова.*

*Аксубай.*
*2.09.1991*

[1] Тәлига Заманова – Татарстанның Аксубай районы Иске Кыязлы авылыннан. Язучы белән күп еллар хат алыша, фондта 30 дан артык хаты саклана.

Исәнмесез, кадерле һәм хөрмәтле Ибраһим абый!

Сезгә сагынычлы кайнар сәламнәр белән Тәлига яза, сәлам бездән барлык гаилә әгъзаларына һәм дусларыгызга. Ибраһим абый, сезнең хатыгызны алып бик тә шатландым. Хат эчендәге «Степные зори» газетасындагы барлык мәкаләләрне укып бетердем. Г. Гришков «Осень патриарха» дигән очеркында Сезне мировой аксакал, үз тормыш юлы белән дә, хәзерге заман яшьләренә, кешелекнең иң яхшы сыйфатларын өлге итеп калдырырлык шәп, соклангыч образ итеп бирә алган. Мин инде Сезнең «Колыма хикәяләре»н авылыбызда укымаган кеше калмагандыр дип уйлаган идем. Бүген бер мәчет карты янына барып чыгарга туры килде. Бу – китап укып утыра. Китап таушалып беткән. Карыйм – «Колыма хикәяләре».

– Каян алдың, дим, – малай Казаннан алып кайтты, – ди.

Минем «Имәннәр тамыр җәйгәндә» дигән әсәрегезне бик тә укыйсым килә. Һич таба алмыйм әле. «Черная Колыма» әсәрегез инглиз-төрек телләренә тәрҗемә ителеп, чит илләрдә дә таратылуы мине бик-бик шатландырды. Дөньякүләм әһәмияткә ия булган шундый зур бәһале әсәр тудыруыгыз белән сез бик бәхетле. Г. Гришков әйткәндәй, Алладан сорый белгәнсез бәхетне, Алла сезнең юлдашыгыз. Мондый бәхетле язмыш бик сирәк кешеләргә генә эләгә бит.

Рәхмәт казах халкына, Сезне бик олылаганнар, зурлаганнар. Мин Сезнең өчен бик шат. Үзебезнең тормыш бер көе тыныч кына ага. Авылда тормыш яхшы, тынычлык, туклык, муллык, Аллага шөкер. Кала кебек таш йортларны икешәр катлы итеп төзи башладылар. 2 шәхси хуҗалык кибет тота. Элекке байларның төшенә дә кермәгән тормыш авылда. Авыл халкы үзе дә бик тырыш, уңганнар. Авылда 2 мәчет эшләп тора. Авыл бик дини, яшьләр дә ураза тота, авыз ачтыра, мәчеткә йөри.

Хатымны кыскартам. Хуш, сау булыгыз, тыныч яшәгез.

*Ихтирам белән, Тәлига (Заманова)*
*(Аксубай р., Иске Кыязлы авылы).*
*22.11.1996*

Исәнмесез, кадерле һәм хөрмәтле Ибраһим ага!

Сезгә, гаиләгезгә, авылдашларыгызга бездән, авылдашларыбыздан кайнар сәлам белән, сәламәтлек, озын гомер һәм тынычлык теләп Тәлига дип белерсез.

Ибраһим ага, хатыгыз өчен бик зур рәхмәт. Сезнең хатыгызны алу белән: «Аллага шөкер, исән-сау икән», дип шатланып, тиз-тиз хатыгызны укый башлыйм. Әле һаман халыкка хезмәт итәсез, халык мәнфәгатен кайгыртып яшисез икән, рәхмәт. Алла хәерле гомерегезне бирсен. Анда китәргә ашыкмагыз әле. Мин Сезнең «Онытырга хакыбыз юк», дигән мәкаләгезне укыдым. «...бәлкем, бусы инде соңгы тапкырыдыр» дигәнсез, авызыгыздан җил алсын. Яшәгез әле, дөнья иркен. Заяга үткән гомерегезне дә камил акыл белән яшәп бетерсәгез иде. Сез бик вакытлы, бик кирәкле чаң суктыгыз. Әкренләп, Сезнең мәкаләгә аваздаш мәкаләләр басыла башлады. Равил Әмирханның «Мәгърур шәхесләр рухы» дигән мәкаләсе чыкты. «Кайтарылган исемнәр» дигән китап та чыккан. Телевизордан М. Мәһдиев: «Сталин корбаннары турында язам», – диде. Садри Җәлал, изелгән, кимсетелгән шәхесләр турында язарга җыенуын әйтте. Шәт, иншалла, «Сез кабызган утлар сүнмәс алар...» .

Сез Казан тапшыруларын тыңлый аласызмы? Һәр җомга көн «Җомга көн кич белән» альманахы чыгарыла. Шул тапшыруларда еш кына Сез күтәргән мәсьәләләр дә яктыртыла. Мин ышанам: бу эш тукталмас, нәкъ Сез күрергә теләгән нәрсәләр тормышка ашачак. Бездә шундый мәкаль дә бар бит әле: «Татар акылы төштән соң». Соңгарып кына уянабыз бит без. Шулай да, сәламәтлегегез борчымаса, язучылар берлеге әгъзаларын әледән-әле кытыклабрак торырсыз дип ышанасы килә. Мөхәммәд Мәһдиев бик күп тапкырлар вәгъдә бирде инде, ул да ярты юлда тукталып калмас…

Семьябыз турында берничә сүз. 3.02. көнне 82 яшьлек әнине (каенана) җирләдек. Бигрәкләр дә авыр булды, кызганыч булды. Әни бигрәкләр дә сабыр, акыллы, олы җанлы кеше иде. Әти (каената) 86 да исән, сәламәт, үз акылында. Мин аларны гомерем буе М. Горькийның Каширин бабай белән әбисенә охшатып яшәдем. Әти дары кебек кабынып китүчән, җитез, тәвәккәл, эшчән карт. Ат тота гомере буе. Печәнне үзе хәзерли. Әни Каширин бабай карчыгы кебек «Великан» карчык иде. Бүген «өчесе»н үткәрдек тә сезгә хат язам. Озак язмый торсам, вөҗданым газаплана...

Үлем! Бик яман нәрсә икән. Сез үлмәгез, үлмәгез, яшәгез, 100 гә кадәр яшәгез! Хуш, сау булыгыз!

*Т. Заманова*

*6.02.1991*

Здравствуй, Ибрагим ага!

Большой привет самому, супруге, детям и внукам. Получил твое письмо, даже два, и то, которое со стихами, со статьей, которую, я полагаю надо дать, как эпилог. Есть одна просьба. Ты обращаешься только к татарским писателям написать, рассказать о тех страшных годах. Это – малая аудитория, может быть, достаточное для издания на татарском языке. Поскольку мы собираемся подняться на союзный уровень, надо расширить географию. Хорошо бы этот обзац развить дальше, сказать, что о сталинщине уже писали Е. Гинзбург, К. Икрамов, В. Шаламов и т.д. и т.п. и ты следишь за этой темой, перечисли еще десяток фамилий, а затем завершим, что таких свидетельств злодеяний должно быть сотни, тысячи, это будет наш общий памятник тем, кто не вернулся.

Ты раньше времени не пугайся поездки в Казань. Я это написал на всякий случай, вполне возможно, что тебе не надо будет ехать, все согласования, которые, видимо, неизбежны в такой большой работе, мы решим по почте. Печатать я заказал три экземпляра. Один сразу, думаю частями, это зависит от машинистки, буду посылать тебе, два сдаю в Татиздат, пусть читают, рецензируют, четвертый повезу в Москву, в «Советский писатель», покажу работающему там Ямилю Мустафину, предварительно я с ним разговаривал. Стихи я твои отдал Н. Беляеву, если хорошо получится, может быть, удастся их встроить в книжку.

Я имею ввиду не те, которые были напечатаны в татарском варианте, а новые, по-моему, они длинноватые, как поэмы. Словом, посмотрим.

Книгу я твою не сокращал, наоборот, за счет более подробного описания некоторых сцен, которые мне показались черезчур киносценарными, она даже прибавилась. Словом, сам увидишь. Я предлагаю поменять названия некоторых глав, тоже посмотришь. Вдруг второй вариант окажется более точным. В Москву еду четырнадцатого ноября, вернусь – двадцатого. В этот же срок вышлю рукопись и тебе. А там обсудим, что делать, как работать дальше.

С приветом, обнимаю.

*(М. Зарипов)*[1].
*30.10.1989*

---

[1] Марсель Зарипов (1931–2017 ) – язучы, тәрҗемәче, журналист.

Добрый день, дорогой Ибрагим ага!

Шлю наилучшие пожелания, сообщаю отчет. Как всегда, человек предполагает, а черт располагает. Я рассчитывал, что к началу завершу всю работу, на самом деле только приблизился к завершающему рубежу. Один раз я своими пальчиками перепечатал книжку, сделал что-то подобие подстрочника. Затем сидел над подстрочником, сам же перепечатал этот текст. Теперь надо, думаю, в последний раз шлифовать книгу перед сдачей ее в издатедьство, что печатать могла машинистка. Фарваз Миннуллин торопит, говорит, что в феврале книгу надо сдавать в призводство. У меня есть несколько вопросов, которые я хотел бы уточнить.

1. В книге пишется, что в Казанской тюрьме были первые секретари Татарского обкома партии Лепа и Разумов. По-моему, это исключено. Разумов уехал в Сибирь в 1934 году, арестовали его в Москве в 1937 году, в Москве же его в 29 октября 1937 года расстреляли. Мог ли он попасть в Казань?

2. Я понял, что церковь, превращенная в тюрьму, представляла из себя одну большую камеру. Так ли это?

3. Хотел бы уточнить – как зэков доставили в лагерь Антибес – на машинах, пешим ходом? Если пешим, то ты был безногим, как тащился в таком виде? Если так, то это надо подчеркнуть особенно.

4. В книге излишне много повторяющихся эпизодов, ситуации. Так, поет Зифа Басырова, поют зэки в вагонах, есть специальная глава «Соловей».

Очень много рассказов, пересказов легенд, сказок, это встречается в шести-семи местах, что, по-моему, явный перебор. Надоедает бесконечные «ха-ха-ха», открывающиеся-закрывающиеся двери, многовато обращений к стихам, я думаю, их надо сократить. В газете «Социалистик Татарстан» я прочитал твои последние статьи. Думаю, из них надо сделать эпилог: «От имени тех, кто не вернулся», дать страниц 12–15, исключив предисловие А. Гилязова.

Книгу твою запланировали в объеме 16 печатных лист. Я думаю, как в этот объем втиснуть отсутствующие в книги куски «Тринадцатое число», «Неотправленное письмо», «Узник с рыжой бородой», для этого книгу надо было планировать 20 листов. Текст твой при переводе не сократился, по-моему, наоборот, даже несколько прибавился, потому что мне пришлось иногда вместо

одного слова использовать пять. Словом, при последней отделке буду думать. Хотя кроме «Рыжей бороды» в книге уже есть чернобородый болгарин, а история с врачихой похоже на историю с медсестрой, опять похожие ситуации. Работал в основном по книжке. А в книжке нет куска, как ты отчитывался на конференции, это тоже интересный материал. Видишь, сколько нам еще надо втиснуть в книжку, удастся ли?

И последнее. В заключении есть место о доносчике, который писал Ставскому […]. Поминать это место без фамилии не имеет смысла, а фамилия заметно усилит смысловую, художественную силу идеи. Сообщи, что делать: вписать фамилию, убрать это место? Вот такие пока замечания, пожелания. Жду ответа.

*С приветом М. Зарипов*
*12.10.1989*

Здравствуй, дорогой Ибрагим!

Долго задержался с ответом, сидели, редактировали книгу. Наконец, кончили, сейчас ее читают корректоры. Скоро, видимо, отправится в типографию. Хорошо, одна гора с плеч. Хочется уже чего-нибудь светлого, не каторжного. Для тебя, твоих родных, друзей, в том числе и мне приятная новость – твою «Колыму» выдвинули на Тукаевскую премию. Список нынче большой, кроме тебя есть Р. Миннуллин, Р. Ахметзянов, М. Магдеев, С. Садыкова. А. Монасыйпов, но будем надеяться на доброе. М. Магдеев написал в комитет письмо, что он просит снять свою кандидатуру и поддерживает тебя. Такие вот пироги!

Большой привет от Нежметдиновых. Они приехали из санатория. По поводу их сочинения об отце я сказал, что они написали ни то, ни се: для газеты – длинно, для книги – коротко, по-моему, им не понравилось, мне показалось, что они обиделись. Таков он горький хлеб литературы, удач всегда меньше, чем обид. Вот и все пока новости. Так что к дню рождения Тукая, приезжай, может, тебе повезет с премией, отметим.

Привет всем твоим, крепко обнимаю и целую. Из Москвы радостных сообщений пока нет.

*М. Зарипов*
*10.03.1990*

Хөрмәтле Ибраһим Сәләхов!

Сезгә хатлар язучылар күп икән. Мин дә бер хат язарга булдым. Гаепләмәгез, зинһар. Иң элек сезгә китап язган өчен бик зур рәхмәтләр укыйм [...]. Үзем турында. Мин 1907 елда Уральск шәһәрендә тудым, сугыш ветераны, инвалид. «58» минем ике абыемны да харап итте. Әнием дә 10 ел йөреп кайтты. Мин дә (алынмасам да) 1956 елга кадәр кысу, кимсетүләрне баштан уздырдым. Минем Г. Тукай белән туганлыгым да бар. Тукай һәм минем әни бер атадан туганнар (Мөхәммәдгариф). Шул сәбәптән минем хәтердә Г. Тукай турында күп кенә истәлекләр сакланган, әлбәттә, әниемнең сөйләүләре буенча. Тәнкыйтьлерәк булганга ахрысы, язуларымны бик басмыйлар. Хәерле булсын. Язуларымны балаларыма калдырам.

*Зур ихтирам белән укучы Хөсәен Зәбиров*[1]
*Казан*
*5.01.1989 ел*

Хөрмәтле Ибраһим абый!

Шатлыгымны уртаклашып, котлау җибәрүегез өчен зур рәхмәт! Быел Сез шигырь бәйрәменә килә алмадыгыз, сәламәтлегегез мөмкинлек бирмидер инде. Юкса, күңелегез белән Казанда, шигырь бәйрәмендә, Тукай янындасыздыр… Ибраһим абый, Казанда чакларыгызда Сезгә бик якын килеп, сөйләшеп китәргә кыймый идем, Сезне һәрвакыт бик күпләр урап ала, һәрчак сезне сораулар белән күмәләр, арыталар кебек тоела. Ә бик сөйләшәсе, якыннан сөйләшәсе килгән чакларым күп булды. Сезнең әсәрегезне журналда укып чыктым да (бер төн эчендә) таң атканда мендәремә капланып еладым. Чегән хатынының баласын тартып алган конвоирның явызлыгы, сезнең күз алдында Мөхтәр Мутин, Г. Нигъмәти, республиканың һ.б. татар зыялыларының һәлакәте, сезгә операция ясаучы докторның шәфкатьлелеге, Зифа Басыйрова моңнарының тайга урманнары аша сезгә барып ирешүе һ.б. һ.б.лар мине тетрәтте, тетрәтте генә түгел, бәгыремне кискәләде. Минем үз язмышым да шома гына юлдан узмаган бит.

[1] Хөсәен Габдрахман улы Зәбиров (1907–1991) – Казаннан. Г. Тукайның башка анадан туган апасы Газизә улы.

Мин 1928 елгы, минем әтине кулак дип Архангельскига сөрәләр, мин өченче кыз бала дөньяга артык булып туам, мине кешегә асрамага биреп (туган апаларына), төньякка китәләр, 2 яшьлек баланы салкын кышта алып китә алмаганнардыр инде. Шулай мин кешедә үстем, әти-әни дигәнне белмим. Үз көчем белән укып, үз көчем белән яшим. Менә шулай абый җаным. Шуңадыр мин сезне әти кебек күреп хөрмәт итәм. Күп авырлыклар күреп үстем. Хәзер инде алар артта калды әлбәттә, шулай да уйлыйм, ни фаҗигалар тудырган бу Сталин режимы. Ата улны, ана кызны, туган туганны белмәс хәлгә китереп, пыр туздырган. Менә минем язмыш кебек язмышлар белән ил тулган.

Ибраһим абый! Казанга кайчан килерсез икән? Бу килүегездә мин Сезнең янга кыюрак киләм, мөмкин булса, бер сөйләшеп утырасы иде, Сезнең килүне белми генә калмасам ярар иде.

Сау-сәламәт булыгыз!

Исәнлектә күрешергә насыйп булсын.

*Сәлам белән Гөлшат Зәйнашева*[1]

*29.04.1991*

Исәнмесез хөрмәтле Ибраһим ага!

Сезнең хатыгыз белән мин Тобол шәһәре татар культура үзәге директоры Әнәс абый Гаитов аркылы таныштым. Мин үзем бу шәһәрдә күп тапкыр булам, андагы татарларның тормышы турында Татарстанның газеталарында яктыртам. Әйе, безнең Төмән һәм Тобол шәһәрләрендә татар культура үзәкләре ачылды. Безнең татарлар үзенең культурасын һәм тарихын белә башлады. Өлкә үзәгендә татарча телевидение һәм радио буенча тапшырулар башланды. Халык шундый тапшыруларны кирәкле диеп таба, яратып күрә дә, тыңлый да. Төмәндә татарча газета чыгарырга да уйлыйбыз, бер-ике сан өлкә газеталарга кушымта итеп чыгардык, бик уңышлы булып чыкты. Үземнең тормыш турында. Үзем Төмән шәһәрендә туып үстем, шул ук шәһәрдә журналистика бүлеген тәмамладым.

---

[1] Гөлшат Зәйнәшева (1928–2005) – шагыйрә, Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты, ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе.

Соңгы вакытта Төмәндәге «Татарстан яшьләре» газетасының хәбәрчесе буларак, үткән ел корпункт совет күләмендә ачтык.

*Ихтирам белән Минзат Ибәтуллин*[1]
*Төмән*
*10.11.1989*

Исәнмесез хөрмәтле Ибраһим ага!

Яңа ел бәйрәме белән сезне. Сезнең язган хатыгызны мин алдым, бик зур рәхмәт. Бу хатта үзебезнең татарлар тормышы турында таныштырып китәсе килә. Әйе, безнең Төмән өлкәсендә торучы милләттәшләребезнең тормышы үзгәреп бара, күпме культура үзәкләре ачыла башлады. Күптән түгел безнең Төмән шәһәрендә өлкә татар-башкорт культура үзәге ачылды. Аларга яңа бина бирелде. Шәһәребездәге типографиядә татар телендә афишалар һәм башка басма продукция чыга башлады. Безнең өлкәдә торучы татарлар Төмән өлкәләрендәге СССРның халык депутатларына обращение язган булган иде. Башкортстанда татар телендә «Кызыл таң» газетасын КПССның Үзәк органы диеп чыгарырга. Безнең идеяне Свердловскида татарлар поддерживать итә. Чит өлкәләрдә торучы татарлар белән Мәскәүгә хат җибәрергә, яисә СССР ның халык депутатлары аркылы да җибәрергә була. Сез дә безнең идеяне якласагыз иде, ничектер сорап Мәскәүгә Верховный Советка хат җибәрсәгез иде. Үзем инде январь Мәскәүгә җыенам, шул ЦКга кереп чыгармын. Өлкәбездә газета чыгару мәсьәләсе бик кыен, эшләүче типографиядә кадрлар юк. Аларны тапсаң, фатир кирәк, әле безнең хәлебез кыен положениеда. 1930 елларда шундый татар телендә Үзәк газеталар булган иде.

Менә шушының белән тәмам.

*Ихтирам белән Минзат Ибәтуллин*
*Төмән*
*25.12.1989*

Әссәламегаләйкем хөрмәтле Ибраһим абый!

Сезгә һәм барча гаилә әгъзаларына безнең икебездән дә Сезгә карата олы ихтирам белән сугарылган сәламнәребезне юллап, Сезгә озын гомер, әгъзаларыгызга сәламәтлек теләп, җавап хаты язарга утырдым.

---

[1] Минзат Ибәтуллин – Төмәннән, газета хезмәткәре, милләтпәрвәр.

Ибраһим абый!

Алдагы хатымда балалар турында язып, Сезнең дә гомерлек яраларыгызга кагылганмын. Гафу итүегезне үтенәм?!

Әйе, кайвакыт бу кешенең дә кайгысы бармы икән дип уйлыйсың. Ә инде сөйләшә башлагач – аның синекеннән дә артык була.

Сезгә хат язганчы «Тайгак кичү»не укып чыккан идем инде. Тетрәндергеч. Җыламыйча уку – мөмкин түгел. Тәмәке элдерергә чыгып йөгермәгән булсагыз – Сез дә юкка чыгасыз икән. Нинди тарих юкка чыгып, без ачык авызлар шулай «яшәп» йөриячәкбез икән.

Минем бер, үзем өчен зарарлы, начар ягым бар. Берәр әсәр укысам, үземне әсәрнең герое белән янәшә тоям, аның кичерешләрен дә йөрәгем аша үткәрәм.

Сезнең тапшыруны (телевизордан) ике мәртәбә карап үзегезне күреп торсам да, күз алдымда 25 яшьлек җегет тәмәке кабызырга чыга кебек торасыз.

Ул урында исән калганга бик сөенгән идем.

Ибраһим абый!

Хатны шул кадәр тиз, шундый матур, рәхәтләнеп укырлык итеп язуыгыз өчен зур рәхмәт сезгә! Мин дә шулай, акылдан язмас өчен тырышырмын. Миңа шундый киңәшләр биргәнегез өчен Аллаһы Тәгалә Сезнең барча теләкләрегезне тормышка ашырырга олы ярдәмен бирсен. Амин!

Күп язам, Сезнең алтындай вакытыгызны бушка үткәрәм шикелле. Ял иткән вакыт укып җибәрергә дә ярар...

Авылыбыз «Мулла иле» диеп атала... Авылыбыз зур (400 гә якын хуҗалык), матур, таза тормышлы. Халык та бай яши. 2 чакрымда гына Зөя суы ага, матур урманлык.

Сәламәт-таза тормышлы кешегә терлек азыгы хәзерләргә дә уңай. Шуңадыр халык бай яши, мал-туар күп асрыйлар. Авылда клуб, мед. пункт, кибет, 10 еллык мәктәп бар.

Элек авылда өч мәхәллә иде. Бер мәчетне сүтеп МТСка алып киттеләр. Манараларын төшереп, берсен клуб, икенчесен балалар бакчасы ясадылар. Балалар бакчасы дигәне генә утырып калды.

Хәзер яңа бакча сала башладылар. Балалар бакчасы яңасына күчкәч искесен (мәчетне) сорап карарга дигән уй йөри әле башта. Ничек булыр.

Сезгә ихлас күңелдән исәнлек-саулык, гомерләрегезгә бәрәкәт, авыр хезмәтегездә бетмәс көч, уйлаган эшләрегезнең тормышка ашуын теләп, кабат сәлам белән, *Ильяс улы Гыйлаҗетдин (Идрисов)*[1]

*22.01.1989*

Исәнмесез, Ибраһим абзый.

Сезнең үзегезгә, гаиләгезгә миннән һәм безнең гаиләдән күп сәламнәр җибәреп калабыз.

1. «Хәсрәт дәрьясы»на килгәндә... Күренүенчә, мин бераз тырышкан булдым, ләкин аңлый алмаган сүзләр һәм җөмләләр дә калды әле. Сез озак көттерми генә төзәтеп җибәрерсез дип калам. Уфа һәм Казан матбугатына җибәрербез. Әмма, минемчә, әлегә башкорт дөньясы гына түгел, хәтта татар дөньясы да ул китапны аңлап, аны кирәгенчә бәһаләрлек дәрәҗәгә барып җитмәгән әле. Шуңа да бит Тукай бүләге Айдарга тәтемәде. Ул китап киләсерәк буын китабы булыр мөгаен. Нишлисең бит, дөнья шулай: Айдар алгарак чыкты, халкыбыз аның артыннан куа алмый. Шуңа да, мәкаләгез бик көчле булган хәлдә дә, ул күп басмаларда дөнья күрер дип уйламыйм. Ялгышсам, бик яхшы булыр.

2. Үзебездә бастыра алсак, вакыт тапсам, «мәшһүр әдибебезнең ялгышуы» кебегрәк сүз әйтер идем. Чөнки бездә, күпләр уйлаганча, башкорт белән татар арасында гауга юк, ә бар шундый бер вазгыять: татарны азаккы 40–50 ел эчендә эш аты итеп кенә кулландылар. Кемдер сүз әйтсә, имеш, татар гауга куптара. Әлеге дәүләт башында утырган түрәләр шушы – татарны кол хәлендә тоткан вазгыятьне саклап калырга тырышалар. Шул ук вакытта бер сүз дәшмә. Сүз чыкса – татар алама, татар дәгъвәче…

3. Алла боерса, үзебез Уфа татарлары бүләге оештырырга уйлыйбыз. Һәм, минемчә, Айдар ул бүләккә беренче тиң дәгъвәче...

4. Бездәге сәяси һәм милләтара хәлләр ифрат катлаулы. Аларны чишү турында уйлаучы да юк ахрысы. Менә озакламый Ю.С. сессиясе булырга тора. Конституция проекты каралырга тиеш. Әмма тел мәсьәләсен урап үтәргә уйлыйлар ахрысы. Чынында түрәләр эчкерсез сәясәт алып бару урынына халык белән качыш уйный, бигрәк тә татар халкы белән.

---

[1] Гыйләҗетдин Идрисов – ТР Яшел Үзән районының Мулла Иле авылыннан, И. Салахов әсәрләрен кызыксынып укучы.

5. Хөкүмәт даирәләренә, шулай итеп, бернинди ышаныч юк. Бөтен ышанычыбыз икътисади тормышның базар системасына күчүенә. Минемчә, шул вакыт татар көчәнергә тиеш. Бүгенге авыр тормышта да инде татарча радио сөйли башлады.

Ярар, Ибраһим абзый. Сезгә тазалык һәм дә яхшы кәеф теләп калам. Күкчәтау һәм Казакъстан турында да бераз язсагыз икән. Шул ук вакытта безнең гәзиткә дә кыска-кыска әйберләр җибәрсәгез, без бик шатланыр идек.

Сәлам белән Сезгә зур ихтирам белән караган

*Кадерле (Имаметдинев).*
*13.08.1992*

Хөрмәтле Ибраһим дустыбыз!

Синең хатыңны алганга күп кенә вакыт узды шикелле. Син килгән вакыттагы кебек, өйдәге борчылулар һаман дәвам итә. Гөлсем хәлендә зур үзгәрешләр юк. Киләчәк нәрсә күрсәтер. Табигать кануннарына буйсынмыйча булмый. Картлык, үлем хәсрәтләре котылгысыз инде алар. 83 яшькә җитәрмен дип уйлаганым да юк иде, җителде бит.

Синең «Имәннәр тамыр җәйгәндә» китабыңны тапшырдылар. Бик кызыксынып укыйм. Татар халкының героик уйларын һәркем белергә тиеш иде. Бик вакытлы, актуаль тема алып, аны дөньяга чыгарган өчен сиңа зур рәхмәт.

Хәзер «культличности» корбаннары турында ачыктан-ачык яза һәм сөйли башладылар. Әле бүген Горбачев та үзенең 70 еллыкка багышланган тантаналы җыелышта сөйләгән докладында объектив дөрес бәя бирде ул чорларга. Шулай булгач, синең матбугатка биргән әсәреңне курыкмыйча чыгарырлар дигән фикергә килдем мин. Иншалла, аны бастырып чыгарырлар.

Ибраһим! Мин үзем сирәк булса да район газетасына язгалыйм. Хәзер күп укып булмый, күзләр начарлана бара.

Хуш, Ибраһим дус, исән булсак, җәй көне күрешербез. Хәзер юлны беләсең инде.

*Сәлам һәм ихтирам белән Гөлсем, Фатих (Исхаковлар)*[1].
*3.11.1987*

---

[1] Фатих Исхаков – журналист; М. Җәлил турында истәлекләр авторы. «Социалистик Татарстан» газетасының 1975 елның 25 июнь санында Ф. Исхаков турында мәкалә урнаштырылган. И. Салахов белән озак еллар хат алышканнар, язучыга Г. Мөхәммәтшин турында да истәлекләр җибәргән.

Хөрмәтле, борынгы дустыбыз, каләмдәшебез Ибраһим!

Соңгы елларда, Синнән уч төбедәй хәбәр булмагач, бик борчылып тора идек. Ниһаять, «Яшь ленинчы» газетасында синең Галимҗан Мөхәммәтшин турындагы истәлекләреңне укыгач, бик куандык. Әле исән-сау яшисең икән. Истәлекләрең, беренчеләрдән булып, бик вакытлы, тирән эчтәлекле, мавыктыргыч булып язылган. Яшьлекнең Казан чорларын искә алып, Гөлсем белән икебезнең дә кайнар яшьләребез күзләрдән мөлдерәп агып төштеләр. Шундый аккан күз яшьләре генә күңелдәге пошынуларны йомшатуга ярдәм итә ала бит. Күңелле яшьлекләрнең гомере кыска булды шул. Күпләр гөнаһсыз һәлак булды, күпләр, исән калсалар да, рухи һәм физик гарипләнделәр.

Галимҗан турында истәлекләр язуың һәм мәрхүмнең исемен-иҗатын гади мисалларда сурәтләвең өчен Сиңа аның туып калган улы Йолдыз да, туган-тумачалары да сиңа чын күңелдән рәхмәт белдерәләр.

Күптән түгел Казанда язучыларның конференциясе булып узды бит. Син катнашкансыңдыр, билгеле. Ул елларда редакциядә эшләүчеләрдән бер син генә исән яшисең шикелле. Касыйм Шәйхетдинов Ватан сугышында вафат булды.

Галимҗанның энесе Госман исән, Казанда яши. Йолдыз исә тарих фәннәре кандидаты, Академиянең Казан филиалында өлкән сотрудник булып эшли. Үзебез искечә шул Атабай авылында яшибез. Мин 80 гә, Гөлсем 76 га җитте. Җиләк-җимеш бакчасында эш белән мавыгып көн үткәрәбез. Икебез дә Ватан сугышы ветераны. «Күкчәтау далаларында»ны бик күп кеше бездән алып сокланып укыдылар һәм сиңа рәхмәт белдерделәр.

Сиңа сәлам һәм ихтирам белән исәнлек-саулык, озын гомер, иҗатында яңа уңышлар теләп,

*Гөлсем, Фатих (Исхаковлар)*
*19.06.1984*

Хөрмәтле Ибраһим дустым!

1988 ел. Мин бик зур борчылу һәм олы кайгы-хәсрәт кочагында көннәремне үткәрәм. Мәшәкате дә күп булды билгеле, күмү, өчесен, җидесен, кырыгын уздырулар һ.б. үзем дә озак кына авырдым, больницада яттым. Баш авырту, әйләнүгә мөбталә булдым.

Жасмин, пионнар чәчәк атулары да күземә күренми, ә Гөлсем бәгърем аларны күрә алмыйча җир куенында ята.

«Язмыштан узмыш юк», диләр, мин үз башымда кичерәм. Бу турыда сиңа хат яздым микән, хәтеремдә юк. Синең «Тайгак кичү» роман-хроникаң татар халкы арасында зур сенсация булды. Бу – тарихта классиклар сафында урын алыр. 4–5 саннардагын тирән кичерешләр белән укыдым. Больницада ятканда «Казан утлары»ның 4 нче санын бик күпләр миннән алып укыдылар. Ул тәмуг утларыннан синең исән калуыңа һәм шул вакыйгаларны хәзерге һәм киләчәк буыннар өчен язуыңа миннән һәм халкыбыздан сиңа зур рәхмәт Ибраһим. Ул заманда яшәсәм дә, смута елларын баштан кичерсәм дә андый вәхшилек, ерткычлыкларны күзаллап булмый иде бит.

Аерым өзекләрен системалы рәвештә радио аша да тапшырып баралар. Чынбарлыкны чын мәгънәсендә язып узган смута елларының сәхифәләрен халкыбызга җиткерүең өчен тагын рәхмәт сиңа.

Романың бик тирән эчтәлекле, әдәби яктан да бик матур итеп язгансың. Менә 5 нче санны көтәбез түземсезлек белән.

Гаиләңә һәм үзеңә сәлам белән нык исәнлек, киләчәктә яңа иҗади уңышлар теләп, ихтирам белән *Фатих агаң.*

*17. 04. 1988*

Хөрмәтле Ибраһим абый!

Көн артыннан көн уза, дөресрәге гомер дигән нәрсә уза, туза. Ләкин, кеше дигән хайван, уйлый белсә дә, ул хакта уйламаска тыръша – мин дә шулай.

Хәзерге заманның пычрак сәясәте һәм әшәке сәясәтчеләре дә тыныч кына, туасы көнгә өметләнеп яшәргә бирмиләр.

Үзенең бүгенге көне белән килешеп яшәгән халык хайван да була алмый торгандыр.

Инде бераз гадиләштерим: сезгә октябрьдә бер хат язган идем инде, шуңа бусын бик үк җәелеп язмыйм. Үзебез шулай бер көе генә яшәп ятабыз. Әллә ни үзгәрешләр юк.

Сезнең хакта күптән түгел «Казан» журналында сәхифә басылып чыкты, фоторәсем белән. Шаһинур белән «Татарстан»га тулы бер битлек басма әзерләп ятабыз, яңа елдан соң дөнья күрер дип уйлыйм.

Сберкнижкагызда бер миллион артыграк акча тупланды инде. Әле тагын бераз булса да язучылар союзыннан ала алмаммы дип торам, хәер алардан сәдака гына инде. Аннан соң, сезнең архив өчен дә түләргә тиешләр бит. Әле очына чыга алган юк. Кем түлисе билгесез. Бер миллион ярымнар (якынча) булыр дип уйлыйм. Әгәр, ходай кушып килсәгез, юлга акча эзләп йөрисе түгел, кайту ягы тәэмин ителгән.

Шамил мәсьәләсендә теге хатымда язган идем инде. Исмәгыйлев белән тагын сөйләшкән идем. Шкловский клиникасына бару өчен Казагстаннан рәсми юллама белән турыдан-туры Мәскәүгә барырга мөмкин, ди ул.

Ибраһим абый! Бу юлларны язу минем өчен бик җиңел түгел, тик шулай да әйтмичә каласым килми: [...] ул үзен шәхес буларак шактый югалткан (аны медиклар деградация личности дип атыйлар). Инсульт (яки паралич) нинди генә формада булмасын, озак сроклы була алмый, ул ике яклы. Шамил өчен иң нәтиҗәле дәва – тынычлык, кешеләр белән даими аралашу (аның үзен генә ялгыз калдыру булмаска тиеш) һәм даими нарко-психотерапевт, невролог күзәтүе, ләкин ул аны белмәскә тиеш, аның өчен бу врач гади терапевт булып тәкъдим ителүе шарт. Дарулар көчле һәм зур дозада булмаска тиеш (көчле дарулар ярамый).

Инде үземнән тагын өсти алам: аның йөрәге нык, эчке органнары исән. Димәк, аңа бу кризистан чыгу мөмкинлеге зур һәм өметле. Аңа бары тик кешелекле (психологик) ярдәм кирәк. Шкловский клиникасы нинди дә булса нәтиҗә бирүе икеле. Аны дәвалау үзегезнең янда, аның көче белән, сезнең көч белән барса, нәтиҗәлерәк булыр кебек.

Гайшә һәм Зәкия апалар белән сирәк кенә булса да сөйләшеп торам.

24 октябрьдә Дәү әнинең (Шаффа Нуриевнаның) туган көнен бик матур итеп, гаилә бәйрәме итеп кенә уздырдык. Сез әйткәнне үтәп, сезнең исемнән бик әйбәт бер коробка конфет алып бардым. Сезгә зур рәхмәтен юллыйм. Бик шатланды. Сәламәтлеге уртача. Бардадан, Гайшәападан хат алган иде. Ул да әйбәт кенә яшәп ята.

Фоат Галимуллин Бардада булып кайтты. Ул Гайшә апа белән күрешеп сөйләшкән. Бу хакта Фоат миңа да сөйләде һәм «Шәһри Казан»да аның күләмле генә җылы мәкаләсе басылып чыкты. Әлбәттә, бу язма сезнең исемгә дә бәйле.

Ибраһим абый, сез миңа үпкәләмәгез дә, ачуланмагыз да, хат язу минем өчен ниндидер бер җәза сыман. Әллә ялкаулык, әллә нәрсә шунда, кечкенә генә , бик кирәкле мәкаләне дә бер утыруда язмасам, айлар буе яза алмыйм, аннары инде аның кирәклеге дә калмый...

Барыгызга да күп сәлам һәм яңа ел котлавы. Яңа ел изгелекле, тыныч, уңышлы, шатлыклы булып, олы сәламәтлек алып килсен.

*Ихтирам белән Арнольд (Кабиров)*
*Казан*
*23.12.1996 ел*

Хөрмәтле Ибраһим абый!

Бик озак хат яза алмадым. Шактый вакыт исәнлек-саулык шәптән түгел иде...

Сүз башында хәбәр итәсем килә. Сезнең «Колыма хикәяләре»гез төрекчәгә тәрҗемә ителеп ята, аны Измирдан Мостафа Өнәр эшли, насыйп булса, озакламый басылып чыгар дип өмет итәргә була.

Казандагы архивыгыз бик әйбәт кулда, тәртипкә китерелә. Ә менә үзегездәгесен Казанга алу проблема. Зөфәр ул эшләр белән шөгыльләнми хәзер, башка бүлектә эшли. Архив белән җитәкчелек Марсель Әхмәтҗановта, ә ул докторлык яклау белән бәйле.

Әгәр сез минем белән килешсәгез, иң гади юлы – берьюлы булмаса да, Әския белән архивыгызны Казанга юллау, әгәр машина белән килүче булса, тагын да әйбәтрәк булыр иде, калганын мин үзем урнаштырыр идем, Әскиядә дә югалмас.

Ибраһим абый! Сезгә дөньялыкта иң каты авырлыкларны җиңәргә көч биргән тәкъдиргә таянып эш итәргә туры килә. Әлбәттә, бу бик күп һәм зур ихтыяр көче таләп итә. Тик, ничек кенә булмасын, Сезнең Баш иелергә тиеш түгел! Үзегезне, сәламәтлегегезне саклагыз, борчылмагыз...

*Ихтирам белән Арнольд (Кабиров)*
*Казан.*
*27.02.1998*

Ассалаумагалейкум Ибрагим абый!

Вчера (8.05) получил от Вас письмо-ответ, за которое очень благодарю и большое спасибо. А, сегодня 9 мая, день Победы! Я Вас поздравляю этим днем и желаю крепкого здоровья, счастья,

благополучия! Дай Алла Вам долгих лет счастливой жизни, а детям, внукам – счастья, только счастья.

«Имәннәр тамыр җәйгәндә» – да, это Ваша книга, но я его не прочитал. Вот, скоро схожу в райбиблиотеку и обязательно прочту. Имею свою маленькую библиотеку, всего 900 книг. Есть книги Г. Тукая, М. Жалиля, Г. Ибрагимова...

...Старый мусульманский кладбище и меня беспокоит. В прошлом году ездил туда, читал «кулхуалла» отцу и всем покойным. Могилу отца не нашел. Раньше стоял памятник (искуственный камень длиной 2 метра), а сейчас его нет. Видать, какой-то сволочь забрал на стройку, чтобы его руки засохли.

Да, я с Вами согласен, в прошлом году областная газета «Кокшетау» поднял вопрос о загородке этого кладбища, но сдвига нет. В этом году (недавно) опять появился заметка на эту тему. Смета, проект, указание есть, а вот дело с мертвой точки не сдвигается.

Я думаю, мертвых надо больше уважать, чем живых. У казахов есть пословица: «өлгендер риза болмай, тере байымайды». Действительно – так оно получается...

Немного о себе: жив и здоров. Работаю начальником ВОХР в Чистопольском хоз. Имею пятерых детей, все взрослые. Есть внуки.

Пишу заметки в «Кокшетау». Да, у меня отец был редактором в Рузаевском газете (1934–38 гг).

Вот, у меня пока все. До свидание. Желаю удачи и жду письма.

*С приветом Д. Казыбек*[1].

*1992*

Хөрмәтле Ибраһим ага Салахов!

Сезгә бу хатны Казаннан Республика фәнни китапханәсеннән методист Калимуллина Раушания яза.

«Казан утлары» журналында басылып чыккан яңа «Тайгак кичү» дип исемләнгән әсәрегезне без барыбыз да зур кызыксыну һәм тетрәнү белән укып чыктык. Әлеге роман-хроника безнең алда соңгы көннәргә кадәр караңгы бер билгесезлек булып кала килгән тарихның бу вәхшилек пәрдәсен ачып салды. Дөрес, газета-жур-

---

[1] Д. Казыбек – тумышы белән Күкчәтаудан, хатларында «Колыма хикәяләре»ннән алган тәэсирләр һәм авыл зираты хакында борчулары белән уртаклаша.

нал битләреннән, рус әдәбиятыннан бу тема инде безгә азмы-күпме таныш, шулай да үзебез укып белгән татар язучыларының ачы язмышы мисалында, үзебезнең җирлектә барган хәлләр турында булганга күрә бу роман безнең өчен аеруча якын. Без үзебезнең шул авыр чорда нахакка гаепләнеп газап чиккән галимнәр, язучылар, артистлар һәм башка талантлы кешеләребез турында бик аз беләбез икән.

Китапханәләрдә Сезнең әсәргә чират торалар. Һәркемнең укыйсы, романны барлык нечкәлекләре белән аңлыйсы килә. Мондый көчле әсәр иҗат иткәнегез, шуның белән бергә ачы хакыйкатьне ачып биргәнегез өчен зур рәхмәт Сезгә! «Тайгак кичү» романы быелгы «Казан утлары» битләрендә басылып чыккан әсәрләрнең иң яхшыларыннан булыр дип уйлыйбыз.

Шул уңайдан без үзебезнең республика китапханәләрендә китап укучылар белән фикер алышулар үткәрергә булдык. Соңрак, әсәр китап булып басылып чыккач, яңа китап премьерасы үткәрергә планлаштырабыз. Хәзерге вакытта премьераның сценариен әзерләүгә керештек инде.

Әгәр мөмкинлек булып Казанга килеп чыгарга уйласагыз, безнең китапханәгә рәхим итегез! Без барыбыз да сезнең белән очрашуга бик шат булыр идек. Ә хәзергә үзегезнең китап укучыларыгызга берәр сүз язып җибәрә алмассыз микән? Без ул сүзләрне премьераның сценариенда кулланыр идек.

Хөрмәтле Ибраһим ага! Без сезгә чын күңелдән нык сәламәтлек, күңел көрлеге, иҗади уңышлар, шатлыклар теләп калабыз!

Ихтирам белән республика фәнни китапханәсе методисты

*Раушания Кәлимуллина*

*Казан.*

*15.08.1988*

Дорогой Салахеддин, салям!

Спасибо тебе за письмо. Ты удивлен моим молчанием? Я очень много думаю о тебе и очень много рассказываю о тебе. Значит, както компенсируется то, непонятное для тебя «молчание».

Причина моего молчания тебе известно. Я как-то тебе писал. Ты по честному написал мне сам, что ты и Полотай забыли мою фамилию, после как я выехал из вашего лагеря. Я, прочитав твое письмо страшно обиделся и не стал писать. И ты делаешь вид, что

вроде не знаешь, за что я обиделся на тебя. Разве тебе не понятно?.. Я за твою поэму «Сыну, который не родился» получил «добавку». Может быть я потому и запомнил твою фамилию?.. Нет. Я считал тебя большим другом. Твои боли – мои боли, твоя радость – моя радость считал. Даже твоими руками плетенная корзина у меня хранится как семейная реликвия. Как память о друге. Я все время хранил тебя (твой образ) в своем сердце и вдруг ты пишешь: «Я забыл твою фамилию». Веришь ли – прошло несколько лет с момента получения этого письма, а не могу забыть и не могу освободиться от того сильного впечатления, кот. поразило тогда меня. Это слово «забыл». Конечно, для тебя может показаться излишней чувствительностью... Но я таков! Прими меня таким, какой я есть. Другого Каляева я тебе не могу найти. Вот так, дорогой Ибрагим!

Я тебя ценил и ценю как человека и как таланта. Всегда ты на своем месте сидишь в моем сердце. Пиши почаще. Только не ищи оправдания. А то рассержусь да приеду в гости доругаться.

Передай большой привет твоей семье.

*Твой Санджи Каляев*[1]
*1968*

Хөрмәтле Ибраһим ага!

«Казакъ тамырыма» исемле шигырегез, Казахстан җирлегендә бастыру өчен, әлбәттә, кулай шигырь. Әмма бездә андагы детальләр, фикерләр ул кадәр үк балкымас шикелле. Җирлек белән бәйләнешен күз алдында тотып, шулай диюем.

Сезгә сәламәтлек һәм яңа иҗади уңышлар теләп, ихтирам белән

*Ш. Маннапов*[2] *(«Социалистик Татарстан»).*
*24.11.1982*

Хөрмәтле Ибраһим абый!

Бездәге кульъязмагыздан чыгып, әсәрегез тематик планга «Колыма хикәяләре» дип кергән иде. Сезнең теләкне искә алып, аңа «Фаҗига-хроника» дип, өстәмә исем дә куйдык. Шул ике исем белән ул производствога төшеп китте. «Казан утлары» кыскарткан

---

[1] Санджи Каляев (1905–1985) – калмык язучысы, фольклорчы, тәрҗемәче, И. Салахов кебек үк төрмә газаплары кичергән шәхес.

[2] Шамил Маннапов (1938–2012) – язучы, ТРның атказанган сәнгать эшлеклесе.

бүлекләрне торгыздык. Хаталарның таба алган кадәресен төзәттек. Эпиграфны саkладык. Шуларның һәммәсе өстенә, Аяз Гыйләҗевнең кыска гына мәкаләсен дә бирдек. Шушы бер-ике ай эчендә китап булып чыгар, дип уйлыйбыз.

Ибраһим абый!

Нәшрият җитәкчеләре 1990 елда «Колыма хикәяләре»н рус телендә чыгару ягында. Сез шуңа ничек карыйсыз? Казанда рус теленә иҗат итүче Марсель Зарипов дигән язучы бар. Әдәби тәрҗемә белән дә актив шөгыльләнә. Ә. Еникинең «Әйтелмәгән васыять», Н.Фәттахның «Ител суы ака торур», В. Нуруллинның «Аккан су юлын табар» кебек әсәрләрен ул тәрҗемә итте. Тәрҗемәләрен мактыйлар. «Колыма хикәяләре»н рус теленә дә тәрҗемә итсә, Сез моңа ничек карыйсыз? Ризамы?

Шул сорауларга җавап көтеп, Сезгә сәламәтлек теләп,

*Фәрваз Миңнуллин*[1]
*1.08.1988*

Хөрмәтле Ибраһим ага!

Иң элек Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре дигән мактаулы исем алуыгыз белән кайнар котлыйбыз! Сезгә сәламәтлек, тыныч картлык теләп калабыз.

Инде килеп, «Канәфер гөле чәчәк атканда» дигән кулъязмагызның язмышына кагылган берничә сүз. Үзегезгә мәгълүм, безнең нәшрият Сезгә карата һәрчак игътибарлы булырга тырышып килде. Соңгы берничә елда дөнья күргән «Имәннәр тамыр җәйгәндә», «Колыма хикәяләре» һәм «Черная Колыма» дигән китаплар шул хакта сөйләсә кирәк.

Ләкин соңгы кулъязмагызны дөньяга чыгару катлаулырак булыр һәм озаккарак сузылыр төсле. Ник дигәндә, тормышлар, шул исәптән безнең нәшриятның хәле дә нык начарланып китте. Берике ел элек кенә тоннасы 240–300 сум торган кәгазь хакы бүген 25 мең сумга күтәрелде. Өстәвенә типография чыгымнары да көннән-көн арта бара. Бүгенге көндә, ничарадан бичара дигәндәй, без штат кыскарту, китап басуны нык киметү кебек күңелсез эшләр белән шөгыльләнергә мәҗбүрбез. «Канәфер гөле чәчәк атканда»

[1] Фәрваз Миңнуллин (1934–1994) – әдәбият тәнкыйтьчесе, язучытәрҗемәче.

язмышын озакка сузуның төп сәбәбе шул. Дөньялар рәтләнеп, нәшрият иркен сулыш ала башлауга без аны файдалану хакында уйлаячакбыз. Билгеле, әсәрләрне яңадан бер кат карап чыгарга, урыны белән нык төзәтергә, шомартырга туры киләчәк.

*Сезгә иҗат уңышлары теләп, Ф. Миңнуллин*
*7.02.1992*

Ибраһим абый, саумысез!

Хатыгызны алдым. Романның дөнья күрә башлавына без барыбыз да шат. Ә исем мәсьәләсенә килгәндә, бәлки Сез хаклыдыр, әмма хәзергесе моментта безгә аның җисеме кыйммәт.

Инде тәрҗемә мәсьәләсе. Һичшиксез тәрҗемә итәргә кирәк. әгәр татарчадан турыдан-туры тәрҗемә итәргә теләүче бар икән, бик яхшы. Андый булмаса, юлга-юл тәрҗемә иттерү эшен Союз үз өстенә ала ала.инде Әсгать Хәмидуллинның теләге бар икән, минемчә, безнең официаль хат язып торуыбыз артыктыр. Әгәр ул тәрҗемә бөтен ягы белән камил булса, аны бастырып чыгару мәсьәләсендә Союзның, әлбәттә, катышы булачак. Үзебез башлаган эшне ахырына кадәр җиткереп булыр дип уйлыйм.

Без монда исән-имин генә яшәп ятабыз. Яңарырга тырышабыз. Сүзебезне кычкырыбрак әйтергә өйрәнәбез. Хак сүз турында әйтәм. Хак булмаганын кычкыручылар һәрвакыт табыла.

*Саулык-сәламәтлек теләп М. Туфан*[1]
*8.05.1988*

Ибраһим абый, исәнмесез!

Хатыгызны алганга айдан артык вакыт узса да җавап яза алмадым, гафу итегез. Сәбәпләрнең объективы да, субъективы да бар.

Сайланма әсәрләр мәсьәләсе бүлектә каралачак. Сезнең идарәгә язган үтенечегезне шул чакта наширләргә тәкъдим итәрбез.

Кульъязмагызны укып чыктым. Куркыныч булып китте. Алла сакласын кабатлануыннан. «Казан утлары»на Ренат Хариска бирдем. Ул укый. Фикерен әлегә белмим – укып чыксын инде. Минемчә, аны тагын бер кат карап чыгып (әдәби эшләнеш ягын) матбугатка тәкъдим итеп буладыр. Кирәкле, гыйбрәтле әсәр.

---

[1] Туфан Миңнуллин (1935–2012) – күренекле татар драматургы, язучы, публицист, җәмәгать эшлеклесе.

Кичә Педагогия институтында Галимҗан Нигъмәтинең 90 еллык юбилеен билгеләп үттек. Шунда мин аның кызына (Йолдыз Нигъмәтуллинага) Сезнең турыда, сезнең Нигъмәти белән күрешүегез турында истәлекләрегездә искә алуыгызны сөйләдем. Бик кызыксынды. Сезне күрәсе килүен һәм әтисенең язмышы турында күбрәк ишетергә теләвен әйтте.

Менә шулар, Ибраһим абый.

*Сезгә саулык-сәламәтлек теләп, Туфан*
*28.10.1987*

(*Хатның икенче ягына И. Салахов «Истәлекләрне кулъязмада иң беренче булып укыган кеше Туфан Миңнуллин булды. Аннан соң Ренат Харис укыды. Менә шушы иптәшләр аңа – матбугатка юл ачтылар. Рәхмәт яугыры аларга» дип язып куйган.)*

Уважаемый Ибрагим Низамович!

С добрым Имантавским приветом к Вам Сергей Ив. Михайлов. Ибрагим Низамович, Ваша поездка в Имантав и наши переговоры о создании историко-этнографического музея на базе Имантавского сельского Совета, даром не прошли, они дают свои результаты. К новому 1990 году завершается строительство двухэтажного здания, куда переходят сотрудники сельской администрации.

Специально был проведен исполком с участием представителей райкома партии и облисполкома Чебаковой Валентины Алексеевны. В районной и областной газетах опубликовано обращение к населению по сбору необходимых экспонатов. Так что лед тронулся!

Уважаемый Ибрагим Низамович, мы очень надеемся на Вашу инициативу, авторитет и весомую помощь в этом благородном мероприятии.

Ждем ваших рекомендаций и совета.

От имени организационного совета музея *Михайлов С.И*[1].

Всего доброго.

*1.12.1989.*
*с. Имантав*

---

[1] С. Михайлов – Казакстан Республикасы Төньяк Казакстан өлкәсендәге Имәнтау авылында тарих-этнография музеен оештыручыларның берсе.

Сәлам Казаннан!

Әссәламәгаләйкүм. Кадерле вә мөхтәрәм Ибраһим ага!

Сезгә, хәләл җефетегезгә, улларыгызга вә оныкларыгызга һәм дә туганнарыгызга кайнар сәламнәр юллап, сезнең һәмәгезгә саулык-сәламәтлек, тазалык-иминлек, бәхетле, тигез-тату тормыш һәм күңел көрлеге-тынычлыгы теләп, тирән ихтирам илә сезнең Шаһинур Мостафин.

Кадерле Ибраһим ага! Сез мине күптәннән ачуланып-аптырап ятасыздыр. Сездән, башымны иеп, гафу үтенәм: сеңелкәшем Илгизә фаҗигале төстә вафат булганнан бирле хат язарга дип бер мәртәбә дә каләм-кәгазь алганым булмады. Үземне һич тә мәҗбүр итә алмадым. Үз хәләтемне үзем дә аңлый алмадым. Гаҗәеп нәрсә икән ул психология дигән нәрсә...

Ниһаять, менә бүген, Ходай Тәгалә рәхмәте һәм ярдәме белән, кулыма каләм алдым һәм беренче эш итеп Сезгә хат-мәптүк язарга утырдым. Сез бер дә үпкәләмәгез, ачуланмагыз: мин нәкъ элеккеге Шаһинур. Очрашкач, моңа үзегез дә ышанырсыз. Һәм сезнең юбилейны үткәрү мәсьәләләре буенча да монда – Язучылар берлегендә һәм сезнең, һәм безнең уртак дуслар арасында оештыру эшләрен башлап йөрдем... Соңыннан, бу хакта сүз чыккач, официаль рәвештә бу эшне үз җилкәмә алдым...

Юбилей дигәннән. Сезнең юбилейга, сезнең мәҗлескә Казаннан һәм башка төбәкләрдән түбәндәге иптәшләр-дуслар барырга теләк белдерделәр:

Казаннан: Аяз Гыйләҗев, Мөхәммәд Мәһдиев, Фоат Галимуллин, Шаһинур Мостафин.

Чаллыдан – Рахмай Хисмәтуллин, Түбән Камадан – Азат Зыятдинов, Алабугадан – Тәбрис Вагыйзов, Менделеевскидан – Марсель Гимазетдинов. Болардан тыш, Кукмарадан Флера һәм Нияз Газизовлар, журналист һәм «Салават күпере» иҗат берләшмәсе җитәкчесе Рәшит Миннегалиев, кинооператор Гомәр Мөбарәкшин барырга әзерләнәләр безнең белән.

Боларга өстәп, Казаннан – Фәрит Хәбибуллин, театр студиясе артистлары һәм Уфадан Фән Вәлиәхмәтовның өч кешелек концерт бригадасы барырга әзерләнә. Әлбәттә, алар һәм без Сезнең юбилейга бәйле барлык очрашуларда һәм кичәләрдә катнашырга исәплибез. 25–26–27 октябрьләрдә Кызылъяр, Күкчәтау, Имәнтауда очрашулар үткәргәч, 28 октябрьдә кайтыр юлга чыксак та була инде.

Ибраһим ага! 21–26 октябрь көннәрендә Мәскәүдә СССР язучыларының IX съезды була, сез анда үзегез дә катнашмыйсызмы? Безнең язучылардан Аяз Гыйләҗев, Мөхәммәд Мәһдиев, Рахмай Хисмәтуллин анда катнашырга тиеш иделәр. Әгәр алар сезнең юбилейга килә алмасалар, Сез алар урынына кемнәрнең килүләрен теләр идегез – әйтеп, хат язсагыз иде, Ибраһим ага!

Яисә юбилей көнен бераз алга күчереп булмыймы? Хәер, монысы була да алмый торгандыр инде. Бәлкем, ул съезд булмас та әле. Шундыйрак фикер дә бар иде...

Ибраһим ага! Сезнең турыда Татарстан телевидениесе һәм радиосы һәм газеталар («Нур», «Чулман-Идел», «Социалистик Таттарстан», «Шәһри Казан», «Татарстан яшьләре» газеталары) зурлап тапшырулар оештырдылар, күләмле язмалар бирделәр. Үзем дә Сезгә багышлап бер әсәр язып ятам...

Сезнең белән очрашып сөйләшүләргә кадәр күп вакыт калмады. Исән-сау килеш очрашырга язсын инде һәммәбезгә. Ходай Тәгалә рәхмәтеннән һәм кодрәтеннән ташламасын. Амин!

*Сезгә зур ихтирам белән Шаһинур Мостафин*[1]
*23.09.1991*

Сәлам Казаннан!

Исәнмесез, кадерле Ибраһим ага! Сезгә, Маһинур апага, егетләрегезгә һәм киленнәргә вә оныкларыгызга дустанә кайнар сәлам!

Сәламнәрнең кайнары шулай ук Күкчәтаудагы барлык дусларга-танышларга!

Без әле һаман Күкчәтаудагы хисләр белән яшибез, анда үткәргән көннәргә кат-кат әйләнеп кайтабыз. Искиткеч якты, күңелле, мәңгегә онытылмаслык булды ул очрашулар! Сезгә һәммәсе өчен дә кайнар рәхмәт, Ибраһим ага! Казанга кайту белән без Сезне тагын Татарстан башкаласына чакырып хөрмәт итү уе белән яна башладык. Монда мин Сезгә «Татарстан ССРның атказанган мәдәният хезмәткәре» исемен бирү турында сүз кузгаттым. Язучылар, җитәкчелек хуплап каршылады. Фоат абый Галимуллин тиз арада Сезгә характеристика да язып бирде (гомумән, ул бик актив). Һәм бергәләшеп киңәшкәннән соң декабрь аенда Казанда очрашулар (Сезнең белән!) үткәрергә дигән фикергә килдек. 13 декабрьдә

[1] Шаһинур Мостафин (1948) – шагыйрь, прозаик, публицист, журналист.

Кави ага Нәҗмигә 90 яшь тулды. Шул уңайдан, анда сезнең дә катнашуны көтәләр иде.

Аннары Тукай музеенда, Татар милли мәдәни үзәгендә, Педагогия институтында, Балтачта, Менделеевскида, Мамадышта (безнең туган авылда мәчет ачу тантанасын үткәрергә иде исәп – сезнең катнашу бик тә мөһим!) һәм дә янә Чаллыда...

Барыбыз да көтәбез! Килегез генә, кадерле Ибраһим ага! Яңа елны да биредә үткәреп китәрсез!

*Ш. Мостафин*

*02.12.1991*

Хөрмәтле Ибраһим абый!

Сезгә хат язучы Гомәр Галинең (Галеев Гомәр Билалов улы – язучы, критик. 1900–1954) апасының улы – Мөбарәк Мусин.

Иң беренче, Ибраһим абый, сезне үткән бәйрәмегез – юбилеегыз белән котлыйм, сезгә нык исәнлек, бетмәс изге эшләрегездә уңышлар һәм шатлыклар телим.

Ибраһим абый, үткән ел абыйның 90 еллыгына (июнь аенда) Ленин мемориалында выставка оештырганнар иде, ә апрель аенда быел Республиканың Министрлар Советы карары белән безнең туган авылның (Г. Гали дә шунда туган – Буа районы Иске Тинчәле авылы) урта мәктәбенә Г. Гали исеме бирделәр. Бүгенге көннәрдә мәктәптә даими эшли торган музей оештыру башланды (колхоз хисабыннан). Репрессиядә булуына карамастан, материаллар (фото, документлар, хатлар) әкренләп кенә җыела инде. «Г. Гали турында» дигән бүлектә сезнең «Колыма хикәяләре» дә тиешле урынын алыр дип торабыз.

Ибраһим абый, шушы уңай белән сезгә булган үтенечләргә күчәм. Бәлки сез абый белән еш аралашмагансыздыр да, шуңа карамастан сездә нинди дә булса фотолар, документлар юкмы? Музейда урын алырлык әйберләрне сез миннән яхшырак беләсез инде. Әгәр төшерергә кирәк булса, мин аларны тиз генә төшереп кире җибәрер идем.

Икенче үтенеч (мин әле сөйләшә алмадым Р.Мостафин, бигрәк тә Гариф Ахунов белән) алар булышлыгы белән безнең якташларның «Г. Гали истәлекләре» дигән кечкенә генә китап чыгарырга исәпләре бар. Шуңа да сездән берәр материал булса, яхшы булыр иде.

Ярый, Ибраһим ага, мин шуның белән бетерәм. Вакытыгыз булмаганны белеп торсам да, хатымны җавапсыз калдырмассыз дип ышанам.

*Мөбарәк Мусин*
*6.11.1991. Казан*

Уважаемый Ибрагим Низамович!

Я получил ваши рассказы и «личные» дела. Сожалею, что поздновато познакомился с вашим творчеством. Но ничего. Теперь будем нагонять упущенное время. Книгу отрецензировали. Отзыв хороший, да я и сам кое-что прочитал. Надо срочно найти переводчиков. Кого вы сами рекомендуете? Зарипова я знаю. Он сделает неплохо. Асхад Хамидуллина не знаю. Но отрывок из повести сделан неплохо. Смотрите сами. Но, честно скажу, лексика бедновата, язык суховат. Я буду требовать высокой художественности! Вижу, что автор несколько скован авторским текстом.

Напишите мне полнее сколько ему лет, кто он такой, кем работает – для заключения договора.

Что переводит Марсель Зарипов? Думаю надо издать листов 202. Повесть (повести) и рассказы. Надо продумать, кто напишет предисловие: показать творчество и … биографию. А может быть вы сами сделаете? «от автора». Кто лучше вас знает вашу биографию? Никто. Объем не ограничиваю. Обрисуйте обстановку 37–38 годов, лит. среду, встречи, темы разговоров. Не надо замыкаться в своем круге. Показать пошире и глубже. Продумайте. Заодно и состав сборника решите. Вышлите фото на титул книги. Вот вроде и все пока.

Будьте здоровы. Над чем работаете? Если что есть нового – давайте присылайте. Желаю удачи. *Искренне Ямиль (Мустафин)*[1]

*9.08.1989*

Здравствуйте, дорогие мои друзья Ибрагим, Магинур!

Какая радость, большое счастье иметь связь с друзьями своей юности! Нас было много, кипевших в одном котле юных, незабываемых дней. Остались трое: Ты, Гиззат и я. Получив адрес Нури от Гиззата, я написал ему инкогнито, письмо. Он прислал, не поняв меня, спрашивал, откуда я его знаю, кто я. Я открыл-

---

[1] Җәмил Мостафин (1927) – язучы, рус телендә яза, Мәскәүдә яши.

ся. Видно, я для него был мелкая сошка, не пожелал продолжать знакомства. Потом мы встретились у Гиззата с Нури и его женой. И все равно гордыня не позволила ему опуститься до копавшихся только в кишках людей.

Теперь и Гиззат вышел из строя. Я рад и тому, что у него умная жена. Магира пишет, Гиззат все время ищет дом «Мы уходим из дома, до усталости бродим и приходим домой спать вечерами».

Какую страшную судьбу прошел ты, дорогой мой друг, вытерпел муки и написал о тех черных днях миллионов невинных, безвинных людей. Я читал твою судьбу в смятении, болью в сердце, хотя никогда не страдал сердечным недугом. Тысячи и тысячи людей прошли через мои руки раненых воинов, защищавших Родину от фашистских варваров. Я спокойно. Я знал анатомию и физиологию человека досконально. И это потому только, может быть, что пять лет в институте я тянул пятерых прикрепленных казахов. Рассказывая, зубря им сам изучил анатомию и физиологию человека и это помогало мне спасать жизнь безнадежных, казалось искромсанных раненых. Учиться, стать врачем-хирургом изрек Глагольев. Может помнишь такого врача в Кокчетаве? Его сын учился со мной в девятилетке, я был у них дома, мастерил с Евгением Глагольевым что либо для его двух сестер-младших. Тогда-то сам врач высокой квалификации сказал: у тебя парень мастеровые руки, учись на врача – хирургом будешь знаменитом!... Знаменитость с меня не получилось, но жизней я спас много за все годы войны. Получал много благодарных писем, что я спас им жизни. Никогда я не терялся, не сжималось мое сердце от боли перед страданиями истерзанных людей. Но, вот читая твою эпопею не выдерживал, откладывал. За что, почему были брошены на муки, гибли миллионы неповинных людей? Какие подлые были в НКВД, какие инструкции получали от Сталина или совсем от другого центра, враждебных советскому строю, желающих любыми путями разрушить Совстрой? Арестовывали свет общества, невинных, преданных строю людей. Сталин с одной мыслью (какой) поднимал страну на вершины развитости, готовил отразить нападение фашизма. Уже 4.07.1941 выступил по радио, объявил всему миру «Наше дело правее, мы победим, враг будет разбит». Тиран, душегуб и, уверенность что народ поднимется по его призывам. За родину, за Сталина поднимались люди в атаку, разгромили страш-

ного, мобилизовавшего экономику на себя фашистского изверга. Фашистские Армии подошли к Москве, окружили Ленинград, не сумели разбить их. Аэростаты, истребители наши не пропускали фашистов летать над этими городами. В то же время наши бомбардировщики бомбили Берлин. Читаю книги Жукова, Василевского других генералов и удивляюсь, как, почему, умело руководил военной победой тот же изверг, душегуб Сталин. А теперь выросшие, воспитанные при Совстрое, поднявшись до вершины власти Генсек КПСС Горбачев решил разрушить СССР, стал господином миллионером. И таких оказалось куча, народ обречен на голод. Могучая, неделимая, спаянная сверхдержава мирно разрушена, междоусобная война кругом, слезы и горе, дикая скачка цен, неудержимая инфляция, распродажа госимущества. На все лады трубя о необходимости ускорить внедрение рыночных механизмов закупорили сосуды экономики, резко замедлило обращение денег. В войне мы знали нехватки спирта, перевязочных материалов, все текло из рога изобилия, не голодали, были одеты. Боеприпасов поступало мощно, получали 100 граммов водки и табак и жалование все офицеры. Откуда бралось все это богатство? После войны снижались цены на все, появилось много товаров и достаточно продуктов. Сахару я покупал всегда мешок – 50 кг. Сейчас 1,5 кг. На месяц, по 0,5 кг. Крупы, макаронных изделий.

С юных лет я начал изучать марксизм-ленинизм, с первых же выступлений Горбачева понял в какую пучину бросает он страну. Теперь компанию Горбачева смели, новая компания ничего пока не добилась сносного. Вся российская промышленность оказалось без средств. Бурный рост цен и длительная задержка зарплаты и невозможно получить деньги в Сбербанке, на что купить продукты? Чем кормить семью. Все так запутано, какой логикой, каким учением пользуюся теперешние руководители? Я в полнейшем замешательстве.

В 1931 году за казенный счет из Петропавловска нас 4 девушек, 2 парня направили в Алма-Ату, на курсы по подготовке в вузы. Я видел 3-4 ряда рефрежератора с гниющим мясом. Кто допускал это. Нас в столовой кормили так по талонам, что моей одной порцией наедались с Гиззатом вдвоем. В стране был голод. В 1933 год снова голод. На улицах Алма-Ата умирали голодные. В марте 1934 года мы студенты собирали истощенных людей на

вокзале, пропускали через бани, все их завшивленную одежду сжигали, людей одевали в рубахи, брюки, телогрейки. Кто, какие силы вызывали голод: разорения, массовый смерть людей?... В 1938 году каждую ночь сотрудник НКВД вызывал меня в кабинет, требовал, что я сознался, что сын Баязитова Багава, что присвоил фамилию Мухаметова. Нелепость такого не давал мне возможность доказать. Следили за каждым моим шагом. Кто были эти нквдышники, откуда, почему получали указания сажать людей неповинных в тюрьмы? Меня выручила жена начальника НКВД, поступив с патологичекими родами. Не будь меня, она бы умерла. Оставили меня в покое. Арестовывали безвинных людей десятками. Какую цель приследовал Сталин? Всю жизнь думаю, разгадать не могу. Зимой 1941-42 года наша дивизия стояла на обороне в Карелии, на левом берегу реки Свирь. На правом берегу финны. Начали посылать воинов через реку взять языка 15–20 чел. Лед как стекло. Финн кричит – русь, не ходи, стрелять буду: половина убитые, половина раненые отползали назад, языка не взяли, полк огалили. Забрали ездовых, санитаров из моей медсанроты стрелками. Кто, зачем давал такие нелепые распоряжения? Какие силы, зачем сейчас творят нелепости не понимал тогда, не понимаю сейчас. Не по карману купить конфеты своим правнучкам. Имеем дачу, фрукты, ягоды там пропадают, варить варенья нет сахару. Для своих детей и внучек в карманах всегда были плитки шоколада, конфет…

Дорогой мой друг Ибрагим! Мое сердце горит в огне с 1937 года, то затихая, то воспламеняясь. Не могу понять, почему Сталин поднимал страну на великую высоту, учил детей бедняков и в тоже время уничтожал лучших, способных работать на благо общества. Откуда, от кого получали свои жестокие инструкции тюремщики, почему все надсотрщики в тюрьмах, концентрационных лагерях были крайне жестокими, бесчеловечными? Кто их инструктовал, ставил на должности. Ты, в своей книге ярко описал эпизоды в разных тюрьмах, лагерях жестокости направленные на явное истребление, не выживание людей, миллионов невинных честных могущих строить, поднимать страну от нищеты к богатству. Такие как я никогда не могли бы стать врачами, инженерами, учеными без советского строя. Кто давал указания таких как мы уже подготовленных тем же государством за казенный счет арестовывать и уничтожать? Дико. Гиззат тоже учился за государственный счет, ра-

ботал честно, хорошо, успешно – арестовали, издевались над ним и направили на гибель. На фронте я тоже видел случаи, как приказывали идти на явную смерть… О таких вещах пишет и А. Греко, в своей книге «Годы войны». Несмотря на все жестокости Сталина страна была поднята, велика, непобедима. Как, какими путями добивался этот жесткий варвар великих побед, сплоченность великой страны? Почему Горбачевская команда решила разрушить страну? Все эти дела не связуются, где правда, где ложь? Если нас учили за казенный счет, наших правнучат будут заставлять работать у господ богачей за скудное пропитание.

*Н. Мухаметов*[1]
*Воронеж. 1992*

Хөрмәтле Ибраһим ага!

Повестыгызны («Казан утларында») укып чыктым. Тирән һәм авыр тәэсир калдыра. Рәхмәт. Бик кирәкле теманы күтәрдегез. Үз халкының моңын-зарын, чыдамлыгын, рухи ныклыгын туплаган яңа шәхес тарих мәйданына килеп басты.

Повестьның беренче бүлегендә этием – Галимҗан Нигъмәти турында да берникадәр мәгълүматлар бар. Мин эти турында китап язам һәм, билгеле, һәрбер «кайнар табадан» алынган факт ифрат кыйммәтле, чөнки, белгәнегезчә, аталарыбыз истәлеген билгеле елларда ерткычлар кырып ташларга, яндырырга, юк итәргә тырыштылар. Мин ул чакларда биш-алты яшьлек малай гына идем.

Минем Сезгә үтенечем: әгәр авыр булмаса, мөмкин кадәр Галимҗан Нигъмәти турында белгәннәрегезне, күргәннәрегезне язып җибәрсәгез, күп рәхмәтләр укыр идем.

Китапны рус телендә язам. Татарча язу минем өчен кыенрак (рус мәктәбендә укыганга күрәме). Язуымда андый-мондый тел кытыршылыкларын тапсагыз, кичерегез.

Үзем турында: Язучылар союзы әгъзасы, тәнкыйтьче, университетта рус һәм көнбатыш әдәбиятларын укытам.

Үзегезгә сәламәтлек һәм яңа иҗади уңышлар теләп калам.

*Энгель (Нигматуллин)*[2]
*9.07.1988*

[1] Н. Мөхәммәтов – И. Салаховның яшьлек дусты.
[2] Энгель Нигъмәтуллин (1930–2001) – әдәбият белгече, тәрҗемәче.

Здравствуйте, Ибрагим Низамович!

Давно собираюсь Вам написать, но все откладывала со дня на день. Прежде всего поздравляю Вас с праздником Великого Октября. Как Вы себя чувствуете, как здоровье? Что нового в Вашей жизни, что Вас волнует?

Немного о своих делах. Мы создали в школе КИД. Я руковожу секцией «Красных следопытов». Решили бороться за присвоение клубу имени Ахата Атнашева. Я побывала в Степняке, познакомилась с Быченко Валентиной Андреевной (она хотела Вам написать). Это завуч по внеклассной работе в СШ № 1. Они собрали кое-какой материал, но трудно с документами, подтверждающими эти сведения. Сейчас мы живем в ожидании приглашения от них, чтобы лучше познакомиться с их материалами.

В Степняке проживает племянница Ахата, в Курганской области – сестра, а в Казани живет его брат. Из Казани мы получили письмо, члены совета дружины пишут нам о том, как они провели лето, чем занимались, как их награждают за активную работу. Мы им позавидовали.

1-ю четверть мы закончили неважно. Класс у меня не из легких, требует много внимания и усилий. Но самое главное: не умеют, а вернее не хотят действовать самостоятельно. А они уже в 6-ом классе. Учу их и сама учусь вместе с ними.

Ибрагим Низамович! Вы летом ездили в г. Казань. Поделитесь, пожалуйста, своими впечатлениями. Что нового Вы узнали об Ахате? Ибрагим Низамович, напишите, пожалуйста, можно ли нам написать Рафаэлю Мустафину. Адрес Вы выслали, но я что-то не решаюсь. Думаю, что вы, писатели, народ очень занятой и наши письма будут отрывать Вас от дела. Вы, наверное, с ними встречались. Напишите, пожалуйста, не будет ли ему наше письмо помехой.

Всего Вам доброго. Ждем Вашего ответа.

*Н. Новокшонова*[1]

*4.11.1986*

---

[1] Н. Новокшонова – укытучы, Күкчәтаудан. Ә. Атнашев (1917–1944) хакында истәлекләр җыю, исемен мәңгеләштерү буенча зур эш алып бара.

Хөрмәтлебез Ибраһим!

Яңа ел белән котлаулар, мул итеп әйтелгән изге теләкләр кабул ит.

8 декабрьдә язган хатыңны миңа соңлап ирештерделәр, чөнки беразврачлар белән аралашып алырга туры килде... Ә аңарчы «Казан утлары»на язганын мин иҗат йортында чакта, Ялтага җибәргәннәр иде. Аннан җавап язу, гомумән, мөмкин булмады – шул ук табиблар белән алыш-бирешле чак иде. Читтә нинди яңалык булсын ди...

«Күңелле китап» турында фикереңне газетаның әдәбият-сәнгать бүлегенә биргән булганнар. Кичә кереп әрләдем үзләрен. Җай табарга вәгъдәләре булды, әгәр тиз арада басмасалар – Хамматовка әйтәчәкмен.

Инде өченче китап (нәкъ шундый ук, ләкин бүтән Хуҗа Насретдиннарны сөйләтеп) эшләнеп бетә, озакламый нәшриятка бирәчәкмен (әмма анда чират хәзер бары тик 1985 елга гына инде...). Эзләреннән йөреп, нәтиҗә ачыклангач хәбәр итәрмен, һәрхәлдә язмаң эзсез «югалмас» дип беләм. Мин бит усаллана да алам!

Мине котлый аласың: әле шушы арада гына Мәскәүдән миңа персональ (союзнореспубликанский) пенсия билгеләүләре турында хәбәр килде, журналны тапшырып яткан көннәр бара. 1983 елның январь-февраль айлары саннарын гәрчә быел мин имзалап төшергән булсам да, аларын инде яңа «баш» (Ренат Харис) күзәтеп чыгарсын дигән карарга килдек, чөнки «ирекккә» ашкыну көчле! Архивны актарасы, барлыйсы бар, басылмаган, очланып җитмәгән әйберләрне якты дөньяга чыгарырга кирәк. Ял итеп йөрисе дә күптән инде зарыктырды... Юбилейдан соң да (60 яшь тулу) бер ел эшләдем бит инде. Союзда (димәк журналда да) ялкау-үшәннәр, дәрәҗә сөючеләр генә күп хәзер, конкрет эш кешеләре бик аз. Нигә дип шулар өчен көчәнергә?..

Романыңа хәерле юл һәм язмыш телим.

Килеп чыккач күрешербез, аңлашырбыз әле.

*Ихтирам белән Зәки (Нури)*

*12.12.1982*

Хөрмәтле Ибраһим ага!

Бу хатны сезгә озак еллар дәвамында сезнең хезмәтләрегезне дөньяга чыгарып килгән Я. Халитовның бүлмәдәше – Таһир Нурмөхәмматов дигән мөхәррир яза. Хәтерләсәгез, Казанга килеп

чыккан бер уңаегызда мин сезнең белән бер-ике сүз алышкалаган идем. Хәзер исә мин сезгә менә нинди максат белән язам: Сез тоткынлыкта чагында кичергән газапларны кичергән Сәрвәр апа белән минем беркадәр якынлыгым бар: әдәби тәрҗемәдә ул безнең остазыбыз, ә рухи яктан әниебез кебек кадерле кешебез. Шуңа күрә аның 90 еллыгы көннәрендә матбугатта берәр мәкалә язып чыкмасак, бу безнең өчен әдәпсезлек кебек бер нәрсә булыр иде. Ләкин бу бурычны үтәү теләге бигрәк тә сезнең «Колыма хикәяләре»гезне укыганнан соң туды дисәм, монда бернинди хилафлык та булмас дип уйлыйм. Сез үзегезнең китабыгызда Сәрвәр апага биргән өлешегез белән минем караңгылана төшкән күз алдымны яктыртып җибәрдегез. Без күп нәрсәләрне белмибез бит, сезнең кебек күпне күргән аксакалларның мәгълүматлары безнең өчен бай хәзинә белән бер бит ул. Сез үзегез белгәннәрдән янә дә кайбер нәрсәләрне өстәсәгез, мин Сәрвәр апага яңадан кайтып, әлеге мәкаләмне тулыландыра төшеп, аның турында очеркмы, документаль хикәяме сыман иркенрәк бер нәрсә язарга тырышып карар идем.

Сезгә хат язуымның икенче сәбәбе шул: мин «Колыма хикәяләре»н бик җентекләп укып чыккан идем. Безнең профессиябез шундый – әсәрләрне бер дә гади укучылар кебек тыныч кына, ләззәтләнеп кенә укый алмыйбыз. Укыган чагыбызда гел тегендимондый «чүп»ләр күзебезне кырып тора. Менә сезнең китапта да типография хаталары калгалаган әле. Кабат бастырганда аларны төзәтү фарыз булыр дигән теләктән мин аларны билгеләп барган идем. Насыйп булса, бер очрашканда, без аларны китапның сездәге данәсенә күчереп куярбыз.

Сезгә сәламнәр юллап калам һәм, әлбәттә, сәламәтлек белән иҗат уңышлары телим.

*Таһир Нурмөхәммәтов*[1]
*Казан*
*16.04.1981*

Сәлам Минзәлә якларыннан!

Исәнмесез! Сез ки Казахстанның Күкчәтау далаларында яшәүче Ибраһим абый – сезгә һәм дә гаиләгезгә тау кадәр сәламнәр

[1] Таһир Нурмөхәммәтов (1930–1999) – язучы-тәрҗемәче, журналист, ТАССР һәм РФнең атказанган мәдәният хезмәткәре.

җибәреп, корычтай сәламәтлек теләп калучы Минзәлә районы Дәвек авылы кешесе Нуруллин Өлфәт.

Ибраһим абый! Сезнең язган хатыгызны һәм хат эченә салып җибәргән фотогызны алдык, зур рәхмәт. Мин үзем 1936 елда туганмын, хатыным һәм дүрт балам бар. Бабабызны (әнкәйнең этисен) 1937 елда «дини агитация» алып бара дип атканнар, аның кабере дә билгесез. Без «Тайгак кичкән» вакытта «егылмыйча» калган корычтай ихтыярлы кешеләр белән горурланабыз. Ибраһим абый, үзем гыйлем иясе кеше булмасам да, җәмгыятебезнең җилгә каршы барганына һәм суның үренә акканына аптырыйм. Югыйсә, эткәйлә, әнкәйләр безнең телне ачтырганда ук алдашма, урлашма, кеше хакына тимә, дип ачтырдылар, ә без аларның киресен эшлибез. Ибраһим абый, мөмкин булса гаиләгез белән безгә кунакка рәхим итегез!

Безгә – Казахстаннан юл кыен түгел. Күкчәтау – Уфа – Бөгелмә – Чаллы – Минзәлә.

*Күп сәламнәр белән Өлфәт (Нуруллин)*[1]
*5.10.1988*

Ибрагим Низамович!

Если вы помните, я показывал Вам письмо Юсупова А.Г. из Татарии, который провел детство в 20-х годах в детдоме Кокчетава. К сожалению, разыскать бывших детдомовцев мне не довелось, поэтому очень прошу Вас написать тов. Юсупову и рассказать о том времени, о судьбах бывших детдомовцев, о нынешнем Кокчетаве все, что Вы знаете.

*Зав. Отделом пропаганды и агитации газеты «Степной маяк» Н. Обухов*
*(Елы күрсәтелмәгән)*

Уважаемый Ибрагим Салахов!

Прошу меня извинить за то, что рискнул обратиться к Вам и отнимаю драгоценное время.

Я пытался связаться с Вами по телефону, но не удалось, вот и решил написать. У меня к Вам большущая просьба – не откажите,

[1] Өлфәт Нуруллин – Минзәлә районы Дәвек авылыннан, хатларында репрессия корбаны булган бабалары язмышы белән уртаклаша.

посмотрите, пожалуйста мои расказы. У меня их три. Очень хочется знать мнение о них члена союза писателей.

Буду Вам очень и очень благодарен. При Вашем согласии – в случае если вы располагаете немного свободным временем – я их Вам перешлю. При чем время, т.е. срок для меня почти не играет ни какого значения.

Благодарю за внимание.

*С уважением Валентин Орлов*[1]
*Кокчетав.*
*11.12.1973*

Ассалаумағалайкүм, и внешне, и душевно красивый мой старший брат – Ибрагим аға!

От меня и Муршиды ханум зур салам сезгә, Маинур җингәйгә, вашим детям, внукам и внучкам.

Теперь несколько слов о нашем житье-бытье: видимо, вы слышали о том, что из жизни ушла Мария ханум. Я попал в трагическое, не только трудное, положение. У детей не суждено, конечно, мне жить. Тем боле я еще «молодой» джигит. «Жалгыздык – душпаныңа бермесин» – «не дай бог одиночества» гласит народная мудрость. Не мне повторить вам об этом.

Тағдыр-судьба заставила меня с кем-то присоединиться. Нашлась такая «молоденькая, миниатюрная» душевно красивая бойжеткен барышня Муршида (ее знала Марьям и я, когда она работала в милиции по определению Владимира Маяковского: «Моя милиция всегда бережет меня»). И через год с лишним мы состыкавались (извините, за такое непоэтичное сравнение). Теперь живем, хлеб-соль жуем. Дети наши на своих крыльях – двое кандидаты наук, один доктор наук, снохи – инженеры, дочери тоже.

Заканчиваю перевод Салтыкова-Щедрина (8 печ. листов) теперь со вчерашнего дня приступил к тәржиме вашей и моей любимой вещи (конечно, вы не поймите в другом аспекте, к переводу чудесного романа «Кокшетау далаларында») к слову так пришлось – ведь, бывший директор изд-ва «Жазушы» Дюсенбек Еркитев вынудил меня и Вас кышкарту-кыскарту-подсократить. Он нашел

---

[1] Валентин Орлов – Күкчәтаудан. Язучыга үз әсәрләрен тәкъдим итә, аннан киңәшләр сорап, хатлар юллый.

аргументы – дәлел. «У сильного – даже задница мельницу вертит» гласит народная поговорка. ..

Теперь вплотную приступил к переводу оставшуюся часть.

Зур рахмат за письмо и книгу.

От всей души поздравляем Вас с восьмым съездом писателей Казахстана и желаем самого крепкого-крепкого здоровья, большого счастья в жизни.

Пишите, звоните, пожалуйста. Приезжайте к нам в гости.

*21.04.1981.*

P.S. К вашему 70-летию выйдет однотомник. Бик әйбәт! Из «Төн кызы» мною переведены четыре вещи ваши – «Гомер дәфтәреннән», «Төн кызы», «Карлыгач» һәм «Диңгез ярында». Все отпечатаны. «Диңгез янында» был опубликован на страницах «Қазақ әдәбиеті» (сокращенный вариант).

Об этих ваших рассказах издатели в курсе. Я еще раз уведомил их. Будут включены они в том ваших произведений.

*Ө. Оспанов*

Ассалаумағалайкүм, бек кадірлі Ибрагим аға!

Сәлеметсізбе?

От меня и Муршида ханум большой привет всем вам.

С каждым днем приближается ваш юбилей. В связи с этим мне хотелось напомнить вам следующее:

1. Вы очень скромный человек. Это – хорошо. Но «жыламаған балаға емшек бермейді» – «Пока дитя не плачет, мать невразумеет» гласит народная поговорка. Поэтому о предстоящем юбилее необходимо ставить в известность областных руководящих органов. Даже можно, не стесняясь, зайти к секретарям обкома вплоть до первого. Ведь Вы воспеваете республику нашу и все время пишете на казахстанскую тематику. Ваш творческий труд должен быть достойно отмечен. Я имею ввиду большую правительственную награду, в крайнем случае – Почетная грамота Президиума Верховного Совета Каз. ССР. немедля надо подать свой голос. С искреннею душою так думаю я.

2. Сегодня был я в обеих редакциях. Редактор «Ленинского знамени» Рима Васильевна и зам. Ред. «Ление туы» Бахыт Мустафин радушно встретили эту чудесную весть. Решили выделить

просторную «жилплощадь» на страницах обеих газет. Будут опубликованы отрывки из трилогии «В степях Кокшетау» (новые главы из романа «Көкшетау даласында»). Просили, чтобы я написал статью в объеме 250–300 строк. Упорно готовлюсь сейчас я…

Вот и все пока вкратце.

Пишите, пожалуйста.

Отрывок и письмо получил я позавчера. За письмо зур рахмат.

*Ө. Оспанов*[1]

*13.08.1981*

Ассалаумағалайкүм, здравствуйте, Ибрагим аға!

«Игіліктің ерте-кеші жок», «Лучше поздно, чем никогда» гласит мудрая народная поговорка.

Моя скромная статья о Вас и вашем творчестве появилась, наконец, на страницах североказахстанских областных газет «Ление туы» и «Ленинское знамя». Я очень доволен и признателен редакторам этих, многоуважаемых газет. Одну из них давным-давно редактировал в течение десяти лет. Очень лестно отзываются главные дирижеры этих изданий о Вас.

Сегодня у меня өте куанышты шақ – изумительно радостный момент. Перед тем, как я начал писать это письмецо был звонок (телефонный). По счету – 19 ти. Большинство их – сыновья и дочери единокровного татарского народа. Бик шаф-әйбәт не только Вам и мне этот момент.

Высылаю вам несколько экз. обеих газет.

Только не забудьте, пожалуйста, пишите или телефон шалтыратыңыз – звоните.

Наш большой салам вашим домочадцам!

*С приветом Өметжан (Оспанов).*

*Кызылжар-Петропавловск.*

*9.10.1981*

Здравствуйте, Ибраһим дос!

Салям.

Ваше письмо от 29-го сентября получил. Искренне благодарю Вас.

---

[1] Өметҗан Оспанов – И. Салахов әсәрләрен казакчага тәрҗемә итә, мәкаләләр яза.

Здоровье мое не важнецкое. Давление очень высокое (200), головная боль. Вчера у нас был лечущий врач. Очень хороший специалист. По его совету сегодня с утра обходил все основные кабинеты поликлиники. Когда я вел разговор о поездке в Алма-Ату. Участковый врач сказал: «В таком состоянии вам нельзя ехать. Так что мне пока не суждено ехать туда. Придется повременить, поэтому убедительно прошу Вас, сами договоритесь об издании романа на казахском языке. Передайте, пожалуйста, тов. Жумабаеву большой поклон и зур салям от меня, пусть никому другому не даст миссию перевода вашего произведения кроме меня. По-моему, я неплохо выдержал такое трудное испытание. Думаю, что он не обидит меня и на сей раз.

Желаю вам доброго пути. По возвращении домой пишите, пожалуйста.

*Өметжан Оспанов*

*2.10.1984*

Здравствуйте уважаемый, Ибрагим Низамович.

Не знаю, получите ли Вы мое письмо. Я не знаю Вашего адреса, но молчать больше не могу. Я прошу Вас помочь мне. Я пишу рассказы, стихи, пишу в свободное от работы время. Но не знаю куда мне обратиться и попросить консультацию. Если Вы сможете помочь мне, то ответьте, пожалуйста, я буду очень рада услышать Ваше замечание и Ваш совет и критику.

*С уважением к Вам Парсукова Вера Павловна.*

*Кокчетав*

*1988*

Исәнме Ибраһим!

Сиңа һәм гаиләңә язгы сәлам! Синең язган хатыңны алдым, рәхмәт.

Миңа бу хатны язганда бер вакыйга искә төште дә сиңа язарга булдым әле. Ир кеше белән хатын-кыз дус булса, кешеләр әшәке уйлыйлар, шуннан чыгып сиңа түбәндәге вакыйганы язарга булдым.

Без яшь чакта (Мусадан аерылгач), Татиздатта эшләгәндә Нури белән (Арсланов) дус кына йөри башладык, бик күңелле үтте ул еллар! Көннәрнең берендә Нури Нәби Дәүлинең сүзен әйтте (интим

характердагы). Ә без беркайчан егет белән кызның саф дуслыгын җуймадык. Ләкин бу сүз үзенекен итте. Мин, хатын кешегә егет белән йөрергә ярамый икән, дигән уй белән, кешеләрнең сүзләреннән куркып, белмәгән-күрмәгән кешегә, ике бала өстенә тиз генә кияүгә чыктым. Үземнең юлыма киртә, иҗатыма тоткынлык, ә Нурины зур хәсрәткә салдым! Аны да, үземне дә бәхетсез иттем. Менә саксыз әйтелгән сүз нишләтте безне.

Безнең синең белән булган һәм бара торган дуслыкны да начар итеп күз алларына китерүчеләр юк түгел.

Ибраһим! Иҗат эше бик четерекле инде ул, бөтен кешегә дә ошатып булмый. Син нинди җәфалар күрсәң дә яза аласың әле, шуңа сөен. Менә минем башымда ничә еллар буе бер әсәр бутала, шуның кайбер главалары язылды инде, башкарып чыгарга көч җитми. Берничә еллар элек, Шәриф абый Камал әдәби йортта мин аңа үземнең мәшәкатьле тормышымны сөйләгәч: «Зәкия, көнгә бер генә бит әйбер яз, елына 360 бит була, үзе бер әсәр, китап» дигән васыять әйткән иде. Менә шул сүз һаман хәтердә, тик эшкә ашырырга көндәлек мәшәкатьләр бирми!..

*Сәлам белән Зәкүш (Зәкия Садыйкова)*

*27.03.1982*

Исәнме Ибраһим!

Сиңа һәм гаиләңә чуктин-чук сәлам!

Их, сиңа авыр чакларда сине якын күреп дус иткәндә – хәтерлисеңме, опера театрында Туфан абый белән икегез моңаешеп басып торганда Зәкиябану икегезне кочаклап күреште – шуннан соң гына язучылар килеп күрешә башлады. Бу күренеш минем хәтердә бик нык саклана....чөнки «кешеләр» үз өрәкләреннән курыккан кебек яшиләр иде...

Шул көннәрдә Туфан абый белән икегезне Яңа бистәгә чакырган идек. Сез сөйләгәндә минем әтинең күзеннән мөлдер-мөлдер яше тамганын күреп мин хәйран калган идем. Ул безнең сүз-әңгәмәгә кысылмаса да, Сезнең никадәр авырлыклар кичергәнне аңлап утыра иде.

Без сезне ничек онытыйк, ди. Иң әһәмиятлесе – без барыбыз да исән!.. Сау булыгыз.

*Зәкия (Гәрәевна) Садыкова*

*15.03.1985*

Исәнме Ибраһим!

Кичәгенә сиңа язган котлау хаты җибәргән идем, менә әле генә Туфан абыйга багышланган «Җырладым да уйладым» дигән тапшыру карадым! Санаулы минутлар бит бездә, аз, ярты сәгать чамасы булгандыр, ләкин безнең тапшыруларны шулай чикләргә туры килә инде, чөнки бик күп проблемаларны чагылдырырга тиешбез!

Туфан абыйның иҗаты күпкырлы, иң матур җырлары яңгырады... «Агыла да болыт агыла» – миңа аның безнең өйдә кунакта чакта сөйләгән истәлеген искә төшерде. Хәтерлимсез?! Теге йортта – карандаш очын тырнак астына яшереп алып чыкканын сөйләгән иде һәм бу җырны да шунда шул оч белән язгандыр дип уйладым. Иптәше Салиаскаровага багышланган җырлар яңгырады. Салиаскарова миңа трамвай көткәндә болай дигән иде: «Зәкия, син Туфан абыеңның кайтуын күрерсең, син аңа, минем аның мәхәббәтенә тап төшермәгәнемне әйт яме» – дип васыятен тапшырган иде. Әле мин бит икесе арасында өйләнешкәнче хат йөртә идем.

Менә икесе дә юк. Киләчәктә дә алар турында да роман язарлар. Мусаны да бит татарлар эзләмәде... Балаларын кире кагарга тырыштылар... Люцияне үз эшендә эшләтмәделәр, юбилейларына да дәшмәскә тырыштылар...

Туфан абыйның да тормышын җырлары сөйли...

Безнең татар язучыларының күбесенең тарихи йөзе әсәрләрендә генә кала. Юбилейларны баштанаяк язып киногa төшереп калдыру турында яшьләр уйламый. Язучылар союзында да бу мәсьәләдә бик мәшәкатьләнмиләр Ә бит иң беренче бу аларның бурычы бит!

Хуш, җавап яз!

*Зәкия Садыйкова*

*17.12.1985*

Хөрмәтле Ибраһим!

Шулай ук гаиләңнең һәммәсенә Бөгелмә районы Карабаш авылында туып, әле дә шунда яшәүче Гомәр Сәйфиевтән, Рәйсә Сәйфиевадан – кыз чактагы фамилиясе Сафиуллинадан сезгә бик күп итеп чын дуслык – бергә педтехникумда укыган сабакташларыңнан сәлам кабул итегез. «Тайгак кичү» романыңны укып чыгып синең исән-саулыгың турында белдек. Бу турыда романың аша, аны укып чыккач бигрәк тә ничек итеп интегү сукмакларың

белән таныштык. Син безне оныткансыңдыр. Мин әле бүгенгедәй Татар мәдәнияте йортына син, Айгистов һәм мин Сәйфиев Гомәр бергә барып Һади Такташ, Гадел Кутуйларның пәрмә-пәр килеп сүз көрәштергәннәрен, шигъри әсәрләрен көчле тәнкыйтьләүләре хәтердә. Ә кызлар, Рәйсәләр Александр Ключарев җитәкчелегендә җырга өйрәнеп йөргәннәр иде. Рәйсә сезнең белән бер чыгарылышта Техникумны тәмамлый. Мин 1 курсны бетергәч, укуны ташлап кайтып киттем. Техникумны тәмам итмичә, Урта Азиягә китеп вакыт уздырып йөрдем... Рәйсә белән 1934 елда тормыш башлап җибәрәбез...

Сугышта командир рота булып утлы еллар уздым. Көчле контузиядән аңым югалып «үлеп ятканмын». Аңым кайткан. Гөнаһ шомлыгына каршы шул чакта әсиргә эләгәм. Менә шул көннән мин тирән бәхетсезлек баткагына батам. Синең шикелле дөньяда булган вәхшилекнең камчысын татырга туры килде. Ачлыгын да, суыгын да – барысын да татыдым. Миңа бик аңлашыла синең күргәннәрең, барысы да минем баштан узды. Менә хәзер партиябезнең бик дөреслек, демократия үткәрүе барыбызга да шатлык-куаныч китерде. Мин моңа бик сөенәм. Көннән-көн тормышыбыз яхшыра. Бу бит зур бәхет дигән сүз. Безнең техникумның элеккеге укучыларының язмышын белмибез. Күпләребез сугышта башларын салды. Безнең гомергә шундый язмыш туры килде. Анан мин үзем дә Муса Җәлил оештырган яшерен оешмага кушылып, ниятләрен үтәгән кеше. Рушад Хисаметдинов, Фәхертдинов Гәрәф Мусаның беренче ярдәмчесе. Курмашев аркылы тоташкан идем. Монда язып кына бетереп булмый. Синең шикелле язучылык талантым һәм осталыгым җитми. Ярый, Ибраһим, вакытың сыйдырса, хат язарсың дип уйлыйбыз.

*Гомәр һәм Рәйсә Сәйфиевләр*[1]

*31.07.1988*

Привет, Ибрагим дорогой!

Получил твое письмо. Значит, мое еще не дошло. А то, я посылал тебе в Переделкино, пришло обратно с пометкой «адресат выбыл». В последнем письме я писал, почему не смог приехать в Москву и Переделкино. Конечно, очень и очень жаль, что мы не смогли встретиться.

[1] Рәйсә Сәйфиева – Бөгелмә районы Карабаш авылыннан. И. Салахов белән Казан педагогия техникумында бергә укыганнар.

Да-а! Издательские дела – это дорога адова. Сам по себе знаю. Мои две рукописи лежат в издательствах – и ни гу-гу! Может к моему столетию ответят. Но я упорный, ты знаешь. Пересижу и их! (не такого пересидели, помнишь?!) А коль пересидели «посаженного мудрого отца» то пересидим и редакторских зубров. Вот было бы хорошо на русском прочитать тебя. Жми на их чертей!

То о чем ты спрашиваешь я, конечно, заметки имею, но никому не говорю. Эта тема не сегодняшняя. Но она обязывает каждого честного человека написать о безвинных и умерших. Из тех наших многие поумирали. Остались ты и Санджи. Недавно я получил письмо от жены Топоркова. Помнишь, художник пожилой (с бородкой) такой был у нас в бараке? Иван Алексеевич Топорков. Я его всегда оберегал. Он мне потом напомнил (когда я у него был в Подмосковье) как я делился с ним пайкой. Я-то забыл совершенно об этом, а он со слезами на глазах рассказывал об этом жене. С Топорковым я все годы переписывался. Он стал слепнуть, старость подошла. Ходил, прилег, отдыхал немного, потом захрипел. Жена к нему – а он уже кончился. Легкая смерть, конечно. Лучше, чем мучиться, как мучился Владимир Августович Степун. Помнишь такого артиста МХАТа? Мы с ним у Алехновича были помощники «смерти». «Лепилы» назывались. Тогда уже старичок. После отбытия я бывал у него в Москве не раз. А если ты читал моего «Петушка», там в воспоминаниях о Жарове я упомянул Степуна. Он заболел раком и ужасно мучился. Никого из близких не было, и няньки до его смерти все вынесли из дому. Потом в Москве я нашел его сестру Попову и она рассказала как умирал Володя. Кстати, ты наверно знаешь, что Володя был внебрачный сын изобретателя радио А. Попова.

С Санджи я не переписываюсь. Один ты остался у меня Ибрагимчик. А кто еще есть живой? Может вспомнишь? Напиши. Я не мог найти артиста К.С. Эггерта. Он освободился. А когда мне рассказал М.И. Жаров, как он его приютил после лагеря и дал адрес. Я написал (в Омск) но уже поздно. Эггерт умер. Кто еще остался? В памяти я почти всех помню, а вот кто пережил то время не знаю.

Обнимаю, старина. Пиши! *Н. Полотай*[1].

*25.11.1981*

---

[1] Николай Полотай (1909–1987) – язучы, юмор һәм сатира остасы. Фондта аның И. Салаховка язган 20 дән артык хаты саклана.

Дорогой, дорогой Ибрагимчик!

Так рад, что получил от тебя письмо. Ей богу, переписка старых друзей – лучшая литература на старости лет. Вот никак не могу получить от тебя твои романы с русской транскрипцией. Но уверен, что получу когда выйдут. Ты помнишь Степуна и Алехновича? Степун умер неск. лет назад, а след Ник. Ник. где-то пропал. Знал только, что он после лагеря поехал в Казахстан и был врачом на какой то шахте, там изобрел какое то лекарство против силикоза. А что дальше – не знаю. Может тебе так лучше через мед. кадры узнать жив ли он? Очень бы хотелось встретиться с ним. Он то мне спасал не раз жизнь, как впрочем, и Володя Степун. Шашкина не помню. С Сандро давно прекратились переписка. А Алдана Семенова я не знал. Да, кстати, он сделал такое же неразумное дело как и Вас. Ажаев, который написал про лагерный труд, а выдал за свободный. Это обман и оскорбляет память погибших. Но возможно иначе Ажаев и не выпустил бы своего романа. Тут же постарался сделать все наоборот Константин Симонов и другие ассы.

Насчет юбилея твоего это дело лично каждого. От своих юбилеев я всегда убегал. На 50 сбежал в Киев. На 60 тоже сбежал. А на 70 согласился, но скромно. Никаких чтоб представителей от общ., и иных организаций, никаких слащавых речей, никаких наград... Сделали у себя в отделении тихомирно. Правда, пришли телевизионщики и киношники, снимали потом вечером по телеку показывали встречу и в Союзе и на телестудии. Газеты наши тоже дали подборки. Дал «Перець» шарж и шарж журнал «Украина», журнал «Жовтень» дал статью обо мне. «Крокодил» отметил о выходе моей юбилейной книжице «Киберетический петушок». Но и «Литературна Украина» дала портрет и поздравление, как и «Литературная газета» а Москве. Слава богу, никаких других вещей не было. Адреса подносили писат. организации и «благодарные» писатели и читатели. Но с твоим мнением могу согласиться. «Пусть!»... Я, кстати, тоже было отказывался от выступлений в кое-каких санаториях, а потом подумал, дай-ка раз схожу, пусть поаплодируют такому-то, которого раньше распинали. Получил удовлетворение. Но больше там не захотел выступать.

Ты не мог найти в Переделкино «Литературную Москву», ее просто нет такой. Есть газета «Московский литератор» и вот в ней

22 мая дали отчет о первом вечере афористов. Привожу один из абзацев статьи:

«Присутствующие много аплодировали тонкому остроумию наших мастеров меткого, лаконичного, изящного слова, вполне оценили конструктивный характер сатирич. осмеяния недостатков. Приведем здесь лишь несколько «Зоосюжетов» писателя Николая Полотая (Ялта): «Пил за нерест, закусывал икрой», «Медведь косолап, а заикнись?», «Прямо мыслил, минуя извилины», «Жирафа в шею не прогонишь», «Мошка, а взлетит – не дотянешься»...

Вот такая оценка. Президиум вечера прислал мне телеграмму с поздравлением и пожеланием скорейшего выздоровления.

Ну, что еще нового?.. Пока хвалиться нечем сатирикам, сам знаешь. С трудом пробиваю переиздание «севастопольских новелл» в Крыму, очень трудно, но все же надеюсь пробью к 84 году, не раньше. А юбилей Севастополя в 83 году. На 83 отказали, много заявок, нет бумаги и т.д...

А пока что будь здрав и весел дорогой Ибрагимчик! Обнимаю.

*Н. Полотай*
*15.12.1981 г.*

Салям, дорогой Ибрагим бек!

Получил твое письмишко. Рад до чертиков. Ты прав, «однонарников» становится мало совсем. Я даже не знаю кто еще жив?. Ты не знаешь?..

...переиздаю свои севастопольские новеллы. Но что хорошо. Киев предложил мне издать полностью Шута Балакирева (сто анекдотов)

А было издано только 70. Дописал новые 30. На уровне «Разбитой статуи». Пропустят ли цензурионы, не знаю. Но главное, что написал. Но это на... 85 год!

Избранное тоже вероятно на 85 год. Но хорошо, что есть надежда, а это прибавляет жизни!

Ибрагим чертяка, не пиши о том, что не доживешь. Не хорони себя заранее. Все будет в свое время, а сейчас надо быть как на фронте: убить могут каждый миг, а может и всю войну – ни царапинки!

Надо как можно больше написать, а главное не забыть и помянуть друзей по жизни. Об этом сейчас у меня забота.

Перешел на короткие рассказы-новеллы? Это говорит о твоем растущем мастерстве. Показатель – не роман, а короткая новелла, тут можно определить степень таланта. А роман мало о чем говорит. Хотя и говорит. Но в наш век романы читают мало. Это я убедился когда сам перешел с фельетонов и юморесок на афоризмы.

Вот такие дела, Ибрагимчик дорогой!

От жены Изиды Викторовны привет тебе и твоей семье! И от меня, естественно.

От «Индигирке» слышал еще в то время. Счастлив ты оказался, что не оказался в тот злополучный рейс на борту. Он-то перевозил нашего брата. Попал в штормягу. Нары сломались. Получилась каша...

Теперь усо!

*Твой Н. Полотай!*
*22.08.1982*

Дорогой друг Ибрагимчик!

Мой старый, верный друг из тех кровных друзей, которых уже почти никого не осталось в живых. Вот вспомнил, что твой день рождения и пишу. Кстати, ты какого года рождения? Кажется 1912, кажется немного моложе меня. Мне-то уже в этом будет 74… Как это говорят: дни идут, время бежит, а годы летят. Вот вспоминаешь свою жизнь и думаешь – какую же горькую иронию сыграла жизнь с нами!.. Ушла романтика, состарилис, и витоге один почти на один. Спасает близкие, жена, внуки/ не родные/сын/ не родной/ Но считаю их все же родными… И кому мы теперь другим нужны?.. Утешаешь свое самолюбие или честолюбие публикаций книг… Но и это уже прошло. Да и когда пишешь и публикуешь, то все равно как-то вроде пишешь их жене, самой близкой женщине, а не просто так, «в общем». Круг сужается близких и помыслы и идеалы сужается. Мы неисправимые романтики первых лет новой жизни остались вроде при пиковом интересе. Жизнь была исковеркана, выплывать после, как сделал наш «друг» Сандро – не хотца. Пишешь свое, что тревожит душу, оскорбляет человеч. достоинство, задевает за живое. Пишешь, чтобы помочь человеку стать человеком. Ты помнишь меня, я был чертовски лиричен по складу своей души. А вот увидел в жизни мерзлость, увидел как простые

хорошие люди страдают и терпят от всяких явных и замаскированных мерзавцев и стал на путь сатирика, чтобы и жизнь свою оправдать и совесть успокоить: мол, не без дела сижу… И вот уже годы к закату. Нет Ибрагимчик! Я не скулю, я еще не собираюсь «околеть», я дал обязательство дожить до 2000 года, и доживу! Но как-то когда друзей верных, с которыми можно было бы, как говорится, мыслить вслух почти не осталось. Многие «друзья» скурвились, ушли в материальные воды, омедведились, овеществились, стали матерыми мещанами, в которых дух перешел в вещь, голова в живот. А вот живет же, паразит!.. Мы там и то думали о нравственности, совести, справедливости, души прекрасные порывы не оставляли нас даже в самые тяжелые дни. А тут тебе – ему все есть: дом, дача, машина, хрусталь, ставка, оклад или престижная пенсия, а он, гад, потерял совесть, мыслит животом и ни о чем святом думать уже перестал. Вот что обидно!.. Потому я и в сатире зол очень. Но не всегда разрешают тех пронять. А это тоже не счастье. В общем, проходят годы, а удовлетворения нет. Так скучаю и так обидно что ушли в иной мир Володя Степун, наверное Николай Николаевич Алехнович, другие друзья по несчастью. Вот только с тобой из наших и переписываюсь и так мне ты дорог этим, что и сказать без слез не могу… Ну, письма письмами. А вот встретимся ли мы или уже нет – обидно думать. А мы же писали! Могли бы о многом поговорить по душам, по совести… И это уже отпадает, старые стали, поездки дальние не для нас. Меня врачи за Ялту не хотят выпускать. Ни в Киев, ни в Москву не поедешь. Да и там уже нет пержних друзей которых приобрел после второго пришествия на землю. Умерли новые друзья Виктор Ардов, Михаил Жаров, Володя Поляков, Микита Годованец, умерли почти все друзья-студенты, а из школьных осталось два-три человека. Когда вернулся, созвал их, так уже снова прошло тридцать лет!.. уже и не собираемся. Правда, иногда севастопольцы приезжают и переписываюсь с ними. Переписка это все же последняя ниточка что связывает памятью с далеким, милым, прошлым. И я ею дорожу. Словно рядом посидел… Вот три дня назад я подписал верстку своего сборника «Черноморская мадонна». Это переиздание моих двух книг севастопольских новелл «Хрустальная вода» и «Родные берега». О Севастополе, о друзьях детства и юности, о встречах после войны. Писал, ревел белухой, выпускал книги, читали друзья

и тоже плакали. В этом году в связи с 200-летием Севастополя экранизировали пять новелл и передавали и по Крымскому и по украинскому телевидению, трижды. И трижды, глядя на них, я ревел. Слезлив стал к старости, что ли. А ведь такую жесткую жизнь прожил. И писем уйму получаю от севастопольцев, и это меня держит как говорится, на земле, что простым людям доставил радость чтением. Это – совесть успокаивает. Может быть, это и есть то, что писателя оправдывает. А сейчас, после переиздания книги, жертвую гонорар за дополнительный тираж на восстановления севастопольского Грибка – такого дорогого памяти севастопольцев. Десять лет добиваюсь его восстановления и … никак. Денег нет. Вот и даю свои деньги. Все же, как патриот города, я должен что-то оставить в память о себе да и городу хорошо будет. Грибок старая реликвия города, по нему грустят все старые севастопольцы. А пробить стену бюрократизма ох, трудно!..

В общем, расписался дорогой Ибрагимчик. А кто его знает, каково тебе читать такие письма? И все же вера в тебя, в твою душу и сердце подсказало, что тебе именно и могу написать это письмо.

Будь здрав дорогой! Пусть беда не заглядывает к вам. Пусть жена твоя, дети, внуки живут счастливо, не знают ни тревог, ни бед.

Обнимаю, крепко целую.

*Твой верный старый друг Н. Полотай*

*Ялта*
*1983*

Дорогой мой Ибрагимчик!

Давно от тебя не было весточки. А сегодня я тебе пишу вот по какому поводу. Вчера выступал в санатории и до начала просматривал еженедельник «Литературная Россия» последние номера. И вот там вдруг наткнулся на некролог о ... Санджи Каляеве, нашем общем друге по... «по тому самому». Я помню. Как он всегда был рад и показывал письма от жены. Первые слова были Санджи «дорогой». Так вот на 78 году кажется (он родился в 1905 году) умер «после продолжительной болезни». Он же был народным, поэтому некролог был большим, содержательным. Конечно, о прошлом – ни слова. (теперь об этом не полагается писать) Да! Не стало еще одгого товарища Каляева народного поэта Калмыцкого народа. Жаль

очень, хотя я в последние годы с ним не переписывался. После моего «удивления» по поводу его стихов он, видимо, обиделся на меня и перестал писать. Что ж!. Он был своего рода фанатиком и не признавал ничего другого, как идеалистика. Пухом будет ему земля.

Как ты, дорогой мой Ибрагим! Стареем, черт побери. Я в свои 75 было совсем опечалился, стало сдавать сердце, завладела меланхолия, считал, что страшно утомился, неспособен ни к чему. Но вот вижу. Как некоторые доживают до 90 лет (мой друг Вадим Арбенин) и еще даже выступают. И писатели живут. Шкловскому было много лет. Каверину, Чуковскому, Бернард Шоу дожил до 93 лет. Так что рано сдаваться! Голова работает. Книги издаю. В прошлом году издал две книги. И в этом будут две (уже в печати). И к 80-летию мне определили «Избранное» Так что зачем клониться? Работать! «До дна последних донца!» И уже радуюсь когда день рождения: «Ага! Еще годик оторвал! Даешь еще год!» А раньше на день именин грустил. От сатиры ухожу, надоело, ничерта толку нет! Сатирики превратились в подхалимов. Никакой сатиры нет. И никого мы не излечиваем, все это наивность. Недаром и Зощенко и Чарли Чаплин разуверились в юморе и сатире, а им было куда меньше лет. Как твое здоровье? Чем себя поддерживаешь? Оптимизмом? А мой утренний девиз перед вставанием один: «Ты жив! Так радуйся Хайям!» Эту фразу мне сказал давно большой артист К.С. Эггерт, когда я проснулся на койке, после того как меня идиоты вынесли в морг (я болел сильно пиодермией), а Гаращенко подумал, что я уже «дуба» дал. Хорошо, Степун спас меня и вызволил из морга. А проснулся – на моей койке сидел Эггерт и улыбаясь сказал ту фразу Омара Хайяма: с тех пор он, как девиз утренний – а потом гимнастика йогов. Так и живу. Работаю по 16 часов в сутки. Пишу, пишу, пишу!..

Это моя жизнь и без писания не могу и дня прожить. Это спасает и держит на поверхности.

Обнимаю тебя, дорогой друг. Никого уже, кажется, в живых не осталось из наших. Может кого знаешь живым? Я всех растерял. Степун давно умер. Алехнович где-то пропал в Азии после освобождения.

Обнимаю. Привет твоей семье, всему твоему роду.

*Полотай*

*22.05.1985*

Сегодня у меня праздник, дорогой Ибрагимчик! От тебя получил письмо и вырезку газеты.

Поздравляю еще раз! 25 раз! Значит, угадал! Обрадовался статье (интервью). И письму, и твой разговор с секр. обкома. Когда мне стукло 60 лет, мне тоже предлагали писать о себе, просить награду. Я тоже отказался. Надо – пусть награждают, а меня не спрашивают. Не наградили, чему я был несказанно рад, иначе пришлось бы говорить «казенную ответную речь», а я такие речи не признаю. Помню, в первые годы я боялся, что наградят сталинскрй премией, ну, думал, снова идти «в солдаты» (премию я бы ни за что не принял, да еще сталинскую!) Представляешь какая была бы пощечина мне, и моя ответная!.. Ты молодец, ответил браво, честно и достойно. В статье многое узнал о тебе, твоем пути литературном. К сожалению, я не могу прочитать твои романы на русском языке. Но чувствую, что не погрешил против правды. Хотя, как сказать, ты ведь многие годы не был в родном краю, а писать со слов очень трудновато... Молодец, что жив, здоров, зубы целые. Правда, на фото ты вышел так, что кажется совсем без зубов. Значит, все же шкандыбаешь на «ноге»? Почему не закажешь полноценную ногу? Трудно? Боли? Но коль чувствуешь себя хорошо, не устало, то продолжай жить и работать во всю... Кто еще из наших жив? Мои все друзья уже отошли в «мир иной»... Я пока держусь, работаю, издаюсь. Кстати, не помню посылал ли тебе рецензию на своего Шута Балакиря? Посылаю сейчас. Рецензия написана с моего ведома, просто помог автору разругать издательства за их политику «кабычегоневышлобы»? У него в том издательстве много лет маринуется рукопись на историч. тему – вот он и сделал сравнение и поругал издательства за их робкость... Как будто после рецензии ему повезло, рукопись пошла в набор. Так что убили два зайца! А Москва все еще медлит с опубликованием рецензии. Знаю, там лежат рецензии Булата Окуджавы, критика Дм. Николаева и Свят. Бэлзы, но их пока не публикуют, чего-то боятся, что ли. Ничего, дождемся!..

Главное, я вышел из плохого состояния, перенервничал, а сейчас вновь взялся за работу. Ты думаешь: хорошо или плохо – 75 лет? Вообще-то юридически говоря, – сатирику любой срок хорош, но я считаю, что людям нашего поколения дожить после 37 года и 41 года до 75 лет, это вообще здорово! Сколько молодежи и нашей, и после нашей погибло в молодые годы! Так что

надо радоваться, что так долго живем. Помнишь у Омара Хайяма: «Ты жив?.. Так радуйся, Хайям!» Вот и я радуюсь. И ты радуйся, и живи столько же. А там посмотрим.

*Обнимаю и целую. Н. Полотай*
*Ялта.*
*15.09.1986*

Салам, дорогой мой Ибрагимчик!

С днем рождения! Помню-помню, дорогой твой день рождения! Мы – молодцы, все же сумели обмануть смерть и … и дожили почти 80 лет. Ох, а как косит смерть друзей! Нашего лагерного брата, поди никого не осталось в живых. Степун умер, Санджи умер и многие, которые тогда вернулись, умерли.

А мы тянем, и приходится только радоваться нашему долгожителю. Правда говорят: жизнь, как басня, измеряется не длиной, а содержанием. Ну, чтож! В писатели большие мы не вышли. Жалеть нечего, ибо в большие пистатели ты сам знаешь – кто и за что попадает. Наград мы не имеем, положения тоже. Но сознание, что ты и я прожили жизнь, занимаясь своим любимом делом, уже оправдывает нашу жизнь, а после смерти – все равно смерть, забудут, и ладно с ним, что забудут, ибо в памяти останутся только «лауреаты». А надолго ли? За 2000 год вряд ли проползут сотни ныне «модных» писателей. А нам на этих модных наплевать. Из писателей ценю Распутина, Ф. Абрамова, Ю. Белова. Вас. Быкова Вл. Чивилихина и, конечно же, Василия Шукшина. Особенно, Абрамова, который правду всегда писал, хотя его десятилетиями не публиковали. Есть народная память. Вот она настоящая оценка писателю. Я хотя и издал уже двадцать книг, но писателем себя не считаю, просто говорю: я литератор, живу литературным трудом.

А что из 20 книг создал хорошее? Ничего. Только рад, что оживил шута Балакирева и создал свой зоопарк. Может это и останется после меня, и этим я рад и даже горд. Но было мне и за шута и за афоризмы как и за басни столько неприятностей что вряд ли, если начать новую жизнь, я снова бы взялся за них! Впрочем, нет вру! Если б начал снова жить, то пожалуй еще с большим рвением взялся за басни и афоризмы. Я, пожалуй бы стал автором 21 века или даже 22, потому что в основе афоризмов всегда философская мысль и это меня утешает – своеобразная оценка современного

мира, явлений и характеров эпохи. Может по ним будут догадываться – какая наша была противоречивая эпоха, так же как по сатире Аристофана и Ювенала можно лучше понять ту эпоху, чем по учебникам… Но это философия для себя в утешение, и чтобы не спадала желание до конца дней писать афоризмы пожалуй, лучшее то написано мною. Правда, Балакирь это штучка, которую обвиняют в намеках на современные явления и характеры. Но стоило бы поднимать пепел прошлого если бы нельзя было выдувать из пепла современные огоньки? Этим и утешаюсь…

А как ты живешь, дорогой мой Ибрагимчик? Я часто вспоминаю нашу ту жизнь, как мы только выжили, теперь даже трудно представить. Я хотел было в какой то форме написать о ней, но разве такая литература пойдет в печать? Скорее меня упрячут еще дальше, чем раньше. Так что оставил эту мысль. Никто не сохранит записки да и кто потом поймет? Молодежь сейчас о войне слышать не хочет, не только о трагедии 37 года, так что наивно и думать чтобы сохранить литер. записи того времени. Степун писал такие заметки, но умер, и все пропало, кто-то забрал и уничтожил из его родственников. Так что на этом и конец. Меня интересует сейчас твое физич. состояние. Все же годы, а ты видимо, все еще на костыле? Не поставил себе ногу? Ведь трудно уже в наши годы, не молоды, не попрыгаешь хотя я стараюсь не бросать йогов и ежедневно занимаюсь, но уже стал сдавать физически трудно стало ходить. Долго работать уже не могу, работаю над афоризмами в кровати под одеялом, когда все уснут и …засыпаю. А днем теперь работы мне хватает, помогаю жене, гости приезжают. Жена болеет, очень надо ее беречь, а она сильно эмоциальная, реагирует быстро и остро на всякую несправедливость, трудно ее приходится успокаивать, но она, правда, быстро отходит, это и радует, живем мы мирно 25 лет. А что у тебя – семья, жена, дети? Как живете? Как здоровье? В общем, Ибрагимчик, меня все о тебе интересует, ты для меня последний из могикан.

*Н. Полотай*

*(вакыты күрсәтелмәгән)*

Исәнмесез, иптәш Салахов Ибраһим!

Бу хатны сезгә билгесез кеше яза. Сезнең «Тайгак кичү» романыгызны укыгач, сез миңа якын кеше булып калдыгыз. Шушы

сезнең язган надзирательләр арасында шушы кеше бар идеме? Ул 1937 елдан 1947 елга шунда хезмәт үтәгән. Сез язган врач Стояновның спиртларын эчү, балык майларын эчүне бик мактанып сөйли иде.

Әгәр дә сез бу кешене танып, аның турында язарга кушсагыз, мин барысын да ачыклап язармын. 1916 елгы – Ибрагимов Муса.

*Сәлам белән Райманова Р.*[1]
*25.04.1989*

Хөрмәтле Ибраһим ага!

Сезгә Иртыш буйларыннан кызу сәламебезне күндереп, исәнлек-саулык теләп калабыз. Бу арада Целиноград-Аблаковлардан хат алып, сезнең аларда булганлыгызны белгән сәбәпле, бу хатны язарга мәгъкуль күрдем.

Сезнең белән таныш булмасак та, «Казан утлары» битләрендә мәкаләгезне күргәли идем. Шуның өчен еракта булсак та – танышлык якынлыгы бар дип исәпләргә туры килә бит.

Үземә килсәк, мин пәйгамбәр гомерен дә ашып киткән 8 дәге татар карты Хөсәен Сабирҗан улы Рамазанов. Көнне күргән, ашаган-эчкән дигәндәй, әле ә булса, җир йөзендә аптырамый, сырхауламый яшисе килә, бик кызык заман бит.

Сезне минем белән яшьтәш дип ишетәм, херле булсын, гомерегезнең озак булуын чын күңелдән телим.

Сезне таныштыру юлы белән, килик матбугат-әдәбият мәсьәләсенә. Мин русча газеталарда 1917 елдан башлап язып киләм әллә корреспондент, рабкор, журналист булганмын, анда әллә ни эш юк. Менә шул газеталарда бу көнгә кадәре мәкаләләремне басып киләм.

Күрсәтелгән 1917 елдан башлап рус телендә пьесалар, шигырьләр, хикәя, тарихи мәкаләләр, башка әдәби жанрлар язып килгәнмен. Шуның һәммәсе җыелып, минем архивта ята килгән.

Менә инде бер ел буе шуларны актарып, үземчә бер системага китердем дә, машинкада үз кулымнан басып, мәкаләләрне китап формасына китердем, ул инде хәзер 3 китап булды. 800 бит (машинопись). Дүртенче китапны басып барам...

---

[1] Рәйхана Райманова – Татарстан Республикасы Азнакай районыннан.

Үземчә шул материалларны ничек тә матбугатка бастырырга уй бар, ләкин Алма-Атага бармагач, кемгә ул кирәк? Кем игътибар итәр икән?

Әлбәттә, сезнең белән бергә булсак, татарча, русча бер хәл итәр идек, ләкин мөмкинлек юк, сез Күкчәтауда – мин Павлодарда.

«Казан утлары»н алып торам. Казан танышларымнан Мәхмүд Хөсәен, язучылардан Габдрахман Әпсәләмов, Сафа Сабиров исемле могътәбәр кешеләр бар, алар китапларын да җибәрделәр, ләкин «һәр кешенең үз кайгысы үзенә» дигәндәй, алар татарча язалар, ә мин русча.

Менә Ибраһим ага, шуның белән хатны кыскартам. Языгыз, нинди нәсихәт бирәсез?

*Ихтирам белән Хөсәен Рамазанов*[1]
*Павлодар. 23.04.1974*

Хөрмәтле Ибраһим дус!

8 гыйнварда язган хатыңны алганга атнага якын вакыт узуына карамастан, авырып ятуым аркасында, тиз генә җавап язып җибәрә алмадым. Гафу үтенәм.

Хатыңны укып, үтенечең турында күп уйланганнан соң, сиңа никадәр генә ярдәм кулымны сузарга теләсәм дә, уңай җавап бирә алмыйм. Үземнең язасы, төзәтәсе, карап чыгасы, яңадан эшләп чыгасы әйберләрем шул кадәр күп җыелды – теге, кем әйтмешли, кыл да сыймый. Җитмәсә, тагы редакцияләрдән тагыла торган һәм баш тартуы һич мөмкин булмаган эшләр, җитмәсә, тагы соңгы вакытларда җилкәгә менеп атланган кәефсезлек (әле суык тия, әле ашказаны бозыла), җитмәсә бирелеп, онытылып, ару-талуны тоймыйча эшләү сәләтенең сизелерлек кимүе – болар барысы да вакытның ифрат дәрәҗәдә дефицитләшүен тудыралар. Кояш чыга да байый гына түгел, ай башлана да ай бетә, ел башлана да ел бетә. Гаҗәп икән ул эшләр җитмешкә якынлашкач...

Ә сиңа әсәреңне тиешле кондициягә җиткереп дөньяга мотлакан чыгарырга кирәк. Минемчә, син кемнеңдер ярдәменә мохтаҗлык кичерә торган түгел, ныклап, үзеңә карата катырак бәгырьле булып

---

[1] Хөсәен Рамазанов – Казакстанның Павлодар шәһәреннән. Журналист, корреспондент.

эшкә керешсәң. Син әсәреңне кыскарту, тирәнәйтү эшен үзең генә дә башкарып чыга аласың. Мин, югыйсә, рецензияләремне булдыра алган кадәр шундый мөстәкыйль эшкә юл ачу максатын күздә тотып яздым. Башкаларның да фикерен байтак ишеткәнсеңдер.

Кыскасы шул, син бүгеннән үк җиң сызганып эшкә керешергә тиеш. Рецензияләрне яңадан бер тапкыр укып чык, үзеңә карата тәнкыйтьчеллек калталарыңны бушатып, өстәлеңә сал һәм эшкә!

Сиңа иң изге теләкләр белән, иҗат куанычлары теләп, сине бик хөрмәт итүче, *Атилла Расих*[1].

*Казан. 27.01.1982*

Хөрмәтле Ибраһим дус!

Сиңа сәламнәр күндергәннән соң, котлау сүзләре әйтмәкче булам. Бу хатны синең «Тайгак кичү»ең журналда басылып чыгу белән язарга теләктә идем, тик көтелмәгән мәшәкатьләр бераз соңгарырга мәҗбүр итте.

Сине искиткеч кирәкле роман язуың белән котлыйм. Бу әсәргә без, укучылар, бик-бик мохтаҗ идек. Без гомуми рәвештә репрессияләр турында әйтелгән сүзләрне күп ишеттек. Мәгәр моңарчы аны якыннан күреп, аның дәһшәтен художество әсәре аша татып, тоеп караганыбыз юк иде. Менә икән ул ничек булган! Тәмуг газапларын кичереп, зөбанилар гөрзие астында кыйналып, тәмугта да була алмый торган мәсхәрәләү, кимсетүләр хәкарәтен кичергәннәр икән безнең кадерле кешеләребез ул көннәрдә! Син менә шуны үзеңнең гаҗәп оста, һәр ягы килгән әсәреңдә ышандырырлык, төгәл буяулар белән бирә, ясап күрсәтә алгансың, рәхмәт сиңа, дус!

Инде безнең хәлләргә килгәндә, әллә ни яңалыклар юк кебек. Еш кына авырыйбыз, күрәсең, картаябыздыр. Инде озаклап, элеккечә үк каләм тибрәтеп булмый. Алай да бу соңгы елларда автобиографик әсәрләр яздым.

Инде шуны да хәбәр итим, бүген генә телефон аша белештем, Нури Арслан бик авырый. Озак вакыт больницада ятып чыккан, тик хәлләре шәптән түгел.

Кайнар сәлам белән, иҗат куанычлары теләп, *Атилла.*

*Казан. 11.07.1988*

---

[1] Атилла Расих (1915–1996) – язучы.

Исәнмесез, Ибраһим абый!

«Татарстан яшьләре» газетасында Сезнең «Йөзебезгә кара якмагыз» исемле мәкаләгезне укып, йөрәгем бик әрнегән иде. Шунда ук утырып газетага җавап яздым, икенче көнне үк бирсеннәр дигән идем, бәйрәм аралары үтеп китте дә менә минем сүзләрне бастырып чыгардылар, бераз кыскартып, усал җирләрен алып, төшереп калдырып билгеле.

Группировкалар турында язганым бар минем, аларның килеп чыгуларының зур бер сәбәбен күрсәтеп язган идем. Өстәвенә, бу көннәрдә үзәк матбугат һәм башка органнар ялгыш аңлатмалар биреп, безнең халык турында ялган информация тарату кебек килеп чыга, әллә белеп эшлиләр, әллә белми эшлиләр... Моның бер очы Кырымга да барып тоташа, читтәге, туган якка кайтасы килгән үзебезнең халык та куркып кала («Казан феномены»ннан шүрләп).

Мондагы үзебезнең халыкның бүгенгесе көнне тәртибе белән мактанып булмый, билгеле. Аракы эчәләр, тәмәке тарталар, сүгенәләр, сугышалар. Менә әле уйлап алдым: бездә дә Мәскәү программасы дигән кебек вәгазь укуны телевидениедән үткәрәсе иде. Мин инде вәгазь укуны сездән башлар идем, аннан соң мәчет әһелләренең кайберләре укыр иде, аннан соң башка язучылар, башка кешеләр... Әмма мин телевидениедә эшләмим. Мин нәшриятта редактор булып эшлим, аларга бу турыда я телефоннан шалтыратасым, я язып җибәрәсем килә, шулай эшләрмен дә, алла боерса.

Ибраһим абый! Сезнең кәефләрегез, сәламәтлегегез ничек? Иҗат эшләрегез барамы? Минем кодрәтемдә булса, телевидение өчен сезне барып яздырып, төшереп алыр идем.

*Сезгә сәламәтлек теләп, Бикә Рәхимова*[1]
*14.11.1989*

Уважаемый Ибрагим абый!

Поздравляем Вас с наступающим праздником и желаем всего самого наилучшего: здоровья, бодрости, хорошего настроения, успехов и удач! У нас настроение самое праздничное, т.к. вот уже несколько лет живем в полном хаосе: перестраивают нашу площадь, Повелецкий вокзал, прилегающие улицы, дома. Все было в лесах, кругом ямы, грязь, строительный материал, пыль, шум,

[1] Бикә Рәхимова (1939–2010) – шагыйрә.

стрекотня – да Вы, Ибрагим абый, все это и сами видели. Грязь, копоть были такими, что уборки хватало только на полдня, а окна можно было мыть каждую неделю. Но всему приходит все же конец. Дождались его, кажется, и мы: строители взяли обязательство кончить перестройку и реконструкцию площади вместо 1990 года к 7 ноября 1987 г. Снимают леса, заканчивают перекраску и отделку нашей Ленинской площади, вокзал стал необычайно красивым и просторным. Ведутся уже оформительские работы. Посреди площади установили постамент с надписью о том, что по этим местам прошла траурная процессия с телом Владимира Ильича Ленина, посадили цветы, хотя уже осень, траву, установили красивые освещения. От окна просто трудно оторваться.

У нас жизнь идет своим очень высоким темпом, еле успеваем листать недели. Не знаю еще точно, вроде предполагается командировка в Кокчетав, если начальство отпустит. Завтра начну хлопотать: получила вызов от Педагогического института. Конечно, очень бы хотелось, буду добываться, а что получится не знаю.

Конечно жалко, что не вышло дело с воспоминаниями. Но может быть время сыграет еще за Вас? Вы же знаете и без моих рекомендаций, что, если попросили выйти из одной двери, надо постучатся в другую. Под лежачий камень и вода не течет. Так учит жизнь. У мамы состояние так же. Но я считаю, что все просто прекрасно, она ходит, делает кое-что по дому, пусть и не в полную силу здорового человека, но и это уже счастье в первый момент болезни мы мечтали, чтобы она была просто с нами, это желание перевыполнилось на 547 %. И это здорово. Она сама, правда, все время недовольна, что не может бегать как прежде, ворочить делами за троих. Я ее успокаиваю, что это желание уже роскошь, и надо быть довольным тем, что нам отпустила судьба, а вернее одарила. За что ей большое спасибо и поклон до земли.

Ибрагим абый, немного о себе то, что вы хотели бы знать. У меня жизнь вроде сложилась не очень просто и однозначно. Было в ней и много радостного и светлого, незабываемого и яркого, но было тяжелого, подчас трагического и драматичного. Конечно, все эти слова относительные, и любые перепетии можно считать по срвнению с встречающимися в жизни не такими уж счастливыми, и не такими уж трагичными, но все же события были не ординарными.

Я родилась в Москве в 1933 г. 5 января. Семья наша жила очень скромно, работал только папа. По характеру он был человеком очень размашистом и щедрым. Всегда старался играть роль богатого человека, обеспеченного и независимого, хотя для этого у него не было ни средств, ни возможностей. Но так он прожил всю свою жизнь: если нас пускал в кино, то отдавал последний рубль так, как будто у него в кармане еще оставалась целая сотня. Если родственники просили помочь, то продавал мамины наряды, украшения, чтобы не сказать нет. Поэтому у многих, кто знал нас, было прочное мнение, что наша семья – это золотой мешок, который можно трясти и трясти. Я думаю, что мы полностью не прогорели в жизни только потому, что мама была всегда хорошей хозяйкой, была нетребовательна и некапризна, в чем-то прижимостой, почти скрягой в хорошем смысле слова, очень скромной и деловитой. И это компенсировало папину расточительность.

В детском саду музыкальный работник открыл у меня хороший слух и посоветовал отдать в музыкальную школу. Итак, с 6 лет я начала учиться музыке. Мои учителя меня очень любили, видимо, за мое спокойцствие и сдержанность, а также старание. Учеба в музыкальной школе наложила свой отпечаток на всю мою жизнь, приучила меня к терпению, усидчивости, развило кругозор в мир необычный, возвышенный и прекрасный. Даже, когда началась война и был оне до эмоций, я продолжила музыкальную школу, хотя это было не очень просто. Училась я на скрипке. В начале войны мы с братом были отправлены со школой в интернат в Рязанскую область, где работали в колхозе. Но пробыли там недолго, т.к. маму с сестричкой из домуправления отправили в Уфу. И папа решил нас соединить. Взял направленный отпуск, забрал нас, и мы поехали искать маму. Как выяснилось позднее, она была не в Уфе, а в области. Отпуск у папы кончался и он взял направление в Оренбург, где жила наша тетя, вообще говоря, не уж такая близкая родственница. Но этот человек старого закала, с прежней психологией, понятиями добра, милосердия, родства. Она сама выросла в большой многодетной семье, в которой мачеха (Сабира апа) все называли ани, хотя она всего на четыре года была старше ее, дети от первого и второго брака – все были равны, в этой семье и воспиталась моя мама (она была сиротой с 6 лет), и папина семья долго жила с ними. Когда мы приехали в Оренбург, вопроса примут ли нас к себе семья тети или

нет, просто не стояло. Даже странно, что никто не говорил, что это большая ответственность в такое тяжелое время воспитывать чужих детей, то появились два лишних рта. С каких доходов и на какие деньги кормить, одевать, где, наконец, укладывать, размещать их. Я до сих пор испытываю благовейное, благодарное чувство к тете и ее мужу (он погиб на войне), людям, которые были к нам и строги, и добры, людям на время заменившими нам и отца и мать. Ну а потом мы соединились сначала с мамой, которая приехала в Оренбург с сестрой, а потом с папой, институт которого переехал в Уфу. В 1943 г. мы вернулись в Москву. Видимо, это Вам и не надо, но почему то мне захотелось об этом вспоминать. Во время войны мама и папа помогали, мне кажется, всей голодающей Москве: высылали посылки с картошкой, мукой, крупами, маслом, луком и т.д. мама все это меняла на наши вещи в деревнях далеко от Уфы. А Москву приехали, можно сказать, голые, но с продуктами.

Школу я кончила с золотой медалью. Далее поступила в Институт международных отношений на юридический факультет. Но когда я уже себя считала студенткой 4 курса неожиданно объявили о реорганизации института и сократили численность студентов на две трети. Я решила начать новую жизнь и изъявила желание пойти в Московский энергетический институт на радиотехнический факультет. Время для меня было очень тяжелым. Ведь только я и мои близкие доподлинно знали, что меня никто не выгонял, что я переведена. Все окружающие. Как мне во всяком случае казалось, полагали, что меня выгнали. Я себя чувствовала очень ущемленной, оскарбленной. Без вины виноватой. Вот тогда и зародилась у меня мысль добиться необычного, невозможного: окончить свое языковое образование, не прирывая учебы в МЭИ. Ми я начала обивать пороги Минвуза, чтобы получить разрещение одновременно учиться на вечерном отделении Института иностранных языков на 4 курсе. Сначала все было, как по Райкину: я в течении двух месяцев через день или два одному и тому же человеку объясняла, зачем пришла, поскольку он меня не узнавал. И только в середине ноября однажды он меня узнал и сказал, чтобы я больше не приходила до 30 мая 1962 г. вот тогда все решиться. И решилось в мою пользу, т.к. меня из МЭИ не выгнали, даже дали разрешение учиться одновременно в другом иституте. Ну с этого дня у меня начались жаркие денечки: утром МЭИ, вечером ИНЯЗ, двойные уроки, двойная

нагрузка. Было не до кино, до театров, учеба, учеба и еще раз учеба, как по Ленину. После окончания ИНЯЗ я поступила работать в вечернюю школу, продолжая учиться в МЭИ. А затем окончила и МЭИ и стала работать инженером. Попала в очень интересную компанию: трое ведущих инженеров были освобождены в 1950г., т.к. участвовали в налаживании связи Берлин–Москва, а мой шеф, также очень крупный специалист попал под немилость в связи с еврейской компанией в 1952 году. Я многому у них научилась, узнала. Эти годы прошли, конечно, не бесследно. В эти годы начинается и моя популярность как прибориста, работающего в области полярографии. Я многим помогала, объясняла, многих учила, т.к. была соавтором приборов, на которых работали химики различных отраслей народного хозяйства: и в геологии, и в металлургии, и в химической промышленности, и в медицине и т.д. я влезала в их задачи, изучала особенности отрасли, брала, как говорится, по большому кругу, и это формирования широты взглядов, глубины понимания проблем. Помогает это мне и сейчас. Когда моя жизнь раздвоилась: в 1975 г. я перешла работать в учебное заведение. Основная линия моей жизни, которая фактически помогла мне встать на ноги и сделать. Как говорится, карьеру стала формально второстепенной, а главное стала работа, которой загружал меня институт. Меня взяли старшим научным сотрудником. В 1966 г. я защитила канд. диссертацию после окончания заочной аспирантуры. Шеф мой умер, и я осталась одна одиношенка, без союзников и друзей на работе. Диссертацию я делала после окончания рабочего дня в других институтах, где было у меня уже много друзей и сообщников: моя безотказность сыграла мне хорошую службу, ко мне очень хорошо относились все, кто работал на моих приборах. Когда в газете «Вечерняя Москва» появилось объявление о моей защите, в институте никто не работал целый деь: все обсуждали неожиданное и непредвиданное событие. Оно застало всех врасплох. К этому времени в нашем предприятии было три кандидата наук, которые пришли уже к нам будучи кандидатами, а из нашей среды уже никто никогда не защищался. Ни директор, ни главный инженер, не имели этого звания. В то же день я получило повышение, в котором накануне было отказано, как мне объяснили, из-за отсутствия должности и денег, хотя для других в этом недостатка не было. Защита прошла более, чем удачна. Было столько народу,

что яблоку негде было упасть. Народ стоял в проходах и у двери. Получение научного звания и повышение в должности упрочили мое положение, а кроме того я открыла дорогу другим, за мной последовали защиты других наших сотрудников. Но обстановка для меня в институте была очень тяжелой: я отдавалась полностью работе, имела большие успехи, которые были и успехами предприятия, но почему-то один мешал работе, другой не помогал и не поддерживал, третий делал вид, что ничего особенного не происходит, а были и пятые, которые говорили, что делается работа, который наш институт не должен заниматься. И это было самое страшное. Я предпринимала отчаянные попытки создать общественное мнение по отношению к нашим работам, на время это продлевало житье нашей группы, а потом все снова и снова повторилось. И я решила уйти. Вот тогда-то и началось раздвоение. Вначале в моей основной работой было разработка терминологических стандартов, касающихся радиотехники – дело совершенно новое для меня. А моя полярография – дело подпольное. Моим коллегам сразу не понравилось, что ко мне приходили и приезжали люди на консультацию. И мне стали делать замечание. Были претензии и к тому, что мой научный интерес касается химического анализа, а нерадиотехники, что я работаю с заводом, а не институтом. Вообщем все, чем я гордилась и, как мне казалось, было ценное в моей работе – предавалось анафеме. И я снова поняла – надо уходить в подполье и чем глубже, тем лучше... Время показало, как я была права. Мои друзья сагитировали меня засесть за докторскую диссертацию: дел к этому времени было сделано много: свыше 5000 приборов работало в союзе, было опубликовано 125 работ, включая и изобретния. Ясно, что на работе об этом никто ничего не знал. И вот в одно прекрасное время я положила перед заведующим кафедрой диссертацию. Вначале было полное оцепенение, потом несвязанные вопросы, вообщем полное замешательство. Как позднее сказал один из моих коллег: «У нас были кандидаты на представление докторской работы, но Вы…? Никто не мог даже предположить, что это возможно». Не зная, как поступить со мной, начались проволочки с прослушиванием работы. Как мне объяснили, это было вызвано забывчивостью…. Забыли, что я заявила такую просьбу. Сейчас все позади, можно даже с долей юмора об этом говорить, но тогда было мне не по себе. В институте двое товарищей провалил защиту

докторской диссертации в то время, и мне настоятельно советовали поговорить с ними, чего я все же не сделала. Защищалась я среди друзей и доброжелателей, народу было много… Не буду вдаваться в подробности, только скажу об одном: я не стала скрываться от людей, которые могли быть моими теоретическими противниками и которые могли выступить публично со своими опровержениями в печати, в письмах т.д... Сразу сформулировала область своих притязаний, которая им была просто не под силу, да и не в их сфере деятельности. И это внесло ясность, и они оказались также моими доброжелателями и союзниками… Ректор предложил перейти в преподавательский штат (что у нас рядовым женщинам, идущим без протеже, недоступно) и предложил должность профессора. Согласно этого положения я преподаю технологию радиоаппаратостроения, то есть дисциплину, как делать радиоаппараты. Этот вопрос очень емкий, серьезный, большой, постоянно меняющицся и совершенствующийся и, по большому счету, не имеющий почти никакого отношения к моим научным интересам. Но я уже привыкла жить двойной жизнью, и даже не знаю, как можно иначе. Ведь такой образ жизни был у меня в юности. Работала в школе, а далее еще больше: поступила на курсы французского, английского, испанского и итальянского языков, где продолжала учиться, начав работать, одновременно поступила в 1963 г. после трех лет работы в заочную аспирантуру, позднее занялась японским языком. Вообщем никогда не имела одной жизни. Поэтому ценю свое и чужое время, умею собираться с мыслями и с силами, когда надо, выполнять подчас сверхзадачи. Дел очень много, большая общественная работа висит на мне, работа, которой я даже не могу потрясать с своем институте, т.к. вызывает раздражение и недовольство.

Высылаю Вам три книжки.

*С уважением Рашида (Салихжанова)*[1]

*5.11.1987*

Многоуважаемый Ибрагим абый!

Очень давно не писала, мало того просто не ответила на письмо Ибрагим абый, хотя это письмо ношу как любовное под сердцем

---

[1] Рәшидә Мөхәммәтфатих кызы Салихҗанова (1933–2012) – профессор, техник фәннәр докторы, приборлар төзү гыйлеме белгече. Фондта 10 хаты саклана.

в своем еженедельнике, оно со мной везде, включая мои дальние поездки. Очень тяжелый год для меня. Поверьте, просто, как говорится, күңел юк язарга. А ведь письмо – это дело серьезное, надо настроиться, иметь душевное спокойствие, даже соответствующую обстановку, когда никто не дергает, ничто не тревожит. А вот такой обстановки, можно сказать, и не было: заботы повседневные, которые накладываются одна на другую…

С 4 июля в отпуске, но это только официально, а фактически продолжаю работать как пчела: принимаю экзамены у лодырей, они меня очень упрашивают, ведь им надо и отдыхать, а какой отдых, когда висит хвост-задолженность по предмету. Тоже жаль, хотя они и лоботрясы, ведь мои ученики, а учеников-студентов мы не выбираем, они появляются стихийно, какие попадаются, такие попадаются, ничего не изменишь, стараешься воздействовать насколько это возможно, а возможностей мало, так как у них соблазнов куча. Ведь сейчас у студентов официально возможность свободного посещения лекций, Вы даже себе, наверное, и представить не можете: студент хочет посещает лекции, хочет гуляет, и никто не может ему сказать слова, т.к. само правительство дало ему такое право. Ну а как при таких порядках научить студента уму-разуму, забыли сделать постановление. Вот и приходится самой выдумывать свой стиль преподавания и отчетности студента. Но вы по себе хорошо знаете, что всякое доброе дело наказуемо. Ведь только то, кто ничего не делает, остается в выигрыше. Им не надо лишний раз шебушиться, терять время на свои же выдумки. Вот представьте, решила научит и тех, кто учится не желает и ввела систему: не ходишь на лекции, изволь сдавать материал пропущенной лекции, плохо ведешь себя на лекции, то же самое. Вроде, с моей колокольни, мероприятие и постановка впроса правильная, она достигает и свою цель, пропускал лекции, но знать обязан и будешь, я не прощу, все с полна спрошу. Но кто при этом оказывается наказанным, как вы думаете – в первую очередь, я. Я первая прихожу в институт и последняя ухожу, все мои коллеги загорают, собирают ягоды, отдыхают на море и в окружении своей семьи, а я как прокаженная сижу с этими оболтусами, причем изменить ничего нельзя, ведь это моя система, и каждая собака в институте об этом знает. Вот так сама придумала, сам и мучаюсь…

Началась моя и литературная деятельность, и уже вышел первый труд – крошечья статья в книжке, посвященной Сара Садыковой «Сагыналар сине якын дуслар». Правда, очень исказили текст первоначальный, главное выбросили, не знаю почему, куски, которые делали эти воспоминания и моменты общения с Сара апой живыми, передавали колорит дружеских взаимоотношений ее с членами нашей семьи, описывали образн куски ее жизни, передавали ее характер, особенность натуры, а главное начало ее композиторской деятельности. Мои воспоминания получились сухими, как технический отчет, хотя, поверьте мне, я их так не написала, да и не могла написать о человеке ярком, светлом, несмотря на все перепитии ее нелегкой судьбы.

У нас на видном месте журнал лежит «Казан утлары» с Вашим портретом, и я всем, кто приходит, показываю и говорю: «Это видный татарский писатель, вот его книжки, он наш близкий друг и родственник». Действует очень сильно, почти магически. Так что спасибо, что вы есть, спасибо, что Вы существуете, спасибо, что судьба свела нас и связала с одним городом и родственными узами…

Жизнь в Москве сейчас не простая, конечно, стало намного лучше, чем было месяца два-три назад. Появились продукты, ассортимент не очень богатый, но жизненный минимум есть, уже хорошо. Правда, все очень дорого: по старинке начинаешь все подряд брать да по многу, и сразу пустеет кошелек, даже оглянуться не успеешь. Промтоварные магазины довольно пустые, если и что-то есть, то кооперативные, либо по особым пропускам. Так что их своих командировок я привожу больше, чем можно купить в Москве.

Теперь ответы на Ваши вопросы. Я окончила школу с золотой медалью. Училась всегда хорошо…В 1955 г. я стала одновременно студенткой 2 курса Моск. энер. института и 4 курса ИНЯЗ, сейчас он носит название им. Мориса Тореза, но вечернего отделения. В 1957 г. я его окончила. К этому времени я уже училась на 4 курсе, вернее перешла на 4 курс МЭИ. Я была реабилитирована, вызывала, разумеется, недоумение всех, т.к. тогда одновременно учиться было незаконно и просто нельзя. Чтобы закрепить диплом, утвердиться, я поступила даже работать учительницей немецкого языка в вечернюю школу рабочей молодежи, которая была организована в стройбате. Моими первыми учениками оказались поволжские немцы и крымские татары. И те и другие во мне просто души не

чаяли. Ну а потом я окончила МЭИ в 1960 г. и начала работать в Центральной лаборатории автоматики, под руководством очень интересного человека. Который очень много определил в моей дальнейшей судьбе, Семена Борисовича Цвасмана. Правда, вместе поработать нам удалось немного. В 1965 г. он умер. Но к тому времени я уже была заочной аспиранткой в Московском институте химического машиностроения. Этот выбор был сделан потому, что будучи инженером радиотехником, свою трудовую деятельность я начала как приборист, специализирующийся в аналитической химии, а именно в области полярографического приборостроения. Это фактически и стало моей судьбой. С.Б. Цвасман познакомил меня не только с азами этой науки, но и с кругом людей, которые были связаны с полярографией...

В 1968 г. наша Центральная лаборатория автоматики превратилась во Всесоюзный научно-исследовательский институт автоматизации черной металлургии, меня перевели на должность старшего научного сотрудника. На большое я не могла рассчитывать, т.к. была беспартийной. Человеком скромным, морально устойчивым и строгим. А ведь таких общество не любит и чем может им за это мстит как может. Мои коллеги по работе двигались вперед, не имея ни работ, ни успехов во внешнем мире. Меня просто не замечали, хотя я постоянно работала новые разработки, которые работали во всем СССР. Я как и прежде везде ездила, учила, внедряла свои приборы, никогда не жила за чужой счет, кормила всю лабораторию с работающими и неработающими людьми, а за все имела моральное удовлетворение. Это меня очень окрыляло и поддерживало. Но в одно прекрасное время что-то стало не по себе, а какой-то мере даже захотелось посмотреть, а как будут идти дела без меня. Здесь подвернулась работа совершенно не из той оперы и области моих интересов, и я объявила, что ухожу. Я поняла, всем было либо безразлично, либо даже радостно. Правда, на следующий день после моего увольнения направление «полярографическое приборостроение» в этом предприятии было закрыто…

На новом месте… Я вжилась в новую тематику, стала просто специалистом в области терминологии по радиотехнике, познакомилась с многими людьми и организациями. Но старое дело я не бросала, хотя это было очень трудно продолжать работу в институте, который не имел никакого отношения к аналитике и

поляроографии. Постепенно я заключила договор о творческом взаимоотношении без материальной оплаты, а затем и нормальные договоры с оплатой. Здесь тоже не обошлось без оскорблений и унижений, но Ходай бар, и не оставил меня. В стране была объявлена продовольственная программа, мои приборы очень хрошо вписывались в эту тематику, терминоглогия с честью была закончена, я снова переходила на свою поляроографическую тематику. Это было в 1981 году...

В 1984 г. получила диплом профессора. Так сейчас и работаю профессором кафедры... Очень велика общественная нагрузка: я член двух Специализированных советов по защите диссертаций, член бюро научного совета АН СССР по аналитической химии, член совета Государственного комитета по науке и технике.

Итак, моя научная профессия – я инженер-приборист. Который разрабатывает приборы-поляроографы. Эти приборы применяют для различного вида контроля воздуха, воды питьевой, сточной, морской, пресной, гальванических растворов, определения состава различных материалов, горных пород и т.д. Они применяются в медицине для анализа крови, тканей, мочи; в сельском хозяйстве для анализа почв, растений, пищевых продуктов: мяса, молока, зерна. Этим занимаются и другие специалисты в СССР, но я делаю поляроографы для широкого применения. Это очень хлопотно, поэтому уважающие себя специалисты старались этим не заниматься, оставляя за собой занятие наукой, теорией – красиво и совершенно неответственно, на виду и никто претензий не предъявляет. И так было долгое время – их считали очень умными специалистами, двигающими науку вперед, их никто не критиковал, не ругал. А на моих приборах все работали, естественно, что из тысячи приборов бывают всякие, что-то может и не работать, конечно, это нехорошо. Но ведь – это единицы, а весь Советский Союз ведь работает! Мне нравится, что моя работа нужна, что я нужна, что от меня зависит успехи многих людей…

Мне очень часто стараются подчеркнуть, что всего знать нельзя, а когда человек на себя много берет – это попахивает дилетантством, хотя с моей стороны для таких заключений никогда не было оснований: я много над собой работаю, чтобы не давать основания для таких заключений, но мужчины не любят, когда женщина вдруг выходит на рубеж выше сильного пола, видимо, именно и поэто-

му приходиться мне выслушивать все это. Я уже за свою жизнь привыкла к такому отношению сильного пола, то же самое было и в дни моей молодости, это продолжается и сейчас. Мужчины неохотно отдают завоеванные позиции, страшно не любят влезание женщин в их сферы, и отсюда стараются словесно или другими средствами принизить достижения женщин-специалистов. Вот такие обиды у меня к жизни.

Вот печатаю и самой как-то тепло от того, что вся жизнь прошла перед глазами со всеми ее достатками и недостатками, радостями и горестями. Было все, наверное это хорошо. Когда не все гладко, то учишься ценить хорошее, удачи, хороших людей, счастливые обстоятельства.

Еще раз прошу передать большой привет всем нашим близким, больших Вам успехов, творческого горения, зеленых дорог на поприще Вашего нелегкого труда.

У меня 260 печатных трудов, в том числе, 4 книжки, 14 авторских свидетельств на изобретения.

*Рашида (Салихжанова)*

*8.06.1991*

Хөрмәтле Ибраһим әфәнде!

Сезнең адресыгызны бер ел буе эзләдем. Бүген бер дус кеше аны миңа тапшырды. Үткән ел ук Сезнең «Колыма хикәяләре»гезне укыгач, сезгә хат язарга теләгән идем. Ләкин безнең кибеттә ике китап кына кайтарылган булганлыктан, аны алып булмады. Ә китабыгызны укучылар байтак булды. Мин дә аны кешедән алып (чираты җиткәч) укый алдым. Рәхмәт сезгә!

Колыма безнең гаилә өчен таныш урын. Әнинең туганы Мөнир Хамис улы Альмушев анда 1939 елдан 1952 елга кадәр каторга газабын күреп, авылга ике күзе дә дөм сукырайгач кайткан, ике айдан соң вафат булды. Ярый әле авылга кайтып үлә алды.

Әнинең кыз туганы София апаның ире Сәүбән Нәүмән улы Алимов, Сәүбән абыйның туганы Нуриман абый, безнең авыл колхозының председателе Абдулхак Билялов анда газап чиккән кешеләр. Нуриман абый анда үлеп калды. Сәүбән абый Мәскәүдә үлде. Абдулхак абыйның хатыны Алия апа ике баласын алып, 1951 елда ире янына барып, ире белән сөрген нужасын тартты. Сталин үлгәч

ике балалары белән яңадан авылга кайттылар. Әле яңадан ике балалары булды. Ике ел торгач, Абдулла абый да вафат булды.

Мин үзебезнең район газетасы өчен «Судьба Биляловых» дигән очерк язып бастырдым («Знамя коммунизма»да ул 7 номерда, «Сельская трибуна»да 6 номерда басылып чыкты).

Әгәр миңа Сезнең адресны дөрес биргән булсалар һәм Сездән җавап ала алсам, мин Сезне ул очерк белән таныштыра алырмын. Ул рус телендә басылды. Сәүбән Алимов, Нуриман Алимов, Мөнир Альмушев, Абдулхак Билялов: бу исемнәр сезгә таныш түгелләрме? Алар да Сусуманда булганнар.

Шуның белән хатымны тәмам итәм.

Хатымның соңында гына булса да Сезне 80 яшь тулу белән котлыйм. Сезгә саулыклы озын гомер, бәхет, иҗади уңышлар телим.

Сәлам белән *Сәяр Вафа улы Сабиров*[1] – РСФСРның атказанган укытучысы, сугыш һәм хезмәт ветераны.

*с. Петряксы. Нижегородской обл.*
*6.10.1991*

Хәерле көн, Ибраһим ага!

Барчагызга да кайнар солдат сәламемне юллыйм. Баһадир ага белән Рауза җиңгигә дә миннән сәлам. Иминлек, тигезлек, сәламәтлек, бәхет телим.

Язган хатыгызны һәм Күкчәтау күчтәнәчен алдым. Барысы өчен дә зур рәхмәт. Күчтәнәчегез җанга җылы өрде. Күңеллрем тулып, ике Камилне тирән ихтирам белән искә алдым. Ә китабыгызны бик яратып укыган идем. Яңадан шул хатирәләрне яңартырмын дип торам.

Солдат хезмәтенә чаклы редакциядә эшләдем. Казан университетының журналистика бүлегендә гыйлем алдым. 1972 елның ноябрь аеннан бирле хезмәттә. Туган җирем – Татарстан. Бишегем – Арча районының Казанбаш авылы. Әдәбиятка Тукайны биргән якташларым белән горурланам. Әти-әнием укытучылар. Алты бала үстек: мин, Азат, Гөлчәчәк, Әлфия, Айрат, Лилия.

Кечкенәдән үк язуга хирес идем. Ул хисем тора-бара көчәйде. Бүгенге көндә дә хикәя, нәсер, очерк ише әйберләр языштырам.

---

[1] Сәяр Сабиров (1924–2014) – Түбән Новгород өлкәсе Петрякс авылыннан. РСФСРның атказанган укытучысы, туган якны өйрәнүче.

Казан газета-журналларында әйберләрем басылып чыккалады. Хәзергә, «яшь – кече, уй – олы. Кайчак әрнү җанда. Әмма шөкер – хыял исән-аман алда!» диебрәк яшим. Йөзтүбән каплана алсам да, янәдән мең артык көч белән торып басарга исәп.

Камилләрне урнаштыру үзе бер тарих булды ул, Ибраһим ага!. Ибраһимов Камил белән өйрәнүләрдә бергә булдык югыйсә. Очрашып, күрешеп йөрдек. Ә сезнең егетне белми идем әле.

Туйлар узды, туннар узды, дигәндәй. Китәрләренә ике көн генә калгач иптәш малаем килеп кермәсенме. «Марат , – ди бу. – Ибраһим аганың малае бездә хезмәт итә икән». Мин бар эшемне ташлап, Камил янына йөгердем. Җылы гына күрештек. Шул чак ул үзенең гозерен сөйләде: «Икебез бергә үстек, бергә җибәрттерә алмассыңмы», – ди бу. Мин аның бу адымын хупладым. Дус писарьлар белән сөйләшеп, икесен бер җиргә озаттым. Соңрак иде шул. Югыйсә, үземнең янда да калдырып була иде. Юл чатына кадәр озата бардым. Җылы гына саубуллаштык. Менә шул көннән бирле хат-хәбәрләре юк. Шунысы гына эчемне пошыра.

Үземнең хәлләргә килгәндә, исән-имин яшәп ятам. Көзгә туган якларга кайтып китәм инде. Сагындыра, җирсетә, Ибраһим ага! Кайчак күңелләрем тулып, җырлап та җибәрәм. Үзебезнең тел тибрәнешләренә, моңнарыбызга зарыгуым көчле. Съезд турында да сезнең хаттан гына белдем. Съезд дигәннән, монда да казакъның олы акыны Кенен Әзербаевның 90 еллыгын үткәрделәр. Яшәгән авылы моннон 15 чакрымда гына булса да, барып булмады. Кояш югалса да аңа битарафлар бар бит әлегә, җибәрмәделәр. Өйгә кайтканчы барыбер күрми калмам дигән әманәтем бар. Барып, күреп, сөйләшеп кайтам әле мин аның белән.

Үзегездә ни хәлләр соң? Сәламәтлекләр ни хәлдә?

*Тирән ихтирам белән Марат (Сәгъдиев)*[1]

*26.06.1974*

Хәерле көн, Ибраһим ага!

Сезгә сагынычлы солдат сәламен юллыйм. Сәламемне гаиләгезгә һәм Ибраһимовларга да тапшырыгыз. Иминлек, сәламәтлек, тигезлек теләп калам. Хатыгыз һәм хәбәрләрегез өчен зур рәхмәт.

---

[1] Марат Сәгъдиев – Арча районы Казанбаш авылыннан.

Үзем исән-сау. Тормыш салмак кына ага. Кайтыр көннәр якынлаша. Торган саен сагыш, җирсү генә көчәя. Юкса, игеннәр дә безнең кайтуны көтә-көтә саргаешып беткәннәрдер күк тоела.

Узган ял көнне шәһәрчеккә, комсомолга Ленин исеме бирелүгә 50 ел тулу тантанасына барган идек. Яхшы гына каршыладылар. Шулай да, Тукай клубындагы әдәби җомгаларга ,университетның «Әллүки» әдәби берләшмәсе кичәләренә җитми инде! Күз алдымнан кинокадрлар сыман әнә шул мизгелләр үтеп торды. Тамакка төен тыгылып, уңайсызланып киттем. Тәнемдәге һәр күзәнәк кайту, уку, язу өмете белән тулы. Кайтуга юлда калган уку арбамны күкрәк белән этәрмен дип, үз-үземә антлар бирдем, Ибраһим ага! Авырлыгыннан да курыкмыйм. Тик, кайбер җаннарның ваклыгы, синнән йөз чөерүе генә аяныч. Тормышның кортсыз алма түгеллегенә инанган идем. Әмма дусларның күбесе онытты. Хәер, ни күрми ир башы белән ат башы! Башта бүрек булсын! Бар авырлык нәни йөрәккә инде. Шагыйрь әйтмешли:

Горур җанга ни кирәк?
Лаек биеклек кирәк
Абынсаң, очар өчен...

Ибраһим ага! Язу турындагы җылы киңәшләрегез өчен олы рәхмәтемне кабул итегез. Басылырга ашыкмыйм. Язам, Ибраһим ага! Бозам, ертам. Ә күңелкәйдә аваз-күкрәүләр, шаша-шаша яңгырлар ява. Язу миңа һәр эшемдә этәргеч, терәк. Йөрәгегезнең алай борчып торуы кайгыга салды мине. Шаулы еллар үз буразналарын сызганнар күрәсең. Нури ага сүзләре белән булса да:

Кичерешләрдән авырып егылсаң да,
Авырулардан каушап егылма.
Безнең әле роман укыйсы бар
Имәнтаулы батыр турында, –

дип әйтергә туры килә. Ибраһим ага! Сез бит озак яшәр өчен тумышлар! Сезнең аңа хакыгыз зур. Яшәгез әле йөзгә чаклы. Юкса, сабантуйлар да сезсез безгә күңелсез.

Туган якларда үзгәреш юк. Язып торалар. «Яңгырлар еш була. Игеннәр Ходайга шөкер», диеп язалар. Амин, шулай булсын. Терәгебез – икмәк. Ә сезнең далалардагы быелгы һавага борчылдым. Артык эссе булу – афәттән бүтәнне китерми инде ул.

Хат көтәм. Тирән ихтирам белән *Маратыгыз (Сәгъдиев).*

*14.07.1974*

Хәерле көн, Ибраһим ага!

Һәммәгезгә сагынычлы сәлам. Тынычлык, иминлек, сәламәтлек теләп калам.

Үзем исән-сау гына йөрим. Бер аяк казах җирендә, икенчесе өйдә. Кайту ягына йөз тотабыз. Дала җилләре кылганнарга сарылып кавышу көен уйный сыман тоела. Хәерле сәгатьтә генә булсын! Соңгы имтиханар бирелде. Бишлегә биреп чыктым. Бу имтихан соңгысы булсын дим. Инде окоп бозларын имезеп, теге еллар афәтен күрсәтмәсен. Аннан соң, бу көннәр ирлек, егетлектә сынау булды ахры. Үз бурычымны бирдем диеп, сөенеп йөрим. Инде исән-сау кайтып җитәсе генә калды.

Хәтерне әйтәм әле – каһәр генә суксын инде! Сезнең күчтәнәчне алдым. Бик зур рәхмәт инде, Ибраһим ага! Мине онытмавыгызга, үз күрүегезгә рәхмәт. Нинди генә җылы сүзләр эзләп багыйм соң, ә? Туган җирләремне искә алып, кабаттан сөенеп куйдым. Күңелем бик булып, «Тәфтиләү»не сызгырып йөрдем. Егетләр дә кәефне сизеп алганнар, мыек астыннан гына көлеп йөриләр.

Камилдән хат юк. Бүген генә хат язып салдым. Бераз «пешекләп» алдым әле үзен. Хатны саран яза, ялкаулана күрәсең. Беренче елларны вакыт та тими инде, ул кадәрлесе дә бар бит әле. Я тегене эшлә, моны тап диеп, бар фикерне чуалталар. Зиһен чуала, эшлисе эш ярты юлда кала. Армия бик тупасландыра. Күәсе сай егетләр күп. Кыз-кыркын, хәмердән башканы белмиләр. Безнең буынның чире ахрысы бу. Тормышка тирән караш, уй-фикер йөртү юк, укымышлы ялкаулар күп. Дилетантлар офицерлар арасында да тулып ята. Бик яшьләй түрә булалар. Кешене тәрбияләү дигән нәрсәгә бармак аша гына карыйлар. Ә яшь халыкның талчыбыктай сыгылучан икәнлеген онытып җибәрәләр. Шуның аркасында күңелсез хәлләр яңгырдан соңгы гөмбәдәй ишәйгәннән-ишәя. Әхлак, тәрбия мәсьәләсенең икенче планга куелуы аянычлы хәл әлбәттә. Тикшереп-нитеп тору юк – тимер чыбык артына куу ягын гына карыйлар. Беркөнне бәхәс китте: «Татарлар ачу саклаучан, астыртын адәмнәр», ди бер түрә. Минем ачу чыкты. Сораша башладым. Безнең халык турында берни белми үзе. «Бер-береңне аңларга теләмәү, бер-береңнең гореф-гадәтен, тарихын белмәү, хөрмәт итмәү китереп чыгара сезнең бу фикерләрегезне. Фикер йөртмичә, сай йөзеп, аш өерәсендә йөзеп йөргән май сыман яшисез. Офык киң», – дидем мин. Ун тәүлеккә кәгазь язып тоттыра язды. Ни дим

инде аңа! Урыс әйтмешли «На не добрых не обижаются, над ними смеются». Безнең тел белән авыз чайкыйсы юк аңа «ассалар да, киссәләр дә калдың тере, чукындырган чагында да чукынмадың татар теле» диеп кенә авызын ябасы иде дә бит!

Ибраһим ага! Кайтышлый кереп, күреп китәм дигән уем бар иде. Әгәр эшелон белән китмәсәм, кереп чыгармын.

*Тирән ихтирам белән, Марат (Сәгъдиев)*
*23.10.1974*

Ибраһим туган!

Хатларың өчен һәм шигырьләрең өчен бик зур рәхмәт.

Үткән хатыңдагы улың турындагы хәбәр бик борчыды. Кайгыгызгы чын күңелдән уртаклашам. Нишлисең бит? Балага үз акылыңны биреп булмый шул! Кыз да үкенгәндер, бәлки, эш үткәннән соң. Синең хатны укыгач та Рамай искә төште. Ул да нәкъ шулай булган бит. Һәм «Рамай» көен соңыннан аның невестасы чыгарган диләр.

Бездә әллә ни яңалыклар юк. Язучыларның бер өлеше съездда хәзер. Мин, гомумән, союзда сирәк булам. Анда кызыклы, күңелле кичәләр дә булып тора торуын, ләкин картлык баса башладымы, күңел күтәренке булмагангамы, ничектер, бер кая да барасы-йөрисе килми. Өй эше белән дә арыйм көне буе. Язу эшенә соңгы айда утыра алганым да юк әле. Шул бик эчне пошыра...

Ярый хәзергә, хуш. Авырмый, армый-талмый эшлә. Шигырьләрең арасында «Казлар» турындагысы аеруча ошады миңа. Тагын да шундый лирик, җылы шигырьләр язсаң иде дип теләп калам.

*Сәлам белән Сәрвәр апаң*[1]
*19.05.1959*

Исәнме, Ибраһим!

Хатыңны алдым, рәхмәт.

Шактый каты авырып алгансың. Хәзер бик сакланырга, тынычлык аннан да артык кирәк.

Мин хәзергә эшләп йөрим, билгеле, төрле вакыт була, иртән эшкә барасы килмәгән вакытлар да була, ә килгәч, яңарып, күңел күтәрелеп китә.

---

[1] Сәрвәр Әдһәмова (1901—1978) – язучы, тәрҗемәче.

Өйдә шул көйдә, аларны эшкәртеп булмый инде хәзер, үзләре белән китә торган чир инде. Хәерле булсын.

13 февральдә Мусаның юбилей кичәсен опера театрында уздырдылар. Мин телевизордан карадым. Юбилей алдыннан Зәкиягә шактый борчылырга туры килде, чөнки Обком кешеләренең балаларны, күрәсең, күрсәтәселәре килмәгән, но шулай булуга карамастан, кичәгә генә түгел, хәтта банкетка – кунак итеп чакырырга вынуждены были. Бобруйск шәһәреннән Мусаның малае хәрби хезмәткәр подполковник килде. Кичәдә Зәкия, Алик, Люция булдылар. Банкетта, Кабардино-Балкариядән килгән язучы Кайсын Кулиев Люция белән Чулпанны икесен ике ягына алып, халыкка күрсәтеп: «Неважно кем тудырган, ә менә бу ике кыз Муса Җәлил кызлары», дип әйткән, ди. Алик әйтә икән: «Ичмасам бер кешенең көче җитте шул сүзне әйтергә», дигән. Менә шуннан соң инде Люция янына килеп, аның белән исәнләшкән кешеләр күп булган.

Мусаның сеңлесе Хәдичә дә килеп сөйләшеп киткән...

Ярый, дускай, сау бул, авырма.

*Сәлам белән Гайшә (Сиражетдинова)*[1]

*1976*

Исәнме, Ибраһим!

Хатыңны алдык, рәхмәт.

Ибраһим, әгәр синең басарлык эшләрең була калса, то син непосредственно Суфияларның өй адресларына җибәр инде, чөнки Габдулла шулай таләп иткән имеш, ник сиңа бүтән авторлар үзләре китерәләр, нишләп Салахов посредник – Зәкия аша эш җибәрә дигән. Үзебез алырбыз, үзебез җибәрербез дип әйтә, ди.

Суфия әйтә: «Хәзер тиз баса алмыйм элеккеге кебек. Мин әкрен генә, үз җаем белән басар идем», ди.

Ә болай Казанда әллә ни яңалыклар юк, без Таҗи Гыйззәткә 80 яшь тулу уңае белән үткәрелгән кичәдә булдык, матур үтте, тик бик кызганыч, үземнең картаюны күрмим, ә менә безнең татар әдипләребезнең картаюларын күреп күңелем тулды. Н. Исәнбәт, Туфан абый, рәхмәт, матур итеп исәнләшеп китте. Дөрес, М. Ногман күрмәде. Таҗи Гыйззәтнең хатыны авыру гына булса да, исән

[1] Гайшә Сиражетдинова (Бикмөхәммәтова) – Татарстан радиокомитеты хезмәткәре .

икән әле. Президиумда ике улы утырдылар, ә берсе минем белән исәнләшеп йөри иде, мин аның Таҗи ага улы икәнен белмәдем.

Күрәсең, безгә радиога килгәләгән булгандыр. Радио да, редактор да шулар ук, һәммәсе үз урыннарында.

Бездә, Татарстанда 3 ел подряд корылык булды инде, хәерле булсын, илдә булса, иренгә тияр әле, тик тынычлык кына булсын.

Син дускай, зур Картатай булдың инде, Маһинур белән икегезне котлыйм, тигезлекләре, бәхетләре белән үссеннәр. Ә сезгә аларга карап, күп еллар шатланып гомер итәргә язсын, нишлисең, закон природы...

*Сәлам белән сагынып, дусларың (Гайшә Сираҗетдинова)*

*25.09.1975*

Уважаемый тов. Салахов!

На Ваш запрос отвечаем: передачу на татарском языке мы дать не можем. Что касается переводов на казахский язык – присылайте. Очерк «Накануне» Уважаемый тов. Салахов!

Из Вашего рассказа мы поняли, что его герой – очень благородный человек. Но стоило ли для доказательства столь очевидной истины перегружать рассказ описаниями природы и кулинарных изделий? Уверен, что нет. Вы просто старались придать видимость многозначительности истории, в которой, в сущности, нет ничего незаурядного… Тем более, что изложена она у Вас не художественно, а чисто или информативно (хотя Вы и «обставили» ее громами и молниями). Хочу надеяться, что этот отзыв не помешает дальнейшему нашему сотрудничеству.

Желаем всего доброго.

*Корреспондент отдела литературы и искусства Н. Скалон.*
*«Ленинская Смена»*

*Алма-Ата*
*1975*

Күңелле көннәр, балалык чакның дусты Ибраһим!

Менә шулай тормыш дәфтәренең бер бите тагын тарихка үтте. Безнең тормышның тарихы калын, киләчәге юка гына калып бара инде. Нишләмәк кирәк?! Синең сүзең чын – кайгырып утырып булмый. Тормыш туктамый, шаулап-гөрләп алга дәвам итә. Безне дә

бергә агызып алып бара, кайгырып утырырга бирми. Шулай булгач – күңелләр яшь булсын, дибез! Синең хатыңны алдым, бик зур рәхмәт! Ибраһим! Синең соравың берничә, октябрьдә мин сиңа бер рәсемне җибәргән идем. Алдыңмы, юкмы? Бер дә язмыйсың. Утырганда сүзләрем күп кебек иде. Белмим , ничек рәтләп язарга. Әллә язмаска? Һәр кайчак шулай уйланам да... Күкчәтауга барыр алдыннан да шундый уй булды. Бер уйладым алып барырга. Аннан дидем, юк.... һәм дөрес эшләгәнмен, чөнки ул чак синең тормышта мәшакатьләр күп иде. Безгә бергә булып сөйләшергә дә туры килмәде. Синең өйдә булырга, гаиләңне күреп танышырга да теләк бар иде. Ул мәсьәлә менә нәрсәдә: димәк, синең язучы булуың да һәм минем язгаласам да, язучылар рәтеннән бик ерак булуым. Иптәшләр арасында синнән башка мине аңларлык кеше юк. Хәтта минем балалар да минем кайчандыр язган шигырьләремне укыячак түгелләр. Алар шулай чәчелеп юк булачаклар. Шулай чәчелеп югала бирсеннәрме? Син ни әйтәсең? Минем ике дәфтәр яшьлек көннәреннән калган шигырьләрем бар. Әгәр дә шуларның кайберләрен күчереп бирсәм, син укыр идеңме? Бәлки синең аша алар башкаларның да күзенә төшеп, күңеленә керер иде. Менә шул мәсьәлә хакында үз фикереңне яз. Мин көтәм. Күпме гомер калды. Син, Ибраһим, минем бу сүзләрне гаепкә алма. Мин бик сәер итеп кенә яздым. Менә шуның белән кечкенә хатымны тәмам итәм.

*Сәлам белән Зәйнәп (Сөләйманова)*[1]
*Алма-Ата*
*31.12.1967*

Ибраһим ага!

Сезгә күптән язасым килсә дә, болай да хатлар күп киләдер дип, һаман яза алмадым.

Бик зур, бик игелекле эш башкардыгыз. Олысы-кечесе рәхмәт укый үзегезгә. Исән-сау булып, тагын яңа әсәрләрегезне күрергә-укырга насып булсын.

Сезнең турыда, я үз язмаларыгызны укыганда, телевизордан күргәндә, Алиш абыебызны да искә алдым, аның турында истәлегегез өчен тагын бер кат рәхмәт укыдым.

---

[1] Зәйнәп Сөләйманова – И. Салаховның балачак дусты.

Казанга килгәндә мөмкинлек чыгып, тагын бер кат музеебызга килсәгез иде дип хыялланам. Хәзер музеебыз аерым матур бүлмәдә, шактый яхшырды кебек...

Сезнең вакытыгызны алдым, гафу итегез. Яхшы теләкләремне җиткерәсем килде.

Иң изге теләкләр һәм күп сәлам белән,

*Илсөяр Сункишева (55 нче мәктәпнең*
*А. Алиш музее җитәкчесе, Алиш абыйның туганы).*
*17. 12.1989*

Исәнмесез Ибраһим абый. Бүген хатыгызны алдым, исәнлегегезне белгәч, бик шатландым. Синең журналда чыккан әсәреңне укып шатландым. Бик яхшы язгансың, синең кебек беркем дә язалмас иде. Ә язарга кирәк иде. Син язганны кызыксынып укыйлар, сөйлиләр. Илебезнең сәнгать кешеләрен харап иткәннәр, дип гөр килеп сөйләшәләр. Сине бик жәлләделәр, мине дә жәлләгез инде, мин дә анда булдым, ул йөргән юлларда йөрдем, дигән идем. Әй Зиннур! Синең аягың бар, дип көлештеләр.

Төрмәдә.

Без утырдык, посып, тешне кысып,
Төрмәнең караңгы бүлмәсендә.
Якты төшми тәрәзәсенә,
Салкын караңгы бүлмәсенә.
Утырдык посып, бер почмагында.
Ялгыз, берәүләп, меңәрләп.
Күзем тонды, карап икенче бүлмәсенә
Аңып китте, һушым китте.
Уйлар уйланып, һаман җан кермәде,
Нәрсә өчен кулга алынганны.
Үлеп булмый күрми:
Һавадан төшкән хәсрәтләрне.
Утырдык, төрмәнең салкын бүлмәсендә
Көттек, тәрәзәдән якты төшкәнен,
Көттек биш ай чамасы,
Хатынны, балаларны, туганнарны.
Көттек инде, хәзер ун ай чамасы.

Ишек ачылмады, якты төшмәде
Безнең караңгы, салкын бүлмәгә.

Беренче шатлык.
Качып-посып яшәдек,
Сталин заманасында.
Койрыкны кыстык
Бот арасына.
Телне кыстык теш арасына...

Ярый, хушыгыз.

*Зиннур Тазеев*[1]

Исәнмесез Ибраһим абый һәм Маһинур апа.

Телевизордан чыгыш һәм сорауларыгызны ишеттем. Сез телевизордан сөйләгәндә минем дә күңелем тулды. Кушылып, өстәмә сүзләр әйтәсе килеп торды. Ул вакыйгалар да минем баштан узды...

1947 нче елда мине дә кулга алдылар. Хөкүмәткә бернинди дә хыянәт итмәдем. Амур өлкәсендә Тахтамыкта дигән станция бар, 20–30 км. Урман арасында, Муртин дигән елга буенда, монда 2 лагерь бар. Орловская һәм Инвалидское. 1947 елның июль аенда, мине дә шушы Инвалидский лагерена китерделәр. Шушы «строго режим»лы лагерьда меңнән артык кеше, шуның 800 кешесе КРД һәм КТР дигән кешеләр иде. 200 кеше 58 статья белән сугыштан соң утыртылган. 1200 кеше кайтарылган булган Колымадан 1946 елда, чирле картлар иде. Хат-хәбәр, элемтә юк. Һәр көнне үлеп торалар. Мин 10 ай булдым, шундагы кешеләр белән таныштым. Шуларның дүртесе бик истә калган. Берсе Миронов Мирон Миронович, генерал-майор, командир 1-ой Казанской дивизии, миңа земляк дип йөри иде. Әйдә, мин сине тагын бер земляк белән таныштырам дип, алып керде бер баракка. Ул бит татарин, образованный, ученый кеше дип сөйли-сөйли барды. Без инде аның белән 10 ел бергә, ди – Габидуллин Әмган дигән кеше иде, Крупскаяны да белә торган булган. Соңгы вакытта Мәскәүдә эшләгән, эштән кайткан вакытта кулга алганнар. Өченчесе Вәлиев

[1] Зиннур Таҗиев – И. Салахов кебек төрмә-лагерь газапларын үз җилкәсендә татыган зат.

Әхмәт, Оренбург өлкәсе Абдуллино дигән җирдән, кавалерийский дивизиянең гл. ветер. врачы булган, 15 ел срок биргәннәр. Тагын икенче урында Колымада янстройда шундый ук хәл булган. Һәм минем күз алдымда да булды. 1948 елның февраль аенда янстройга алып килделәр, Магаданнан 1600 км. чамасы. 350 кеше идек, барыбыз да 58 статьялы кешеләр. Участок саен зур мазарат, берәр базга унар кеше күмгәннәр, өстенә такта бастырып Ф.И.О. КРД яки КТР һәм туган елын, үлгән елын да карандаш белән язып куйганнар иде. Шушы янстройда бик күп меңләгән кеше вафат булды. 1950 елда Оротукан дигән лагерьга китерделәр. 1951 елның башында центральный больницага китерделәр, Дебен дигән поселокта, өч ел эшләдем 1954 елның 4 январенда чыгардылар паспорт биреп. 1955 елның 1 маенда Казанга кайттым, Казаннан туган авылга. 1955 елда өйләнеп, Лениногорскига килдем. 4 балам бар...

Ибраһим абый! Хушыгыз, хат язгыгыз.

*Зиннур (Тазеев)*
*1989*

Хөрмәтле Сәләхов әфәнде!

Татар халкының милләт буларак саклануы, үсеше һәм ныгуы, аның милли аңының торышына бәйле. Явыз Иванның Казанны басып алуына 440 ел үткәч, ниһаять, янә үз дәүләтчелегебезне торгызу мөмкинлекләре туды.

Матбугатка бу җәһәттән аеруча зур роль туры килә. Җир шарының төрле төбәкләренә чәчелеп утырган татар халкын рухи туплау, берләштерү нәкъ менә матбугатның милли бурычы да инде. Бөтентатар басмасы сыйфатында «Сөембикә» бу бурычны матур гына үтәп килә. Ул быел халыкара аренага чыкты. «Periodika islamica» халыкара каталогына кертелде. Әлеге кыйблабызга без киләчәктә дә турылыклы булырбыз.

Сез татар милли хәрәкәтенең күренекле эшлеклесе. Безнең максатлар уртак. Шуңа күрә милләттәшләребез арасында 1993 елның икенче яртысына журналны таратуны Үзәкнең эш планына кертүегезне үтенәбез.

*Р. Туфитуллова*[1]

[1] Роза Туфитулова (1945) – журналист, җәмәгать эшлеклесе.

Исәнмесез, хөрмәтле Ибраһим ага. Сезнең 85 яшь тулу уңае белән, бәйрәмнәрегез чоры. Котлыйм сезне, изге теләкләремне белдереп Петропавелның «Туган тел» радиотапшыруы мөхәррире Фәүзия Шәрифулла кызы Фәйзуллина.

Исегездә булса, мин сезнең белән 1995 елның 3 декабрендә Күкчәтауда сәхнәдә әңгәмә корган идем. Сезнең әңгәмә декабрь радиотапшыруында чыкты һәм ул очрашуда туган телебезнең язмышы, бу чорларда күтәрелгән торгызу мәсьәләләре турында 15 августта (1996 ел) тагын бер радиотапшыру ясап, халкыбызга бирдем. Бу радиотапшыруларда Рәшидә апа Дәүләткильдеева белән (декабрь 1995 ел) һәм Мөнәвәрә апа Сагдеева белән очрашып, сөйләшеп, яхшы гына радиотапшырулар булып чыкты. Мин ул язмаларны Алматы радиосы аша җибәрермен дигән идем, бераз авырып калдым. Көз җитә. Сәламәтлек кояшлы көндә генә. Эш күп. Мин Сезгә укып күрсәтерменме, дип ниятләп йөргән шигырьләрем, әкиятләрем, поэма кисәкләрем дә бар иде. Күп кенә татарча радиотапшыруларымны кассетага язып киләм. Аларда да күп кенә үз иҗатым. Һәр радиотапшыру үзе үк зур бер иҗади гамәл. Илһамланып «Туган тел»не алып барам. Сезнең шигырегезне тыңладым телевидение аша. Рәисә Гариф кызы Бикмухаметова бик яхшы ике телле тапшыру әзерләп чыгарды Сезнең 85 яшегез тулу уңае белән. Халыкларны бик сөендерде...

Туган телнең авыр язмышы – ул безнең язмыш инде. Аны хәзер яшереп тотар урын калмады. Теләкләр ташкындай, мөмкинлекләр юк. Яңа уку елы – утырып ела, укытучылар юк. Безгә әһәмият – мәшәкать арасыннан гына. Менә замана. Үземнең бер генә шигыремне Сезнең игьтибарыгызга:

Туган телем

Мин шатланам
Йокым качса,
Йөрәк типсә,
Күңел тибрәнсә.
Мин шатланам
Хәтта ачы булса,
Тәннәремне борчу алса да...
Мин шатланам
Торып каләм алсам,

Туган телем, Синең өчен,
Тукайларча,
Мин бик борчылам.

*Кабат сәламнәр белән Фәүзия Фәйзуллина*[1]
*24.08.1996 ел*

Исәнмесез, хөрмәтле Ибраһим абый.

Хатыгызны алып укыдым, бик зур рәхмәт, бик шатландым. Күп еллар алай күтәренкелек күңелдә булганы юк иде. Күп сәлам Маһинур апага. Күп сәлам Рәшидә Газизовна белән Мөнәвәрә ападан. Сезнең хатыгызны (телефон аша гына булса да) аларга укыдым. Бик шатландылар... Рәшидә Газизовна күп китапларын бирде безнең иҗтимагый үзәккә, кулланабыз. Пластинкаларны да килеп алсагыз әйбәт булыр дигән иде, аның янына да бу көннәрдә барып кайтырмын дим. Күкчәтауда ничек яңа уку елы башланды? Бездә быел өч укытучыны Казанга җибәрергә булганнар иде, тора-бара берсен дә җибәрә алмадылар. Бөтенләй бу яктан хәерчелеккә калганбыз инде. «Туган тел « түгәрәге һаман үз эшен башлап җибәрә алмый. Үзебез вакытында кайгыртып әзерләнә алмагач, беркемне дә гаеплисе килми, ә шулай да бездә бу елларда башлаган эшләргә күп киртәләр дә тыгыла бугай инде, шул «укытучылар юк» имеш, инде. Заманасы шулай булгач, ышанырлык та.

Бер балалар бакчасында бер группа баланы татар теленә өйрәтәләр, анда бик тәҗрибәле Дәүләтгәрәева Рауза апабыз бар. Ул Петропавелның 7 еллык мәктәбен бетергән кеше, гомере буе мәктәптә эшләгән, пенсионер, рәхмәт яугыры, бер сөенечебез. Әзмәз оештырылганнары да җимерелә дә тагын башлыйбыз, акча мәсьәләсенә барысы да барып терәлә. Күкчәтау радио аша чыгышларны ничек оештыра икән (татар телендә). Кем анда сезнең радиода? Мин кассетага языштырып калдырам. Сезнең чыгышыгызны да язып калдырдым. Ибраһим абый, мин сезгә тагын бер-ике шигыремне язарга булдым.

[1] Фәүзия Фәйзуллина – Казакстанның Петропавел шәһәрендә «Туган тел» радиотапшыруы мөхәррире.

Үгет

Туган тел – ул җылы учак,
Сыенып җылын әле.
Колагың сал,
Барысын да
Әлифба битләреннән.
Син аны бүген укып чык,
Син дә бер шатлан мәгәр,
Сөенчегә миннән бүләк –
Бу шигырь, укысаң әгәр.
Орлык итеп сал син аны
Җаныңның иң түренә,
Бөреләнеп шытып чыга,
Беравык ният итсәң,
Кадерләп үстергән гөл кебек
Кулыңа китап алсаң.

* * *

Җылы якка кошлар китте,
Агачлар яфрак койды.
Әле генә яшел үләннәр
Җирне сагышка салды.

* * *

Әле үләннәр,
Ятып аунарлык,
Бер купшы келәм – хәйран калырлык.
Урманга керәм,
Җиздәй яфраклар
Сүлгәннәр хәлсез
Түшәлеп җиргә.
(1995 ел)

Ибраһим абый, ә инде бу шигырем сезнең спектакльнең бер өлешен телевизор аша караганнан соң туды.

Тәрәзәмнән сагыш
Тәгәрәп төшәр,

Көзге салкын яңгырдай,
Ничек түзим
Әйтми сүзләремне,
Ничек елыйм
Түкми яшемне?
Көтәрмен мин
Йомып күзләремне
Шытырдатып кысып серемне,
Тик күңелдә
Болыт түземлекне
Калдырмас ла,
Хәтта шәүләмне.
Ничек түзим
Әйтми сүзләремне?
Ник елыймын
Түкми яшемне?
Син китәсең,
Күреп туймый калдым,
Мәхәббәттән үлем –
Бер адым...
(1996)

Мин сезне алҗыттым да инде ахры. Сезнең беренче җибәргән шигыремә югары билге бирүегез рухландырды күрәсең. Саусәламәт булыгыз.

*Ихтирам белән Фәүзия Шәрифулла кызы (Фәйзуллина).*
*Петропавел.*
*17.18.1996*

Ибраһим!

Сез мине оныткансыздыр инде. Мин – 36–37 елларда Казан пед. институтында сезнең курсташыгыз Әсма Утякаева булам. Бәлки хәтерегезгә төшәр.

Мин Сезнең исән булуыгызга шатланып, үземнең барлыгымны да белдерәсем килде. Курсташлардан бары Хатыйпның исән икәнлеген генә беләм, башкаларны белмим.

Сезнең хакта «Казан утлары» аша белдем. Әгәр мөмкин булса, кыскача гына булса да үзегез хакында һәм курсташларны, белгән булсагыз, язып җибәрсәгез иде.

Сезгә ныклы сәламәтлек һәм эшегездә зур иҗади уңышлар теләп, *Әсма һәм кызым Ралия (Үтәкаева)*[1].

*Башкортстан.*
*25.12.1989*

Башкортстан, Кушнаренко районы, Әсма Үтәкәева.

Кадерле Ибраһим дустым һәм якыннарың өчен изге теләкләр белән кайнар сәламнәр җибәрәбез. Барчагызга да яхшы сәламәтлек, тыныч тормыш теләп калабыз.

Синең хатың һәм истәлекле рәсемең белән «Татар теле» газетасын алып бик шатландым. Барысы өчен дә зур рәхмәт! Сиңа 80 яшь тулуны бик зурлап котлаганнар. Аны оештыручыларга бик рәхмәт инде.

Яшь вакытларың заяга үткәне өчен Ходай синең язмышыңа зур яхшылык иткәндер һәм син ул язмышка хас кеше. Үткәннәрне уйламыйча, сәламәтлегең әйбәт булса, якты дөньяның матурлыгына сокланып, әйтәсе сүзләреңне әйтеп, һич үкенечсез яшәргә дә яшәргә инде сиңа, Ибраһим!

Казанда сине алып киткәндә (арестовать итеп) мин кайда булганмындыр. Каникулга кадәр үк мин Башкортстанга санаториягә киткән идем. Каникул беткәч барганда (син юк идең) бер бүлмәдә яшәгән дус кызым Басыйрова Мөршидә генә бик кайгырып синең хакта сөйләде.

Мин ул вакытта авылдан әтинең җыеп саклаган зур бер кәрзин китапларын алып барган идем (фольклор материаллары китерегез дип, безгә укытучы Фазлулла ага кушкан иде). Минем әти дини мәдрәсәләрдә күп укыган һәм үзе матур әдәбият белән кызыксынып шуларны укып яткан. Мин аларны Казанга алып киттем. Анда төрле китаплар бар иде: Тукай, Г. Ибраһимов, М. Гафури, Акмулла шигырьләре һәм төрле романнар, җыентыклар бар иде.

Без аларны бүлмәдә актарып, бик кызыклы булгач, укый башладык. Күрше бүлмәдәге ирләр-егетләр дә кереп алып чыктылар.

[1] Әсма Үтәкаева – И. Салахов белән Казан педагогия институтында бергә укыганнар.

Фазлулла агайга күрсәтә алмадым. Шунда бер көнне мине Черек Күл буендагы МВДга чакырдылар. Төнге сәгать 12 гә повестка белән.

Мине анда Мөршидә озата барды. Ул мине ярты сәгать көтәрмен дә кайтып китәрмен дип калды.

Ә мине анда өске катка кадәр менгереп бер начальник рус янына керттеләр. Ул миннән күп нәрсәләр турында сорады. Әти-әниләр хакында, мин алдадым (без кулак ителгән идек). Аның өстәлендә мин алып килгән китапның берсе ята иде. Мин аны күргәч тә, минем китап икәнен әйттем.

Ул китапка Г. Исхаки язган бер бит кенә мәкаләсен миннән русчага тәрҗемә иттерде һәм комсомолка башым белән шундый китап белән шөгыльләнүем өчен тирги башлады. Мин ул китапны авылда кеше түбәләреннән алып, фольклор өчен китердем дип алдадым.

Ул китапта Болгар ханлыгы Суфия шәһәренең искиткеч матурлыгы язылган иде. Шуннан үземә башкортча дип бер роман биреп чыгарды. Мылтыклы каравылчы мине урамга чыгарып җибәрде.

Сәгать төнге 2 иде. Мөршидә мине кызганып елап утырган. Миңа ишек ачты. Ул надан урыс бер китапны да калдырмый ягып бетерергә кушты, иртәгә үк тикшерергә барырлар, үзеңне ябып куярбыз, диде. Без Мөршидә белән икәүләп төнлә ул китапларны елый-елый яндырдык. Мөршидә миңа шунда синең хакта бик хафаланып сөйләде. Башка студентлардан бер нәрсә дә ишетмәдем.

Ибраһим, син Хатыйп белән бер бүлмәдә яши идең бит, сине шуннан алып киткәннәрдер. Хәзер аның белән сөйләшкәнсездер. Синең калган әйберләреңне (әниеңнең рәсемен) ул да белмиме? Хәзер без Хатыйптан башка бер кешене дә белмибез бит. Мин Хатыйпны 1952 елда Казанда очраткан идем. Ул Мөршидәне Казакъстанда яши диде. Ул казакъ егете белән йөри иде. Шуларны ничек тә табарга иде... Хуш, Ибраһим, ихтирам белән *Әсма (Үтәкаева).*

*1991 ел*

Шәриктәшем, хөрмәтле Ибраһим, сезгә, гаиләгезгә ихлас күңелдән изге теләкләр белән кайнар сәлам җибәрәм.

Бүген сездән хат һәм фото алып бик шатландык. Һәр хатыбызга вакытында җавап язганыгыз өчен сезгә зур рәхмәтләр яусын. Сезгә болай да хатлар күп килгәч, барына да җавап язарга күп була.

Хәзер зурайдык бит инде, сезнең күпне күргән, күпне кичергән организмыгызга мәңгелек яшьлек телисе килә. Сәламәтлегегез әйбәт, акылыгыз саф чагында озак, озак яшәсәгез иде, Ибраһим!

Теге фотодагы шәриктәшләрнең исем, фамилияләре язып куелмаган иде. Хәзер аларның күбесен үзем дә онытканмын инде. Белгәннәремне язам: Дәүкәева Әминә, Габдрахманов Фазыл, Аюпова, Сөләйманов, Усманов Хатыйп, Әмиров, Әдһәмова Зәйнәб, Басырова Мөршидә, Гимадиев, Әдһәмова, Биктимирова Дания. Шулай итеп, фотодагы 20 кешенең 7 сенең исемнәрен белмим икән. Бу фотоны күчереп төшергәндә иң читтә утырган минем якын дустым Басырова Мөршидә эләкмәгән. Элек мин аны Казагыстанда дип ишеткән идем, хәзер исәнлеген белмим. Шәриктәшләрдән Думаева Әминә, Мифтахов Фәдүт, Назиров Лотфилар да фотога төшмәгәннәр.

Назиров Л. Дүртөйледә яшәде, былтыр гына үлде. Фәдүт М. сугышта үлде (шагыйрь иде). Думаеваны белмим инде. Сугышка кадәр Ишембайда иде. Бу фото, бәлки, Хатыйпта бардыр. Очрашсагыз, аңарда башка фотолар да бардыр әле, карарсыз.

*Күп сәлам белән, Әсма (Үтәкаева)*

*Башкортстан, Кушнаренко авылы.*
*8.07.1991*

Башкортстан, Кушнаренко авылы, Әсмадан. Саумысез, шәриктәшем Ибраһим һәм бөтен гаилә әгъзалары!

Барчагызга да ерактан сагыну сәламнәребезне җибәрәбез! Изге теләкләребез бүләк булсын! Озак хат язмый торгач, мин хәзер сиңа Ибраһим, билгесез кеше кебек кенә тоелырмын инде. Хат яза алмый гомер үткәрүемә үзем бик үкенәм һәм сездән гафу үтенәм, җәй көне кызым Ралия икебезнең карточкабызны җибәргән икән. Мин ул вакытта авырый идем. Әнә шул рәсемдә дә минем куркыныч карчыкка әйләнгәнем күренеп тора инде. Кызым җибәргән, ә үзем риза түгел идем картлык та җиткән шул. Ә син Ибраһим, һаман да яхшы сакланасың, синең хакта язылганнарны укып та, чын кеше, олы җанлы акыл иясе, һаман актив булып яшәвеңә чын күңелдән сокланам һәм озын гомер телим. Яшь вакытларыңның авыр михнәтен зур шатлыклар алыштырсын...

Хәзер миңа 76 яшь. Күп михнәтләр күргән кеше булдым. Мин пединститутка кадәр Казанда медицина техникумын тәмамлап, бер

ел Казан поликлиникасында эшләгән идем. Институтның өченче курсыннан авырып китkән идем. Шуннан тормышка чыгып, Уфада «Коммуна» (хәзерге «Кызыл таң») газетасында эшләдем. Аннан сугыш вакытында үзебезнең авылга кайтып укыттым. Аннан, шул сәламәтлек начар булу сәбәпле, яңадан медицина буенча эшләдем. Дүрт кыз үстердем. Өч кызым тормышта, дүртенчесе тормышка чыкмады, минем белән яши. Ул музыка укытучысы. Менә минем гомеремнең кыскача тарихы шулай. Мин хәзер сиңа безнең белән бергә укыган Фәдүт Мифтахов белән төшкән карточкабызны җибәрәм, бәлки танырсың. Ул да матур гына шагыйрь иде. Сугышта әрәм булды...

Хуш, Ралия белән икебездән дә кайнар сәлам.

*Әсма Үтәкаева*
*14.11.1991*

Исәнмесез, шәриктәшем Ибраһим һәм Маһинур. Сезгә кайнар сәламнәр белән, тату, тыныч, сәламәт тормышта озак еллар яшәвегезне теләп калабыз. 2 июньдә язган хатыңны алдым, бик зур рәхмәт. Хатыгыз өчен бик шатландым. Замандашларымның бердәнберсе сез генә хат язасыз бит. Бергә укыган кешеләрнең кайда икәннәрен дә белмим, әллә исән дә түгелләр инде. Яшьрәк вакытта нишләп хәбәрләшмәгәнбездер инде. Сезгә дә язмыйлар бит, алар арасыннан бер Хатыйп кына калган булса да, аның белән дә хәбәрләшмисез ахры. Сез кыш көне Казанга баргач, анда Хатыйп белән дә очрашкансыздыр дип уйлыйм. Минемчә, күп нәрсәләрне Хатыйп кына белергә тиеш төсле, ул нишләп сезнең белән сөйләшми, әллә бик нык картаеп киткәнме, нигә алай?

Мин хәзер Казанга бара алмавыма бик үкенәм, анда минем бик якын кешеләрем бар, тик бара алмыйм гына шул. Күп еллар элек Казанга күчәргә уйлап йөргән чакларымда Хатыйпны күргән идем, тик аның белән сөйләшергә сүз тапмадык. Хәзер күрә алсам, мин аңардан күп итеп сорашыр идем...

Замандашларымны югалтсам да, хәзер минем яшьрәк дусларым да бар. Алар – сезнең әсәрләрегезне яратып укучылар. Әле менә бүген безнең янда Чакмагыштан килгән Тимербикә Хәкимова кунакта, ул да сезгә азрак язмакчы була.

«Исәнмесез, Ибраһим ага!

Хәләл җефетегез Маһинур апага, шулай ук балаларыгызга да миннән күп сәлам. Мин Әсма апаларның дусты Тимербикә булам, 49 яшьтәмен. Чакмагыштан кунакка килгән идем.

Сезнең „Тайгак кичү“ исемле роман-хроникагызны күптән, „Казан утлары“ журналында ук укыган идем. Шулкадәр дә җәфа күрүгә кеше резервларының мөмкинлекләренә исем китте. Аннан ул аерым китап булып басылып чыккач, „Колыма хикәяләре“н укыдым. Нишлисең бит, Ходай сезгә язмышның иң ачысын тәгаенләгән. Шул хәлләрдән соң да кеше булып калып, башыгыздан үткәннәрне язуыгыз өчен рәхмәт сезгә. Мин сезнең фидакарьлегегез алдында баш иям. Ихтирам белән Тимербикә.»

*Әсма (Үтәкаева)*

*13.06.1992*

Хөрмәтле Ибраһим ага!

Әле генә «Колыма хикәяләре» дигән кулъязмагызны укып чыктым. Дөресен әйтим, тетрәнеп, бугазыма тыгылган төенне газапланып йота-йота укыдым. Су юлында юшкын утырып кала... Сезнең әсәрдән соң минем күңелемә тулып калган нәрсә – горурлык! Кешенең сынмас ихтыяр көчен, сүнмәс өмете барлыгын күреп сокланмаска, горурланмаска мөмкинме соң?!

Алай да биргән икән үзегезгә түземне!

Без Сезнең белән май-июнь айларында очрашып сөйләшкән идек. Әгәр дә шул вакытта ук кулъязманы миңа калдырган булсагыз, без аның белән «Казан утлары»ның 1988 елгы 1 нче санын башлаган булыр идек, бәлки иртәрәк тә бирә алган булыр идек... Аяз Гыйләҗевкә рәхмәт – ул миңа Сезнең әсәрегезнең Туфан Миңнуллинда булуын әйтте, дөресрәге, Пицундадан хат белән хәбәр итте. Шунысын да әйтергә кирәк – әсәрне тел, стиль ягыннан бик нык карап чыгасы бар. Моны Т. Әйдигә тапшырдык. Ул тиз генә эшләп бирә алса, без «Колыма хикәяәләре»н 1988 елның яз-җәй айларында басып чыгарырга уйлап торабыз. Әлбәттә, Сез риза булсагыз, чөнки бу әсәр безгә, редакциягә кермәгән булып исәпләнә бит әле. Сездән хат көтеп, исәнлек теләп, революциянең 70 еллыгы белән котлап, *Ренат Харис*[1].

*4.11.1987*

[1] Ренат Харис (1945) – шагыйрь, җәмәгать эшлеклесе.

Исәнмесез Ибраһим абый!

Хатыгызны алдым. Рәхмәт! Тагын бер тапкыр, чын күңелдән, үзегезне Татарстан биргән исем белән тәбрикләргә телим. Татар хезмәткәрләре сезнең өчен бик шат.

Минемчә, сез иң зур бүләккә лаек шәхес. Ул бүләк – халык хәтере. Еллар узар. Татар халкы да ирекле булыр. Тормыш рәтләнер. Ирекле өчен көрәшкән улларын искә алганда халкым минем Кол Гали белән бергә Ибраһим Салаховның исемен дә күңелендә саклап, буыннардан буыннарга тапшыра барыр.

Корылтайда халык күп булды. Бик күп. Корылтайга кадәр акрын килделәр. «...переворот... национальность...», бик тыныч булды шул көннәрдә Казанда. Корылтайның бер документы басылмады, ә «демократлар» тавыш күтәрәләр «...покушение на конституцию…». Аларның теләк – безне талау һәм Россиягә буйсындыру. Минем фикер – корылтайда кайбер әйберләр ашыгыч рәвештә эшләнде. Фикер алышмыйча кабул ителгән әйберләр бар. Шуңа карамастан, Корылтай булды, ул не «...представлял часть татарского населения...», шулай язалар «демократлар». Ул халык исеменнән үткәрелгән һәм шуңа лаек та.

Ә инде сатлык җаннар турында әйткән дә алар бар. Берсе – үзәк матбугатка чыгу өчен халкын пычрата. Икенчесе – марҗага әйләнеп «права личности выше права нации…» дип язып чыга. Алар бар. Ләкин аларны акыл белән, фактларга таянып, экономика белән бәйләп җиңәргә була. Акыл белән, белем белән җиңәргә кирәк. Шул ук вакытта иң мөһиме, мин аны беренче урынга куяр идем – халыкка хезмәт итү. Акырмыйча, үзеңне җәлләмичә хезмәт итү кирәк. Минем хезмәт – яшьләр театрын булдыру. Татар балаларына эстетик тәрбия бирү, талантларны үстерү, аларга ярдәм итү, тарихны саклап калу, шәхесләрнең исемнәрен саклап калу. Бик авыр бара сценарий. Шулай да эшләп бетерергә тырышам, эш көнем иртән башланып, 24 сәгатькә кадәр. Ләкин мин шат. Көн уңышлы узса, канатлар үсә.

Шуның белән саубуллашам.

*Ихтирам белән Фәрит (Хәбибуллин)*[1]

*14.02.1992*

[1] Фәрит Хәбибуллин (1941–2007) – Татар яшьләр театрының беренче мөдире һәм режиссеры (1987–2001), Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе.

Исәнмесез Ибраһим абый!

Барлык хатларыгызны алдым. Үз вакытында берсенә җавап бирә алмадым. Гафу үтенәм. Соңгы вакытта сезнең иҗатыгыз белән генә яшим. Эштә дә сез минем янәшәдә генә басып торасыз сыман тоела миңа, өндә дә шулай. Мин гел сезнең белән киңәшкән булам. Шул кадәр әсәрегезгә чумып киттем, әйтерсең, үзем язганмын аны. Ул хәзер минем тәнемнең бер өлеше. Аны чыгармыйча башка әсәрләргә тотынмыйбыз.

Репетицияләр яхшы уза. Июнь аенда театрга җитен комбинатының мәдәният йортын бирделәр. Хөкүмәтнең карары нигезендә тагын бер бинаны кабул иттем. Искә төшердегезме, ул элек Алафузов театры дип атала иде – Киров районында. Шул бинаны кабул итү белән берничә ай вакыт узды. Паровое отопление алыштыру, бер өлешеннән «Риф» исемле банкны чыгарасы, телефоннар кую. Һәм башка эшләр...

Шуңа карамастан «Тайгак кичү»нең репетицияләрен җылы һәм зур сәхнәдә үткәрәбез. Февральнең 10 ына кадәр коллективка күрсәтергә планлаштырабыз. Киләчәк планнар шундый. Февральнең икенче өлешендә официаль тапшыру үткәрербез. Март аенда «Тайгак кичү»не Тинчурин фестивалена чыгарып күрсәтергә планга керттек. Ул Академия сәхнәсендә булачак. Фестиваль 27–28 мартка кадәр булачак. Мин сезне шул фестиваль көннәренә театр исеменнән чакырам. Бөтен расходын үзебезгә алабыз. Икенче ягы, Ибраһим абый! Миңа сез белгән кешеләрнең, аларның балаларының адреслары кирәк. Исәп, сез килгәч, аларны спектакльләргә чакыру. Сезнең белән бергә «Тайгак кичү»не карасыннар. Бу эшкә исән калган бөтен «халык дошманнары»н чакырырга исәп бар...

*Ихтирам белән Фәрит (Хәбибуллин)*
*28.01.1996*

Ибрай дус!

Синең тырышып-тырмашып роман язып ятуың мине бик куандыра, вак-төяк белән вакыт әрәм иткәнче, чирәм җир кешеләре турында зур әсәр эшләвең мең тапкыр әйбәт. Менә ничә ел инде шул хакта җыелыш саен сөйлиләр, язалар, әсәр һаман юк. Син бит шунда туып-үскән, әчесен-төчесен шунда татыган кеше. Ул якны син яхшы беләсең, язучы өчен бу иң кыйммәтле! Син инде ничек тә

тырыш, ташлама, башка нәрсәне читкә куеп тор. Материаль хәлең авырлашса, безгә яз, ярдәм итәрбез.

Союзга керү дә шул романга бәйләнгән, шул хәл итәчәк. Элеккеләр шуңа сайлау өчен генә яраячак. Иптәшләр шундый фикердә торалар. Синең ерып чыгуыңа без барыбыз да ышанабыз!

Синең журналда басылган шигырьләрне зур урындагы абзыйлар бер дә яратмадылар, бабай заманы бик күңелсез, каралтып бирелә, диделәр...

Берәр яңа очеркың юкмы. Син бит вәгъдә иткән идең, роман чыкканчы кыскарак әйберләр дә бирергә иде. Син бит вакыйгаларның эчендә яшисең. МТСларны үзгәртү дә редакцияне бик кызыксындыра.

Май ахырында безнең союзның съезды булырга тиеш.

*Сәлам белән Сибгат Хәким*[1]

*19.03.1958*

Хөрмәтле Ибраһим абый!

Рәхмәтләр төшсен инде сиңа!

Аптырарлык бит, үз намусыңны югалтмау, иманга, милләткә тугры калу, ул гына да түгел, үз фикереңне теләсә кайда, теләсә нинди яшьтә әйтә алырлык булып калу өчен кешене, ягъни бу система шартларында «барыбер таркалачак» кешене шәхес итеп тәрбияләү өчен Сталин-Берия режимы ун ел каторгада «тәрбияләргә» тиеш иде микәнни? Нигә берәү дә (рәхмәт, Әбрар Кәримуллин күтәреп алды) әйтмәде? Әгәр каһәрле Сталин лагерьларын үтмәгән булсагыз, сез бу фикерне әйтә алырлык хәлдә саклана алыр идегез микән? Менә бит мәсьәләнең кызыгы кайда!

Мин ул әйберне көне-төне подписка артыннан чабып күрми калганмын. Күптән түгел мин Чаллы педагогия институтында укытучылар һәм студентлар өчен лекция укыдым. Аның исеме «Халык мәгарифе һәм милләт». Шуннан соң мине тәнәфестә егетләр уратып алдылар. Күрдегезме? Юк, кайда? «Ватаным Татарстанда». Синең ул әйбереңмиңа таныш иде, әмма газетада күрү үзе бер

[1] Сибгат Хәким (1911–1986) – күренекле татар шагыйре, публицист, җәмәгать эшлеклесе, Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты.

нәрсә бит. Укып чыктым һәм сезнең пәйгамбәрлеккә таң калдым. Ышанычыгызны акларга тырышырмын. Алла боерса. Соңгы тамчы каныма кадәр милләт өчен көрәшәчәкмен.

Әһлиуллинга сезнең мәкаләне баскан өчен зур рәхмәт әйттем. Тыйнаксызлык булса да, сорыйм әле, Ибраһим ага, минем «Казан утлары»ндагы «Өч аяклы ат»ны укыдыгызмы? Укысагыз, фикерегезне язмассызмы? Ул миңа бик тә кадерле. Сездән хат көтәм.

*Мәңге сезнеке Айдар Хәлим*
*(Елы күрсәтелмәгән).*

Хөрмәтле Ибраһим абзый!

Төчеләнү дип уйлый күрмәгез – сезнең кешелеклелегез һәм рухи батырлыгыгыз алдында баш иям. «Колыма хикәяләре» – хикәя дип гади бер бөеклек белән аталган. Бу безнең милләтне башка милләтләр алдында коткара торган бердәнбер әсәр, дисәм, ялгышмамдыр...

Сез минем иң яраткан әдипләремнең берсе. Әле сезгә хат язар алдыннан гына – тәрәзәгә карадым да, каеннарның моңача күрелмәгән яшеллеген төсмерләп, сезнең исемгә бер шигырь яздым. Ул үзеннән-үзе туды:

Көнем йоклаганда төнем
Оялчан карап китте.
Һич кенә сагынмас идем,
Сөюем харап итте.
Әй, тормыш, сөеп изсәң дә
Нәфрәттән изелмәдем.
Ашаудан еш өзелсәм дә,
Яшәүдән өзелмәдем.
Бу ни газап, каеннарның
Яшел поэмасыннан,
Ай чыга гүя имезеп
Һәр яфрак баласына...
Быелгы чын яшеллекне
Беренче кабат күрәм.
Ахры, бу арган күңелне
Яшәртә торган сүрә.
Мин киләм елга ярына.

Ул кире ага, бахыр.
Үләр идем – шуны бүген
Күрмәсәм тәүге тапкыр.

*Айдар Хәлим*[1]
*15.05.1992*

Мөхтәрәм Ибраһим ага!

Хатыгызны алган идем, әмма һәрвакыттагыча вакытында җавап биреп булмады. Подписка күп вакытны һәм көчне әләф-тәләф итә. Менә кичә генә Арча якларыннан кайтып кердем – анда бер атна булдым. Язучылар Гөлшат Зәйнашева, Мөсәгыйть Хәбибуллин, Рәфкать Кәрамиләр белән бергә йөрдем. Миңа, чын татар, бигрәк тә Арча мохитен озак күрми торган кешегә мондый очрашулар бигрәк тә кызыклы тоелды. Мәктәпләрдә татар рухы уяна... Кенәр мәктәбендә биш йөз бала белән «Туган тел»не җырлаганда күзгә яшьләр килде. Мәктәпләрдә зур тәнәфес вакытында балаларның нәкъ без үскәндәге сыман гармун моңына әйләнеп уйнаганнарын күрү дә тетрәтте мине...

Подписка, болай, бара сыман. Үзебез предприятиеләр белән сөйләшеп, дәүләт һәм предприятиеләр исәбенә үткәрәбез. Әлегә билгеле түгел – күпмедер. Быелгы елны бер биш мең җыйсак та әйбәт булыр кебек. Сезнең журналны пропагандалавыгыз безне бик куандырды. Ил төкерсә – күл була, ди. Алда бурыч бер генә – милләтне агарту. Татар дөньясында иң яхшы публицистик журналларның берсен тудыру. Әйе, сез дөрес әйтәсез – миңа инде артка чигенү юк. Әмма татарның бердәмсезлеге... вакыт-вакыт күңелләрем өшеп китә шул. Аннан мин бик нечкә күңелле авыл баласы. Сәяси көрәшче итеп тәрбияләү өчен акча сарыф ителмәде безгә. Үзем әле «Милләт һәм прогресс» дигән темага лекция язып утырам – мин аны киләсе атнада педагогия институты студентларына һәм укытучыларына укырга тиешмен...

Менә Сезгә «Аргамак»ның Уфа санын җибәрәбез. Укып карагыз да, фикерегезне языгыз. Хәзер шундый ук сан Әлмәткә багышлап чыгарылачак. Алда – керәшен саны тора. Сезнең яңа әсәрләрегез булса – рәхим итегез. Халык авыз иҗаты җәүһәрләре булса,

[1] Айдар Хәлим (1942) – язучы, публицист, җәмәгать эшлеклесе.

табылса, шундыйлар белән кызыксынучылар булса, безгә җибәрсеннәр иде.

*Сездән хат көтеп, Айдар Хәлим*
*25.10.92*

Исәнмесез, хөрмәтле Ибраһим абый!.

Хатыгыз һәм бүләгегез өчен бик зур рәхмәт. Тиз генә җавап яза алмадым, кичерегез. Эш күп, йөгерү дә йөгерү. Җитмәсә, тагын партбюро секретаре. Икенче мәртәбә сайладылар. Ике конференция – районный һәм өлкәнең делегаты...

Ялга (пенсиягә) чыккансыз икән, котлы булсын. Кулыгыз бушаган икән, хәзер инде иркенләп әдәбиятка бирелергә була. Андый рәхәтлек турында мин хыялланам гына. Алай да булса, А. Расихның «Ямашев»ын тәрҗемә итеп, эшкәртеп, шомартып, кайбер җирләрен үзгәртеп, нәшриятка тапшырдым. Рецензияләр уңай бәя бирделәр. Хәзер роман производствода: 1974 тә чыга.

Күптән түгел генә З. Нуридан хат алдым. 1974 елда Язучылар съезды җыйналачак, чакырырбыз, дип язган. Тик съездның кайсы айда булачагын әйтмәгән.

Бүген генә 30 Казан кунакларын озаттым. Татар дәүләт опера театры «Җәлил» операсын һәм зур концерт күрсәттеләр. Сәхнәдә түгел, безнең телевидениедә. Ф. Насретдинов, З. Хисмәтуллина, Р. Билялова, А. Аббасов һәм башка танылган артистлар булды. Опера да, концерт та бик шәп үтте. Тик мине өлкә башлыкларының кайберләре орыша: имеш тә, үзеңнең татарларыңны күрсәтергә тырышасың.

Менә шундый хәлләр...

Ярый, Ибраһим ага, сау булыгыз. Үзегезне һәм гаиләгезне Яңа, 1974 ел белән тәбриклим, зур иҗади уңышлар, ак бәхетләр, исәнлек-саулык телим.

*Ихтирам белән Әсгать (Хәмидуллин)*[1]
*1974*

Хөрмәтле Ибраһим ага!

Яңа гына хатыгыз килеп төште – мин җибәргән тәрҗемәне алгансыз, укыгансыз, охшаткансыз икән. Шул хәбәрегезне ишетеп, бик куандым. Рәхмәт.

[1] Әсгать Хәмидуллин (1923–2002) – журналист, язучы, тәрҗемәче.

Иң башлап Күкчәтау газетасында романыгызның бер бүлеге чыгуы да күңелле эш. Укысыннар якташларыгыз, кем икәнегезне белеп хөрмәт күрсәтсеннәр.

«Гонорарын тәрҗемәчегә җибәрегез» – дигәнсең. Сез үзегезне рәнҗетмәгез инде. Ярар, бу юлы шулай булсын, машинка расходларын раслар. Ләкин киләчәктә Сезгә дә, тәрҗемәчегә дә гонорарны түләсеннәр.

Ренат Мөхәммәдиевка, әлбәттә, җибәрегез тәрҗемәне, укып карасыннар. Һәм шарт җибәрсеннәр, ышанычлы булсын. Хезмәтемне ташлап утырдым бит. Ул турыда жәлләмим дә. Ихлас күңелдән тәрҗемәлим. Инде шактый тәҗрибәм дә бар – тәрҗемәчелек тәҗрибәсе генә түгел, нәшриятның баш редакторы тәҗрибәсе дә...

Үземне хәзер Госкомиздатка эшкә чакыралар – ведущий редактор-куратор итеп. Барам, эшлим дип анык җавап биргәнем юк әле – киләчәктә күз күрер.

Сезнең «Имәннәрегез...» 1990 елның темпланына кергән (казакъ телендә) – ул турыда Госкомиздат башлыклары әйтте үземә.

Хәзер «Колыма»ның тәрҗемәсен дәвамлыйм. Көн саен 4–5 сәгать утырам. В. Шаламовның «Колыма хикәяләре»н һәм башка авторларның шул темага язылган әсәрләрен укып чыктым. Сезнең әсәр аларныкыннан ким түгел.

«Линкольн приискасы»н танышырга «Простор» журналына бирдем. Охшатсалар, аңа кушып, 3–4 бүлеген бирермен, дип килештем.

Романыгызның «Сандугач» исемле бүлеге бик көчле язылган. Ләкин мине бер нәрсә шомландыра: Гурилевның «Соловеен» бас тавышы белән җырлауны рус укучылары хупламый, чөнки ул романс иң югары хатын-кыз тавышы өчен язылган. Ләкин баслар өчен тагын бер «Сандугач» бар (Пушкин шигыренә):

«Соловей мой, соловей

Птица малая, лесная...» дип башлана. Ул романсны Шаляпин да җырлаган. Икенчедән ул романста сагыш та күп. Ничек уйлыйсыз – шулай үзгәртсәк?

Үзегезгә, гаиләгезгә ихлас күңелдән нык сәламәтлек, ак бәхетләр телим.

*Күп сәлам белән Әсгать (Хәмидуллин)*

*10.09.1988*

Хөрмәтле Ибраһим ага!

Хатыгызны, «Соц. Татарстан» газетын алдым – бик зур рәхмәт. Шифаханәдән чыгуыгызны белеп шатландым, авырулар, чирләр шунда калсын инде. Әлбәттә, сакланып йөрегез инде, бирешмәгез ул авыруларга...

Аяз Гыйләҗев Сезнең роман турында бик шәп мәкалә язган. Тирән фикерле, гаять сәнгатьчә. Үзенең «җан авазы» булып чыккан, ифрат дулкынланып язган. Мин мәкаләне ике мәртәбә укып чыктым. Аның тәнкыйтьчеләрне кисәтеп әйткән сүзләре бик дөрес. Әсәрегез китап булып чыккач, тәнкыйтьчеләр дә өнсез-сүзсез калмас дип уйлыйм. Р. Мостафин бер хатында романыгыз турында бик уңай фикер йөртә. Мин аңа «Кара сакаллы кеше»нең тәрҗемәсен җибәргән идем – яраткан һәм нәшриятка бүлек мөдиренә тапшырган...

Әгәр дә Казанда Сезнең әсәрегезнең русча тәрҗемәсен чыгару мәсьәләсе чишелсә һәм тәрҗемәче итеп мине кабул итсәләр – ул эшкә җиң сызганып утырырга мөмкинлек туа.

Исән-сау булыгыз, ак бәхетләр насыйп булсын!

*Зур ихтирам белән Әсгать (Хәмидуллин)*

*4.04.1989*

Хөрмәтле Ибраһим ага!

Казан каласыннан күп сәлам!

Хатыгызны алдым, рәхмәт. Менә сезгә тагын журналның 11 саны (1989). Шуның белән «Тайгак кичү» безнең журналда төгәлләнде. Тәрҗемә, рус телендә җыйнаклырак итү максатыннан, ана телебездәге вариантыннан бераз аерыла шул. Без аңа аңлы рәвештә бардык. Өзекләргә сезнең баштан үткән коточкыч хәлләрнең иң-иң характерлыларын, дәвернең һәм аның ялчыларының мәрхәмәтсезлеген чагылдырганнарын кертергә теләдек. Шуңа күрә бераз хронология дә үзгәргәләде. Уебызча, хикмәт бит анда түгел. Ул замандагы ерткычлыкларны һәм шәхес культы тудырган кыямәтне, шуларны татып та саф йөрәкле булып калган иманлы кешеләрне күрсәтүдә. Журналыбыз ике телдә чыга. Ана теле вариантында мөмкин булганча сезнең автор коллизиясеннән тайпылмаска тырыштык.

*Озын гомер, сәламәтлек теләп, Әнәс Хәсәнов*[1]

*21.11.1989*

[1] Әнәс Хәсәнов (1935) – журналист, язучы, тәрҗемәче.

Хәерле көн, Ибраһим дус!

Хатыңны алдым, рәхмәт. Синең трилогия өстендә янып-ашкынып эшләвең – каһарманнарга хас егетлек. Шул титаник тырышлыгыңның, гигант эшеңнең җимешле нәтиҗәсен күрергә насыйп булсын. Амин! Елена Владимировна белән ахирәт дус булуың да бик күңелгә хуш туры килде. Бу хезмәтеңне уңышлы тәмамлый алсаң, аның киләчәге дә бик зур. Син аның аркылы Союз мәйданына күтәрелә аласың. Куйбышев кадәр Куйбышев турында трилогия – титаник талант сорый торган хезмәт бит ул. Син миңа кульязмаңны җибәрдем дип язасың. Кызганычка каршы, минем кулга килеп эләкмәде ул. Эләксә дә тиз генә укып булмас иде. Мине хәзер меңгә телгәлиләр. Мин коеп куйган шагыйрь генә түгел. Мин хәзер лектор да, пропагандист та, журналист та, кичәләр алып баручы да, артист та хәтта!. Күп йөрим, күп күрәм, күп язам. М. Җәлил турында Заһид Хәбибуллин белән яңа җыр яздык. Юбилей көннәрендә башкарылыр дип торабыз. Үзем матбугатка «Үлемсезлек дулкынында» дигән мәкалә язып тапшырдым. Басылгач, җибәрермен. Нәшрияттан киттем. Җитәр, 23 ел тоташ редактор булып тир түктем. Тавык чүпләп бетермәслек хезмәт бит ул. Хатыңны язып тор.

*Мәхмүт Хөсәен*[1]
*30.01.1976*

Исәнмесез!

Ибраһим абый, сез моннан бик күп еллар элек Казанга килгәч, радиода Рокыя ханым Юнусова янында булганда (ул балалар өчен тапшырулар редакторы иде) мин сезгә, Ибраһим абый, дип эндәшә идем. Шуңа күрә сез Гали әфәнде дип мөрәҗәгать итсәгез дә, мин ул вакыттагыча сезгә, Ибраһим абый, дим. Бәлки сез миңа абый да түгелсездер, сезнең төгәл туган елыгызны белмим. Мин 1919 елның 2 ноябрендә якты дөньяга килгәнмен. Бәлки хәтерлисездер, сез радиода булганда мин художестволы тапшыруларның баш редакторы булып эшли идем.

---

[1] Мәхмүт Хөсәен (1923–1993) – шагыйрь, ТАССРның атказанган мәдәният хезмәткәре.

Мин Әлмәт татар дәүләт драма театрына баш режиссер булып шушы елның 7 июлендә кайттым. Нигә кайттым дим? Чөнки пенсия яшем җиткәннән (2.11.1979) соң, 1983 елның 18 мартына кадәр эшләгәч, Ташкентка күчкән идек. Бу театрда 1969 ел башыннан бирле баш режиссер булып эшләгән идем. Әлмәт климаты бик начар тәэсир итү аркасында сәламәтлегем шактый ук какшагач күчтем Ташкентка. Чөнки андагы климатның миңа бик ошавын белә идем, һәр елны диярлек җәйге ялымны шунда үткәрергә туры килә иде. Анда баргач та тезләр дә шыгырдамый, бил дә авыртмый башлый иде.

Менә шулай сәламәтлегем бик нык яхшыргач, театрның кат-кат чакыруына озак каршы тора алмадым.

Театр хәзер шәһәр үзәгенең иң яхшы бинаның берсендә. Перестройканың милли мәсьәләне күтәрүе нәтиҗәсендә булды бу бина. Юкса, моңа кадәр дә ул бинаны берничә тапкыр сораган идек, ләкин гел кире җавап алынды. Хәзер бөтен шартлар бар! Эшлә генә. Бу да миңа Әлмәткә күчәргә өндәде. Шулай да Ташкент сагындыра. Анда квартирам шәһәр үзәгендә диярлек.

Мин бик нык читкә киттем. «Казан утлары»ннан сезнең «Тайгак кичү» романын Ташкентта вакытта ук укыган идем. Рокыя ханым киңәш биргән иде. Укыганда «Бу әсәр буенча спектакль тудырып булмас микән?» дип укыган идем. Ләкин укып чыккач, соравыма уңай җавап ала алмадым. Әсәрне бик нык дулкынланып, йотлыгып укыдым, күзләремә яшь килде, хәтта килеп кенә калмады, үксегән вакытларым да булды.

Аяз иҗат йортыннан язган хатларның берсендә сезнең шул романны сәхнәләштерү – инсценировка тудыру турында киңәш биргән һәм сезнең адресны да хәбәр иткән иде. Мин сезгә хат язып өлгергәнче, сезнең үзегездән хат килде. Аязны мин бик яхшы беләм. Аның 7–8 драма әсәрен сәхнәгә куйдым. Ул сезнең роман турында шундый киңәш биргәч, димәк, әсәрне сәхнәгә бастырып була дигән сүздер. Мин ялгышамдыр. Бәлки бик ялгышмыймдыр да, бәлки сезнең баштан кичкән вакыйгалар белән махсус драма әсәре тудырырга кирәктер. Һәрхәлдә әсәрнең темасына буйсынып, аның каһарманнарын сәхнәгә бастыру бик күңелле хәл булыр иде, ләкин андый драма әсәрен кем тудырыр? Сез үзегезме? Аязмы?

Хатым озын булды. Хатыгызда кузгатылган мәсьәлә турында җавап бирә алдым бугай.

Сездән хат көтеп, барыгызга да кайнар сәлам белән *Г. Хөсәенов*[1].

*6.11.1989*

Исәнмесез!

Ибраһим ага, язган хатыгызны алдым. Җавап язу берничә көнгә тоткарланды. Беренчедән, Аяздан хат булмасмы дип торсам, икенчедән, үземнең дә вакыт бик кысан булды. Мәдинә Маликованың «Йөрәк ничек түзсен?!» дигән трагедиясе буенча спектакль чыгару белән бергә, кышкы гастрольләргә дә хәзерләнергә туры килде. Сезнең «Тайгак кичү» турында Аяз иҗат йортыннан язган иде, мин аңа үземнең фикеремне белдереп җавап хаты да юллаган идем. Шул турыда нәрсә язар икән дип көткән идем, хат-хәбәр булмады. «Тайгак кичү»не инсценировкага салу-сәхнәгә куяр өчен яраклаштыру минем кулымнан килмәячәген мин сезгә дә хатларымның берсендә белдергән идем. Бәлки үзегез эшләрсез, бәлки Аяз алыныр дигән идем. Чын драма әсәре буларак эшләнгәннән соң сәхнәгә кую ул минем эшем-вазыйфам. Әсәрнең темасы безне бик тә кызыксындыра. Ләкин ул теманы сәхнә кануннарына буйсындырып эшкәртергә –драма әсәре тудырырга кирәк бит! Хәзерге драма әсәрләре 30нчы еллар драматургиясеннән бик нык аерыла. Хәзерге театр да 30 нчы еллар театры түгел.

Сигезендә мин Ташкентка очам, мин Ташкентта яши идем бит, бик чакырганга күрә договор белән баш режиссер вазифасына алындым инде. Ташкентта квартирам бар. Квартираны саклар өчен анда пропискадан төшмәдем, монда исә артистлар тулай торагында яши бирәм.

Ташкентта декабрь ахырларына кадәр диярлек торырга уйлыйм, 26 декабрьдә Түбән Камада спектакль, шуңа кадәр мин кайтып җитәргә тиеш.

Хатымны тәмамлыйм.

*Гали Хөсәенев*

*2.12.1989*

[1] Гали Хөсәенев – (1919–2001) – актер, режиссер, ТАССР һәм РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе.

Хөрмәтле «картлачым» Ибраһим!

Барыннан да элек, сине 60 яшь тулу, ягъни без картлачлар сафына басуың белән котлыйм. Зарар юк, карт алаша бураздны бозмый, ди рус мәкале.

Хатыңны алдым, минем адреска карата әйткән җылы фикерләрең өчен рәхмәт – гәрчә мин андый мактау сүзләрен күбрәк аванс алу рәвешендә кабул итсәм дә! Әмма кайчан булса да ул «авансла»ны түләргә дә кирәк булыр бит, шайтан алгыры.

Күзләрем авырту сәбәпле, язу-сызу эшләрен минимумга калдырып кыскартырга туры килсә дә, иске дусларны җавапсыз калдыру гөнаһ булыр дип уйлап, менә шушы юлларны сызгаларга булдым.

«Казан утлары»ның 8 нче номерында синең «Карлыгач» дигән хикәяңне укып, Р. Ролланча: «Браво, Браво! Жив Курилка» дип кычкырып куйдым. Телне дә онытмагансың, традицион хикәя жанрын да истән чыгармагансың, тулаем, укыла торган җылы хикәя чыккан. Әле кичә генә Язучылар союзы идарәсенең киңәйтелгән утырышында журналның дүрт саны (5, 6, 7, 8) турында, төрле аспектларда, сигез доклад булды, анда да синең хикәяң турында әйтелгән җылы фикерләр колакка кереп калды.

Ярый, туганкай, бирешмик әле, 60ның югары ягында да тормыш бар, әле нинди генә тормыш, тәҗрибә белән тулган!

*Сәлам һәм хөрмәт хисе белән, Фатих Хөсни!*[1]
*31.08.1971*

Хөрмәтле Ибраһим кордаш һәм борынгы дус!

Барыннан да элек, әлбәттә, үзеңә, гаиләңә һәм, әгәр тавыкчебешләрең булса, хәтта аларга да күптин-күп, чуктин-чук сәламнәремне күндереп, хәер-фатиха, саулык-сәламәтлек, җан тынычлыгы, һичшиксез, кесәңнең дә буш булмавын теләп калмактамын. Син бухгалтер кеше, хәтта бөтен башка якларың килгән вакытта да, кесәң такыр булса да, әллә кая сикереп булмый. Болар өстенә, хәтта болардан бик элек, иҗат «сикерешләре» насыйп итсен иде! Амин!

Бик җылы һәм бик дустанә язылган хатыңны алдым. Шатлыктан башым күккә тия язды, ихлас әйтәм, бик сөнедердең. Үзең иҗат кешесе, башыңнан кичкән хәлдер, безнең «братка» күпме генә

[1] Фатих Хөсни (1908–1996) – язучы-прозаик, әдәби тәнкыйтьче, публицист һәм драматург.

кирәк! Бигрәк тә шул эшнең профессионалы, үзе язган (һәм начар язмаган) кешенең шундый уңай фикер әйтүе бик зур куаныч ул.

Сәламәтлегеңне һәм әле, читен булса да, «романны аркылыга-буйга сукалый» торуыңны ишетеп шулай ук бер кул чабып куйдым. «Менә бит кеше! Дөнья дигәне күрсәтәсен күрсәтте үзенә, җиденче ун белән бара, үз татарыннан һәм аның теленнән читтә яши, шулай да серне бирми, аны «боковую» китәргә ашыкмый, роман хәтле романны җиңеп чыгып килә. Афәрин, тәхсин» мин әйтәм.

Күргән-белгән дусларга сәламеңнен ничек тә җиткерергә тырышырмын. Ләкин, дөресен әйтергә кирәк, элекке кебек аралашып, шаулашып яшәү юк хәзер. Картлары барысы да «мәчет картларына» әверелделәр, авырудан, үлемнән котлары чыгып яши, урта һәм яшьрәк буын безне бик араларына кертмиләр... Ләкин, хосусан мин үзем, тыкшынам әле, теге «пить» ягына киткәндә, алардан арттырып җибәрмәсәм, алардан калышмыйм. Шуңа күрә минем белән шаярырга бик базмыйлар.

Татарстанда тырышып-тырышып икмәк җыялар. Ләкин көннәр бу эш өчен бик шәп тормый – яңгырлар...

Ярый, хуп! Сүзләр күп, сагыну да бетәрлек түгел, ә менә ак кәгазь бите тулды, чак кына күңел дә булды.

*Тагын бер кат чук-чук сәлам белән: Фатих (Хөсни).*
*12.08.1974*

Хөрмәтле Ибраһим абый!

Сезнең яңа басыла торган романыгыз аркасында, ниһаять, «Казан утлары» журналы да укучылар тарафыннан көтеп алына торганга әверелде.

Балтачка күптән килгәнегез юк ахры, чөнки безнең «Хезмәт» газетасы редакциясендә соңгы тапкыр булуыгызга байтак вакыт узды. Килергә уйламыйсызмы? Район китапханәсе кызлары, журналда басылып беткәч, сезнең роман буенча укучылар конференциясе уздырырга кызыгалар.

Ә минем сезгә хат язуымның төп сәбәбе менә болай. Сез беләсезме икән, романыгызда шактый урын бирелгән Алкин – безнең як кешесе, Орга бик якын Носла авылыныкы, элек безнең Яңгул волостенда эшләгән. Районда семьясы белән аның укытучы улы Разит Алкин яши, хатыны Хатирә апа исә әле безнең районда, әле Казандагы кызында тора. Эш шунда: безнең Алкин турында га-

зетага бөтенләй диярлек язганыбыз юк, район кешеләре аны белми дип әйтерлек. Шушы бушлыкны тулыландыру өчен сездә Алкин турында өстәмә материаллар калмадымы, булса, безнең газета өчен аерым язып җибәрә алмыйсызмы? Шунда үзегезнең безнең районга бәйләнешегез дә тагын бер язылыр иде.

Сезгә һәм барлык семьягызга иминлек, сәламәтлек, иҗат уңышлары теләп, Балтач районы «Хезмәт» газетасы редакциясенең партия тормышы бүлеге мөдире *Рәфыйк Шәрәфиев*[1].

*14 апрель 1988*

Хөрмәтле Ибраһим абый!

Хатыгыз өчен зур рәхмәт. Ә мин сезне тагын борчырга батырчылык итәм. Алкинның Казандагы хатыны белән (әлегә хат аша гына) элемтәгә кергән идем. Аның хәбәр итүенчә, Риаз Алкин кулга алынган чакта, Казанның Бауман райкомында I секретарь булган. Сезнең романда ул – горком секретаре. Бу очракта сезнең ялгыш хәтерләвегез яисә ул ягына артык әһәмият бирмичә язуыгыз мөмкинме?

Икенче соравым – кайтуыгызны алданрак хәбәр итсәгез, мин китапханәче кызларга әйтеп куяр идем. Аларның конференция үткәрү теләкләре нык, романны ошаттылар. Хәзер «Дети Арбата»ны сораучыларга да «аннан да әйбәт» дип сезнең роман чыккан «Казан утлары»н тоттыралар...

*Сезгә һәм семьягызга сәламәтлек, иминлек теләп:*
*Рәфыйк Шәрәфиев.*
*10.05.1988*

Хөрмәтле Ибраһим ага Сәләхов!

Шундый җылы, игелекле хат язып җибәрүегез өчен рәхмәт яусын Сезгә. Без бит чыннан да җылы сүзгә, каләмдәшләребезнең ихлас бәясенә мохтаҗ яшибез. Инде менә ничә әсәрем басылып чыга, матбугатта да уңай да, кире дә бәя юк. Гомумән бер сүз юк, әйтерсең, М. Юныс исемле язучы да юк бу дөньяда. Мин, билгеле, рәнҗемим. Заманы шундый. Язучы үзенә тәнкыйтьче ялларга тиеш. Әдәбият мафия кулына күчте. Һәм без Сезнең белән искелекнең, беркатлылыкның бер үрнәге генәдербез бәлки.

[1] Рәфыйк Шәрәфиев – Балтач районы «Хезмәт» газетасы редакциясенең партия тормышы бүлеге мөдире.

Сезнең әсәрнең мин «Казан утлары»нда йотылып укыдым. Андый әсәр бәлки безнең әдәбиятта булмас та. Культ чорын Әпсәләмовлар, А. Шамовлар һәм «Коръән серләре»нең авторына охшашлы кешеләр генә яктыртты. Торгынлык чорында безнең әдәбият бөтенләй диярлек ахунлашып бетте. Татар әдәбияты искә төшү белән эч ачыта башлый. Башны күтәреп, гәүдәне турайтып сүз әйтергә мөмкинлек туды шикелле, ә бездә һаман шул ук ялагайлык, коллар психологиясе идарә итә.

«Европа ат сагына»ның «КУ» яртысын баскан һәм анда бер генә имгәтелмәгән фикер дә юк. Хәтта европалыларның ат сагынуларына багышланган әсәрнең җан өлешен дә сызып ташлаганнар.

«КУ»нда проза бүлеген Тәйфыйк Әйди җитәкли башлады. Аны Сез беләторгансыздыр?

17–18 майда Казанда Язучылар съезды. Шуңа барырга җыенам. Әгәр Сез дә килсәгез, бәлки очрашырбыз да әле.

Сезгә кайнар сәлам, иҗат уңышлыклары, сәламәтлек, озын гомер һәм куанычлы табышлар теләп калучы, *Миргазиян Юныс*[1].

*6.05.1989*

Хәерле көн! Исәнмесез, ерактагы дуслар. Сезнең тарафларга хатымны юллаган гына идем.

Бүген төнлә башыма тагын бер фикер-идея килде, шуны хәбәр итәргә ашыгып кулыма каләм алдым.

Татарстанның крайны өйрәнү музее каршында эшләүче ветераннар Советы безнең Казан дәүләт педагогия техникумының 100 еллык юбилеен үткәрү мәсьәләсен күтәргән иде. Ул тарих Учительская школадан ук башлана икән. Хәтерлисеңме, техникумда укыганда Гөлсем Шакирова (бездән бер курска алда иде) бар иде. Ул безнең ветераннар Советында бу эшне башлап йөрүче иде. Үткән ел ул, кызганычка каршы, үлеп китте. Хәзер ул эш ни хәлдәдер, белмим.

Сәлах, менә син шул турыда документаль повесть язсаң иде. Заманында техникум алдынгы уку йортларыннан булып, зур роль уйнаган мәктәп. Безнең чорда да ул шәһәрнең культура үзәкләренең берсе иде.

[1] Миргазиян Юныс (1927–2014) – күренекле язучы-прозаик, публицист, эссеист, Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты .

Техникумнан никадәр күренекле кешеләр чыкты! Безнең поток-тан гына да тарихта эз калдырган байтак шәхесләр бар. Бу эштә материаллар туплауда мин сиңа ярдәм итә алам. Чөнки җанлы тарих сәхифәләрен ачарга исән кешеләр бар.

Исеңдәме, Васәй бар иде. Ул соңыннан ВУЗ укытучысы булды. Ә Бадыйгов обком секретаре, профсоюз әһеле булу дәрәҗәсенә кадәр күтәрелде.

Шафикова Уфадамы, Казахстандамы КПСС комитет секретаре булган диделәр.

Язучы, шагыйрьләр, журналистлар чыкты бездән. Мостафа Ногман, үзең, Гаяз Кәти, Әхмәт Ишмури һ.б. – бихисап инде алар.

Безне укыткан Илһамия апа Богданович исән, Казанда яши бит. Аның малае Казан ортопедия клиникасы директоры, фәннәр докторы.

Ә сугышта күпме кеше башларын салды. Кузьма Рябов бар иде. Чибәр, зифа егет, Бишбалтада яшәде. Ул да сугышта һәлак булды бит.

Хәтерлисеңме икән, Галия Ерусалимова бар иде. Ул чегән кызы булып биегәндә идәннәр селкенә иде. Галия дә исән, Казанда яши. Ә Гәрәй абый куя торган бию, пирамидаларны карарга ярты Казан җыела иде.

Культура мәркәзләре димәктән, ул елларда бит Академия театры белән Мәдәният йортыннан башка җир юк иде. Без, яшьләр, күбесенчә, шунда агыла идек. Такташ, Кутуй, Сириньнәрне без шунда тыңлап үстек.

Безнең атаклы «Зәңгәр күл» учхозы экиятләрдә генә сөйләнә торган гаҗәеп матур җиргә – табигатьнең гүзәл бер бер почмагына урнашкан иде. Зәңгәр күлдә көймәдә йөрүләр, Казанка елгасында су керүләр, агач утыртулар, бәрәңге, кишер алулар – болар барысы да хәтергә уелып калган күренешләр...

Мин боларны ни өчен яздым? Шушы тәкъдим турында уйлап кара әле. Мемуарлар язарга утырмаган булсаң, бу тема бик әйбәт тема инде. Әгәр мин язучы булсам, аны читләп үтмәс идем...

*Сәлам белән Рокыя (Юнысова)*[1]

*17.05.1980*

---

[1] Рокыя Юнысова – радиода балалар өчен тапшырулар редакторы, И. Салахов белән Казан пед. техникумында бергә укыганнар. Фондта аның язучыга язган 60 тан артык хаты саклана.

Сәлам хаты. Исәнмесез, ерактагы якын дуслар!

Үзегездә ни хәлләр, Казанга җыенмыйсызмы?..

Сәлах, мин синең «Казан утлары» журналында чыккан «Мәхәббәт картаямы?» дигән кыска повестеңне укып чыктым. Ярыйсы ук шома язылган, вакыйгалар мавыктыргыч итеп төзелгән. Аеруча миңа техникум тормышын, Зәңгәр күл күренешләрен тасвирлаган урыннары ошады. Герой үзе дә, героиня да җыелма образлар булып, минем аңлавымча, алар аерым шәхесләрдән күчерелгәннәр. Ә язучы фантазиясе, кичерешләре белән баетылып (ягъни рух өреп) тулы канлы образлар булып гәүдәләнгәннәр. Шуңа күрә аларга ышанасың, алар чын тормышта да нәкъ шулай яшәгәннәрдер дип гөман итәсең. Повестьның исемен шулай дискуссион атавың, минемчә, бик дөрес, ул уйланырга мәҗбүр итә. Ә ахыры кинәтрәк бетә, шикелле. Җыентыкларыңа кертергә уйласаң, финалын ныклабрак уйла әле. Үзең кара тагын. Мин язучы да, тәнкыйтьче дә түгел, тик укучы буларак кына үз фикеремне яздым...

*Рокыя (Юнысова)*

*6.08.1980*

Исәнмесез, дуслар!

Чуктин-чук сәламнәреңне Зөләйхага, Нури Арсланга тапшырдым...

Сәлах, синең очерк-истәлек чыккан газетаны табып, укып чыктым. Үзем генә түгел, ул елларда газета-журналларда эшләгән кешеләргә дә шалтыраттым, хәбәрләштем, фикерләре белән уртаклашуларын үтендем (Фатыйх Исхаков, Галия Гаязова, Зәкия Садыйкова, Зәйнәб Фәрдиева һ.б.).

Галимҗанның улы Йолдызга гына шалтырата алмадым. Укыганнардыр, үзеңә бер-бер артлы хатлар ява башлар әле.

Минем фикер болай: ничәмә дистә еллар буе шагыйрь турында ләм-мим булмаган бер вакытта бу истәлекнең басылуы редакциянең дә, авторның да зур батырлыгы, минемчә. Озак тотуларының сәбәбе: җентекләп тикшерүдер мөгаен. Әмма укыганда нык кыскартылганы сизелә, урыны-урыны белән логик фикерләү өзелеп кала. Истәлекнең ахыры да кинәт кенә бетә. Галимҗан шигырьләреннән өзекләр күбрәк бирелгән булса, нур өстенә нур өстәлер иде, урта өлешендә «Идел» поэмасыннан өзек кирәк иде.

Үзе исән чакта ул, без яшьләрне, ялкынлы шигырьләре белән авызына карата, дәртләндерә иде бит. Минем хәтердә аның бурлаклар, Идел өстендә чайкалган ак пароходлар, киң дәрьяда чинап очучы акчарлаклары һ.б. манзаралар сакланып калган...

Минем дустым Зәйнәб Фәрдиева әйтә: сугыштан соң Галимҗанның хатыны Рабыйга ханым подвалларда архив документлары җыеп, подшивкалар актарып, бөерләренә салкын тидереп, дөнья куйды. Гали Хуҗи аларны җыентык итеп чыгарырга җыенган булган. Бәхетсезлеккә каршы, үзе дә үлеп китә. Белмим, ул җыентык чыгып җитә алгандырмы, юкмы...

Үзәк телевидениенең беренче программасыннан шушы көннәрдә генә совет властенең беренче елларында совет мәктәбе өчен барган аяусыз көрәш турында «шкрабы (школьные работники)» дигән өч серияле фильм барды. Менә шунда төп рольне башкарган артистны (Николай Гудков) мин гел Галимҗан Мөхәммәтшинга ошатып утырдым. Нәкъ син язгандагыча, терекөмеш төсле напористый, кызу канлы, гаделсезлекләргә түзеп тора алмаучан итеп башкарды ул рольне. Кечерәк буйлы, почык борынлы, өстендә дә хаки төсендәге гимнастерка, киң каеш...

*Ихтирам һәм сәлам белән Рокыя*

*8.09.1986*

Сәлам хат.

Сәлах белән Маһинур ханым. Безнең чуктин-чук сәламнәребезне кабул итегез...

Хәзер «Казан утлары»ның яңа, 9 нчы санын укыйм. Анда Нури Арслан шигырьләре дә бирелгән, фәлсәфи шигырьләр белән мавыга.

Евгения Гинзбург романыннан өзекләрне укып барам. Әмма бик озакка сузылды...

Аның ире Василийның этисе безнең Казанда яши бит. Быел үзенә 90 яшь тула, ә Вася Америкада яши икән. Менә шундый хәлләр.

«КУ» журналыннан М. Горькийның Гаяз Исхакыйга язган хатларын укыдыңмы, фикерең ничек соң?

«КУ» сентябрь санында гарәп әлифбасы нигезендә татарча уку-язу дәресләре бирелә башлады.

Бер уйлаганда без бәхетле. Өч төрле (гарәп, латин, рус) шрифтында язылганны укый, яза алабыз. Не шути с нами, без атаклы

телче, татар халкының философы Җамал Вәлидинең үзеннән дәрес алган шәкертләр булырбыз. Шулай бит.

Гарәп хәрефләре дигәч, кылт итеп, Мостафа Ногман искә төште. Ул үзенең шигырьләрен, җыр текстларын гел гарәп хәрефләре белән генә яза иде. Аннан безгә (радиога) килеп «шомыртым»га (машинистка Суфияга) диктовать итә иде. Дөньялар үзгәрә, ул үзгәргән саен фикер йөртү дә башкача. Әле күпме классикларыбызның әдәбият мәйданына әйләнеп кайтасылары бар (Дәрдемәнд, Сәгыйть Рәми, Сәгыйть Сүнчәләй, Садри Җәлал һ.б.), укырга әзер булып тор.

Бу җәһәттән безнең балаларыбыз бәхетсезләр. Үз ана телләрендә укый-яза, юньләп сөйләшә белмиләр. Бер уйлаганда, мең еллык әдәбияты, гүзәл тарихы булган татар халкының теле, культурасы бетүгә таба бара.

Нинди зур фаҗига! Шул ук вакытта Америка, Япония, Финляндия, Польшада яшәүче татарлар үз телләрен, гореф-гадәтләрен югалтмыйча саклап киләләр.

Семьяңда үз балаң белән ана телендә сөйләшмә, балаңа көйләп бишек җырлары җырлама, экиятләр сөйләмә, туган телеңдә укытма. Шул да булдымы культуралылык!..

Алтын көз керде, әбиләр чуагы башланды. Кояш нурларында яфраклар саф алтын төсенә керде. Хәерең белән кил әй, 1989 елның кышы!

Хәерле гомерләрегезгә ак бәхетләр теләп, *Рокыя (Юнысова).*

*29.09.1988*

Сәлам хат.

Үзең оператив, аккурат эшлисең дә инде. Журналист йөрәкле язучы икәнең әллә кайдан күренеп тора. Чөнки минем бер хатымны да җавапсыз калдырганың юк. Башкаларга да шулай тиз, төгәл җавап язасыңдыр дип уйлыйм. Ничек өлгерәсең?

Хәзер бит синең адресатлар бөтен ил буйлап, алай гына да түгел, чит илдәге милләттәшләрдән дә хатлар аласыңдыр шаять...

Сиңа солидный язучы буларак, секретариат штаты булдырырга кирәк минемчә. Һич югында, Толстойга беркеткән кебек, личный секретарь һәм өй эче җәмәгатьләрен җигү кирәк. Юкса, ул кадәр йөзләгән, меңләгән хатларга җавап биреп барсаң, синең роман, по-

весть, очерк, мәкалә һ.б. язарга вакытың калмаячак. Ял көннәре, төн йокылары хисабына эшли торган вакытларың үтеп бара, уен түгел, 90 нчы дистәне ваттың бит!

Бу турыда уйла әле, яме. Казанда яшәсәгез, мин ул эшкә алынып идем.

Сәлах! «Соц.Татарстан» газетасында чыккан «Тагын кемгә балта күтәрәбез» дигән мәкаләңне укып чыккач, синең чын публицист икәнеңә инандым. Моңарчы мин сине прозаик, шагыйрь дип кенә йөри идем. Яшьлегеңдәге журналистлык ялкының сүнмәгән икән. Синдәге дәртле ашкыну дәвам итә икән... Афәрин!

Аннары килеп, мин әле синең турыда үткән ел «Казан утлары» журналында басылган Аяз Гыйләҗевның «Илче» исемле мәкаләсен укып таң калдым. Бик тә синең эчке дөньяңны ачып салган. Синең ыруың Себер (татар) казаклары нәселеннән икән ләбаса. Әйтәм аны син нык, таза бәдәнле, какшамас нык рухлы. Менә кайдан башлана икән аның тамыры?!

Ул мәкаләдә синең ике романыңа да («Имәннәр тамыр җәйгәндә» һәм «Тайгак кичү») анализ ясала һәм сиңа мәдхия укыла. Мәкаләнең синнән килгән хат белән тәмамлануы да уңышлы!

Афәрин сиңа!

Әминә исеменә атап хат язуың өчен рәхмәт, мин аны, мотлак, аңа юллаячакмын.

Да, безнең шәриктәшләр сирәгәйде. Бик җәл. Без ничек тә Сараны эзләп табарга тиеш. Ул бичара, Әсәте эшләгән этлекләре өчен (сиңа карата) синнән оялып, качып йөри. Практика үткәндә (техникумны тәмамлаганда) бер районда мин Яңа Кенәрдә, ул Мөндештә укытканда очраша идек. Казанда Әсәт (Әсадуллин) белән яшәгәндә мин аларда еш була идем.

Казанда көн туа, яңадан-яңа вакыйгалар булып тора, араларында коточкычлары да бар.

3.02 дә Хәсән абый Туфанның кызын Маяковская урамындагы квартирасына кереп үтергәннәр, ди. Менә бит явызлык, ерткычлык ни дәрәҗәгә барып җитә ә?

Каян килә бу кансызлык, миһербансызлык?!

Ул бичараның (исеме Гөлгенә) балачагы да, яшьлеге дә булмады бит, халык дошманы баласы булганга кимсенеп яшәгәндер. Үз тырышлыгы белән укып, университетта студентларга белем бирү өчен аз казганмагандыр. Җиң сызганып эшләп йөргәндә нинди

фаҗига! Әле дә ярый Хәсән ага исән түгел иде. Юкса, хәсрәтеннән йөрәге ярылып үлгән булыр иде...

Менә шундый хәлләр. Җинаятьчеләрне эзлиләр, табарлармы, юкмы.

Айдар Хәлимгә 50 яшь тулу уңаеннан бик зур тантана булган. Кичә телевидениедән шуны кыскартып тапшырдылар. Гаҗәп талантлы шагыйрь, татар өчен җан атар икән. Атаклы китабы Литвада басылып чыккан. Яшь кенә булса да күп михнәтләр чиккән, туры сүзле булуы өчен озак төпләнеп яши алмаган, гел күчеп йөргән. Ул юбилей кичәсендә бик күп шигырь яңгырады. Юбиляр үзе дә байтак шигырьләрен укыды...

Ярый, күп сөйләдем, хуш, сау булып торыгыз.

*Р. Юнысова*

*17.02.1992*

ЭЧТӘЛЕК

Кереш . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 3
Хатларым барып җитәрме? . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 9
Күңел җылысын салып хатыма... . . . . . . . . . . . . . . . . . 65

**ПИСЬМА МОИ СБЕРЕГУТ...**

(из личного архива Ибрагима Салахова)

Корректор *Я.М. Абдулкадыйрова*
Компьютерная верстка *Н.Т. Абдуллиной*
Дизайн обложки *А.В. Булатова*

Подписано в печать: 16.11.2017.
Печать офсетная. Гарнитура «Times».
Формат: 60×84 1/16.
Усл.-печ. л. 17,7. Уч.-изд. л. 13,8. Тираж 200 экз. Заказ

Оригинал-макет подготовлен в Институте языка, литературы
и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ
420111, Казань, ул. К. Маркса, 12

ООО «ТКС Контакт»
420021, Казань, ул. Г. Тукая, 91